# КАЗАН УТЛАРЫ




7

ИЮЛЬ

1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**7**
ИЮЛЬ
1981

## *Бу санда*

Г. ЛАТЫЙП. Таңнар, таулар... Шигырьләр . . . 3
С. САБИРОВ. Утлы фарватердан. Повесть . . . 8
Г. РӘХИМ. Олыгаю. Шигырьләр . . . 50

ХИКӘЯЛӘР

К. КӘРИМОВ. Бер арбада . . . 55
Г. ХӘСӘНОВ. Карт сандугач . . . 72
Х. ГАЙНЕТДИНОВ. Әбиләр чуагы . . . 75
Х. КАШАПОВ. Ак әби . . . 79

К. БУЛАТОВА. Печән өсте. Шигырьләр . . . 82
Ә. РӘШИТОВ. Яңа шигырьләр . . . 85
Х. ТӨХФИ. Төрле еллардан. Шигырьләр . . . 88
Р. ХӘЛИУЛЛИНА. Яшенле яшьлегем. Шигырьләр . 92
Ә. МӘХМҮДОВ. Бәхетем үзем белән. Шигырьләр 96

КПССның XXVI СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА

М. ЗАРИПОВ. Шәһәрнең ачкычлары . . . 97
М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ. Ерактан төшкән килен . 106

ОЧЕРКЛАР ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Ф. ХУҖИӘХМӘТОВА. Яннарына үзем барам . . 111
Т. ӘЙДИ. Мәрзия ханым истәлеге . . . 119

И. Н. УЛЬЯНОВНЫҢ ТУУЫНА 150 ЕЛ

Ж. МИНДУБАЕВ, Ж. ТРОФИМОВ. Яктылыкка таба 124

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Г. АХУНОВ. Яңарыш . . . 138
С. МАННАПОВ. Мин сезгә ышанам . . . 145
Ф. ГАЛИМУЛЛИН. Хикәя укыганда . . . 151

КИТАП КҮЗӘТҮ

Э. НИГЪМӘТУЛЛИН. Йолдызлар сүнмәсен . . 154
Ф. [illegible]МОВ. [illegible] баскычларын санаганда 159

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Х. МӘХМҮТОВ.** Мәңгелек ядкарь . . . . 163

ДУСЛАР ИҖАТЫ

Бездә кунакта: удмурт шагыйрьләре . . . . . 167

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Җ. ГЫЙЛЬМАНОВ.** Соңгы «таяныч» . . . . . 178
**С. БАТТАЛ.** Шигъри мөрәҗәгать . . . . . 183

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Х. ГОБӘЙДУЛЛИН.** Г. Казанскийның тууына 90 ел 185
**Ф. БӘЙРӘМОВА.** А. Хәйруллинага 60 яшь . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . 189

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ** (баш редактор урынбасары), **РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ**

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.
**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 24/III-1981 ел. Басарга кул куелды 10/VI-1981 ел. ПФ 07270. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 102944.
Заказ Д-119. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

## Галимҗан Латыйп

# ТАҢНАР, ТАУЛАР...

### Сәгать теле

Сәгать теле саный минутларны,
Гасырларны саный төп-төгәл.
Вакыт дигәннәргә бик тә сизгер,
Һәр нәрсәгә итә игътибар.

Килгән ханнар, килгән «ак» патшалар,
Буйсындырган җирне, суларны.
Планетаны урталайга ярып,
Алга үткән Ленин урамы.

Төп урамнан — Ленин урамыннан,
Атлый халык Кызыл Мәйданга.
Ә дәвамы аның мең-мең тармак,
Тармакларның очы кайларда?

Мең төрле төс монда, күп төрле тел,
Якты уйлар бергә кушыла.
Ленин!
          Ленин!
                    Ленин! — дибез,
Ант итәбез менә шушында.

Антыбыз хак безнең, антыбыз пакь,
Чын күңелдән, бөтен йөрәктән.
Сабый чактан безне ата-баба
Яхшылыкка гына өйрәткән.

Дөреслибез җанны, иманны без,
Раслыйбыз кыйблanaмәне.
Утта, суда
Сабан туйларында,
Иманыбыз Ленин иманы!

●

Юл — Мәскәүдән. Можайски аша.
Минскига таба ул үтә.
Көне буе шау-гөр килә дә ул,
Тынып кала бераз кич-иртә.

Ике яклап нарат урманнары,
Җил югында оеп утыра.
Үрелеп карый урман зәңгәр күккә —
Ул кояшка таба омтыла.

Ничә тапкыр сугыш үткән моннан,
Җуелмаган әле яралар.
Шул эзләрдән нарат чәерләре
Күз яшьләре сыман тамалар.

Юл буенда солдат каберләре,
Истәлекле, изге бу яклар.
Монда һаман чәчәк бәйләмнәре,
Ылыслардан үргән веноклар.

Дошманнарны юлдан яздырганда
Ятып калган күпме батырлар?!.
...Юллар матур, юллар иркен хәзер,
Шар тәгәрәтерлек — такырлар.

## Тол хатын

Еллар үткән саен сагындыра
Яудан кайтмый калган батырлар.
Бер мин генә түгел, бу дөньяда
Тол калдылар күпме хатыннар?!.

Бераз җиңел булыр иде кебек,
Торып-торып җаным көймәсә,
Ничәмә ел инде төшләремә
Керә дә ул көлеп сөйләшә.

Кайтмасын да беләм, тик шулай да,
Суынмый шул күңел дигәнең.
Чыгып китәмен дә, йөгерә-йөгерә
Кайтып керәм һаман өйгә мин.

Ярый әле төшләремә керә,
Ташламый ул мине һаман да:
Оныталмыймы, әллә кызганамы
Ялгыз яшәп, ялгыз янганга?

Язмышыма бер дә үпкәләмим:
Сагынырлык кешем бар минем.
Боега дип уйламагыз тагын,
Канатларым һаман пар минем.

## Бер кайта

Кырын салып ап-ак бүрекләрен
Утыралар кышкы урамнар.
Үзебезнең карлар, безнең кыш бу,
Үзебезнең генә бураннар.

Күпме эзләр калган урамнарда,
Кем санаган аны, кем белгән?
Кайберләре аның ярылып ята,
Кайберләре инде күмелгән.

Төрле җилләр исте бу яклардан,
Көйдерделәр җанны, бәгырьне.
Ат чаптырып, олау алыштырып,
Китерделәр монда әмерне.

Бөтенесен күрде адәм башы:
Богау... сөрген... ачлык... сугышын...
Түзде ләкин, түзде — бөгелмәде
Көчкә алганда да сулышын.

Таралдылар эзләр еракларга,
Җир шарының төрле ягына.
Юк, онытмый авыл ул эзләрне
Төшләрендә күреп сагына.

Исәннәре түзми, туган як дип,
Әйләнә дә, урап бер кайта.
Яуда ятып калган батырларның
Хәтирәләр гомерен озайта.

●

Пыскып янган учак — учак түгел.
Дөрләп янган учак җылыта.
Яктылыгын җиргә бирә-бирә
Януларын гүя оныта.

Кеше дә бит шушы учак сыман
Яна ала икән — гомерле:
Еллар саны түгел, яшәү яме
Озынайта яшәр гомерне.

Искәртмәстән бер көн китә кеше,
Үзенә бер матур моң булып,
Төшкән кишәрлеге әллә бетә,
Әллә бетми кала урылып.

Бәргәләнми дөньям кала диеп,
Комсыз булмый тыйнак кешеләр.
Вакытлыча гына аерылып
Китә кебек Җирдән — эшеннән.

Ир йөрәкле ирләр — Ил йөрәкле,
Шуларда ул бөтен таяныч.
...Йөксез арба кебек шалтыр-шолтыр
Бушка үтсә гомер — аяныч.

## Таңнар, таулар

Тәрәзәмә таң нурлары куна,
Шул нурларга карыйм, сөенәм.
Бакчаларда шомырт куаклары
Баштанаяк актан киенгән.

Тәрәзәмне ачам, җилләр керә,
Җилләр алар җитез канатлы.
Таңнарны да, янар тауларны да
Яктылыгы өчен яраттым.

Күңелемдә минем яз шатлыгы,
Җылы яңгыр тора яварга.
Олы хаклык өчен янганнарны
Ошатам мин янартауларга.

●

Күпме дуслар китте... әрнеп калдык.
Еламадык. Булдык сабыр, нык.
Яшьнәр еллар калды яшьнәмичә,
Без яшибез һаман сагынып.

Сәбәпчеләр булды. Алар һаман
Төйнәделәр серле төеннәр...
Озатканда исә соңгы юлга
Атладылар кара киемнән.

Хәтта нотык сөйләделәр шунда:
«Иртә киттең, дускай, бик иртә!..»—
Кылганнарны юкка чыгарырга
Бер кагындың исә шул җитә...

Җир ананың алым-талымы юк.
Кабул итә яхшы, яманын.
Үзе китсә китә, яктылыгы
Балкып кала олы җаннарның.

Күпме дуслар иртә китеп барды,
Без яшибез һаман сагынып...
Киткәннәргә әллә нәрсә түгел,
Калганнарга бирсен сабырлык.

## Янар

Сорыйсың доктор, хәлемне...
Сөендерәсем килә.
Бөтен дөньяны гел актан
Киендерәсем килә.

Әйләнми телем әйтергә:
«Авырта әле» диеп.—
Сырхауга сихәт бирәм дип,
Йөрисең янып-көеп.

Доктор, тизрәк бу җанымның
Ертыгын ямасаңчы:
Билчәннәр утыйсым бар бит,
Кулларым канаганчы.

Хагыннан, нахакларыннан
Күрсә дә җаным зарар,
Моңарчы янганнан да ул
Мең кат көчлерәк янар!

●

Ыргыла диңгез, ыргыла,
Ярыннан чыкмак була.
Каршыга баскан ташларны
Ул бәреп екмак була.

Тартыша ике баһадир —
Дулкыннар белән ташлар.
Егылса аның берәрсе,
Тәгәрәр кебек башлар.

Иминлек кирәк диңгезгә,
Иминлек кирәк ташка.
Дөньяның асыл халәте
Хәвеф-хәтәрдән башка.

Яшәсен — янар чәчәкләр,
Кызарып пешсен җимеш,
Ташы таш, диңгезе диңгез,
Кояшы кояш килеш.

## Сафа Сабиров

# УТЛЫ ФАРВАТЕРДАН

**ПОВЕСТЬ**

***Яшь Совет республикасы язмышы хәл кылынган авыр көннәрдә Татарстанның Идел һәм Кама буе шәһәр-авылларын ак бандалардан һәм фетнәче чехлардан азат итүче кызыл матрослар һәм елгачыларның якты истәлегенә багышлана.***

**I**



Сугыш бәласе уйламаган-көтмәгән яктан килеп төште.

Мин пароходтан калып, тиф белән каты авырган хәлдә, Нижний Новгородта больницага кергән вакытта дөнья имин, андый-мондый шомланырлык бернинди дә хәвеф-хәтәр сизелми кебек иде.

Өч атнадан соң, савыгып больницадан чыгуыма безнең «Сирень» пароходы инде күптән рейска китеп барган, һәм гомумән, шәһәрдә бөтенләй атмосфера үзгәргән, киеренкеләнгән иде. Мин больницада һушсыз хәлдә яткан вакытта, Себер якларында һәм Урта Идел, Кама буйларында фетнәче чехлар белән акгвардияче бандалар Советка каршы күтәрелгән, яңа сугыш башланган.

Халык арасында төрле имеш-мимешләр йөри. Аклар якынлашуын сизеп, элекке байгуралар баш калкыткан, авыл җирләрендә кулак фетнәләре кузгалган дип сөйлиләр... Шул арада дошманның Казан шәһәрен алуы, гаять зур көчләр белән Идел буйлап Нижний Новгородка, аннан Мәскәүгә походка җыенуы турында берсеннән-берсе хәвефле хәбәрләр дә килеп житте.

Әнә шундый шомлы көннәрнең берсендә, Мәкәрҗә ярминкәсе аша үтешли, мин такта койма янында җыелган бер төркем ир-атның бик игътибар белән нииндидер игълан укып торганын күрдем. Игъланда яңа оештырыла башлаган хәрби флотилиягә диңгез белгечләрен хезмәткә чакыру турында язылган иде. Белдерүнең азагында катгый рәвештә искәртеп тә куелган: «Отрядка керергә теләүчеләрдән Совет власте платформасында тору, командирларга һәм үз иптәшләренә карата һичшиксез намуслы булу таләп ителә. Шундый хасиятләре булмаган кешеләрнең мәшәкатьләнеп йөрмәвен үтенәбез.

Идел хәрби флотилиясе комиссары
Н. Маркин».

Сары сакаллы, урта яшьләрдәге бер елгачы, белдерүнең азаккы сүзләрен абына-сөртенә кычкырып укып чыкканнан соң, үзалдына сөйләнгәндәй әйтеп куйды:

— Белдерүенә караганда бу Маркин дигәннәре төпле кеше булса кирәк.

— Маркин шундый ул,— диде озын буйлы бер матрос, елгачының сүзен җөпләп.— Ни житте, әштер-өштер эшли торганнардан түгел.

Берничә кеше шундук аңа таба борылып, кызыксыну белән сорашта башлады:

— Сез аны беләсезмени?

— Әйтегез әле,ниндирәк кеше ул?

— Патша хөкүмәтенең теге яшерен договорларын бастырып чыгарып, бөтен дөньяга фаш иткән матрос Маркин түгелме?

— Нәкъ үзе,— диде матрос.— Николай Маркин — Балтика матросы. Октябрь көннәрендә Петроградта матрослар отрядын вакытлы хөкүмәткә каршы штурмга алып барган егет. Бирегә ул Ленин фәрманы белән хәрби флотилия оештырырга килде. Кыска гына вакыт эчендә күпме пароходны коралландырып, фронтка җибәрергә әзерләде... Мин үзем аның белән бер корабта — «Ваня»да хезмәт итәм, тиздән без фронтка китәбез.

Моны ул, үзалдына мактанган сыман, эчке горурлык белән әйтте. Аннары, кешеләр арасыннан мине күреп, бер мәл төбәлеп карап торды да:

— Чү, нихәл, туган, терелеп чыктыңмыни?! — дип дусларча кулын биреп күреште.

Танымый торам икән, бу егет — больницада минем белән бер палатада, күрше караватта яткан Николай Кармашов лабаса. Бераз сихәтләнә төшкәч, сәгатьләр буе гәпләшеп утыра-утыра тәмам дуслашып беткән якын таныш ич. Теге чакны, савыгып, миннән элегрәк больницадан чыкканда, ул шундый ябык — мачта кебек озын гәүдәсен көчкә йөртә иде. Хәзер ярыйсы гына тазарган, йөзе көләч. Тик шунысы сәер: сөйләвенә караганда, сугышта ул атлы гаскәрдә, аннары пулеметчы булып хезмәт иткән. Хәзер исә хәрби флот киеменнән, тиз генә танырлык та түгел үзен...

Хәер, сөйләшә торгач, анысы да ачыкланды: больницадан соң бераз хәл кергәч тә, хәрби флотилиягә язылган, «Ваня» корабында пулеметчылар старшинасы, судовой комитет секретаре икән. Минем эшсез каңгырып йөрүемне белүгә:

— Безнең корабка бер рулевой кирәк. Син елгачы, штурвальный ич! — дип мине флотилиягә керергә үгетли башлады.— Тиздән сезнең якка, Казанны аклардан чистартырга китәбез... Әйдә безнең корабка. Комиссарга мин сине үзем рекомендовать итәрмен.

Бу киңәшкә мин бернинди икеләнүсез, бик теләп күндем һәм «Ваня» корабын эзләп, шундук пристаньга төшәргә теләк белдердем.

— Бар, бар, төшә тор,— диде Кармашев.— Андый-мондый тоткарлык килеп чыкса, Николай Григорьевичка әйт, мин җибәрде диген. Озакламый үзем дә барып житәм.

Эшне озын-озакка сузмыйча, туп-туры Ока буена юл тоттым. Пристаньга якыная барган саен, сугыш киеренкелеге, фронт сулышы көчлерәк сизелә бара иде. Кая карама, анда хәрби диңгезче: житди кыяфәтле командирлар, кайтарма якалы, ачык изүле зәңгәр күлмәк кигән матрослар очрый. Бескозырка тасмаларына алтын хәрефләр белән «Балтфлот», «Севаст. хәрби порты», «Громобой» дип язылган.

Яңа килеп туктаган пароход басмасында яшькелт гимнастеркалы чекистлар белән бергә хәрби матрослар да пассажирларның документларын тикшерәләр.

Кыска итеп кырыккан кара сакал-мыеклы бер матрос миңа «Ваня» корабының кайда торганын әйтте һәм, үзенчә шаяртып булса кирәк, туктап сорады:

— Бездә ни йомышың бар, кем кирәк иде?

Мин дә аңа шаяру белән:

— Күпне белсәң, тиз картаерсың,— дип җавап кайтардым да, сөзәк ярдан түбән төшеп киттем.

Миңа кирәк кораб шуннан ерак түгел, киң такта басмага яны белән тора иде. Аның бортына һәм коткару боҗраларына эре хәрефләр белән «Ваня» дип язылган. Кырына бишле номеры да куелган. Зур плакаттан кулына винтовка тоткан хәрби диңгезче яуга ашыктыргандай яр салып тора: «Матрос туганнар! Революция безне көнчыгыш фронтка, тизрәк Казанны, Семберне азат итәргә чакыра!»

Корабта кызу эш вакыты. Чүкеч, балта тавышлары яңгырап китә. Һавада олиф, буяу исе. Бер төркем матрос сөзәк яр өстендәге складтан, вагоннардан трюмга төрле әрҗә, капчык ташый, палундра, сак бул дип, кычкыра-кычкыра мичкә тәгәрәтә иде.

Трап янында вахта торучы мылтыклы япь-яшь матрос минем сорауга олыларча житди кыяфәт белән:

— Юк, комиссар корабта түгел... әлерәк кенә складка менеп китте,— дип яр өстенә таба баш какты.

Ул өлкәнрәк күренергә теләп булса кирәк, бала йонысыдай гына мыек җибәргән. Өстендәге диңгезче формасын да, мөгаен, кичәле-бүгенле генә кигән күрәсең, әледән-әле үзенә үзе сокланулы карап ала, буш кулы белән юклы-барлы мыегын сыпырып куя иде.

— Әй, туганкай, безнең комиссарда ни йомышың бар? — диде ул эреләнүен кинәт онытып.— Казна эше беләнме, әллә болай гынамы?

— Ничек дисәң дә була... Әгәр алсалар, сезнең корабка хезмәткә керергә исәп.

— Һы, соңга калгансың, туганкай, алданрак кыймылдарга иде... Хәер, барыбер алмас идек, син хәрби диңгезче түгел бит.— Матрос, причалга карап алды да күкрәген киереп, смирно басты.— Әнә, комиссар төшеп килә, миңа ышанмасаң, хәзер үзе әйтер...

Мин борылып ул күрсәткән якка карадым. Әмма анда комиссарга охшашлы берәү дә күренми, бая миңа причалда очраган базык гәүдәле, кара сакал-мыеклы матрос кына җәһәт адымнар белән траптан менеп килә иде. Ул палубага аяк басу белән, яшүсмер сакчы аңа шундук хәбәр итте:

— Иптәш комиссар, менә бу егачы безгә хезмәткә керергә сорап килгән... Урын юк, соңга калгансың, мин әйтәм. Ә ул ышанырга теләми, сезне көтеп тора.

Мин бу сакаллы матросның комиссар Маркин икәнлеген аңлап алдым. Күрер күзгә ул үзенең тышкы кыяфәте белән зур дәрәҗәле комиссарга бер дә охшамаган, бүтән матрослардан һичнинди аермасы юк шикелле: өстендә ачык изүле, киң якалы фланель күлмәк, билендә киң кара каеш. Уңга яткырып тараган аксыл-соры чәче калку маңгаена чак кына төшеп тора. Әмма аның үз-үзен тотышында, зәңгәр күзләренең сынаучан-җылы карашында кешене үзенә җәлеп итү һәм ихтыяр көче сизелә иде.

Аның бу хасиятен мин шундук искәреп алдым һәм, дөресен әйтим, бая яр өстендә очрашканда ихтирамсыз сөйләшкәнем өчен бераз уңайсызланып та калдым. Комиссар яшүсмер матросны үтә житди кыяфәт белән тыңлаганнан соң:

— Юнга Чурков, күрәм, бик телеңә салына башлагансың,— диде һәм зәңгәр күзләрендә туган елмаюын яшерергә теләгәндәй, кырыс кына тамак кырып куйды.— Постта торганда сөйләшергә ярамый. Син хәзер гади малай-шалай түгел, ә эшче-крестьян хәрби флоты диңгезчесе...

Димәк, үзеңне хәрбиләрчә тотарга тиешсең.— Аннары комиссар миңа таба борылып карады: — Әһә, син бая яр буенда очраган егет ич. Киеменә караганда, елгачыга охшагансың. Нинди һөнәрең бар?

— Хәрби һөнәрем юк, елгачы мин — штурвальный, монда сезнең егет Кармашов җибәрде. Ул рулевой кирәк дип әйткән иде.

— Шулаймы, рулевоймы...— Комиссар якында гына шпиль барабанын буяп маташучы карт елгачыны дәшеп алды.— Митрич, синең вахтаңа рулевой җитми бит. Менә бу егетне Кармашов җибәргән.

Митрич агай корабта лоцман икән. Беренче карашка йомыкый гына күренсә дә, бик төпченүчән булып чыкты. Рубкага менеп икәү генә калгач, фарватерны ничек белүемне, аеруча кыен перекатларда су тирәнлеген, агым юнәлешен ачыклауны бәйнә-бәйнә җентекләп сораштырды һәм ниһаять, канәгать булды. Конторга төшкәч, комиссарга ныклап әйтте:

— Елганы белү ягыннан тел-теш тидерерлек түгел, молодец! — дип хәтта мактады да.— Бераз тазарып, көч-куәт кергәч, безнең авыр штурвалны әйләндерергә бик кулай булыр.

— Кулыннан эш килә торганмы... Ә политик ягы ничек? — Комиссар минем таныклыкны, больницадан алган кәгазьне игътибар белән укып чыкты, утәли күрергә теләгәндәй, зур зәңгәр күзләре белән бер мәл миңа карап торды.— Без бит флотилиягә үзләре теләп килүчеләрне, Совет власте, хезмәт халкы азатлыгы өчен аңлы рәвештә көрәшүчеләрне генә алабыз. Син ничек?.. Болай кешедән ишетеп кенә түгелдер ич?

— Юк, иптәш комиссар. Җыен контр, ил дошманнары безнең өскә ябырылып килгән вакытта ничек тик ятмак кирәк.

— Анысын дөрес әйтәсең, туганкай, намуслы кеше мондый кыен чакны көрәштән читтә посып ятарга тиеш түгел... Митрич, Кармашов та рекомендовать иткәч, әйдә алыйк.— Комиссар минем таныклыкны ачып тагын укырга тотынды: — Фамилиясе Беляев, исеме — Василий... Юк, ничектер бүтәнчәрәк, Василь икән... Ник болай, Василийны шулай үзгәртеп язмаганнардыр ич?

— Дөресе шулай, иптәш командир, Вәсил — безнең Казан татарларында еш очрый торган исем.

— Син үзең дә шул яктанмыни?! Әйтәм аны, бераз акцент белән сөйләшәсең... Димәк, Василь туган, Казанны, син туган-үскән якларны азат итәргә барабыз.

Комиссар янынннан мин күтәренке күңел белән чыктым. Боцман Поляков тулай кубриктан ятак бирде. Мин ике катлы агач караватның аскысында урын-җиремне рәтләп җәйгән арада кубрикка төшкән юнга Чурков бик гаҗәпләнде:

— Алдылармы? Кем итеп? Алайса, туганкай, бергә сугышабыз...

Шунда мин аның ике сүзенең берендә туганкай дип эндәшүе дә, юклы-барлы мыек җибәреп маташуы да комиссарга охшарга теләүдән икәнлеген сизеп алдым. Хәер, андыйлар бер ул гына түгел, комиссарга ияреп сакал-мыек үстерүчеләр, һәр эштә аның кебек булырга тырышучылар корабта шактый күп булып чыкты.

Озакламыйча шәһәрдән Кармашов та кайтып төште һәм минем инде кубрикта урнашкан бу[illegible]ымны күреп:

— Хәрби диңгезче б[illegible]луың белән тәбрик итәм, Василь туган,— диде кулымнан кысып.

Мин сөенечемне яшермәдем. Урамда матрос күргән саен күзем яна, диңгезче булырга кызыга идем. Менә кечкенәдән килгән хыялым тормышка ашты, ниһаять, мин кызыл флотилия матросы булдым.

## II

Шул ук көнне мин тагын бер яңа кеше — корабның повары, безнең як кешесе Алимҗан исемле егет белән таныштым.

Кубрикта урнашып, бераз баш-күз алганнан соң, Кармашов корабны күрсәтергә алып чыккан иде. Без алгы палубадан койрык якка үткәндә якында гына татар җыры ишетелә башлады:

Алыстан ла күгәреп ай күренгән
Чал Иделкәй буе тирәге.
Кая гына барсаң, дуслар кирәк,
Дус-иш икән дөнья терәге.

Шунда туктап, мин аны тын да алмыйча тыңладым һәм, бу җырда үз уй-моңнарымны ишеткәндәй, кинәт дулкынланып киттем.

— Безнең кок Алим тавышы, шул җырлый,— диде Кармашов камбузга таба күрсәтеп.— Гел шулай ул, кайчан үтмә, камбуз эченнән аның җырлаганы ишетелеп тора...

Без сөйләшкәнне ишетеп булса кирәк, камбуз ишегеннән башын тыгып кок үзе карады һәм көйләвеннән туктап:

— Ни йомыш, туганнар, төшке ашка соңга калдыгызмыни? — диде һәм миңа сынаучан карап алды.

— Кая, запасың булса, бераз ашатып җибәр,— диде Кармашов.— Бер уңайдан, менә яңа иптәшне дә матрос ризыгыннан авыз иттер. Сиңа якташ егет, саранланма, мулрак салып бир...

Инде шактый куера төшкән борчак ашы, берәр кипкән балык белән чирек кадак арыш икмәге алдык та, ачык палубада зур такта өстәл тирәли урнашып ашарга керештек. Безнең белән бергә кок үзе дә зур калай кружка тотып чәй эчәргә утырды һәм чытырман кебек куе җирән кашлары астыннан яшькелт күзләрен бер мәл миңа текәп торганнан соң:

— Әйт әле, син чыннан да безнең якташмы?! — диде мишәр акценты белән.— Атың ницек, тумыш-цыгышың кай төбәктән? И, Вәсил туган, сүәгең белән тирең генә калган, ник болай ябыктың әле син?

Без күптәнге дуслар кебек бик җиңел сөйләшеп киттек. Ул Чистай ягыннан булып чыкты. Авылда әти-әнисе, быел яз гына туган бәләкәй улы белән хатыны бар икән.

— Без бөтен нәселебез белән аш осталары, мин үсмер малай цактан ук әти белән бергә Мәкәрҗә ресторааннарына эшкә йөри идем,— дип сөйләп китте Алимҗан.— Кирәк-яракка бераз акца ясарга келәп, быел да барган идем, менә сугыш цыкты бит... Безнең якларны анда дошман басып алган ди... Мондый вакытта кухняда ятарга йөрәк түзмәде, туган... Тупцы булырга келәп флотилиягә язылдым. Мәгәр менә тагын камбузга. Минем боевой пост барыбер туп янында, сугыш вакытында снаряд бирәп торацакмын...

Гәп корып утырганда, Алимҗанның кубыз уйнарга яратуын белдем. Аның кубызы да үзе белән, халат кесәсендә генә икән. Кармашов икебезне генә калдырып, кубрикка төшеп китүкәч, ул һич тә ялындырып тормастан, шундук моңлы көйгә уйнап та җибәрде. Азактан колакка ягымлы йомшак тавыш белән җырның ахыргы сүзләрен телдән тәмамлады:

Ямьле Агыйдел буйлары,
Бетерәдер хәсрәтле уйларны...

Эч пошкан минутларда үземнең дә җырларга ярата торган гадәтем бар. Бәләкәй генә кубыз теленнән таралган моңлы көй туган якларга алып киткәндәй булды, соңгы вакытта рухымны басып торган авыр хисләрдән арынып, җиңеләеп калдым.

Алимҗан рус көйләрен дә әйбәт кенә уйный белә икән. Кубыз тавышына безнең тирәгә бүтән матрослар җыела башлагач, ул мәшһүр «Варяг» көен сыздырып җибәрде. Юнга Чурков каядыр су өстенә кара-

ган хәлдә нәзек тавыш белән сузып җырлый башлады. Аның артыннан җырны бүтәннәр дә дәррәү күтәреп алдылар.

...Врагу не сдается наш гордый «Варяг»,
Пощады никто не желает...

Җыр тәмам булгач, үз көйләреннән үзләре моңланып, бер мәлгә барысы да тынып калды. Алимҗан янәшә утырган юнга Чурковның иңенә кулын салып:

— Әй моңлы да җырлыйсың инде, Володя,— диде.— Укысаң, синнән оста җырчы чыгар иде. Кубызда уйнарга мин үзем өйрәтермен... Сугыш беткәч, җырчы булырга укырга җибәрербез...

Алимҗанның бу вәгъдәсе коры сүз генә булып калмады. Шуннан бирле мин юнга Чурковның камбуз тирәсендә чуалганын еш күрә башладым: бергәләп аш-су пешерә, савыт-саба юалар, эштән буш сәгатьләрдә Алимҗан аны кубыз уйнарга өйрәтә иде.



## III

Кояш кичкә авышкан, көнозын эсседә эшләп арган матрослар ялга туктаган иде; Алимҗан да камбузда савыт-сабасын юып бетергәннән соң палубага һава алырга чыккан иде.

Шулчак күрше дебаркадерга «Ломоносов» пароходы килеп туктады. Астрахань белән Нижний Новгород арасында йөри торган ике катлы бу зур пароходны да хәрбиләр алып, хәзер флотилиянең йөзмә тәэминат базасы иткәннәр.

— Ул пароходның өлкән повары Илья Храмов — минем белеш егет, былтыр җәен бергә эшләгән идек,— диде Алимҗан.— Салгаларга ярата иде. Әйдә, барып килик әле,ниләр майтарып ята икән.

Трап янында вахта торучы чытык чырайлы матрос башта безне пароходка һич тә уткәрәсе түгел иде. Кемгә килүебезне белгәч кенә йомшарды.

— Илья Федорович янынамыни?! Баштук әйтәләр аны,— диде, мыек астыннан елмаеп.— Хәзер ул кок түгел, аны баталер итеп күчерделәр бит. Барыгыз, әнә арткы трюмга төшегез, ул шунда булыр.

— Ницек, ницек?.. Нинди баталер, анысы кем була тагын? — дип кабат сорады Алимҗан.

— Склад мөдире, сезнеңчә әйтсәк, кладовойчы буладыр. Их, коры җир диңгезчеләре, шуны да белмисез.

Без кергәндә асылмалы фонарь белән яктыртылган өстәл янында ике диңгезче эчеп утыра иде. Алларында ярты кисәк ипи, бер түтәрәм ит, ысланган балык. Күмүшкә исе белән тәмәке төтене катнаш тынчу һава. Башына матрос бескозыркасы, өстенә гимнастерка кигән һәм чын кавалеристларча кәкре кылыч таккан әкәмәт бәндә, Алимҗанны күрү белән таныды.

— И Алим дус, бик вакытлы килгәнсең... Әйдә, утырыгыз...— дип шатланып каршылады һәм зур чиректән калай кружкаларга күмүшкә сала башлады.— Бүген минем туган көнем бит, менә кулдаш белән шуны билгеләп утыра идек. Былтырдан бирле күрешкән юк, әйдә, очрашу хөрмәтенә берәрне аударыйк әле.

Күренеп тора, болар икесе дә шактый кызмача. Болай бик сәрхуш булмаса да, Ильяның табак кебек түгәрәк бите, күз төпләре шешенке, хәрәкәтләре тотрыксыз иде.

Мондый очрашуны Алимҗан көтмәгән иде булса кирәк, ул алдындагы кружканы терсәге белән читкәрәк этәрде, монда килгәне өчен уңайсызланудан чырае караңгыланды.

Шул мәлне якында гына аяк тавышлары һәм кемнендер командирларча калын тавыш белән:

— Әйдә, начальник, складыңны күрик әле, ашамлыкларны ничек саклыйлар икән...— дип әйткәне ишетелде.

Бу — комиссар Маркин тавышы икәнлеген без шундук абайлап алдык. Кинәт айнып киткән Илья табындагы шешәне тиз генә өстәл астына яшергән арада Николай Григорьевич ишектән үзе килеп керде һәм, мондагы хәлне башына сыйдыра алмагандай, бер мәлгә аптырап калды, ирен читләре калтырап куйды. Шулай да ул капыл кабынып китмәде, аны-моны сизмәгәндәй:

— Иптәш начальник, боларның кайсы баталер, кайсы ярдәмче? — дип сорады.— Күрсәтегез әле, күпме азык-төлек кабул иттегез? Караусыз әрәм-шәрәм булып ятмыйлармы?..

Кулына фонарь тоткан Илья конторкадан башлап чыгып китте. Комиссар белән база начальнигы аның артыннан кузгалдылар. Ә без, форсаттан файдаланып, мыштым гына ычкынырга уйлаган идек тә, ниятебез барып чыкмады. Трапка таба борылуыбызы күреп, комиссар безне туктатты, кирәк булуыгыз бар дип, үзе белән бергә складны карарга кушты.

Николай Григорьевичка, мөгаен, берәрсе хәбәр иткән яки үзе борчылып килгән булса кирәк, амбардай зур трюмда чыннан да һичнинди рәт-чират юк иде.

Бер урында, сул як борт буена өелгән онлы капчыклар яныннан узгәндә ярым караңгы тынлыкта тып-тып тамчы тамуы ишетелде. Бу хәлгә аптырап калган комиссар фонарьны үз кулына алып, өемне җентекләбрәк карарга кереште.

— Палубадан су тама түгелме соң?! Аска кадәр агып төшкән ич... Моны ничек аңларга, җинаять бит бу?!

Конторкага кабат әйләнеп кергәч тә, әле һаман тынычлана алмыйча ул:

— Син нәрсә, шушы җинаятьчел хуҗасызлыкны күрмисеңмени?! Моны ничек аңларга, ә? — дип иң әүвәл база начальнигын яман кыздыра башлады.— Шуны да карамагач, нинди начальник син?

— Гаеп миндә, Николай Григорьевич, зинһар, гафу итегез,— диде база начальнигы, акланып.— Бу арада бөтен вакытым төрле учреждениеләрдә, складларда азык юллап үтте, монысына кул җитмәде... Менә сез килер алдыннан гына кайтып кердем, хәзер үк барысын да тәртипкә салырга керешәм.

— Хәзер үк эшкә тотыныгыз. Ә бу адәм актыкларының монда эзләре булмасын. Алар урынына намуслы егетләр куегыз.— Ниһаять, безгә дә чират житте, комиссар икебезгә дә каш астыннан ачулы карап сорады: — Сез дә самогон чөмерәсезме?!

Комиссар алдында кинәт бик уңайсыз булып китте, битемнең кызарып чыгуын сиздем. Алимҗан тапкыррак икән. Мин ни әйтергә белмичә аптырап торган арада ул шик-шөбһә калдырмаслык кыюлык белән:

— Никак нет, иптәш комиссар, беребез дә самогон чөмерүче түгел, тамчы да эчмәгән без,— дип, икебез өчен дә җавап кайтарды.— Былтыр бергә эшләгән белешнең хәлен белергә генә керүебез иде.

Бу сүзләрнең ихласлыгына комиссар ышанды бугай, ачуы басыла төште, йөзенә ягымлылык чыкты. Инде үзгәргән йомшак тавыш белән:

— Киләчәктә мондый компаниядә чуалмаска киңәш итәм. Барыгыз, юлыгызда булыгыз,— диде.

Без тизрәк чыгып киттек, бу хәлдән җиңел котылуыбызга сөенә-сөенә, яр буйлап үзебезнең корабка элдерттек.

Иртәгесен корабларда командирларны сафка тезеп, комиссарның теге исерекбашларны флотилиядән куып чыгару турындагы боерыгын игълан иттеләр.

Иртәгә отряд фронтка китәчәк. Инде корабка һәртөрле сугыш кирәк-яраклары, ягулык һәм азык-төлек төялеп бетте. Трюмнар гына түгел, хәтта өске ачык палуба һәм коридорлар да он тулы капчыклар, снаряд һәм патрон әрҗәләре, балык мичкәләре, тагын әллә ниләр белән шыгрым тулды. Бераз соңгарак калып булса да, ниһаять, медикамент, хуҗалык кирәк-яраклары килеп житте. Әмма барыбызның да иң борчыганы — Петроградтан вагонга төяп җибәрелгән хәрби диңгез формасы һаман юк та юк. Күпчелегебез базар халкы кебек чуар, төрле киемнән йөрергә мәҗбүрбез.

Хәер, аңар карап кына поход тоткарланачак түгел, әлбәттә. Һәр корабтагы кебек, безнең «Ваня»да да соңгы хәзерлек эшләре бара. Митрич белән без дә штурвалны тагын бер кабат тикшереп чыктык, подшипникларын майладык, сигнал утларын кабызып карадык һәм эш барышында тагын да якыннанрак таныштык.

Юнга Володя Чурков та безнең тирәдә чуалды, үсмерләргә хас хирыслык белән штурвал күпчәген уңга-сулга борып карады һәм Митричтән рөхсәт сорап, хәтта гудок кычкыртып та алды. Мәкәрҗә ярминкәсендә, пристаньда каңгырып, теләсә кайда кунып йөргән бу урам ятимен Николай Григорьевич кызганып, корабка үзе алып кайткан һәм шулчак палубада булган матрослар алдында: «Менә безгә яңа иптәш — юнга Чурков килде, минем ярдәмчем булыр»,— дип әйткән. Шуннан бирле аны корабта бөтен команда әчкерсез елмаю белән комиссар ярдәмчесе дип йөртә икән.

Менә, ниһаять, бөтен әзерләнү-җыену эшләре тәмам булды. Төштән соң, походка китәр алдыннан туган-тумачалары, дуслары белән саубуллашу өчен, теләгәннәргә, иртәгегә хәтле шәһәргә чыгарга рөхсәт ителде.

Нижний Новгородта хушлашырдай беркемем дә юк минем. Шулай да башкалар белән бергә шәһәргә мин дә чыктым һәм, пароходчылык идарәсендә кадрлар бүлегенә кереп, үземнең хәрби хезмәткә китүемне хәбәр иттем, эшемнән расчет алдым. Бер уңайдан, үзем эшләгән «Сирень» пароходы турында да сораштырып караган идем, әмма, кызганычка каршы, берни дә ачыклый алмадым. Казанга төшеп киткән иде, шәһәрне аклар алганнан бирле, андагы пароходлар турында һични билгеле түгел, дип әйттеләр.

Ахырдан мин идарәнең аскы катындагы экспедиция бүлегенә кердем. Безнең пароходка килгән газета, хатлар, идарәдән җибәрелгән төрле күрсәтмә приказларны еш кына мин әлек тә шуннан үзем алып кайта торган идем. Бу юлы безнең пароходка ни бары бер пакет килгән булып чыкты. Мин аны адресыннан ук таныдым: хат Казаннан, Миңзифа кулы белән язылган иде.

Күптән күп сагынычлы кайнар сәламнәрдән соң, ул хатта түбәндәге хәбәрләр бар иде.

«...Бу арада безнең монда тормыш тәмам мәхшәр көненә әйләнде, дөньяның асты өскә килеп бетте. Бүгенме, иртәгәме, яңа власть бетә, һәркайда элекке түрәләр, байлар кайтачак дип сөйлиләр.

Хәзер безнең пароходка кораллы кызылармеецлар отряды төялә. Кама буе авылларында, Чаллы якларында баш күтәргән сәнәкчеләр, кулаклар совет активистларын аяусыз асалар, кисәләр икән. Әти әйтә, бу отряд шул фетнәчеләрне бастырырга бара, ди.

Бу мәктүбне юлга чыгар алдыннан, бик ашыгыч арада язам. Әнә төяп бетерәләр инде, хәзер кузгалып китәбез. Әти сиңа күп итеп сәламнәр юллый, син анда исән-сау микән дип борчыла. Мин дә бик борчылам, гел уйлап йөргәнгәме, еш кына төшләремдә күрәм...

Теге чакны Нижний Новгородта сине аңсыз хәлдә больницага илтеп

салгачтын, иртәгесен хәлеңне белергә барган идем, яныңа кертмәделәр, һушсыз ята, больницада карантин дип, якын да җибәрмәделәр. Кичен инде без рейска китеп бардык. Шуннан бирле ут эчендә яшим, ашым аш, йокым йокы түгел. Исән-иминме син, бер хат-хәбәрең булмаудан йөрәгем өзгәләнә.

Васил бәгырем, безгә тагын кавышу-күрешүләр кайчан насыйп булыр икән? Сине бик сагынып, бер күрергә интизар булып калучы Миңзифаң дип белерсең».

Хатны укып чыккач, мин шатлыгымнан чүт кычкырып җибәрмәдем. Идарәнең ярым караңгы коридоры кинәт яктырып киткән кебек тоелды, соңгы атналарда кичергән каты авыру да, кайгы-сагышлар да каядыр таралып, юкка чыккан кебек булды. Колагымда Миңзифаның сагыну, сөю сүзләре генә яңгырады. Урамда тиз-тиз атлап кайтканда үземне аның белән кулга-кул тотынып барган кебек чиксез бәхетле хис иттем.

Мин корабка кайтып җиткәч тә әле һаман тынычлана алмадым. Бөтен кораб өчен бик мөһим хәбәр китергәндәй, ишектән керү белән:

— Хат алдым, егетләр, хат килде!— дип, эчемә сыймаган шатлыгымны бөтен кубрикка белдердем.— Чынлап әгәр, Казаннан Миңзифадан... Шөкерана, исән-саулар. Синең өчен борчылабыз, бик сагындым, бик күрәсем килә дип язган...

Кубрикташларым исә, минем шатлыгымны уртаклашкандай, бу хәбәрне елмаеп каршылдылар һәм бик гаҗәпләнделәр. Үз почмагында нидер язып утырган пулеметчы Вишневский бер мәл уйланып торганнан соң:

— Чынлап та Казаннанмы?? Дошман кулындагы шәһәрдән ничек җибәрә алган?— дип гаҗәпләнде.

Шунда мин үзем өчен көтелмәгән күңелсез ачыш ясадым. Хатны, түземсезлек белән, ашык-пошык укыганда, мин, шатлыклы дулкынланудан, андагы сагыну, сөю сүзләрен генә күргәнмен бит. Аек баштан уйласам артык шатланырлык хәбәр дә юк: хәзер Казанда да, Кама буйларында да аклар лабаса. Димәк, Миңзифалар да шунда, дошман ягында, аларның язмышлары билгесез.

Мин, акыллы баш, әнә шул аяныч хакыйкатьне истән чыгарганмын.

## V

Ниһаять, көткән көн килеп җитте. Флотилиянең хәлен Мәскәүгә хәбәр иткәннән соң, әзер кораблардан торган беренче отрядка ашыгыч рәвештә походка чыгарга приказ алынды.

Бүген көндез шул уңай белән безне фронтка озату митингы булырга тиеш иде. Әмма төш җитәрәк, кинәт башланган яңгыр өч сәгать буе коеп яуды. Көн аязганны көтәргә, митингны билгеләнгән вакыттан бераз кичектерергә туры килде.

Шифалы яңгыр туктаганнан соң, болытлар күчеп киткән тарафта, Идел ярларын бер-берсенә тоташтырып, һавада мәһабәт салават күпере балкыды. Әйләнә-тирәдә бар дөнья — яр буйларындагы пристань каралтылары, дебаркадер һәм пароходлар, тау итәгендәге урамнар, хәтта чал Идел үзе дә сафланып, ничектер яшәреп, матураеп калды.

Меңә төрле төстәге флаглар белән бәйрәмчә бизәлгән корабларда без рейдка чыктык һәм Идел белән Ока елгалары бергә кушылган турыда, Мүкле тау каршында якорь салдык. Иң алда отрядның флагманы — безнең «Ваня». Үзе болай гади буксир пароход кына булса да, аның алгы һәм арткы палубасында озын көпшәле туплар, өске катына пулеметлар куелган, дошман пулясыннан саклау өчен рубка тирәли һәм палуба читләренә комлы капчыклар әрдәнәләп өелгән... Бездән чак

кына арттарак «Добрый», «Олень» корабларьы, катерлар һәм болын кебек иркен палубасына эре калибрлы егерме ике туп куелган зур тимер баржа — үзе бер крепость сыман йөзмә форт «Сережа» горур тора.

Корабларда командалар өске палубага чыгып сафка тезелде. Һәркемнең чын хәрбиме түгелме икәнен, тышкы кыяфәтеннән, сафта ничек торуыннан күреп белергә мөмкин иде. Уң як борт буйлап балтикчылар тезелгән. Болар үзләрен эре тоталар, комиссар турында безнең Маркин дип горурланырга яраталар. Сул як бортта кара дингезчеләр. Алар күптән түгел генә Новороссийскида, Ленин фәрманы буенча, корабларын, немецларга эләкмәсен өчен, диңгезгә батырып Иделгә килгән егетләр. Ә безнең арада демобилизацияләнгән солдатлар, минемише хәрби хезмәт күрмәгән рулевойлар, көрәк сакаллы карт лоцманнар бар — үзгә бер чуар халык. Хәзергә әле безнең тышкы кыяфәт эленкесалынкы, сафта торыш та ташка үлчим.

Безнең боцман — әзмәвер кебек зур таза гәүдәле балтикчы Иван Поляков, гадәтенчә, ашыкмый гына сафларын җентекләп күздән кичергәннән соң, кемгәдер зарлангандай:

— Болай бары:ыз да молодцы, чын бөркетләр... Форманың чуарлыгы гына бөтен күренешне боза,— дип ризасызлык белән чыраен сытты.— Обмундирование тәки килеп җитмәде шул...

Шул арада бөтен пристань, елгага караган тау итәкләре меңләгән халык белән тулды. Губерна Советы һәм партия оешмалары житәкчеләре, затон эшчеләре, төрле мичкә, әрҗәләрдән әмәлләнгән трибунадан безгә хәерле юл, зур җиңүләр теләделәр.

Безнең комиссар Маркин да алар арасында — трибунада, һәрвакыттагыча, аның өстендә гади матрос формасы, хәрәкәтләре ашкынулы, йөзе җитди. Үзенә сүз бирелгәч, ул бескозыркасын кулына алып, алга чыгып басты да, иң элек затон һәм завод эшчеләренә, елгачыларга флотилияне төзүдә, корабларны коралландыруда булышулары өчен кайнар рәхмәт белдерде һәм, беренче сүзләре белән үк магнитлагандай, бар халыкның игътибарын үзенә җәлеп итте.

Мин комиссарның шундый ялкынлы оратор икәнлеген күреп сокландым. Аның куәтле ачык тавыш белән:

— Сез барыгыз да яхшы беләсез, Казанда, Зөя янында хәзергә безнең хәлләр кыен, күп корбаннар биреп ирешкән азатлыктан хезмәт халкын мәхрүм итәргә кара көчләр ябырылып килә. Иптәш Ленин безнең флотилиягә зур өмет баглый. Без Совет власте дошманнарына каршы фидакарь рәвештә сугышырбыз, дошманның мәкерле ниятләрен өзәрбез.

Кадерле иптәшләр, туганнар!.. Бу ышанычны аклар өчен, туган халкыбызның азатлыгы өчен без — революция матрослары — барын да эшләрбез, кирәксә, гомеребезне дә кызганмабыз, әмма бер карыш та кире чигенмәбез, дошманнарны тар-мар итмичә туктамабыз... Мин моны сезгә бөтен флотилия исеменнән изге антыбыз итеп әйтәм.

Сез булышсагыз, без үзебезне тагын да көчлерәк хис итәрбез, дошманнарны катырак дөмбәсләрбез...

Безнең комиссарны барысы да тын да алмыйча йотылып тыңлады, аның кайнар йөрәктән чыккан сүзләре күңелләрне тетрәтте. Ул туктауга халык хуплап аваз бирде:

— Коралларны да, боеприпасларын да җибәрербез, тик сез генә анда нык тора күрегез...

— Хушыгыз, балакайлар, хәерле юл сезгә...

Ихлас күңелдән әйтелгән бу сүзләрдән кинәт күңелем талпынып куйды, көчем арткандай булды, зур изге көрәшкә баруыбызны бөтен йөрәгем белән тойдым. Сафта минем белән янәшә торучы якташым — Чистай мишәре Алимҗанның да йөрәге ашкынып тибә икән.

— Вәсил дус, сизәсеңме... — диде ул, ияbашы белән миңа кагылып.— Туган якка кайтабыз бит, ак бандаларны дөмбәсләргә... Әзер тор, мин әйтәм, күрмәгәннәрен күрсәтерлек, умыртка сөякләрен сындырырлык булсын.

Митингтан соң, Николай Григорьевич рубкага менүгә, кораблар якорьларын күтәреп, бер-бер артлы агым уңаена борылдылар. Тиз йөрешле «Олень» алдан чыкты. Сакчы катер һәм юл салучы буларак, ин алдан шул барачак. Безнең «Ваня» йөзмә форт «Сережа»ны буксирга алды. Сафның койрыгына «Добрый» килеп кушылды. Әлегә заводтан чыгып өлгермәгән бүтән кораблар һәм ашыгыч рәвештә Балтикадан җибәрелгән җиңел эсминецлар фронтка безнең арттан соңарак үзләре киләчәк.

Ниһаять, машиналарны катырак эшләтергә сигнал бирелде. Су өстендә ак күбекле йөгерек дулкыннар кайнатып, отряд юлга кузгалды, рейдтагы пароход, баркасларның саубуллашу гудоклары яңгырады.

Киң фарватерга, агым уңаена чыккач, отряд тизлеген арттыра төште. Комиссар белән лоцман рубканың ачык тәрәзәсеннән игътибар белән алга карап баралар. Мин исә, штурвал янында торсам да, күңелем белән отрядтан күп алда очам, туган-үскән шәһәрем Казанны азат итәргә, Миңзифамны күрергә ашкынам.

## VI

Ачык фарватерга чыккач, Идел күзгә күренеп киңәйде, әйләнә-тирәдә берсеннән-берсе мәһабәт күренешләр ачылды. Елганың сул ягында көндезге мул яңгырдан соң куе-яшел төскә кергән иксез-чиксез тугайлар, куе әрәмәләр. Унда — фантастик диварлар, таш кыялар, үркәч-үркәч күтәрелгән таулар.

Походның беренче көне, беренче вахта...

Зур штурвал көпчәгенең бер ягында лоцман Митрич, икенче ягында мин, корабны фарватердан турылап барабыз.

Билгеләнгән срокта юлга чыгуыбызга Николай Григорьевич та канәгать, күңеле күтәренке.

— Менә, Иван Васильевич, ниһаять, без дә кузгалдык... Хәерле булсын,— ди ул, рубка алдындагы такта эскәмиядә янәшә утырган боцман Поляковка елмаюлы карап.

— Әйе, Николай Григорьевич, ә хәзергә кешеләргә бераз ял бирсәк тә зыян итмәс, бу көннәрдә эш күп булды, бик арыдылар.

Үз уйларына чумган комиссар, боцманга карамыйча гына:

— Яңа куелган туплар да тиешенчә сыналмаган, корабларның йөрешен, маневрлылыгын белмибез... Димәк, юлда вакытны заяга үткәрмәскә, барып җиткәнче, буш арадан файдаланып калырга кирәк. Халык бераз ял итеп алсын да, иртәгә өйрәнүләрне башларбыз,— диде.

Юлга чыкканның өченче көнендә иртән, Мари тугайлары буеннан үткәч, отряд Звенигово затоны тамагына төшеп җитте. Аны башлап күрүче кеше — сигналчы булды.

— Елганың сул ягында култык тамагыннан бераз эчкәрәк ниндидер сәер пароход тора,— диде ул, бинокльдән каравын дәвам иттереп.— Миңа гына ике булып күренәме, әллә чынлап та шулаймы, ул пароход ике торбалы кебек: берсе — алда, икенчесе — рубка артында.

Сигналчы әйткән пароход үзе әле рәтләп күренми, тәбәнәк яр буендагы әрәмәлек өстеннән аның биек мачтасы белән аллы-артлы ике торбасы гына калкып тора иде. Шулай да мин аны күрү белән таныдым һәм «Мария» туташ булса кирәк дип уйлап куйдым. Бераздан, лоцман Митрич та шуны раслады:

— «Мария» туташ — элекке «Волга» ширкәте пароходы... Бөтен

Иделдә бер генә, аның эше торбалы бүтән пароход юк. Зур егәрле буксир, әгәр төзек булса, безгә иң кулае шул.

Затон тамагы каршында «Сережа»ны якорьга куеп, аның комендантны кара диңгезче Лепетенконы үзебез белән алдык та, Звенигово затонына кердек. Нәкъ лоцман Митрич әйткәнчә, «Мария» пароходы, дөресрәге, аның капитаны бирегә Нижний Новгородтан качып килгән һәм тыныч көннәр туганны көтеп яткан булып чыкты. Николай Григорьевич та, «Сережа» коменданты Лепетенко да җентекләп карап чыгу белән пароходны бик ошаттылар. Командасы да таралмаган икән.

— Пароход белән бергә хәрби флотилиягә безне дә алыгыз, Совет власте өчен бергә сугышырбыз,— дип теләк белдерделәр алар.

— Иптәш Лепетенко, менә бу «Мария» туташ синең «Сережа»ңа мөгаен әйбәт кәләш булыр,— диде комиссар.

Комиссарның бу сүзләрен бөтен команда хуплап каршылады. Кочегарлар берсен-берсе ашыктыра-ашыктыра казаннардан пар күтәртергә керештеләр.

Бераздан, «Мария» затоннан чыгып, форт-баржаны буксирга алгач, отряд тагын юлга кузгалды. Хәзер инде безне һични тоткарламый, куәтле буксир «Сережа»ны як-якка салулатмыйча, зур тизлектә җиңел тартып бара иде.

Шул ук көнне Иләт елгасы тамагы турыннан үтеп бераз барганнан соң, еракта Идел өстеннән ярдан-ярга сузылган челтәрле гигант корылма — тимер юл күпере күренә башлады. Елганың сул як ярында, күпердән бераз югарыдарак Паратск затоны. Аңда, тимер юл күпереннән түбәндәрәк — Зөя елгасы тамагында флотилиянең төп базасы. Нижний Новгородтан элегрәк җибәрелгән һәм Паратск эшчеләре коралландырган кораблар, истребитель катерлар, баркаслар — барсы да шунда. Аларның командалары отряд киләсен алдан белгән һәм махсус көтеп алган кебек, безне ихлас куанып, бердәм алкышлап каршыладылар.

Комиссар Маркин алгарак чыкты:

— Революция матрослары, туганнарым минем!..— диде ул, дулкынлы яңгыравык тавыш белән.— Гаять кыен шартларда бер карыш та чигенмичә, дошманга батырларча каршы торуыгыз, бик мөһим тимер юл күперен саклап калуыгыз өчен сезгә зур рәхмәт... Сез моңарчы бирешмәгәнсез икән, хәзер инде без бергәләп һөҗүмгә күчеп, ул контрларның арт сабакларын укыта башларбыз. Бөтен мөмкинлегебез бар. Моны бездән бөтен Совет иле көтә, иптәш Ленин көтә...

## VII

Комиссарның кешеләрне үзенә җәлеп итә торган тылсымлы көче бар сыман. Аның янында үзеңне ничектер акыллырак, көчлерәк хис итәсең. Шунлыктан без барыбыз да аңа якынрак торырга, приказларны җиренә җиткереп үтәргә тырышабыз.

Безнең отряд Нижний Новгородтан юлга чыкканчы ук аны, флотилиянең политкомиссары булуы өстенә, командующий ярдәмчесе итеп билгеләгәннәр икән. Зөядә бу хәбәрне ишетү күңелләргә хуш килде. Революциядән соң Совет ягына күчкән патша офицерларына күпләр шикләнеп караган бер вакытта, үзебезнең кеше — матрос комиссар Николай Маркинның командующий ярдәмчесе булуы төрле имеш-мимешләргә, анархист җаннарның котки таратып бугаз киерүләренә чик куйды. Зөягә килеп коры җир гаскәрләре штабы белән бәйләнешкә кергәч тә, без дошманга отпор бирә башладык һәм караңгы төннәрнең берсендә алгы позициягә — Морквашь култыгына күчеп, дошманны тагын да катырак кысрыкларга керештек. Моңарчы әледән-әле һөҗүм ясаган ак флотилия кораблары Югары Ослан тауларындагы туплар сагы астында тора башлады.

Бу уңышлардан отрядта хәтта башы әйләнүчеләр, хәзер инде бик борчылмаска мөмкин, акларның кикриген шиңдердек дип, гамьсезләнүчеләр, Зөягә, Морквашка чыкканда кәеф-сафага бирелүчеләр дә табылды. Николай Григорьевич бу чирне бик тиз сизеп алды һәм кораблар-ның командирларын, комиссарларын җыеп үткәргән оператив киңәшмәдә катгый чара күрергә кирәклеген әйтте.

— Тынычланырга һич тә урын юк, дошман көчле һәм мәкерле, разведка мәгълүматларын караганда, иртәгә зур һөҗүмгә әзерләнә,— диде.— Приказ шундый, иптәшләр, акларның һөҗүменә каршы алдан үзебез һөҗүм итәбез. Безгә кыюрак булырга, адмирал Старкның сатлык офицерларын тагын да катырак дөмбәсләргә вакыт... Озын сүзнең кыскасы шул, иптәшләр: корабларыгызга кайтыгыз да җыена башлагыз һәм, сигнал булу белән, яуга чыгарга әзер торыгыз.

Иртәгесен рубка өстендә торучы күзәтүче кинәт бөтен корабка ишетелерлек яңгыравык ачы тавыш белән:

— Югары Ослан ягыннан дошман кораблары менеп килә...— дип кычкырып җибәрде.

Мин аскы палубада камбузга утын ярып маташа идем. Безнең кок, үзе әйтүенә караганда, бөтен Мәкәрҗәгә данлы аш остасы булган мәзәкче Алимҗан, яңа пешкән ухасын комиссарга татытып чыкканнан соң, гадәтенчә, мактанырга гына керешкән иде. Сигналчы хәбәрен ишетү белән, кинәт теше сызлый башлагандай:

— Их, мур кыргырлары, бигрәк тә вакытсыз киләләр,— дип өстендәге ак халатын тиз генә салып атты.— Шундый шәп уха пешергән идем...

Корабта сугышчан тревога игълан ителүгә һәркем үз постына ашыкты. Мин менеп җиткәндә Николай Григорьевич инде рубкада, сигналчыаның, тизрәк походка кузгалырга, дигән приказын башка корабларга хәбәр итә башлаган иде. Шул арада, иске кителен төймәли-төймәли, лоцман Митрич та менеп житте һәм авыз эченнән генә нидер сөйләнә-сөйләнә чукынып алды. Тупчылар, пулеметчылар да үз постларына басты.

Түбәннән механик Кулик, һәрвакыттагыча көр тавыш белән, машина әзер, дип хәбәр итүгә, якорьны күтәрергә команда булды. Башка кораблар да бик тиз кузгалды.

Барыбызның да күз карашы алга, бер-бер артлы тезелешеп, Югары Ослан ягыннан агымга каршы менеп килүче дошман корабларына төбәлде. Башлап акларның иң көчле һәм тиз йөрешле корабларыннан берсе, тупларын безгә төзәгән «Ливадия» килә иде. Бүтәннәре аның торбасыннан бөркелеп чыккан куе төтен пәрдәсе аша начар күренә, дөресрәге, анда-санда караеп күләгәләре генә күзгә чалынып куя иде.

Ара әле шактый ерак булса да, «Ливадия» башлап туптан атып җибәрде. Аның беренче снаряды, безгә җилеп житәлмичә, ярты юлда суга төште һәм ул шартлаган урыннан өскә болганчык су баганасы бәреп чыкты. Ара якынайгач дошманның бүтән кораблары да дәррәү ут ачтылар.

Лоцман да, мин дә мондый хәтәр гарасатка гомердә беренче мәртәбә эләгүебез, якында гөрселдәп снаряд шартлаган саен ирексездән сискәнеп куябыз. Комиссар исә тыныч, бернигә исе китмәгәндәй ачык күперчеккә чыгып басты һәм алгы палубадан тупчыларның тынгысызлануын күзәтеп:

— Ашыкмагыз, вакыт житкәч үзем әйтермен,— дип рупордан кисәтеп куйды.— Карагыз аны, снарядлар чамалы, кабаланмыйча, төзәп кенә атарга тырышыгыз.

Ике ара тагын да якыная төшкәч, ул, тиз генә биноклен күзеннән алып, дошманның алгы корабына ут ачарга приказ бирде. Тупчылар

залп бирүгә, зилзилә купкандай, бөтен кораб селкенеп алды. Рубка каршында урнашкан Кармашов командасы да дүрт пулеметтан берьюлы атарга кереште.

Аклар соңгы көннәрдә чигенүләре өчен үч алырга уйлагандай, тупларыннан ата-ата, кыю рәвештә каршы килүен дәвам иттерә.

Сугышның иң кызган минутларында безнең алгы тупта ниндидер тоткарлык килеп чыкты. Ярый әле пулеметчылар өлгер, «Ливадия»дә һичкемгә баш калкытырга бирмиләр. Бигрәк тә Вишневский хәтәр ашкынып ата: аның тирәсендә палуба буш гильза һәм тасма белән тулы, кызган пулеметыннан пар чыга, маңгаеннан кара тир ага, ә үзе көйдергеч кургаш утын ярсып яудыра бирә.

Бераз вакыт үтүгә, алгы тупны да рәтләп өлгерделәр һәм дошман өстенә ашкынып ата башладылар. «Ливадия» белән безнең ара якынайганнан-якыная, аның рубкасында, алгы тубы янында кабаланучы кешеләре ачыграк күренә бара. Кара-каршы бәрелешмәс өчен, лоцман белән мин, сүз куешкандай, штурвалны чак кына сулгарак тотабыз. Николай Григорьевич моны күрү белән:

— Туп-туры тотыгыз,— диде һәм рупордан кисәтеп куйды: — Чигенмәсәләр абордажга [1] алабыз... Туганнар, атакага әзерләнегез...

Хәлбуки, эш абордажга барып җитмәде. Кораблар менә-менә кара каршы килеп бәрелешә дигәндә генә, «Ливадия» чыдамады, туры курстан кинәт сулга тайпылып, ашыгыч рәвештә кире чигенә башлады. Дошманның бүтән кораблары да,— барлыгы биш судно,— тиз генә борылып, аның артыннан иярде. Аларның берсенә ут капкан булса кирәк, койрык ягыннан бөркелеп-бөркелеп кара төтен, ялкын телләре чыга, ә икенче кораб бөтен корпусы белән уңга авышкан иде.

Без, кызып килгән шәпкә ур-ра кычкыра-кычкыра, аларны эзәрлекли киттек. Комендорларның инде снарядлары беткән булса да, пулеметчылар һәм безнең арттан килүче бүтән кораблардан әле һаман ярсып ата бирделәр.

Югары Осланга җитәрәк, биек тау өстеннән дошман батареялары безнең өскә котырынып ата башлагач кына, эзәрлекләүне туктатырга приказ бирелде. Тәмам кызган пулеметчылар гына болгавыр шаушуда приказны ишетми калдылар булса кирәк, әле һаман әсәрләнеп атуларын дәвам иттерәләр иде.

Батареялар уты астыннан чыгып кайту ягына борылгач, барыбыз да җиңел сулап куйдык һәм һәркайсыбыз ничектер ныгып, батыраеп киткәндәй булды. Николай Григорьевич сигнал белән бөтен отрядка рәхмәт белдерде.

Кок Алимҗан бәрелеш вакытында тупчыларга снарядлар бирүдә булышкан иде. Сугыш басылуга ул камбузына кереп, ак халатын киеп алды, буш кәстрүл төбенә шакый-шакый, кунакчыл тавыш белән:

— Әй, бөркетләр, ишетегез, тыңлагыз...— дип җырлагандай сузып җибәрде.— Миски, кашык алыгыз да уха ашарга килегез...

## VIII

Беркөнге каты бәрелештән соң ак флотилия кораблары Печищидан югары күтәрелмәс булды. Инициатива безнең кулга күчте, дошман көчләре урнашкан Югары Ослан рейдына, Казан пристаньнарына тагын да еш рак һәм көчлерәк һөҗүм итәргә керештек.

Тик шунысы бик сәер, һөҗүм киләсен алдан белгән кебек, дошман

[1] Абордаж — ишкәкле һәм җилкәнле флот заманында дошман кораблар бер-берсенә орынышып, кылыч, сөңге, мылтык кебек кораллары белән үзара сугышу алымы.

гел сизгер була һәм безнең отрядны тау өстендәге батареяларыннан ут ачып каршылый иде.

Эш болайга киткәч, бу хәлне ачыклау максаты белән, пулеметчылар старшинасы Кармашов командалыгында таулар арасына разведкага өч кешелек группа җибәрергә карар кылынды. Пулеметчы Вишневскийдан тыш, бу тирәләрне белгән кеше дип, отрядка мине дә билгеләделәр. Юлга чыгар алдыннан безгә бурычны комиссар үзе аңлатты:

— Кыя тауның елгага авыш кәрнизендә ниндидер шикле каралты бар, — диде ул, каршыдагы урманлы тау сыртына күрсәтеп. — Акларның күзәтү посты шунда түгел микән? Баягынак походтан кайтканда без аңа берничә залп та биргән идек... Сезнең бурыч — Печищи белән Морквааш арасындагы тау өсләрен айкап кайту. Артиллерия батареялары, күзәтү постлары кайда урнашканын белсәгез, шул җиткән.

Идел өстенә кичке караңгы иңгәч, безне көймә белән яр буена чыгарып куйдылар. Башта чуар ташлар өстеннән су буйлап Печищига таба бардык. Уң якта су читеннән үк күтәрелгән текә тау, өстенә уелып төшәргә торган кыя ташлар. Сулда, аяк астында, тынгысыз дулкыннар чалт-чалт ярга бәрелә. Бу тирәне мин шактый беләм. Әле былтыр гына Аракчино затонында кышлаганда ял көннәрендә Морквааш урманына еш кына ауга чыккалый идем.

Яхшы хәтерлим, Печищига җитәрәк, тау арасында уелмалы тирән тарлавык бар. Без шуннан ары бармаска булдык, тиз генә киңәшеп алганнан соң, шул тарлавыктан тау арасына кереп киттек.

Куе чытырманлы һәм чокыр-чакырлы тарлавык эчендә күзгә төртсәң күренмәслек дөм караңгы иде. Мылтыгымны кысып тоткан хәлдә, иелә-бөгелә берничә адым атлауга, мин ниндидер түмгәккә абынып, чүт егылмадым, башымнан фуражкам төшеп китте. Валя Вишневский герман сугышында дошман тылына күп йөргән разведчик, минем тәҗрибәсезлегемне абайлап, шыпырт кына:

— Фуражкаң төшмәсен өчен каешын ияк астыннан эләктер, — диде, — караңгыда күз кырые беләнрәк карап барырга тырыш.

Шулай эшләүнең чыннан да бераз файдасы тиде, ахры, тирә-юньдә агач кәүсәләре ачыграк күренә башлаган кебек булды. Аннары күз дә караңгыга ияләшә төште бугай, моннан соң инде мин бүтән абынмыйсөртенми бара башладым.

Ниһаять, караңгы тарлавык түбәндә калды, без тауга менеп җиттек. Агачлык бетте, урылган арыш басуы башланды.

Урман кырыеннан ярты чакрым чамасы үтәргә өлгермәдек, башлап баручы Кармашов кинәт нәрсәгәдер абынып, алга чайкалып китте һәм ачулы мыгырданды:

— Тфу, шайтан алгыры, чүт мәтәлмәдем.

— Телефон чыбыгы ич бу! — диде Вишневский, куе үлән арасыннан кабельне табып алып.

Телефон чыбыгы урман буеннан сузылган иде. Җентекләбрәк карагач, абага, нарат үләне каплаган юлда көпчәк, дага эзләре дә күренде. Урман эченнән төнге тынлыкны бозып, кайдадыр якында гына ат кешнәгәне ишетелде.

Шул юл белән тагын бераз баргач, без кечерәк кенә ачыклыкка килеп чыктык. Ай яктысында балкыган түгәрәк аланда атлар төркеме тыныч кына утлап йөри, алардан арырак, куаклык күләгәсендә көпшәләре белән Иделгә таба төбәлгән көпчәкле туплар тора иде.

— Берәү, икәү... Әһә... барлыгы өчәү икән.

— Әнә тагын берсе, башкаларыннан сулдарак аерым тора, — дип өстәде Вишневский. — Монда, брат, тулы бер батарея. Кара син аларны, нинди шәп урнашканнар, тиз генә күрерлек тә түгел үзләрен.

Туплар янында иңенә мылтык аскан сакчы ашыкмый гына арлы-бирле йөренә иде. Тышауланган озын торыклы бер ат, кетерт-кетерт үлән чемченә-чемченә, без поскан куаклыкка якын ук килде һәм, чит кешеләр барын хәбәр иткәндәй, шомлы пошкырып җибәрде. Туплар янындагы сакчы сискәнеп, әйләнә-тирәгә борчулы каранып алды да таралышкан атларны алан уртасына куалап җыя башлады.

— Ярар, күрдек, белдек,— диде Қармашов.— Хәзер инде шыпырт кына ычкынырга кирәк. Болар монда, берни дә булмаган кебек, рәхәтләнеп черем итә бирсеннәр.

Яңадан урман читенә чыктык. Таң якынлашып килә, үләнгә мул булып салкын чык төшкән. Вакыт тар, ашыгырга, бу тирәдән хәвеф-хәтәрсез тизрәк ычкынырга кирәк. Безнең алда тагын бер мөһим бурыч — яктырганчы комиссар әйткән теге шикле каралтыны күрәсебеләсе бар бит әле.

Куе үлән ерып барганда тагын баягы телефон чыбыгына юлыктык. Чыбыкның икенче очы безне Иделгә караган биек тау сыртына алып чыкты.

Қаралты дигәне еракта түгел, сирәк наратлы сыртның елга ягындагы кәрнизенә җай гына урнашкан. Элек ул, мөгаен, берәр байның яки түрәнең җәйге дачасы булгандыр. Хәзер анда акларның күзәтү посты булуы бик ихтимал: моннан торып безнең корабларның Морквагн култыгыннан походка чыгуын уч төбендәге шикелле ачык күрергә һәм ул хакта алдан ук хәбәр итеп өлгерергә тулы мөмкинлек бар.

Дача йортында ул-бу күренми. Текә тау кырыендагы ике катлы бу өйнең тәрәзәләре һәм балкон ишеге төбенә тикле ачык: болдырында әллә үле, әллә исерек шунда, кулларын як-якка ташлап ниндидер бер гәүдә чалкан ята. Агач арасыннан беравык карап торганнан соң, Қармашов акрын гына:

— Менә болай итик,— диде.— Васил белән мин төшеп анда ни барын беләбез. Ә син, Всеволод, шунда кал, яшерен засада фәлән була калса, безгә ярдәмгә әзер тор.

Агачлар арасыннан шыпырт кына төшеп өйнең аскы тәрәзәләреннән карадык, бер җан иясе дә күренмәгәч, эчкә сикереп кереп, тиз генә бөтен бүлмәләрне йөреп чыктык. Кичә безнең тупчылар залпы нәтиҗәсе булса кирәк, өйнең бер почмагы һәм верандасы җимерелгән, балконнан өзек телефон чыбыгы салынып төшкән. Болдырдагы җансыз гәүдәдән тыш, балкон идәнендә тагын ике үле солдат ята иде.

Барыбыз да бергә җыелгач, бөтен өй эчен тагын бер мәртәбә карап чыктык — акларның монда күзәтү пункты булганлыгы ап-ачык иде. Өске катта балконга чыга торган зур бүлмәнең бер почмагында идән тулы китап аунап ята. Барысының да тышына көмеш хәрефләр белән «Энциклопедия» дип язылган. Қармашов аларның бер-икесен актарып караганнан соң:

— Беразын алыйк әле, матросларга укырга булыр,— диде һәм, каяндыр бау табып, бер өем китапны аркылы-торкылы бәйләргә кереште.

Вишневский күрше бүлмәдән зур торбалы граммофон, бер тартма тәлинкә күтәреп керде.

— Төзек, әйбәт эшли, — диде ул, шатланып.— Боларны да алып кайтабыз... Ял сәгатьләрендә музыка тыңлау безнең братка да хәрам булмас...

Әнә шулай көр күңел белән ганимәтләрне күтәргән хәлдә без Морквагн култыгына кайтып кергәндә, кояш инде шактый күтәрелгән, корабларда иртәнге хәрәкәт башланган иде. Безнең «Ваня» боцманы Поляков, бер төркем матрослар белән, яр буенда учак ягып, көймә сумалалый иде. Безне күрүгә, алар, эшләреннән туктап, граммофонны карарга, кызыксынып, сораштырырга керештеләр. Мачта кебек

озын буйлы матрос Прокофьев, сүзгә катнашмыйча, кайнар сумала казаны янында маташкан җиреннән:

— Бездә әнә ничек бит,— дип зарлана башлады.— Кичә бүрек хәтле дуңгыз баласы алып кайткан өчен комиссар мине бөтен команда алдында эт итеп сүкте, ә үзенең ышанычлы активистлары әнә күпме төягән...

— Тукта әле, син үзеңне безнең белән тиңләштермә,— һәрвакыт сабыр холыклы Кармашов кинәт кабынып китте.— Бөтен авыл күз алдында бичара карчыкның бердәнбер дуңгыз баласын талап алган өчен син туймас корсакны судка бирергә кирәк иде. Ә без боларны буржуй дачасыннан конфискацияләп алдык. Үзебезгә түгел, судовой комитетка, бөтен командага бит бу.

Комиссар Маркин кораб рубкасыннан без кайтканны күреп торган икән. Яр буенда чәкәләшү башлангач, ул капитан басмасына чыгып, ризасызлык белән рупордан:

— Кармашов, нинди базар ачтыгыз анда?! — дип кычкырды.

Без, ни әйтергә белмичә, аптырап калдык. Кармашов җавап эзләгәндәй, бер миңа, бер Вишневскийга борчулы карап алганнан соң, ыкмык итеп акланырга тотынды:

— Китаплар бу, Николай Григорьевич... Әйе, энциклопедия томнары. Тегендә, дачада аунап яталар иде. Командага укырга булыр дип алып кайттык.

— Иптәш комиссар, бу граммофонны да шуннан, — дип Вишневский да сүзгә кушылды.

— Кармашов, китапларың белән әйдә корабка кер, ниләр белеп кайтканыңны сөйлә. Ә граммофонның кирәге юк. Андый нәрсәне монда күземә күрсәтмәгез.

Бик жәл булса да, безгә һичсүзсез буйсынырга, бөтен команда алдында граммофонны, тәлинкәләре-ние белән урманга кертеп ташларга туры килде. Шуның белән үзебез дә ничектер җиңеләеп, пакьланып калган кебек булдык.

Бу көнне отряд төнлә без күреп кайткан аклар батареясының көлен күккә очырды, дошманны отыры кысрыклап, Югары Осланга, Казанка елгасы тамагына хәтле тоткарсыз төшәргә мөмкинлек яулап алынды.

## IX

Сугыш дәвамында Кызыл флотилия көннән-көн көчәя, чыныга бара. Балтикадан Ленин фәрманы белән ашыгыч рәвештә җибәрелгән өч эсминец килеп кушылганнан соң, флотилия тагын да куәтләнде.

Шундый көннәрнең берсендә флотилия базасында бик чибәр бер яшь хатын күзгә еш чалына башлады. Үзе коры җир гаскәриләрчә киенгән: нәзек билендә киң сары каеш, кобурасы да бар. Ә беркөнне мин аны пристаньда бөтенләй бүтән кыяфәттә күрдем. Ул ак ефәк күлмәктән иде. Колакларында асыл ташлы алкалар җемелди, коңгырт чәчен матур итеп артка яткырып тараган. Ханым, кичке уенга чыккан яшь кыз кебек, бер диңгезче командир белән бик күңелле итеп кәләкәлә сөйләшеп тора иде.

Баштарак корабларда аның турында төрле сүзләр йөрде. Ул моннан ерак түгел Зөядә урнашкан армия штабында разведка комиссары һәм шул ук вакытта Мәскәү газеталарына сугыш турында хәбәрләр язып торучы, имеш. Ул флотилия командующиеның хатыны, имеш. Минем белән бер вахтада торучы сигналчы Прокофьев исә, бик белдекле кыяфәт белән, агач авызланып: «Бернинди комиссар да, хәбәрче дә түгел, командующийның сөяркәсе ул», — диде.

Ә ханым бу шикле карашларны, гайбәтләрне бөтенләй сизмәгәндәй, үзен горур тотып йөри бирде. Соңгы көннәрдә ул матросларның хезмәттән буш сәгатьләрендә корабларга килеп, сыйнфый көрәш тарихы, большевиклар партиясе, Совет власте турында лекцияләр укый башлады.

Берсендә башка фронтлардагы хәлләр турында тыңлаганнан соң, арадан бер акыллы баш иң алгы рәттә утырган жиреннән:

— Сез үзегез кем соң? — дип сорау бирде.

Сорау бирүче иң әүвәл үзе шаркылдап көлеп җибәрде. Ләкин аңар иярүче табылмады, киресенчә, аның өчен барыбыз да бик уңайсызланып калдык. Минем янда утырган Алимҗан түзмәде:

— Әй, сакаллы сабый, тозсызланма... — дип тегенең авызын каплады.

Башкалар да төрле яктан шелтәле сүзләр яудыра башладылар. Докладчы ханым үзе берни дә булмагандай сабыр гына:

— Шауламагыз, иптәшләр, фронт хәлләренә катнашы булмаса да, бу сорауны да җавапсыз калдырмыйк,— диде ул мәгънәле елмаеп.— Иптәш минем семья тормышымны бик белергә тели икән, әйтеп бирим: флотилия командующие — минем ирем. Мин үзем штабта хезмәт итәм, сезнең хакта газеталарга хәбәрләр, очерклар язам.

Тагын берничә көннән безнең «Ваня» корабыннан бер төркем матросларга, тиз йөрешле катерга утырып, таң белән ашыгыч разведкага барырга боерык булган иде. Тик шунысы сәер, гадәттә, мондый хәтәр походларга без төнгә каршы чыга торган идек, ә бу юлы алай итмәделәр. Отрядка заданиены бүген дә комиссар үзе бирде:

— Туганнар, сезгә ышаренмичә, ачыктан-ачык барырга туры киләчәк,— диде ул.— Максат шул: үз өстегезгә ут ачтырып, ничек тә дошманның артиллерия позицияләрен билгеләргә кирәк.

Катер юлга чыгарга торганда гына, яр буеннан чаптар атта теге ханым килеп чыкты һәм сыгылмалы такта траптан кызу-кызу атлап менгән шәпкә кычкырып җибәрде:

— Туктагыз, кузгалмый торыгыз әле... Көчкә килеп өлгердем... Иптәшләр, мин дә сезнең белән барам.

Бу юлы ул яшькелт гимнастерка, кызыл йолдызлы фуражка кигән, күн планшет аскан; битләре алсуланган бу мөлаем хатыннан үзенә җәлеп иттергеч нәфислек тә, кыюлык та бөркелеп тора иде.

Безнең арада эленке-салынкырак киенгән кайбер матрослар уңайсызланып, тиз генә бил каешларын рәтләп, төзәтенеп алдылар. Комиссар Маркин исә ханымның юлын бүлде:

— Юк, иптәш Рейснер, һич тә рөхсәтем юк. Поход хәтәр булачак, ярамый.

— Беләм, Николай Григорьевич, хәтәр булганга, дөресрәге, дошманның Ослан тауларындагы ут позицияләрен төгәл белү армия штабына бик кирәк булганга күрә барам,— диде Лариса Михайловна, сүз көрәштерергә урын калдырмаслык итеп.— Сез онытмагыз: мин армия штабының разведка комиссары да ич әле.

Эш болайга киткәч, Николай Григорьевич артык сүз куертып тормады, Лариса Михайловна читтәрәк торган арада, катер командирын каты кисәтеп куйды:

— Кара аны, дошман ут ачкан минутларда Лариса Михайловнаны кубрикка төшерергә тырышыгыз.

Яр буеннан кузгалып китүгә катер командиры миңа штурвалны агым уңаена борырга команда бирде. Лариса Михайловна иңендәге планшетын салып, рубка каршындагы эскәмиягә куйды, бинокльдән уң яктагы биек тауларга карап бара башлады. Миннән сулдарак, ачык тәрәзә буенда басып торган сигналчы Прокофьев:

— Бу комиссар хатынны әйтәм, чибәр бит, шайтан, күңел аздыргыч,— дип авыз чайкарга тотынды.— Бернидән курыкмый, янәсе, ачык палубада кукраеп тора... Менә ут яудыра башласыннар әле, күрербез, шунда ничек кыланыр икән.

— Сигналчы Прокофьев,— диде катер командиры аның сүзен бүлеп.— Юкны лыкылдаганчы, үз вазифаңны белеп, яхшырак күзәт.

Катер зур тизлек белән баруын дәвам иттерде. Алда, елганың сөзәк ярында Казан каласы пәйда булды. Хәзер анда акгвардиячеләр, фетнәче чехлар хакимлек итә.

Катер Югары Ослан пристане турына җитте. Лариса Михайловна, бинокльдән аерылып, катер командирына курсны ярга таба якынрак тотарга кулы белән ишарә ясады. Аклар әле һаман ут ачмагач, борчылу белән:

— Болай ярамый, мачтага тизрәк кызыл флаг күтәрик, кем килгәнен күрсеннәр...— диде.— Вакытны бүтән сузарга мөмкин түгел, ата башларга кирәк.

Ихтимал, дошман башта катерны чыннан да танымагандыр, үз судноларыннан берсе дип уйлагандыр. Һәрхәлдә, бер мәл никтер ут ачмадылар. Тик бераздан, без яр буендагы баржаларга туптан атып җибәргәч кенә, ниһаять, абайлап алдылар һәм бөтен тирә-юньне гөрселдәтеп, берничә урыннан берьюлы дәррәү атарга тотындылар.

Күзәтүчеләр шундук үз эшләренә кереште. Ә Лариса Михайловна яңа ноктадан ут күренгән саен, төтен катнаш очкын бәреп чыккан һәр позицияне үз картасына төшерә барды.

Тиздән дошман тупчылары безне прицелга алды, әйләнә-тирәдә сикереп-сикереп су кайный. Снарядлар якында гына төшеп шартлаган саен, катер әле уңга, әле сулга янтаеп ала, рульгә буйсынмыйча, читкә чалулый. Сигналчы Прокофьев авыз эченнән нидер сөйләнә-сөйләнә тиз генә чукынып алды. Катер командиры ут астыннан тизрәк чыгар өчен рульне сулга борырга, машинаны бар куәтенә эшләтергә боерык бирде. Шул чакны инде өс-башы манма су булып чыланган Лариса Михайловна, эшеннән бүленеп, аңа каршы төште:

— Борылырга ашыкмагыз... Пристаньнан түбәндәрәк тә ут ноктальары юк микән, белик әле,— дип яр буеннан ерагаймыйча, шул курс белән баруны дәвам иттерергә әйдәде.

Бу кыю ниятка бер мин генә түгел, башкалар да таң калды. Комиссар хатынны башта санга сукмаган чая, үтә гайрәтле егетләр дә, үз күзләренә ышанмыйча, бер-берсенә аптыраулы карашып алдылар. Нык кына каушап калган сигналчы Прокофьев та комиссар үрнәгендә үзен кулга алырга, шүрләвен җиңеп кыюрак булырга тырышты.

Дошман тупчыларының ачуы кузгалды булса кирәк, тагын да ашыгыбрак ата, катер тирәсендә су баганалары һаман саен ешрак бәреп чыга башлады; түбәнтен генә очып үткән бер снаряд мачтаны, төптән кискәндәй итеп, сындырып китте. Лариса Михайловна дошманның яңа ачылган ут нокталарын картасына терки бара бирде.

Тик бераздан, Югары Ослан авылы турыннан үтеп, Маркиз атавына җитәрәк кенә, ул күзеннән биноклен алды:

— Җитте, булды бугай... Инде бу тәмуг төбеннән тизрәк ычкынырга кирәк...— диде һәм картасын планшетына салып куйды.— Молодцы, иптәшләр!.. Курку белмәс батыр егетләр, чын мәгънәсендә революцион матрослар икәнсез!

Катер хәвефле урыннан чыгып, кайту ягына борылгач, Лариса Михайловна тагын да ачылып китте һәм тирләгән битләрен кулъяулыгы белән сөртә-сөртә:

— Диңгезчеләр — батыр йөрәкле, тапкыр халык, аларны диңгез чыныктыра... Әгәр хатын-кызларны алсалар, мин үзем дә, бик теләп,

диңгезче булыр идем, — дип матур иреннәре арасыннан ак тешләрен җемелдәтеп елмаеп куйды.

Аның елмаюы башкаларга да күчте, рубка эче җанланып китте.

Соңрак безнең бу хәтәр поход, үзенә бер төрле риваять кебек, телдән телгә күчеп, тиз арада барлык корабларга һәм Зөя тирәсендә урнашкан коры җир гаскәрләренә мәгълүм булды. Һәм шуның белән матрослар арасында Лариса Михайловна Рейснерны читсенү, аның турында чәнечкеле сөйләүләр, ирониялe көлүләр дә бетте. Хәтта иң дорфа матрослар да аңа, иптәш комиссар дип, олылап эндәшергә күнектеләр. Үзе юкта аның турында сүз чыкса, безнең Лариса Михайловна дип ихтирам белән телгә ала башладылар.

## X

Безнең отряд бирегә әле кичә генә килеп төшкән кебек иде. Бактың исә, инде өч атна үтеп тә өлгергән.

Шул вакыт эчендә без су өстендә көн-төн туктаусыз дәвам иткән хәтәр походлар, каты бәрелешләр нәтиҗәсендә ак адмирал Старк флотилиясенең төп көчләрен Түбән Осланга чигенергә мәҗбүр иттек. Югары Осланнан дошманның коры җир гаскәрләре дә бәреп чыгарылгач, Идел ягыннан Казанны штурмларга юл ачылды.

Унынчы сентябрьгә каршы төндә коры җир гаскәрләре белән бергә флотилиядә дә хәлиткеч штурмга кызу әзерлек барды. Безнең «Ваня»га төнге тынлыкта кораллы десант отряды төялде. Болар Балтика матрослары, Паратск затоны эшчеләре, күптән түгел генә яуда һәлак булган «Дельфин» һәм «Ташкент» командалары — барысы да утлар-сулар кичкән, каты бәрелешләрдә сыналган ышанычлы сугышчылар иде.

Инде барысы да төялеп, кайсы-кая урнашып беткәч, таң алдыннан штабтан командующий ярдәмчесе комиссар Маркин кайтып керде. Десантчылар тулы палубаны үтеп өске катка менү белән:

— Туганнар, дуслар!..— дип эндәште ул.— Ниһаять, хәлиткеч тарихи сәгатьләр якынаеп килә, Казанны штурмлый башлыйбыз. Моңарчы һәрчак авангардта булган «Ваня» командасы һәм аңа төялгән десантчылар отряды бу юлы да сынатмас, бүген дә бүтән корабларга батырлык һәм революцион аңлылык, тәртип үрнәге күрсәтерләр дип ышанам...

Таң атканда флотилиянең төп көчләре ике отрядка бүленеп, шаушусыз гына юлга чыкты. Бер удар отряд елганың сул як яры буйлап китеп барды һәм, Аракчино, Дубки турыларыннан үтеп, Казанка елгасы тамагына җитәрәк Кремльгә, Аргы тамакка ут ачты. Эре калибрлы туплар тавышыннан бөтен әйләнә-тирә, баш очында гына күк күкрәгәндәй, өзлексез гөрселди башлады. Пристаньнар ягында ялкын телләре күтәрелде.

Десантчы диңгезчеләр һәм Петроград марш батальонын төягән икенче колонна, безнең «Ваня» артыннан тезелеп, Ослан таулары ягыннан юл тотты һәм иртәнге томан пәрдәсе астында шәһәр турыннан хәвеф-хәтәрсез үтеп өлгерде. Кремль һәм Елан тавындагы дошман тупчылары бу маневрны сизеп ут ача башлаганда отряд инде Аргы тамакка төшеп җиткән иде.

Безнең «Ваня» туп һәм пулеметлардан ата-ата элекке «Кавказ һәм Меркурий» ширкәте пристанена беренче булып бәреп керде. «Добрый», «Ольга», «Коновод» кораблары да берьюлы диярлек «Самолет» причалларына килеп туктады. Без дәррәү причалга ташландык һәм коты очкан акларны яр өстендәге повозкалар арасыннан эзәрлекли киттек.

Иң алдан наганын болгый-болгый комиссар Маркин әйдәп бара. Дошманга борылып карарга да ирек бирмәс өчен гранаталар ыргыта-ыргыта алга ыргылабыз. Чигенгән чакта аклар ташлап калдырган ватык туплар, арбалар, ат үләксәләре юл өстендә аунап кала. Бакалтай ягында офыкны кара төтен белән каплап, нефть баклары, амбарлар яна...

Аргы тамак белән бистә арасында җәй көннәрендә яртылаш кибә торган кечерәк кенә Ички елгасы бар. Моңарчы бик җитез элдерткән дошман шунда житкәч, кинәт туктады, тәбәнәк яр артына ышыкланып, каршылык күрсәтә башлады. Комиссар отрядка җиргә ятарга кушты һәм кемнәргәдер кулы белән елгага таба ишарә ясады. Шунда мин үземнән сулдарак пулеметчылар командасыннан Кармашов белән Вишневский һәм Алимҗанның, пластуннарча җиргә ятып, юл читендәге куе үлән арасыннан алга шуышканын күрдем. Күп тә үтмәде, елгага җитәргә унбиш-егерме адым каларак, алар өчесе дә берьюлы диярлек селтәнеп, яр астына граната тондырдылар. Гөрселдәп шартлау тынуга без ур-ра кычкыра-кычкыра тагын атакага ташландык.

Бистәгә барып керү белән урам сугышлары кабынып китте. Зур мәйдан уртасындагы кызыл чиркәү тәрәзәсеннән пулемет ут яудыра башлагач, без тагын җиргә ятарга, каралты артларына посарга мәҗбүр булдык. Якындагы өй почмагына ышыкланган комиссар, кулы белән ишарә ясап, аннан чиркәүгә таба күрсәтте.

— Аңлашыла,— диде Вишневский.

Койма тактасын каерып тиз генә бакчага кердек тә, чия, алмагачлар арасыннан иелә-сыгыла әчкәре китеп бардык.

Башта без чиркәү эчендә бер-ике пулеметчы гына бардыр дип уйлаган идек. Хәзер исә, яртылай ачык авыр тимер ишектән шау-шусыз гына барып керсәк, дошманның биредә бөтен бер оборона пункты булуын күрдек.

Ярым караңгы чиркәүнең сул як стенасы буена снаряд каплары өелгән. Парадный ишек янында бер төркем солдат ашыга-ашыга лафетлы тупны каршыдагы мәйданга таба борып маташа иде. Шулардан уңдарак тышка караган рәшәткәле тәрәзә аша чандыр гына бер солдат пулеметтан ут яудыра; кара сакаллы поп аңа патронлы лента биреп тора иде. Башлап безне шул поп күрде.

Әмма ул авызын ачып кычкырганчы, Вишневский граната ыргытып өлгерде. Без дә гранаталарыбызны тупчылар өстенә тондырып, тиз генә ишек артына ышыкландык.

Урамда безнекеләр дәррәү күтәрелеп тагын алга ыргылдылар. Без куып җиткәндә, отряд, бистәне үтеп, дошманны эзәрлекли-эзәрлекли, дамбага ук кергән иде.

Шунда безне атлы кызыл гаскәрләр куып җитте һәм кылычларын һавада уйната-уйната дошманның Лаеш юлына таба чигенә башлаган көчләрен эзәрлекли китте.

Шәһәр үзәгенә без беренчеләрдән булып кердек. Менә, ниһаять, мин туган-үскән шәһәрем Казанда! Яз башыннан бирле күрмәгән, өзелеп сагынган таныш урамнардан узабыз. Дошманның Кремльгә кереп бикләнгән бер өере әле һаман каршылык күрсәтә, шул яктан көчле атышлар ишетелә иде. Бөтен отряд белән без дә шунда ашыктык һәм коры җир гаскәрләре белән бергә Кремльне штурмлауда катнаштык.

Һәр яктан утлы боҗра белән камалган дошман калдыклары моннан соң инде озак каршылык күрсәтә алмады. Айдан артык газап чиккән Казан каласы ак бандитлардан тулысынча азат ителде. Шундук шәһәр урамнары, мәйданнар халык белән тулды, тантаналы митинглар башланып китте.

Пристаньга төшеп җитәрәк, Бишбалта аша үткәндә кемнеңдер көчсез калтыравык тавыш белән:

— Васил-л!.. Әй, Васил энем, бер генә минутка туктачы,— дип миңа кычкырганын ишеттем һәм тротуар тулы халык арасында якын танышым Сөләйман абзыйның кул изәп торганын күрдем.

Бу минутта безнең боцман миннән байтак алда, колоннаның башында бара иде. Аннан сорамыйча сафтан чыгарга базмадым, мөмкин түгел иде, сафта барган шәпкә:

— Хәзер түгел, Сөләйман абзый... кичен... кичкырын килергә тырышырмын,— дип әйтергә өлгердем.

...Бөтен шәһәрдә, бистәләрдә гөрләгән халык тантанасы пристаньны да үз эченә алган: дебаркадер, пароход мачталарында байраклар җилферди, һәркемнең йөзендә шатлык. Моңарчы таныш түгел кешеләр, якын туганнар кебек кочаклашып, бер-берсен олы җиңү белән тәбрик итә иде.

Беренче булып пристаньга десант төшергән һәм шәһәргә башлап кергән өчен безнең команда Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты Кызыл Байрагы белән бүләкләнде.

Николай Григорьевич:

— Иптәшләр, бу җиңүләрдән соң мин корабыбызны «Ваня-коммунист» дип атарга киңәш итәм,— диде.— Аның командасы бүген чын батырларча, коммунистларча сугышты. Бу мактаулы исемне алар киләчәктә дә аклар дип ышанам.

Яңа исем барыбызның да күңеленә хуш килде. Кичен боцман Поляков корабның бортларына һәм коткару бөятләренә зур хәрефләр белән «Ваня-коммунист» дип язып та куйды.

## XI

Җиңү тантанасы арасында, күңелләргә авыр кайгы салып, дошманнарның шәһәрдә кылган кара эшләре, коточкыч ерткычлыклары калкып чыга башлады; партия, совет оешмалары җитәкчеләрен, яңа властька турылыклы бик күпләрне судсыз-тикшерүсез явызларча газаплап үтерүләре мәгълүм булды. Канлы террор корбаннары арасында минем белән бергә эшләгән елгачылар да бар иде. Минем якыннарым Миңзифа белән Исхак абый да әле һаман күренми, аларның бәлагә таруы бик ихтимал. Болай сузарга ярамый. Флотилия Казанда торган арада, аларны ничек тә эзләп табып, хәлләрен белергә кирәк.

Мин әнә шундый карарга килдем. Митингтан соң тиз генә кырындым, юындым да, Бишбалтага барып кайтырга ният кылдым. Алимҗан минем кая җыенуымны белү белән:

— Юк, Васил дус, хәрби диңгезче сөйгән кызы янына болай барырга тиеш түгел. Мә, менә моны үлчәп бак әле,— дип үзенең рәешкә кия торган кайтарма якалы, ачык изүле ак күлмәген бирде. Зәңгәр якалы ак матроскадан тыш, миңа тагын рәтлерәк бескозырка, җиз якорьлы киң каеш та бирделәр, каяндыр табып алып, ирексезләп диярлек, хәтта одеколон да сиптерттеләр. Ниһаять, киенеп бетеп, көзгегә карагач, үзем дә хәйран калдым: нәкъ хәрби диңгезче кыяфәтенә кергәнмен ләбаса.

Мәкәрҗә ярминкәсендә Миңзифага бүләккә дип сатып алган зәңгәр чәчәкле бик матур ефәк яулыгым бар иде. Шуны төреп култык астына кыстырдым да корабтан чыгып киттем.

Көндез шәһәрдән кайтканда урамда миңа кычкырган Сөләйман агай Бишбалтаның Кул буе урамында, кечкенә-кечкенә ике тәрәзәсе Бакалтай ягына караган тәбәнәк кенә өйдә тора. Башта мин шул карт янына кереп белешергә булдым.

Хәзер монда кая карама, иртәнге сугыш эзе: снаряд шартлаган тирән-тирән чокырлар, каерып ташланган рельслар, җимерек повоз-

калар аяныч хәлдә аунап ята. Казанка елгасы дугайланып борылган урында зур ябалдашлы куш өянке генә бәла-казага аптырап калгандай, тып-тын утыра иде.

Миңа бик таныш һәм кадерле хатирәләр белән бәйле өянке бу. Соңгы мәртәбә мин монда быел апрель азагында, безнең «Сирень» затоннан чыккан көнне булдым. Беренче рейска китәр алдыннан пристаньда грузчиклар пароходка йөк төйи иде. Һәркем шат, иртәгә булачак Беренче май бәйрәменә хәзерлек белән мәшгуль; бөтен пароходта бер мин генә төшенке күңелле, иртәгә рейска Миңзифаны күрмичә китәм дип борчылып йөри идем.

Үткән кышны, Зифа шәһәрдә медицина курсларында укый башлаганнан бирле, аның белән без сирәк очраштык. Шулай да Иделдә боз киткәч, навигация ачыласы көнне әтисен юлга озату сылтавы белән ул ничек тә затонга кайтып китәр кебек хәбәр иткән иде. Әмма никтер кайтмады, минем өметләнеп көтүләрем коры хыял гына булып калды, күрәсең.

Шул чак Зифаның әтисе Исхак абый мине палубада очратып:

— Вәсил, сиңа бер йомыш бар,— диде.— Тиздән Бирге тамактагы паром пристанена Миңзифа килеп житәргә тиеш. Авырсынмасаң, көймә белән барып, син аны пароходка алып кайтчы.

— Шулаймы, килергә тиешме?

— Берәр тоткарлык-фәлән килеп чыкмаса, сәгать биш белән алты арасында шунда көтәр күк әйткән иде... Укып бетергәч, безнең пароходка доктор итеп жибәргәннәр бит...

Башта мин пристань көймәсе белән генә китмәкче идем. Ниятемне безнең боцман Габдуллин бүлде.

— Доктор кешене андый әҗәл тагарагында алып кайту килешмәс, әнә үзебезнең көймә белән бар.

Һәм мин, тиз генә җыенып, юлга чыгып киттем.

Язгы Идел, ярларыннан ашып, әллә кайларга җәелгән. Аргы тамак белән бистә арасын су баскан чак иде. Ике ишкәкле җиңел көймәдә шул араны тиз үткән кебек булсам да, бераз соңга калдым, әйткән вакытка барып өлгерә алмадым.

Мин Бишбалтага барып җиткәндә, Зифа инде шунда, паром басмасында иде. Кулында җыйнак кына кәрзин. Кыска юбка, зәңгәр кофта кигән. Куе коңгырт чәче, кызыл өрпәк астыннан чыгып, иңнәренә сибелгән. Әйтеп бетергесез матур, сөйкемле иде ул, су өстендәге ишле көймәләр арасыннан Миңзифа башта мине танымады. Басма кырыена килеп җитәрәк, якыннан эндәшкәч кенә:

— И, күрми дә торам... Син килгәнсең икән, бик әйбәт,— дип гаҗәпләнде һәм, көймәнең ярга килеп терәлгәнен дә көтмичә, кәрзинен миңа сузды, аннары үзе көймәгә сикереп төште.

— Зифа, сине укып кайтуың белән тәбрик итәм,— дидем.— Ярый әле безнең пароходка җибәргәннәр. Күрмичә китәм дип, борчыла башлаган идем.

— Бөтенләй онытып бетермәгәнсең икән әле...

— Исхак абый әйтү белән, пароходларны узардай булып, жанфәрманга ашыктым. Юлда килгәндә башыма уй төште: Зифа хәзер зур кеше — доктор булган, ай-һай бу кызый минем ише гидайны санга сугар микән?..

Мин моны үземчә шаяртып, мәзәк өчен генә әйткән идем. Миңзифаның шуңа хәтере кала язды.

— Менә нәрсә, гидай дус, мин доктор түгел, кыска сроклы курста укыган фельдшер гына. Мине үз итсәң, якын күрсәң, алай уйлама.

— Бетте, жаным, бетте, зинһар гафу ит... Бүтән беркайчан алай әйтмәм.

Зифа, койрык яктан минем яныма күчеп, сул як ишкәкне кулына алды.

Парлап ишә башлагач, көймә агым уңаена тагын да җәһәтрәк бара башлады. Тиздән без пар өянке янына килеп җиттек. Куе тармакларын як-якка киң җәйгән пар өянке ташкын уртасында горур тора, аның болытсыман каралҗым шәүләсе агым су өстендә чайкала иде.

— Вәсил, карале, нинди матур өянке... Әйдә бор, туктап бераз гына торыйк әле.

Көймәне борып, өянкенең аскы ботагына тотындым. Миңзифа исә, башын күтәреп югары караган хәлдә:

— Күр син бер-берсенә ничек елышып үскәннәр, каты җил-давылларда бер-берсен ышыклагандай янәшә торалар,— дип үзе дә миңа сыенды һәм, кочаклап, битемнән үпте. Мин дә аны кочаклап, битләрен, кайнар иреннәрен тәкатьсез шашынып үбә башладым.

Миңзифа мине бар көченә этәреп, тиз генә койрык якка күчеп утырды, үз күзенә үзе ышанмагандай, бер мәл шаккатып карап торды.

Шулай итеп бер-беребезгә карамыйча, бөтенләй чит-ят кешеләр кебек, бер кәлимә сүз катмыйча кузгалып киттек һәм пароходка шактый соңарып, кичке эңгер-меңгердә генә кайтып кердек. Кеше-кара күзенә чалынмас өчен басма янына күләгә яктан гына килеп туктаган идем. Әллә инде безне махсус көтеп торганнар, алгы пролетта бер төркем кеше тәмәке көйрәтеп утыра иде.

Безнең чалханы боцман Габдуллин кабул итеп алды.

— Бик вакытлы кайтып җиттегез, юкса капитан дулый башлаган иде,— диде ул, шыпырт кына.

Миңзифаны барысы да аяк өсте торып ачык йөз белән каршыладылар. Хәтта һәрвакыт түрәләрчә рәсми-кәпрәеп йөрүчән капитан Шаһиморатов та Миңзифа белән ягымлы исәнләште. Мин көймәне бәйләп, пролетта икәү генә калгач:

— Безобразие, кай җәһәннәмдә шул тикле дөньяңны онытып йөрисең...— дип мине орышырга тотынды.— Йөкне төяп бетерүгә карамастан, синең аркада пароход китә алмыйча тора...

Күреп торам, йөкне яңа гына төяп бетергәннәр, трюм капкачларын ябарга да өлгермәгәннәр әле... Соңгы вакытта еш шулай итә, мине Миңзифадан көнләп, һич тә юкка бәйләнә ул.

Миңзифаның этисе Исхак абый заманында озак еллар мәдрәсәдә укыган кеше. Азактан, этисенә буйсынмыйча, мулла булудан баш тартып, туган авылыннан киткәннән соң, үз гомерендә күп нужалар чиксә дә, ул барыбер укымышлы кеше, үзенең бердәнбер кызын капитан Шаһиморатов ише дәрәҗәлерәк кешегә бирергә өметләнә икән — бу бик табигый.

Этисенең андый хыялларына моңарчы Миңзифа бер дә әһәмият бирмичә, иске караш дип кенә уйлый иде сыман. Хәзер исә, пар өянке янында үпкәннән бирле ул да мине тинсенми булса кирәк: палубада ара-тирә очрашкалаганда минем яннан бик житди кыяфәт белән күрмәмешкә салышып үтеп китә.

Хәер, Миңзифа һаман эштә: авыру пассажирларга, команда членнарына ярдәм күрсәтүдән бушамый. Һәр рейстан соң пароходта женteклəп дизенфекция ясарга туры килә, чөнки һәркайда тиф таралган вакыт. Шундый көннәрнең берсендә, мин үзем дә авырып, Нижний Новгородта больницага кердем.

Менә хәзер, Казанны дошманнан азат иткәч, аларны эзләп Бишбалтага Сөләйман карт янына баруым да күңел юатырлык берни бирмәде.

— Юк, шәһәрдә түгел, аклар белән китте бит алар,— диде ул, йөрәккә шом салып.— Элекке хуҗаның доверенныен, шат, хәтерлисеңдер. Шәһәргә аклар кергән көнне үк каяндыр шул мәлгунь килеп чык-

ты да, элеккедән дә зәһәррәк аяусызланырга тотынды. Кызыллар килә дигән хәбәр тарала башлагач та, беренче булып үкчәсен күтәрде. Үз ише җыен кара йөрәкнең мал-мөлкәтен «Сирень»гә төяделәр дә чыгып олактылар. Пароход капитаны Шаһиморатов команда членнарын мәҗбүр итте. Исхак кордашны, ату белән куркытып, озата барырга куштылар...

## XII

Казанны дошманнан азат иткәннән соң, флотилия икегә бүленде. Бер отряд Идел буйлап түбән таба — Сембер, Самара, Сызрань шәһәрләре тирәсендә акгвардиячеләргә һәм фетнәче чехларга каршы сугышучы кызыл гаскәрләргә ярдәмгә юнәлде. Кораллы пароходларны, өч миноносец һәм истребитель катерларны берләштергән икенче отряд, Казаннан чигенүче дошман флотилиясен эзәрлекләп, Кама елгасы буйлап китеп барды.

Безнең «Ваня-коммунист» исә, флотилиядән аерылып, бернича көнгә Нижний Новгородка менеп китте. Чөнки ул ашыгыч ремонтка мохтаҗ иде.

Күптән түгел генә үзләре коралландырып фронтка озаткан данлы корабны ремонтлауда завод эшчеләре көнне-төнне белми эшләделәр. Кыска гына вакыт эчендә кораб корпусының тишекләре ямалды, машинасы төзәтелде, рубкасы броня белән тышланды.

Шул арада Николай Григорьевич алны-ялны белмичә затоннарда бүтән пароходларны һәм «Атаман Разин» йөзмә фортын коралландыруны ашыктырып йөрде. Фронттагы корабларга сугыш кирәк-яраклары, командаларга азык-төлек, кием-салым җибәртүне ашыктырды.

Бөтен командага бер төсле хәрби дингез формасы бирелде. Безгә дә хәрби дингезче кыяфәте керде, күңелләр күтәрелеп китте. Пароходчылык идарәсендә бескозырка тасмамдагы алтын хәрефләр белән язылган «Ваня-коммунист» исеменә ихтирам белән күз салып китүләрен сизеп чын күңелдән горурландым.

Әмма идарәдә мин күңел юатырлык берни дә белә алмадым. Әлеге дә баягы, миңа шул үзем белгән мәгълүматны: Казаннан чигенгәндә аклар үзләре белән байтак пароходны алып китте, «Сирень» дә шунда булса кирәк, дип әйттеләр.

Ә биш көннән без тагын юлга чыктык.

Судовой комитет секретаре Кармашов игъланнар тактасына еш кына газеталар элә, халыкара хәлләр, фронт яңалыклары турында белдереп тора иде. Соңгы мәгълүматларга караганда, адмирал Старк флотилиясе бу көннәрдә Кама буйлап үкчәсен күтәрә һәм Казаннан чигенүче ак бандитларны мөмкин кадәр тизрәк елганың сул ягына чыгарып, һәлакәттән коткарырга тырыша иде. Җыелышта комиссар да шул хакта әйтте:

— Хәзерге көндә, туганнар, безнең алда иң мөһиме — тизрәк үзебезнең Кама елгасындагы төп көчләрне куып җитү һәм дошманның әнә шул планын өзү.

Шул максат белән «Ваня-коммунист» беркайда туктамыйча, агым уңаена зур тизлектә алга, фронтка ашыга.

Минем вахта вакыты. Лоцман Митричның аяклары сызлый башлаганнан бирле, миңа штурвал янында күбрәк үземә генә торырга туры килә. Ярый әле яңа штурвал куйдылар. Эш ансатланды, рульне кирәк якка бору берни түгел.

Казан турына җитәрәк бөтен команда өске палубага чыкты. Николай Григорьевич корабны пристаньга якынрак тотарга кушты һәм, хәр шәһәрне сәламләп, гудок кычкырта башлады. Пристань кешеләре

«Ваня-коммунист»ны тану белән, эшләреннән туктап, безгә кулларын, баш киемнәрен селкеп калды.

«Ваня-коммунист» һаман алга ашыгып, Кама елгасы буйлап үргә каршы менеп китте. Кая карама, сугыш эзе: җимерек авыл һәм пристаньнар, игеннәре җыелмаган басулар.

Явыз дошман үзе белән алып китә алмаган һәр нәрсәне яндырган, дебаркадерларны шартлатып батырган. Кулларына эләккән совет активистларын, алдынгы укытучыларны, йөзмә төрмәгә төяп, үзе белән алып киткән һәм ерткычларча үтереп, караңгы төннәрдә елгага ташлап барган.

Чистай белән Берсут арасын үткәндә безгә сугышның тагын бер корбаны — койрык ягы палуба тиңентен суга баткан ак пароход очрады. Текәлебрәк карау белән мин аны танып алдым һәм кинәт дулкынлануымны тыя алмыйча, кычкырып җибәрдем:

— Бу безнең «Сирень» ич!.. Теге чакны Казанда аңа аклар төялеп китте дип әйткәннәр иде. Ул монда ничек утырып калган икән?..

Николай Григорьевич рубка алдында барган җиреннән:

— Шулаймы, син эшләгән пароходмы? — диде.— Чү, анда кемдер бар ич, әнә капитан күперчегеннән безгә кул болгый...

Үзебез дә сайга утырмас өчен аның янына без саклык белән, тирәнлекне үлчи-үлчи акрын гына якынайдык. Безнең корабтан ыргыткан чалка очын ифрат ябык гәүдәле, сүлпән хәрәкәтле өлкән яшьләрдәге ир кеше көчкә кабул итеп алды.

— Уф, ярый әле туктадыгыз... Юкса түзәр хәл калмаган иде,— диде ул, авыр сулап. Аннары мине күреп хәйран калды: — Васил, син исәнмени әле, хәрби диңгезче булдыңмыни?!. Оныттыңмыни, Халит ич мин, боцман Халит Габдуллин...

Ул шундый ябыккан, яңаклары эчкә батып кергән, буй-буй сызыклы ситсы күлмәк аша калак сөякләре беленеп тора. Битләрен җирән сакал-мыек баскан, үзе дәшмәсә, танырмын димә. Ул бераз тынычлангач, мин түземсезлек белән сораштыра башладым:

— Бүтәннәрегез кайда, Исхак абыйлар исән-саумы?..

— Кая, башта тартырга бир әле,— дип боцман тәмәке сорап алып, төтенгә тончыга-тончыга көйрәтергә тотынды. Тирәсендә башка матрослар да җыелганын күреп, русчага күчте: — Казанкага аклар басып кергәндә, бәхетсезлеккә каршы, безнең машинабыз төзек түгел иде. Шунлыктан, башкалар белән китеп котыла алмадык.

Беркөн шулай рейстан кайтып керсәк, пристаньда мәхшәр. Дебаркадер янына туктауга, барысы да кызу көнне су күргән хайван көтүе шикелле, берсен-берсе этә-ега пароходка ташланды... Байгура токымнары тизрәк качып котылырга ашыга икән. Аларны Уфага хәтле саклап озата барырга ун кешелек кораллы конвой шундук пароходны үз кулына алды.

Моны сизү белән, командадан берничә кеше бу пычрак эштә катнашырга теләмичә, ыгы-зыгы арасында шыпырт кына чыгып юк булды. Ә без, качып китә алмаучылар, юлга чыккач, пароходны ничек тә үзебезнең якта саклап калырга, ягъни, төнлә халык тынгач, кингстонны ачып, саерак урында аны комга утыртырга исәп тоттык... Әмма без өлгермичә калдык. Машинистлар белән без түбәндә маташкан вакытта пароход полный ходка барган шәпкә, кинәт нәрсәгәдер бик каты бәрелеп, шып туктады. Корпус эченә ургылып су тула башлады. Соңыннан белдек: пароход борыны белән сайга утырган, каты бәрелүдән корпусның төбе тишелгән икән.

Ул чакны рубкада лоцман Исхак агай үзе генә булган. Капитан Шаһиморатов йомыш белән аска төшеп киткән арада пароходны сайга шул утыртканлыгы мәгълүм булды... Исхак абзыйны канга батырганчы кыйнадылар-кыйнадылар да, иртәгесен узгынчы йөзмә төрмәгә би-

реп җибәрделәр. Ак сөяк пассажирлар да, алар белән бергә капитан Шаһиморатов та Казаннан чигенүче бүтән пароходларга көчеп утырып, үз юлларына олакты... Менә шуннан бирле буксир көтеп яту шунда. Ашарга берни калмагач, өченче көн бөтен команданы Чистайга озаткан идем. Алардан да әле һаман һичнинди хәбәр-хәтер юк.

Күреп торам, боцманның сүзе тиз генә бетәргә охшамаган. Ниһаять, түзмәдем, ул туктап тәмәке суырган бер арада:

— Исхак абый кызы Зифа кайда? Ул да алар белән китмәгәндер ич? — дип сорадым.

— Юк, Зифа алар белән түгел. Аклардан соң ул әтисен эзләп, түбән яктан килгән беренче баркас белән Алабугага таба китеп барды...

Аннары боцман безгә ярым хәрабә хәленә төшкән пароходны күрсәтеп йөрде. Беренче класс салонында зыялы әфәнделәр тарафыннан пианино җимереп ташланган, идәндә ак мәрмәр кыз сыны аунап ята, зур-зур көзгеләр, каюталарның тәрәзәләре ватылып-чәрдәкләнеп беткән. Бер уңайдан без минем каютаның да ишеген ачкан идек, идән уртасында җәелеп яткан кан эзе күреп, катып калдык.

— Теге чакны, конвой начальнигы кыйнаганнан соң, Исхак агайны шушында ябып куйганнар иде,— диде боцман.

Пароходның цистернасында безгә бик тә кирәкле ягулык мазут бар икән. Комиссар кушуы буенча, машинистлар аны шундук корабка суыртып ала башладылар. Аннары «Сирень» боцманына берничә көнлек ашамлык, махорка биргәннән соң, юлга кузгалырга приказ булды. Боцман Габдуллин чалканы ычкындырганда безгә рәхмәтләр әйтеп, уңышлар теләп калды. Аның күңелен күтәрергә теләп, Николай Григорьевич рупордан:

— Хуш, дускай, син монда бик моңайма,— дип кычкырды.— Белеп тор, тиздән без ул контрларны куып җитәрбез һәм барысы өчен дә үч алырбыз. Хәзер эшләр шуңа табан бара.

## XIII

Безнең кок Алимҗанны бөтен корабта иң җор, иң мәзәкче кеше дип әйтергә мөмкин. Аның тирәсендә һәрчак агай-эне җыелган булыр, күңелле шаяру-көлү яңгырап торыр.

Әмма бүген мин аны кичке аш вакытында камбуз тәрәзәсеннән күреп бик аптырап калдым. Һәрвакыт көр күңелле дустым бу юлы каты хасталы кеше сыман ябыгып калган, хәрәкәтләре сүлпән, күзләре кайгылы һәм яшь тулы иде. Мин:

— Ни булды сиңа? — дип сорадым аннан.

— Көндез Чистайда туктап торган арада пристаньда бер авылдашны очраттым,— диде ул.— Фетнәче-сәнәкчеләр төнлә безнең өйгә ут төрткәннәр, әти-әнине шунда тереләтә яндырганнар...

Алимҗан, сүзсез калып, халат җиңе белән яшьле күзләрен сөртеп алды.

— Улың ничек, хатының? Исәннәрме?

— Хәзергә алары исән кебек, күрше авылга әбиләргә киткән чаклары булган...

Бу шомлы хәбәр тиз арада һәркемгә мәгълүм булды һәм бөтен корабка кайгылы төс керде. Бүтән кичләрне Алимҗан тирәсендә шаугөр килеп торган арткы палубада бүген авыр тынлык иде. Барыбызга да бик авыр булып китте. Бу минутта һәркем үзенең туган-үскән ягы, кардәш-ыруы, якын дус-ишләре турында авыр уйга талды булса кирәк. Газиз туганым кебек якыннарым Миңзифа белән Исхак абый да шундый бәла-казага тап булмагае дип, мин дә бик борчыла башладым.

Шул чак өстән, рубкадан җитез адымнар белән комиссар Маркин

төште. Кәефле чагы булса кирәк, ул авыз эченнән иштелер-иштелмәс кенә нидер көйли, какча йөзе ачык иде. Үз каютасына үтешли ул, нидер сизенгәндәй, безнең янга туктады һәм, өстәл кырыендагы буш урынга утырып, тәмәке төрергә тотынды. Аннары, киеренке тынлыкның сәбәбен белгәч, үзе дә уйга калды, ачык йөзендә борчылу күләгәсе чагылып үтте. Тәмәкәсенә ут кабызып ул әкрен генә сөйләп китте:

— Алтынчы елның көзендә Владикавказда зур демонстрация булды. Әти белән бергә мин дә урамга чыктым. Ул чакны миңа инде унөч яшь иде, барысы да хәтердә, урам тулы демонстрантлар. Шәһәр үзәгенә җитәрәк, көтмәгәндә, ян тыкрыктан атлы жандармнар килеп чыкты. Котырган этләр өередәй безнең өскә ташландылар. Жандармнарның берсе алгы сафта байрак тотып баручы әтигә кылыч белән селтәнде.

Николай Григорьевич, авыр сулап, тынып калды. Аның янында утырган юнга Чурков балаларча беркатлылык белән:

— Их, хәзер булса, күрмәгәннәрен күрсәтер идек без аларның! — диде, йодрыкларын йомарлап.

Николай Григорьевич юнганың иңеннән аталарча сыйпап алды да, сүзен дәвам итте:

— Совет власте язмышы хәл ителгән бу авыр көннәрдә безнең беребезгә дә җиңел түгел. Түзәргә туры килә... Минем үземнең дә Саратовта бертуган апам белән сеңелем торып калды. Хәзер ул якларда кара көчләр котыра. Әгәр туганнары комиссар икәнен белсәләр, аларның да башларыннан сыйпамаслар, әлбәттә.

## XIV

Кама елгасы буйлап күтәрелә торгач, егерме тугызынчы сентябрьдә Алабуга пристаненнан бераз югарыдарак флотилиянең төп көчләрен куып җиттек.

Каманың түбәнге агымында зур шәһәрнең берсе булган Алабуга без килеп җитәр алдыннан гына аклардан азат ителгән һәм бөтен флотилиядә киеренкелек хөкем сөрә, кешеләрнең йөзендә җиңү шатлыгы балкый иде.

Шактый кыен һәм алҗыткыч походтан соң, командага ял бирелде. Шәһәргә чыгып, бераз җилләнеп кайтырбыз дип өметләнгән идек. Әмма без уйлаганча булып чыкмады. Комиссар флотилия штабы урнашкан «Илья Муромец» пароходында фронт хәлләре белән танышып кайткач, кичекмәстән кузгалырга, чигенүче аклар флотилиясен эзәрлекләп Чаллыга таба киткән алдынгы отрядка ярдәмгә барырга ашыктыра башлады.

Без монда акгвардиячеләрнең тагын бер мәкерлегенә — Алабугадан чигенгән чакта фарватерның иң тар турында батырып калдырылган таш тулы ике баржага тарыдык. Ялгыш бәрелмәс өчен, алар янында тиранлекне үлчи-үлчи, саклык белән генә үтәргә туры килде.

Николай Григорьевич бүген никтер аеруча борчулы, биноклен күзеннән алмыйча, яр буйларын, куе урманлы тау араларын туктаусыз күзәтеп бара. Ул сигналчыларга игътибарлырак булырга кисәтеп куйды. Тупчы һәм пулеметчыларга әзер торырга боерык бирде.

— Иптәшләр,— диде ул,— без коры җир гаскәрләреннән егерме утыз чакрымнарга алдарак барабыз, бу тирәләрдә хәзергә әле елганың ике як ярында да аклар, һич көтмәгәндә хәтәр хәл килеп чыгуы ихтимал.

Бераз баргач, комиссар сүзләрен раслагандай, куәтле гөрселдәү тавышы ишетелде. Беренче шартлауга икенчесе, өченчесе кушылды һәм туп тавышлары тоташ бер гүләүгә әйләнде.

Тиздән алда, күгелҗем томанлы су өстендә бер төркем кораб кү-

ренде. Алар фронталь сафка тезелгән хәлдә тупларыннан ата-ата үргә каршы киләләр, залп биргән саен алар өстендә һавага саргылт дары төтене бөркелә иде. Рубка өстендә бинокльдән карап баручы сигналчы кинәт кычкырып җибәрде:

— Үзебезнекеләр ич бу!.. Әнә, «Добрый», «Товарищ», «Революция авангарды», «Атаман Разин» форты... Тик кемгә атулары гына аңлашылмый, чөнки ул тирәдә һичнинди дошман корабы күренми.

Бу хәлгә аптырап калган күзәтүче бинокльдән төбәлеп аны-моны ачыклаган арада Чаллы турында, елганың уң ягындагы затон тамагыннан бер-бер артлы тезелешеп зур тизлектә дошманның алты корабы чыгып килгәне күренде. Морквах, Югары Ослан, Казан шәһәре янында каты бәрелешләрдә күп тапкырлар очрашкан таныш кораблар.

— Кара син акыллы башларны... Шунда яшеренеп, безнең өскә арттан китереп бәрмәкче булганнар...— Комиссар кичекмәстән сугышчан тревога игълан итте.

Бу минутта безнең кораблар тимер ташкын кебек зур тизлектә ыргылып алга бара һәм алар барысы да дошманның башлап килүче кораллы пароходына төзәп ата, снарядлары шуның тирәсенә төшеп шартлый иде. Менә «Милютин» кара төтен белән капланып яна башлады һәм, барышын акрынайтып, бүтән кораблар артына ышыкланды. Николай Григорьевич бердәм залпларга сокланып ачык күперчектә карап барган шәпкә:

— Менә бу безнеңчә, берсенә кирәген бирделәр...— дип кычкырып җибәрде, бинокленнән аерылып, маңгаен сыпырып куйды.— Хәзер инде чират икенчесенә... Анысына да нәкъ шулай, утны бергә туплап яудырырга кирәк.

Шул арада без дә снаряд барып житәрлек якынаеп өлгердек. Алгы тупның комендорлары инде баядан бирле түземсезлек белән кыҗрап киләләр иде. Ут ачарга команда булуга алар дошман өстенә ашкынып ут яудыра башладылар.

Бераздан дошман кораблары, туплардан ата-ата, уң як яр буйлап Тын тауларга таба чигенә башлады.

Кичке эңгер-меңгер куера төшкәч отряд Чаллыдан берничә чакрым югарыдарак сул як яр буенда якорьга туктады, көндезге сугыштан арыган кешеләргә ял бирелде. Комиссар корабларның командирларын чакыртып командаларның хәлен, сугыш кирәк-яракларын һәм ягулык запасларын белеште, аларны көндез штабтан алган соңгы мәгълүматлар белән таныштырды, отрядка иртәгә иртүк кузгалырга дигән фәрман бирелде.

Шул арада Чаллыдан әйләнеп кайткан разведка катеры элеваторда шактый икмәк запасы булуын хәбәр итте.

— Маякчы карттан сорашып белдек, аның улы элеваторда үлчәүче булып эшли икән,— диде разведка командиры.— Элеватор аклар кулында. Чигенергә туры килсә, элеваторны ашлыгы-ние белән бергә яндырып китәргә җыеналар ди.

— Икмәкне саклап калу һәм баржаларга төяп, Нижний Новгородка, Мәскәүгә озату — гаять мөһим бурыч. Коры җир гаскәрләре килеп җиткәнче, элеваторны ничек тә саклап калырга кирәк.— Николай Григорьевич командирларны күздән кичерде.

Шул максат белән төнге караңгыда елганың сул як ярына десант төшерергә туры килде.

...Иртәгесен иртүк якорьларны күтәреп, без тагын юлга кузгалдык. Кичә Чаллы янында күздән югалган дошман отряды, без киләсен алар алдан сизеп, уяу торган булса кирәк, снаряд җитәрлек арага якынайганны да көтмәстән, башлап үзләре ут ачтылар.

Әмма шунысы сәер, дошман отряды бу юлы никтер чынлап торып сугышырга җөрьәт итмәде. Бик тиз арада якорьдан кузгалды да, нәкъ

кичәге кебек, безгә каршы тупларыннан ата-ата, тагын Кама буйлап үргә каршы чигенә башлады. Шулай алтмыш чакрымнан артыграк юл үткәч, Минзәлә пристанена җитәрәк, кичкырын бөтен отряд белән тагын якорь салдык.

— Җитте, Митрич, бүген шуннан ары бармыйбыз...— диде комиссар, кораб тәмам туктаганнан соң.— Без инде болай да коры җир гаскәрләреннән җитмеш-сиксән чакрым алда. Хәзер аеруча сак булырга, барыннан да бигрәк дошманның ник болай тоткарсыз чигенүен, нинди авыр мәкер коруын ачыкларга кирәк. Безнең өчен бу — бик мөһим бурыч.

## XV

Түбәнге палубада кемдер балалайка чиртә. Әле аннан, әле моннан үзара шаяру, көлү тавышлары ишетелә.

Алимҗан гына җитди, уйчан чырайлы, авыр кайгысыннан онытылырга теләп булса кирәк, ул һаман эш белән мәшгуль. Әнә ул балык тотарга хирыс егетләр белән койрык якта ятьмә рәтләп маташа.

— Әйдә, әйдә, тугани, җәһәтрәк кыймылда,— дип ашыктыра ул аларны.— Табын янында кыю булган күк, эштә дә тартынып торма.

Безнең кубрикта юнга Чурков кубыз тартырга керешкән. Алимҗан аны әле кайчан гына өйрәтә башлаган иде. Бер ай эчендә хәйран остарып өлгергән, әнә ничек теттереп уйный.

Өстәлнең аргы башында пулеметчы Вишневский нидер язып утыра. Хәер, ул гел шулай, аз гына буш ара чыктымы, аулаграк бер почмакка урнаша да, язуына керешә.

Беркөнне шул язганнарның беразын укып күрсәткәч, барыбыз да хәйран калдык. Ул, хикмәт иясе, шулай сәгатьләр буе утырып, баштан кичкән сугыш хәлләре, яуда һәлак булган иптәшләр турында, гыйбрәтле кыйсса кебек бик тә килештереп, дәфтәренә язып бара икән.

Юнга Чурков балаларча беркатлылык белән аннан:

— Дядя Воля, көн саен иренмичә ничек шулай язасың, аның нигә кирәге бар?— дип сораган иде.

— Кирәк була ул, Володя. Бүген кирәкмәсә, соңыннан, сугышлар беткәч...— диде Вишневский, дәфтәрен ябып.— Әгәр мин дә, бүтән кеше дә язмаса да, безнең совет власте өчен сугышып йөрүләрне, синең комиссар Маркин ярдәмчесе булып хезмәт итүеңне киләчәк буыннарга кем җиткерер?

Шул аңлашудан бирле без Вишневскийга мөмкин кадәр уңайлыклар тудырырга, ул язганда артык шауламаска тырышабыз. Рубка өстендәге күзәтүченең көчле тавыш белән мигафоннан:

— Иптәш комиссар!..— дип кычкырганы бөтен корабка яңгырап үтте.— «Межень»нан сигнал: сезне ашыгыч рәвештә киңәшмәгә чакыралар.

Командующий урнашкан «Межень» пароходы (элек патша яхтасы), йөзмә госпиталь «Христофор Колумб» һәм флотилиянең бүтән кораблары — барысы да безнең алдынгы отрядтан ике чакрым чамасы түбәндәрәк, елганың дугайлы сул як яры буенда якорьга туктаган; аларның торбаларыннан акрын гын күтәрелгән каралҗым сыек төтен, кичке аяз күктә кысыр болыт сыман, таралмыйча эленеп тора иде. Николай Григорьевич ике ишкәкче матрос белән җиңел көймәдә шунда китеп барды.

Бераздан, эңгер-меңгер җитәрәк, Алимҗан белән киткән балыкчылар кайтып керде. Аларның юллары уңган бугай, кәрзиннәре тулы күренә. Бик туңган, өс-башлары манма суга чыланып беткән булсалар да, авызлары колакка җиткән иде. Барыннан да бигрәк юнга Чурков

шат. Ул бескозыркасын тасмасы белән бәйләп муенына аскан да, башына күн козыреклы кара фуражка киеп куйган. Бу фуражканы күргә мин әллә нишләп киттем, Чурковның башыннан салдырып алдым да әйләндереп-әйләндереп карарга керештем:

— Син моны кайдан алдың?! Бу безнең Исхак абый фуражкасы ич! — дип кычкырып җибәрдем.— Минеке белән бер иштән. Без аны быел яз затон кибетеннән сатып алган идек...

— Бер иштән булса соң, әллә урлаганмы ул аны...— Алимҗан балыклы кәрзинен палубага куеп, юнганы якларга тотынды.— Балык сөзгәндә су төбеннән ятмәгә эләгеп чыкты.

— Хәтерлисеңме, мин сиңа Миңзифаның этисе Исхак абыйны аклар үлем баржасында алып киткәннәр дип сөйләгән идем. Бу фуражка — аның фуражкасы бит. Шулай булгач...

Мәсьәләнең асылы, ниһаять, Алимҗанга да барып җитте, шомлы шаккатудан күзләре шар булды. Нидер эзләгәндәй, юеш фуражканың эчен-тышын җентекләп карарга кереште.

Палубада кинәт авыр тынлык туды, балыкчылар табып кайткан тишек түбәле фуражка күз алдында мәеткә әверелгәндәй булды. Ләкин барыбер, Исхак абзыйның үтерелүенә ышанасы килми, ул әле исәндер дигән өмет күңелне җылытып тора иде.

## XVI

Комиссар Маркин киңәшмәдән караңгы төшкәндә генә кайтып керде. Палубага күтәрелгәндә аның гадәттәге ачык йөзе бу юлы никтер борчулы, иреннәре кысылган, бөтен кыяфәтеннән тынгысыз киеренкелек сизелеп тора иде.

Матрослар әле кубрикларга таралмаган, йоклар алдыннан махорка тарта-тарта, өске палубада тыныч кына әңгәмә корып утыралар иде. Комиссарны хәрби гадәт буенча барыбыз да аягүрә торып каршыладык. Судовой комитет секретаре Николай Кармашов:

— Николай Григорьевич, штабта нинди яңалыклар бар? Башка фронтлардан сөенечле хәбәрләр юкмы?— дип кызыксынып сорады.

— Бар, туганнар, яңалыклар бар,— диде комиссар, безнең янда тукталып. — Адмирал Старк үзенең бөтен флотилиясен моннан ун чакрым чамасы югарыдарак, елганың уң ягындагы Пьяный Бор авылы турында туплаган. Шуннан торып ул Казаннан чигенүче ак бандаларны корабларга төяп Каманың сул як ярына чыгарырга нияти... Без дошманның бу мәкерле ниятен өзәргә тиешбез — менә шул.

Казанны азат иткәннән бирле дошманны гел кысрыклап килеп, җиңү дәртен татыган матрослар шаулашырга тотындылар, бөтенесен җиңел генә хәл ителгәнгә санап кайнарланып алдылар.

— Туганнар,— диде Николай Григорьевич артык шапырынучыларга ризасыз карап,— без үзебезнең коры җир гаскәрләреннән күп алда барабыз. Елганың уң як ярында чигенүче ак армия, сул якта кулак фетнәләре, сәнәкчеләр котырына... Аннары ак флотилияне дә хәлсезгә санарга ярамый, яралы ерткыч икеләтә куркыныч була дип тикмәгә әйтмиләр. Адмирал Старк — бик мәкерле дошман, һич уйламаган, көтмәгән алдавычлар коруы бик ихтимал. Безгә аннан да хәйләкәррәк, зирәгрәк булырга кирәк.

Комиссарның һәр сүзен йотып алырдай тыңлап торган юнга Володя Чурков, сүзен әйтми калудан курыккан сыман:

— Мин дә шулай уйлыйм,— диде. — Иң яхшысы шул: көтмәгәндә бәреп дөмбәсләү.

— Күрәсез, минем ярдәмчем иптәш Чурков та шуны хуплый, димәк, дөрес уйлыйбыз...— Николай Григорьевич мыек астыннан сизе-

лер-сизелмәс кенә елмайды, юнганың иңбашыннан сыйпап алды һәм, кинәт җитдиләнеп: — Иптәш Кармашов, һәр корабтан бишәр кеше алып, отряд оештыр да, иртәгә таң алдыннан десант төшерергә әзер бул. Кара аны, барсы да үзләре теләп баручы кыю һәм батыр егетләр булсын. Винтовка, гранаталардан тыш, пулемет, тагын Казанда кулга төшергән ике җиңел тупны алыгыз...

— Аңлашылды,— диде Кармашов.

— Дошман тылына барасыз, иптәш Кармашов, сине отрядның командиры итеп билгелим. Пулеметчы Вишневский ярдәмчегез булыр. Иртән яктырганчы елганың сул як ярына төшәсез дә, әрәмәләр арасыннан тавыш-тынсыз гына Пьяный Борга таба китәсез. Дошманның Пьяный Бор утравы янында тупланган корабларына туп һәм пулеметлардан кинәт дәррәү ут ачып, паника тудырырга тырышыгыз. Шул чак без бөтен отряд белән бу яктан атакалыйбыз...



## XVII

Мин йокыдан уянып палубага чыкканда тышта яктыра башламаган иде әле. Әйләнә-тирәне таң алдыннан була торган куе караңгылык баскан: якында гына аяк тавышлары, өзек-өзек сүзләр ишетелгәләп китә. Кармашов отрядын юлга озаталар икән. Ниһаять, барысы да көймәләргә төялеп, урнашып беттеләр. Отряд командиры Кармашов Николай Григорьевич каршына килеп смирно басты да:

— Иптәш комиссар, десант отряды юлга чыгарга әзер, кузгалырга рөхсәт итегез,— дип мөрәҗәгать итте.

— Юлыгыз уң булсын!

Таң атып, офык аллана башлаганда, десантчылар инде елганы кичкәннәр, аларны озата баручы көймәләр кире кайтып киләләр иде.

Көнчыгышта офык артыннан гаять зур утлы шар сыман кояш калкып чыкты һәм үзенең беренче нурлары белән каюта тәрәзәләрендә, туп көпшәләрендә җемелди башлады.

Безнең корабның койрык ягында берәр туп һәм пулемет белән коралланган ике бронекатер тора иде. Николай Григорьевич аларның командирларын чакыртып алды да, ашыгыч рәвештә разведкага барырга боерык бирде. •

Катерлар юлга кузгалды. Дошман күзенә бик ташланмас өчен, алар томан куерак булган уң як яр буйлап агымга каршы менеп киттеләр. Безнең карашлар да шул тарафка — Пьяный Борга таба юнәлгән: Кармашов отряды аклар өстенә ут ачканны түземсезлек белән көтәбез һәм боерык булуга кузгалып китәргә әзер торабыз.

Безнең разведка катерлары инде байтак юл алып, елганың уң як ярында кечерәк кенә Малиновка авылы турыннан үттеләр һәм зур тизлектә барган шәпкә якындагы томанлы утрау күләгәсенә кереп күздән югалдылар. Шулай да дошман аларны күреп алды булса кирәк, елганың уң тармагы буйлап тиздән кораблар килеп чыктылар һәм туплардан ата-ата безнең бронекатерларга каршы ташландылар. Иртәнге томан аша үзләрен ачык танып булмаса да, аларның снарядлары төшеп шартлаудан күтәрелгән биек-биек су баганалары ачык күренә. Томан эченнән безнең катерлар тагын килеп чыкты. Дошман снарядлары эләкмәсен өчен алар әле уңга, әле сулга маневрлар ясап, туплырыннан ата-ата һаман каршы баралар иде.

Нәкъ шул чакны, Пьяный Бор турыннан пулемет һәм туплардан ата башладылар. Бу исә дошманның утрау артындагы көчләренә көтелмәгән хәл, кинәт тылдан китереп бәргән кебек тоелды күрәсең: анда башланган гудок тавышлары, тәртипсез атышлар шуның билгесе, матавык тууы турында сөйли иде.

Рубканың ачык тәрәзәсеннән тын да алмыйча карап торган Николай Григорьевич кәефле елмаю белән:

— Әһә, Кармашов отряды барып җиткән,— диде.

Секунды белән сугышчан тревога игълан ителде. Бүтән корабларга да, тиз генә кузгалып, безнең арттан иярергә сигнал бирелде.

Түбәндә машина эшли башлауга, «Ваня-коммунист» кузгалып та китте һәм үткен борыны белән киң елганы ярып үргә каршы ыргылды. Ераклыкны үлчәп баручы әледән-әле кычкырып хәбәр итә башлады:

— Дошман корабына дүрт чакрым ара...

— Өч ярым.

— Өч чакрым...

Кораб әнә шулай зур тизлектә дошманга каршы ыргылып барганда күзәтче, корт чаккандай, ачык тавыш белән:

— Иптәш комиссар, дошман тубы күренә,— дип кычкырып җибәрде.

Ярдагы ул тупны барыбыз да күреп алдык. Кечерәк кенә калкулык артына яшерелгән булса да, аның туры безгә караган түгәрәк кара авызы тәбәнәк тал-чыбыклар арасыннан бераз калкып тора. Ара шундый якын, рәтләп төзәп торасы да юк. Атып җибәрсә, беренче снаряды белән үк безне зир-зәбәр итәчәк, ничек тә аннан элек ут ачарга кирәк. Әмма хәзергә ул-бу сизелми, безне, күрмиләр дип уйлап булса кирәк, никтер сузалар иде. Николай Григорьевич моның мәкерле серенә төшенү белән:

— Аңлашыла, безне алга үткәреп, арттан бәрмәкчеләр,— диде һәм тиз генә алгы туптан атарга боерды.

Алгы тупның комендоры Степан Овсейчук — тиз һәм төз атуы белән дан тотучы егет. Иптәшләре аның турында: әгәр теләсә, ул очар кошка да һичшиксез эләктерәчәк дип, шаярталар иде. Степан бу юлы да шөһрәтен аклады: яр өстендәге утын әрдәнәсен бер атудан челпәрәмә китереп һавага күтәрде. Әле генә безгә хәвеф янап торган дошман тубы, җимерек арба кебек, яны белән авып төште.

Снаряд шартлаган төштә тузан катнаш төтен таралгач, әлеге утын әрдәнәләре артында дошманның бөтен бер батареясы яшеренеп торганлыгы ачыкланды. Тик шунысы бик сәер, хәзергә ул туплар янында беркем дә юк иде шикелле. Хуҗаларын безнең снаряд кырып ташлаганмы, әллә куркудан урман эченә кереп качканнармы,— анысы безгә караңгы. Комиссар тиз генә десант әзерләргә боерды, ә бүтән корабларга дошман отрядына каршы бара торырга, разведка катерларына ярдәмгә ашыгырга сигнал бирелде.

Хәлбуки, тугайда су сай булу сәбәпле, кораб белән ярга якын килеп, тиз генә десант төшерергә мөмкин түгел, көймәләр белән чуалырга ара тар. Без монда инде ансыз да артык озакладык. Ярда исә хәрәкәт кузгалды, дошман солдатлары урман эченнән йөгереп чыгып, ашыга-ашыга туплар янында мәш килергә тотынды.

Без чигенергә теләп, машинаны артка таба эшләткән арада, аклар безне прицельга алып та өлгерделәр бугай. Снарядларның берсе, койрык якта шартлап, рульне бозды ахры, штурвал авыр әйләнә башлады. Икенче снаряд, бөтен корабны тетрәтеп, аста корпус эчендә ярылды, аннары түбәннән сөйләшү торбасы буенча кемдер шомлы тавыш белән:

— Иптәш комиссар, машина бүлегендә снаряд шартлады, пар торбасы ярылды,— дип хәбәр итте.

Бу хәвефле хәбәрне комиссарга җиткерергә өлгермәдем, якында гына төшеп калган тагын бер снаряд ярылды һәм шартлау дулкыны мине аяктан екты. Мин тиз генә торып штурвал янына баскач, ни булганын күреп шаккаттым: рубканың арткы ягы бәреп ташланган, төтен торбасы яртылай умырылган, лоцман Митрич дәдәй, кулларын

як-якка җәйгән хәлдә, сул як ишек янында йөзтүбән хәрәкәтсез ята иде.

Николай Григорьевич һаман шунда, сулъяк басмачада, кулындагы рупордан кычкырып приказ бирә-бирә сугыш белән идарә итә; аның боерыгы буенча алгы туп һәм пулеметлар яр өстенә ут яудыра, арткы орудие безнең бронекатерларны эзәрлекләп килүче дошман корабларына каршы ярсып ата иде.

Яр өстеннән дошман уты көчәйгәннән-көчәя бара. Әнә тагын бер снаряд арткы палубага төшеп шартлады һәм бөтен койрык як, төпкә упкандай, кинәт чүгеп куйды. Каерылып карауга өнме бу, төшемме дип аптырап калдым: әле генә дошман корабларына каршы ут яудырып торган орудие нигезеннән куптарып ташланган, аның тирәсендәге буш гильзалар арасында комендорларның канлы гәүдәләре генә хәрәкәтсез ята иде.

Күрәм, комиссар басмачадан кычкырып нидер әйтә, кулындагы рупоры белән ишарәләп, рульне уңга, фарватер ягына борырга куша бугай. Әмма минем хәл юк, көчкә басып торам. Штурвалны бора башлауга, кулым ычкынып, сәрхуш кеше кебек, чайкалып егылып китәм.

Комиссар тиз генә рубкага кереп, ашыга-ашыга штурвалны бора башлады. Аның артыннан ук кереп юнга Чурков та штурвал янына басты.

— Монда мин торам... Иптәш комиссар, барыгыз, сез тегендә командалык итегез...— диде ул, басмачага таба күрсәтеп.

Бу минутта аның хәрәкәтләре кыю, тәвәккәл, бөтен кыяфәтеннән иң хәтәр приказны да үтәргә әзер торуы күренә иде. Николай Григорьевич аны монда ут астында калдырырга теләмәде, ахры, штурвалны бирмәде. Түбәннән менеп җиткән Алимҗан белән юнгага мине рубкадан алып чыгарга кушты да палубага төшеп китте. Чөнки хәзер инде штурвал сафтан чыккан, аста каюталардан күтәрелгән тончыктыргыч кайнар төтен һәм ялкын телләре инде монда бәреп керә башлаган, рубка менә-менә дөрләп кабынып китәргә тора иде.

Алимҗан белән Володя Чурков икесе ике яктан култыклап мине палубага төшергәндә, инде машинасы сафтан чыккан һәм рульсез калган «Ваня-коммунист» борыны белән акрын гына уңга, агым уңаена авыша бара, аның каюталары кара төтен катнаш ялкын эчендә; алгы туп янында бер ялгызы исән калган комендор Степан Овсейчук исә әле һаман каршылык күрсәтә иде.

Хәлбуки безнең «Ваня»ның хәле мөшкелләнгәннән мөшкеләнә. яңгын отыры җәелә бара, яралылар һәм һәлак булучылар саны арткаңнан арта бара иде. Уңга авышкан хәлдә, яны белән сайга утырып, «Ваня» бөтенләй хәрәкәтсез калды. Дошман снарядлары тиюдән булса кирәк, урта палубада әрдәнәләп өелгән үзебезнең туп ядрәләре гөрстгөрст шартлый башлады. Комиссар бөтен палубага ишетелерлек итеп кычкырып команда бирде:

— Барыгызга да суга сикерергә! Дошман кулына әләгерлек булмасын, сул як ярга таба йөзегез, анда — безнекеләр,— диде һәм Чурковка судан коткару бөяте кидереп, аны палубадан төртеп төшерде.

Юнга артыннан бүтәннәр дә, буш мичкә һәм снаряд ящиклары алып, суга сикерә башлады. Алимҗан алгы туп янында кинәт тукталып:

— Иптәш комиссар, сез безнең белән төшмисезмени? Алайса, без дә калабыз,— диде.

Николай Григорьевич аны кырт кисте:

— Күп сөйләшеп торыр чак түгел. Приказ шундый: хәзер үк суга сикерегез... Марш!..

Комиссар комендор Овсейчук белән бергә туптан атуын дәвам иттерә иде.

Катгый боерык булгач, Алимҗан бүтән сузмады. Каяндыр бөят бөҗраларына табып, берсен миңа кидертте, икенчесен үзе алды. Борт читендә без бер мәлгә туктап, үле гәүдәләләр тулы палубаны, дөрләп янган каюталарны соңгы тапкыр күздән кичердек. Алимҗан үзәк өзгеч ачыну белән әйтте:

— Хуш, «Ваня!» Хушыгыз, дуслар. Сезнең өчен без үч алырбыз. Алырбыз! Дөмегер дошман. Мин моны ант итеп әйтәм.

«Ваня»ның һәлакәте йөрәгемне телеп алды. Дустым белән бергә мин дә ант иттем, кара йөрәкләрне тәмам дөмектергәнче сугышырга үземә сүз биреп, суга ташландым.

Су бөтен тәнне үтәли көйдереп алды. Өскә калкып чыксам, Алимҗан белән Володя Чурков та, башка матрослар да шунда, төрлебез төрле әйбергә тотынган хәлдә, дулкыннар арасында бата-чума агым уңаена китеп барабыз.

Мин каерылып тагын «Ваня-коммунист»ка карадым. Комиссар белән комендор Овсейчук әле һаман туптан ата иделәр.

Тәмам ярсыган дошман хәзер бөтен утын безнең өскә яудыра. Пуля яңгырыннан әйләнә-тирәдә су өсте кайнап тора, әле бер, әле икенче иптәш яраланып, бата бара. Алимҗан белән юнга Чурков мине икесе ике яктан тоткан хәлдә:

— Бераз гына түз, бирешмә, хәзер котылабыз,— дип буш куллары белән ишә-ишә, мине ут астыннан алып чыгарга тырышалар иде.

Шул чак бик якында, безнең янда гына төшеп елга төбендә снаряд ярылды һәм түбәннән бәреп чыккан коточкыч көч мине, йомычкадай бөтереп алып, каядыр төпсез упкынга ташлады...

## XVIII

Җиңел көймәбез су өстеннән уйнаклап кына бара, ишкәкләрне каерып алган саен, очып китәргә омтылган акчарлак сыман, алга таба җиңелчә талпынып-талпынып куя.

Койрык якта миңа каршы утырган Миңзифа бармак очларын суга тыгып, вак дулкыннар белән шаяра, учына су алып, як-якка көмеш тамчылар чәчрәтеп бара. Елмайганда аның болай да сөйкемле йөзе тагын да матураеп, яктырып китә...

Шул чак көтмәгәндә каяндыр гудок тавышы ишетелә һәм пристань ягыннан безнең «Сирень» килеп чыга. Аның бөтен палубасы соры шинель кигән кораллы солдат белән тулы. Өске басмада һәрвакыттагыча тәкәббер кыяфәтле капитан Шаһиморатов, кулы белән безгә таба төртеп күрсәтә-күрсәтә, үз янындагы погонлы офицерга нидер сөйләп бара.

Аның кулында элмәкле озын бау. Пароход безгә якын ук килеп житкәч, Шаһиморатов шул бауның элмәкле очын көймәгә ыргытты да, Миңзифаны биленнән эләктереп алып, күз иярмәс житезлек белән өскә күтәртә башлады. Ә мин көймәм белән бергә пароход көпчәге астына кереп менә-менә һәлак булам дигәндә, куркудан уянып киттем.

Гаҗәп хәл, инде уянып, куркыныч төштән арынган булсам да, мин әле һаман саташам кебек. Хәлем бик авыр, бөтен тәнем кыйнап ташлаган кебек сызлый, колак шаулый: бер кәлимә сүз әйтерлек, күземне ачып карарлык та хәлем юк.

Кемдер минем хәлне сизде, күрәсең, авызга кашык белән су салды.

— Чү, уяна, аңга килә бугай,— дип сөйләнә-сөйләнә тирле маңгаемны сөртеп алды. Бик кыенлык белән күземне ачып карасам, юнга Чурков утыра икән. Тик шунысы бик сәер, ул гадәттәгечә хәрби фор-

мадан түгел, ә никтер соры халат кигән, башына чалма кебек итеп ак марля ураган, үзеннән күңел болгатчык йод исе килә.

Шунда мин, тәмам аңыма килеп, ни булганын ачык абайлап алдым: соңгы сугыш күп иптәшләрнең һәлак булуы, утлы корабтан суга сикерүебез — барысы да берьюлы күз алдыма килеп басты, мин тагын каядыр төпсез упкынга чумдым...

Уянып яңадан аңыма килгәндә тәннең сызлавы бераз басылган, колак та баягы кебек шауламый. Маңгаема юеш сөлге куелган, кемдер беләгемне капшап, йөрәк тибешемне санап маташа иде. Юнга Володя Чурков бик җитди кыяфәт белән терсәгемнән тотып, минем пульсны санап утыра икән. Ул шат тавыш белән бөтен палатага хәбәр итте:

— Уяна, җан керә... Тереләчәк дип әйткән идем бит! Әнә, күзләрен ача башлады...

Күрше караватларда ятучы авырулар да, минем күңелне күтәрергә теләгәндәй, молодец, баһадир икәнсең, бирешмәдең дип, мактау сүзләре әйттеләр. Володя исә бер генә минутка да янымнан китмичә, йомшак күңелле няня кебек, гел кайгыртып, ни кирәк, шуны биреп торды. Ул сөйләгәннәрдән мин иң әүвәл үземнең «Христофор Колумб» йөзмә госпиталендә икәнемне, дүрт тәүлек саташып һушсыз ятканнан соң, бүген беренче мәртәбә аңыма килгәнемне белдем.

— Теге көнне суда снаряд шартлаганда мин читтәрәк идем,— дип сүзен дәвам итте Володя. — Сез икегез дә яраландыгыз. Син һуштан язып, миңгерәү балык кебек, дулкын арасында хәрәкәтсез калдың. Ә дядя Алимҗан тирәсендә су кан төсле булып кызарды... Мин аңа ярдәм итмәкче идем, ул минем белән маташма, әнә аны коткарырга тырыш дип, сиңа күрсәтте. Улымны онытмасын, ярдәмсез калдырмасын диде... Катерчылар килеп коткармаса, шунда без дә балыкларга азык булачак идек.

Якын дустым Алимҗанның үлемен ишетү миңа гаять авыр булды, күз алларым томаланып китте... Володяның да күзләре яшьләнде. Ул, бичара, берничә көн эчендә шактый ябыккан һәм зур халат кигәнгәме, ничектер олыгаеп киткән кебек. Аның элекке көязлегеннән карамыек төкләре генә торып калган иде.

— Дядя Алимҗанның кубызы минем кесәдә калган икән,— диде ул, чалбар кесәсеннән кубыз алып. — Аның төсе итеп саклыйм мин моны.

Аннары ул «Ваня-коммунист»ның һәлакәте, исән калган команда членнарының кичә Нижний Новгородка яңа кораб алырга китүләре турында сөйләде.

— Күпме ялынып үтенсәм дә, мине үзләре белән алмадылар. Тиздән кире кайтабыз, аягың төзәлгәч тә сине килеп алырбыз дип, мине шунда калдырдылар... Николай Григорьевич исән булса, әлбәттә, алай итмәс иде.

— Комиссарга ни булган, әллә ул да яраландымы?

— Яраланган гына булса иде!..— Володя авыр сулап куйды, халат җиңе белән яшьле күзләрен сөртте.— «Ваня-коммунист» белән бергә Николай Григорьевич та һәлак булды... Гәүдәсен дә тапмадылар...

Өченче көн, мин монда һушсыз яткан вакытта, корабларда матәм митинглары үткәргән булганнар. Бөтен флотилия исеменнән Мәскәүгә, иптәш Ленинга җибәргән телеграммада сөекле комиссар өчен ак бандитлардан аяусыз үч кайтарырга, аларны тиз арада тәмам тар-мар итеп, совет җиреннән бөтенләй себереп ташларга тантаналы вәгъдә биргәннәр.

Палатада ятучы авыруларның байтагы — безнең кораб матрослары. Юнга Чурковның бу хәлләрне миңа сөйләве, аларның авыр уй-хисләрен кузгатты булса кирәк, кемнәрнеңдер, тамак кырганы ишетелде, кайсыдыр, сулышы кысылган сыман, тирән уфылдап куйды.

Шунда Володя миңа якынрак иелеп, сер әйткәндәй, минем колагыма:

— Дядя Василь, монда бик чибәр бер медсестра гел сине карап, кайгыртып тора,— дип пышылдап әйтте.— Аз гына буш вакыты булдымы, шундук керә дә, йөрәк тибешеңне тыңлый, дарулар эчертә.

Володя сүзен әйтеп бетерергә өлгермәде, ул килеп тә керде. Башына кар кебек ак калфак кигән, алъяпкыч күкрәкчәсендә кызыл хач сурәте. Мин аны күрүгә үк танып алдым.

— Зифа, синме бу?! — Яткан җиремнән ихтыярсыз талпынып куйдым.

— Уяндыңмы... ниһаять...— диде Миңзифа кулымны йомшак кына сыйпап.— Кузгала күрмә, тик ят. Сиңа дулкынланырга ярамый әле, өзлегеп китүең бар.

Ул миңа авыз ачарга да бирмәде.

— Васил җаным, хәлең җиңеләйгәч, без синең белән һәммәсен дә иркенләп сөйләшербез әле... — диде Миңзифа. — Хәзер тыныч кына ят, йокларга тырыш, яме,— дип иркәле елмайды да, палатадан чыгып китте.

Берсеннән-берсе хәтәр куркыныч хәбәрләрдән һәм көтелмәгән күрешүдән башым әйләнә, уйларым бутала башлады. Күз кабакларым авыраеп йокыга талуымны сизми дә калдым.

Мин уянып, күземне ачуга, яныма тагын Володя килеп утырды һәм бик үпкәле тавыш белән врачлардан зарланырга тотынды:

— Бигрәк вакчыллар инде, юкка да бәйләнәләр: аягың төзәлмәгән дип, тәки чыгармадылар... Шулар аркасында үзебезнекеләр белән Нижнийга яңа кораб алырга китәлми калдым. Менә хәзер монда каңгырып ят инде.

Миңзифаның эше күп булса кирәк, безнең палатага врач обход ясаганда һәм авыруларга дару өләшкәндә генә бер-ике мәртәбә кереп чыкты.

Кичке аштан соң коридорда тынлык урнашкач кына ул минем янымда озаграк утырды.

— И белсәң икән, эш шундый күп, тын алырга да вакыт юк,— диде ул, көттергән өчен гафу үтенгәндәй елмаеп.

Бу юлы без иркенләбрәк сөйләшә алдык. Минем бер җирем дә яралы түгел, каты контужен булганмын икән. Колаклар шаулавы шуның аркасында, димәк.

— Теге көнне, каты сугыштан соң, иптәшләрең сине һушсыз хәлдә бирегә китергәч, бик курыккан идем,— диде Миңзифа. — Болай булгач, шөкер инде, акрынлап рәтләнерсең кебек.

Миңзифа үзе бу йөзмә госпитальгә миннән өч көн генә элек килгән икән. Аны монда бер хатын җибәргән булган. Үлем баржасы артыннан этисен эзләп барганда, Алабуга пристаненда очраган әлеге хатын аңа шуннан ары барма, харап кына булырсың, дип әйткән һәм аның медичка икәнлеген белгәч, йөзмә госпитальгә эшкә урнаштырган.

Исхак абыйның беркөн судан табылган фуражкасы келт итеп искә төште. Әмма ул хакта әйтеп, Миңзифаның соңгы өметен өзәргә минем телем бармады.

## XIX

Хәлем акрынлап җиңеләя бара.

Безнең госпиталь фронттан шактый еракта, нарат урманы белән капланган биек тау каршында якорьда тора. Әйләнә-тирәдә гадәттән тыш тынлык, дөньяда бернинди сугыш, аяусыз кан коюлар юктыр шикелле. Күк күкрәгәндәй, ара-тирә еракtan ишетелгән туп тавышлары гына кайдадыр офык артында каты сугышлар барганын искә төшереп тора.

Без, инде савыгып килүчеләр, баш врачны күргән саен тизрәк госпитальдән чыгаруны сорап аптыратабыз. Тик ятудан котылырга теләп, кайберәүләр камбузда бәрәңге әрчешәләр, яр буеннан коры утын җыеп керәләр. Юнга Володяга машинистлардан кемдер гади тимер чыбыктан берничә кармак әмәлләп биргән. Шул безгә бик ярап куйды тагын, күп вакыт койрык якта балык тоткан булып утырабыз. Володя, әллә нидә бер бәләкәй генә чабак тартып чыгарса да, бөтен пароходны ду китереп шатлана.

Кайчак ул чалбар кесәсеннән тиз генә кубызын ала да, эчке дулкынлану белән бирелеп уйнарга тотына. Уйнап туктагач, кем алдындадыр горурланырга теләгәндәй, җырның күңеленә аеруча якын ике юлын телдән дә кабатлап куя:

...Врагу не сдается наш гордый «Варяг»,
Пощады никто не желает...

— Карале, дядя Василь,— ди ул, бермәл уйланып торганнан соң,— безнең «Ваня-коммунист» та нәкъ шулай булды бит: дошманга бирелмәде, беркем дә калтырап төшмәде... Шәп җыр, юкса Николай Григорьевич аны яратып җырламас иде...

Ниһаять, савыгып килүчеләрне берәм-берәм дәштереп, комиссия аша үткәрә башладылар. Бүген кичкырын Володя белән миңа да чират житте. Баш врач Володяны хезмәттән азат итеп, балалар йортына укырга җибәрмәкче булган иде. Юнганың күзләре яшьләнүен күргәч, фикерен үзгәртте:

— Мин сиңа яхшылык теләп шулай эшләмәкче идем... Ярар, алайса синеңчә булсын, корабка бар. Тиздән, кышка туктар вакыт житкәч, калганын шунда хәл итәрбез...

Озаклап тикшергәннән соң:

— Бетте, өстеңә киен... Бәхетең бар икән, егет, контузиянең эзе дә калмады, имән кебек тазасың... Хезмәтеңне дәвам итәргә рөхсәт бирәм, юлга әзерләнергә мөмкин,— дип баш врач мине дә канатландырып чыгарды. Үземне инде болай да сау-сәламәт хис итсәм дә, атаклы врач әйткәч, күңелем икеләтә күтәрелеп китте. Коридорда Миңзифаны очрату белән:

— Таза-саумын, контузиянең әсәрен дә тапмадылар,— дип шатлыгымны уртаклашырга ашыктым.

— Тагы аерылышабыз икән,— диде ул, сулкылдап.— Эти китте дә эзсез югалды... Инде синсез дә калсам...

Мин ни әйтергә белмичә аптырап төштем. Коридорда болай тору уңайсыз иде. Миңзифаны култыклап каютасына керттем, кружка белән су бирдем. Ул тынычлангандай булды, ак кыекчасын салып, яшьле күзләрен сөртте.

— Син дә китеп югалсаң, ялгыз башым нишләрмен...— дип дулкынланып сөйләнә-сөйләнә, башымнан, битләремнән сыйпап иркәләргә кереште.

Моңарчы аның беркайчан мине иркәләгәне, үз итеп сөю сүзләре әйткәне юк иде. Без сүзсез генә аңлаша идек бугай. Әгәр ул хакта мин читләтеп кенә сиздерсәм дә, Миңзифаның йөзенә ризасызлык чыга иде. Хәзер исә аның гәҗизлегеннән күңелем тулып китте:

— Тукта, зинһар, алай өзгәләнмә... Мин бөтенләйгә китмим ләбаса,— дип аны юатырга тырыштым.

Миңзифа чәчләремнән сыйпап куйды:

— И, күрми дә торам, чал керә башлаган түгелме соң?

— Картайган бу дип миннән бизмәссең бит?..

— Юкны сөйләмә, зинһар! — Миңзифа миңа якынрак елышты һәм кайнар иреннәре белән колагыма пышылдады: — Их, белсәң икән, Ва-

сил бәгырем, көннән-көн көчлерәк яратам үзеңне. Тик син генә әллә нинди, суынган сыман. Элек син алай түгел идең...

— Авызың бер пешкәч, өреп кабарга туры килә ул. Теге чакны көймәдә хәтерең калганнан соң, тагын үпкәләтермен дип куркам.

— Чынлапмы, шуннан гынамы?! — Миңзифа җиңел сулап куйды, күзләре зур булып ачылды.— Ә мин, киресенчә, үземне гаепләдем, ул көнге көрпәлегем өчен үкенә-үкенә тәмам интегеп беттем...

Бу аңлашудан соң минем иңнән тау төшкән кебек булды. Бер-беребезне өр-яңадан табышкандай, шатлыгымнан:

— Гомерлек дустым, тормыш юлдашым минем...— дип Миңзифаны кочаклап алдым.

## XX

Бүген бездә көтелмәгән ике вакыйга булды.

Иртән кояш бераз җылыта төшкәч, койрык якта кармак салып утыра идек, елга уртасында агымга каршы менеп килгән моторлы катер күренде һәм берничә минуттан ук безнең госпиталь янына борылып туктады. Палубага гаскәри френч, кызыл йолдызлы фуражка кигән зифа буйлы яшь кенә хатын-кыз сикереп менде.

Бу безнең белән бер катерда Югары Ослаһга хәтәр разведкага барган һәм куркусыз кыюлыгы белән барыбызны да шаккатырган комиссар хатын Рейснер иде.

Лариса Михайловнаны танып белүчеләр бер мин генә түгел икән. Палубада булган бүтән авырулар да аңа хөрмәт күрсәтеп аяк өсте торып каршыладылар. Күренеп тора, бу очрашуга ул үзе дә шат иде. Һәркем белән кул биреп күреште. Бераздан бар халыкны аскы палубага җыелышка чакырдылар. Бөтен госпиталь халкы: ак халатлы врачлар, медсестралар һәм санитарлар, үз аягы белән йөри алырлык сырхаулар төрле әрҗә, такталардан әмәлләгән эскәмияләргә урнаша башладылар. Миңзифа килеп керүгә кинәт бөтен пролет яктырып киткәндәй булды. Ул эскәмияләр арасыннан җитез адымнар белән үткәндә күпләр аңа сокланулы карап алды. Моны ул үзе дә сизде һәм бераз каушады да бугай, минем яныма килеп утыргач, йөзе алсуланып, тагын да матурланып китте.

Бар халык урнашып бетүгә, канцеляриедән госпиталь башлыклары белән Рейснер чыкты. Алар түгәрәк өстәл тирәли утырышкач, баш врач кунакның кем икәнлеген, монда нинди максат белән килүен аңлатып нотык сөйли башлаган иде, Лариса Михайловна аны бүлдерде.

— Мин сезгә үтеп барышлый, бик азга, хәлегезне белергә һәм яңа газеталар биреп калдырырга гына кердем,— дип сөйләп китте.— Иң элек, иптәшләр, сезгә шуны хәбәр итәргә телим: күптән түгел генә яуда һәлак булган «Ваня-коммунист»ка алмашка Нижний Новгородтан шул ук исемдә яңа кораб кораллandырып җибәргәннәр, бүген-иртәгә аның бирегә килеп җитүен көтәбез. Командасына тәҗрибәле машинистлар, рулевойлар җитми дип хәбәр иткәннәр. Сезнең арада инде савыккан, хәл кергән белгечләр булса, без аларны яңа корабка чакырабыз. Көзге суыклар башланып, елганы боз каплаганчы аклар бандасын бу тирәдә тар-мар итәргә кирәк.

Лариса Михайловна чит илләр һәм фронт хәлләре турында да сөйләп үтте.

— Тагын бер күңелле хәбәрне әйтергә оныткан мын икән,— диде Лариса Михайловна, шат елмаеп.— Кичә безнең эсминецлар Гольяны пристанена кыю налет ясап, акларның борын астыннан «үлем баржасы»н алып чыктылар һәм дүрт йөз утыздан артык кешене үлемнән коткардылар...

Хәзер ак флотилия зур югалтулар белән туктаусыз артка тәгәри, безнең минага эләгеп шартлаган «Труд» корабы су төбендә ята. Дошманнар белеп торсыннар, аларның барысын да шундый ук язмыш көтә...

Лариса Михайловна «үлем баржасы»н телгә алу белән Миңзифа кинәт бөтен гәүдәсе белән калтырап куйды һәм кайнар дулкынлану белән: «Ишетәсеңме, азат иткәннәр... Исән булса, бәлки минем әти дә котылгандыр»,— дип колагыма пышылдады.

Лариса Михайловна сөйләгән вакытта бер-ике мәртәбә миңа игътибар белән караган кебек булган иде, китәр алдыннан саубуллашканда ул миңа тагын игътибар белән төбәп карап торганнан соң эндәште.

— Исемә төште: сез «Ваня-коммунист»тан бит — койрыкчы...— Хәлегез ничек, рәтләнеп буламы?.. Шулаймы, инде сау-сәламәтме... Алайса, яңа корабта хезмәт итәргә сез әзер?..

Мин көне-сәгате белән китәргә әзер булуымны әйттем. Лариса Михайловнаның күз карашы минем белән янәшә басып торган Миңзифага тукталды.

— Минем сезне дә кайдадыр күргәнем бар шикелле,— диде ул.— Алабуга пристанендә түгелме?.. Әйбәт урнаштыгызмы, эшлисезме?..

Без аны бөтен госпиталь белән озатып калдык.

Палатада тынлык. Төшке аштан соң була торган йокы сәгате.

Күзгә һич йокы керми. Борчулы уйларга чумган хәлдә, йокылы-уяулы ятканда, кинәт тирә-юньне яңгыратып якында гына гудок тавышы ишетелде. Тиз генә кузгалып тәрәзәдән карасам, елга уртасыннан буксир пароход менеп килә икән.

Менә ул фарватердан туры безгә таба борылды, кораб якыная төшкәч, террасаданмы, аскы палубаданмы кемнәрдер бөтен госпитальне күтәреп кычкырып җибәрде:

— Ур-ра, яңа «Ваня-коммунист» килә!..

— Ваня-коммунист!

— Тегесеннән зуррак та, көчлерәк тә күренә бу, туганкаем...

Мин тиз генә халатымны иңемә салып, алгы пролетка төшкәндә анда байтак кеше җыелып өлгергән иде. Яңа «Ваня-коммунист» корабы инде янәшә килеп туктаган, палубасы тулы матрослар безне кул болгап сәламли, командасының байтагы яңа халык, яшь-җилкенчәк.

Күрми дә торам, арада элекке «Ваня» да бергә хезмәт иткән дуслар да бар ич. Әнә өске катта, пулеметлар янында Вишневский белән Кармашов елмаеп торалар. Юнга Чурков аларны күрүгә:

— Дядя Воля, дядя Коля!..— дип кычкырып җибәрде һәм, борт аша сикереп, алар янына йөгереп менеп китте.

Мин дә яңа корабка кердем. Вишневский үз күзләренә үзе ышанмагандай:

— Василь дускай, синме бу?!.— дип гаҗәпләнде.

— Молодец, бирешмәгәнсең, болай булгач, адмирал Старкның арт сабагын укытабыз әле.

Вишневский төскә-биткә ябыккан булса да, үзе болай көр күңелле күренә. Мыегын кыргангамы, йөзе ачыла төшкән, коңгырт күзләре сынаучан карый: кин иңсәле базык гәүдәсеннән, бөтен кыяфәтеннән ашкыну һәм ихтыяр көче бөркелеп тора иде.

— Воля дус, үзең нихәл? — дидем мин,— һаман язасыңмы?

— Хезмәттән буш сәгатьләрдә тырышам инде... Тик шунысы аяныч, теге чакны Пьяный Бор янында «Ваня-коммунист» белән бергә минем язмалар да харап булды. Исеңдәдер, ул көнне мин десантта идем бит...

Без монда, өске каттагы пулеметлар янында бер-беребезне бүлеп, баштан кичкәннәрне сөйләп торганда, госпиталь террасасыннан Миңзифа кычкырды:

— Васил, Володя, чыгыгыз әле... Монда ашыктыралар, тизрәк җыенырга кушалар.

— Бу нинди медсестра сиңа шулай назлы эндәшә? — диде Вишневский.

— Бу — шул, мин эзләгән кыз инде. Казанда эзләгәнемне һич тә көтмәгәндә менә бирегә, госпитальдә таптым.

Вишневскийның йөзе яктырып китте.

Миңзифа, ашыктырып тагын дәшкәч, Володя белән миңа госпитальгә чыгарга туры килде.

Документларны тиз генә алдым да, Миңзифалар каютасына кердем. Ул минем кием-салымны инде алдан ук юып, үтүкләп куйган икән. Госпиталь халатын салып, үз чалбар-күлмәгемне, безкозыркамны кидем. Киң якорьлы каеш та бугач, миңа кеше төсе керде бугай. Миңзифа бер читтән сүзсез генә карап торган җиреннән:

— Хәрби форма ифрат килешә икән сиңа,— диде, авыр сулап, һәм миңа сыенды.— Васил, Рейснер йөзмә төрмәдәге тоткыннарны коткару турында әйткән иде. Әгәр әтине очратсаң, минем монда икәнемне әйт, яме... Васил, мин сине сагынып көтәрмен... Хатларыңны еш рак яз, мине онытып бетермә...

— Миңзифа, бердәнберем, син һәрвакыт минем күңелемдә булырсың... Тиздән, дошманнарны җиңеп кайткач, без кавышырбыз һәм бүтән һичкайчан аерылышмабыз,— дип яшьле битләрен үбә-үбә аны тынычландырырга тырыштым...

Менә мин яңа «Ваня-коммунист» корабында. Мәгәр монда кергәч, миңа тын алырга да бирмәделәр. Корабта Кама фарватерын белүче кеше — юл буе алмашсыз торып тәмам алҗыган бердәнбер лоцман хәзер каютасында үлеп йокыга чумган икән. Аның урынына мине куйдылар.

Шунлыктан, кораб кузгалып киткәндә, Миңзифаны рәтләп күреп тә булмады. Штурвал янында торган килеш рубканың ачык тәрәзәсеннән кул изәп кенә саубуллаша алдым. Госпиталь террасасында безне озатып калучылар арасында ак алъяпкычлы, ак кыекчалы Миңзифа бу минутта бигрәк тә сөйкемле һәм моңсу булып тоелды.

Түбәндә машина бар куәтенә эшли башлауга «Ваня-коммунист» зур тизлеккә күчте һәм үткен борыны белән елганы урталай ярып алга ыргылды. Йөзмә госпиталь артта калып, инде күздән югалган булса да, мин әледән-әле шул якка ихтыярсыз каерылып карап алам һәм террасада ак яулыгын болгап торган Миңзифаны күргәндәй булам.

Кораб зур тизлектә алга бара. Елганың сул ягында — Минзәлә пристане, без азат иткән яр буйлары. Алда, Пьяный Бор авылына җитәрәк, уң як ярда моннан өч атна элек каты сугышта безнең «Ваня-коммунист», комиссарыбыз Николай Григорьевич Маркин һәм ярты команда һәлак булган Малиновка култыгына күренеш ачылды.

Бу хакта бөтен команда тиз белеп өлгерде, палуба һәм өске басмалар шундук халык белән тулды. Пулеметчылар — барысы да яңа килгән яшь матрослар — рубка алдына Вишневский тирәсенә җыелдылар. Юнга Володя штурвал янына минем белән янәшәгә килеп басты.

Елгага очлаеп кергән тәбәнәк комлык турында кечкенә генә утраусыман су эченнән калкып торган нindидер каралҗым нәрсә күренде. Биноклҗдән карау белән йөрәгем жу итеп китте. Бу — шул үзе, яуда һәлак булган безнең «Ваня-коммунист» хәрабәләре иде. Корпусы яртылаш су астында, рубка һәм каюталары янып беткән, дошманнардан үч алырга чакыргандай, биек торбасы гына кичке шәфакъ кызыллыгында караеп тора иде.

Кораб командиры мачта очындагы кызыл флагны яртылаш түбән төшерергә, машинаны акрынайтырга приказ бирде. Сузып-сузып яңгыраган гудок тавышы палубадагы тез сафлар өстеннән елга киңлекләренә җәелде, кабарынкы ярларга, ерак урман өсләренә матәм моңы булып таралды.

Мул сулы чал Кама елгасының түбәнге агымында, Красный Бор авылыннан ерак түгел урында, нарат урманы эченә дугайланып уелып кергән текә ярлы мәшһүр култык бар. Дәһшәтле унсигезенче елның көзендә бу култыкта данлы кызыл флотилия отрядының акгвардияче бандаларга каршы батырларча сугышуы турында дулкынландыргыч бәетләр, риваятьләр сөйлиләр, җырлар җырлыйлар.

Красный Бор авылы үзәгендә комиссар Маркин һәм аның батыр көрәштәшләре — кызыл матрослар хөрмәтенә куелган һәйкәл — обелиск итәген мәктәп балалары чәчәкләр белән бизи, пионерга кергәндә алар Коммунистлар партиясе эшенә һәрвакыт турылыклы булырга тантаналы вәгъдә бирәләр. Безнең көннәрдә дә бу култыктан снаряд гильзалары табыла. Карт нарат кәүсәләрендәге яралар әле дә төзәлмәгән, урман кискәндә агачлардан кургаш ядрәләр килеп чыга.

Камада йөзгән мәһабәт теплоходлар, куәтле буксирлар бу култыкка җитәрәк йөрешләрен акрынайталар. Тантаналы-моңсу гудок тавышлары дулкыннардан-дулкыннарга күчеп хәтер ярларына килеп кагыла.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Чечен һәм ингуш мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Акыл акчага сатылмый.*
*Мәэлдәсәң — бүре ботарлый, тының чыкмаса — суеп ашыйлар.*
*Күпне теләгән — аздан коры калыр.*
*Киленгә дип кайралган теш үз малаен тешләгән.*
*Кәҗә мөгезе тотка түгел.*
*Атыңны тыңлаталмагач, ияр кыйнап ни файда.*
*Хатының белән киңәш тә шуның киресен эшлә.*
*Яңгырдан качып чапканда шарлавыкка егылган.*
*Сыерын инде урлаткач, ник абзарын биклисең?*
*Җимеше юк агачка беркем дә таяк атмый.*
*Пычракны су да юа алмый, чиста — утта да янмый.*

## Гәрәй Рәхим

# ОЛЫГАЮ

## Үлән арасыннан йөгергән бөҗәк

Күкләрдә кояш, җирдә чәчәкле җәй.
Парланып ята болында яшь кизәк.
Диңгез-елгалар тулы җылымса су,
Үлән арасыннан йөгерә бөҗәк.

Әлсерәп ята Җир июнь эссесендә,
Алты кыйтгасы алты җылы түшәк.
Алты кыйтганың кайсына юл алдың,
Үлән арасыннан йөгергән бөҗәк?!

Алты кыйтганың гаугалы бары да,
Борын-борынгыдан ил-халыклар үҗәт.
Сак бул, синең дә гомрең кыл өстендә,
Үлән арасыннан йөгергән бөҗәк.

Бикфорд шнурына юлыгырсың ялгыш,
Канатларың янар ялкында дөрләп.
Энтомолог энәсенә килеп эләгерсең
Үлән арасында күп йөрсәң, бөҗәк.

Кинәт өстеңә химикат сибәрләр,
Яки самолеттан атарлар төзәп.
Тукталган җиреңнән кузгалма, катып кал,
Үлән арасыннан йөгермә, бөҗәк!

Алты кыйтганың һәр мыскал җирен
Замана күзләре торалар күзләп —
Синең йөгерүең күптән экранда,
Үлән арасына качма да, бөҗәк.

Кайда соң Ватаның? Вавилонмы, Римме?
Әллә Бөек Болгармы — сыртың тулы бизәк.
...Син, дускай, тиз генә борыл да, кайтып кит,
Үлән арасыннан йөгер, бөҗәк.

## Өч плакат

ТРИПТИХ

1. ЫШАНЫРГА

Аллага ышанырга —
Мәхәббәт алласына,
Матурлык алласына,
Көч-рух алласына!

Ышанырга
Яшел чирәм арасындагы
Энә күзедәй нәни бөҗәк алласына,
Һәм динозавр, фил, кит алласына!

Ышанырга
Татарстанның Лениногорск районы,
Аланлык авылындагы чөгендер басуында
Моннан бик күп еллар элек
Әнкәм онытып калдырган көрәк алласына;
Шул ук авылда
Үзе үләсе көнне
Әткәм бүкәнгә чабып калдырган
Балта алласына!

Ышанырга
Җир өсте алласына
Һәм җир асты алласына;
Су өсте алласына
Һәм су асты алласына;
Ут һәм җил алласына;
Эт һәм кеше алласына!
Үз аллаңа һәм күршең алласына!

Ләкин ышанмаска
Өметсезлек алласына,
Җирдә бернигә дә, беркемгә дә ышанмау алласына...

2. САГЫНЫРГА

Сагынырга
Җир шарының тыныч киләчәген;
Юньле үлем белән үләчәгең
(Ул барыбер сиңа килми китмәс);

Сагынырга
Инде күптән үлгән,
Син белмәгән һәм белгән
Әти-бабаларыңны, апа-абыйларыңны,
Эне-сеңелләреңне, әти-әниеңне;

Бик сагынган чагыңны да сагынырга —
кузең яшьле чакны,
сугыш елларындагы фәкыйрь балачакны,
сагышлы йөзеңне —
үз-үзеңне һәрчак сагына бел!

һәм, әлбәттә, сагына бел
иң бәхетле көннәреңне,
сөйгәнең кочагында үткәргән төннәреңне,
шаркылдап көлгәнеңне!

3. КЫЗГАНМАСКА

Кызганмаска
Җирдәге беркемне дә һәм бернине дә.
Табигать бар иткән
һәрбер әйбер, һәр күзәнәк, һәр күренеш
Чиксез бөек.
Ә бөекләр кызганыч булмыйлар беркайчан да!

Шул исәптән син үзең дә!

## Сандугач

Сап-сары кош, сары сандугачкай
Җим эзләнеп йөри түтәлдә.
Сандугачым, һич уйламый идем
Күрермен дип сине бу хәлдә.

Бөек җырчы! Синең сайравыңа
Баш ияләр җирдә барчасы.
Табигатьнең бирдәнбере, даны,
Сайрый торган кошлар патшасы...

Чебен-черки җыеп көн итәсең...
Ничә очып килдең бакчама.
Горур шул син, сайрауларың өчен
Алмыйсың бер тиен акча да.

Без, кешеләр, алай түгелләрбез,
Эшне шактый оста йөртәбез.
Синнән мең кат ямьсез сайрасак та
Акчалата түләү көтәбез.

Сәхнәләрдә калай каккан булып,
Чыккан булып конкурс-ярышка,
Лауреатлар булып бетәбез без
Черки безелдәгән тавышка.

Ә үзебез сиңа сокланабыз
Тормышыбыз тук һәм мул чакта.
Сандугачлар ач түгелме, диеп,
Уйлау ярар иде шул чакта.

Көязләнеп затлы сәхнәләрдә
Көй ватканда бугач ертучы —
Черки җыеп яши сандугачкай,
Илләрара халык җырчысы.

## Мәхәббәткә мәхәббәт

Мин гашыйкмын сезгә, гашыйклар!
Сөюегез аркасында
юньле тормыш,
юньле куыш
Коралмаган мәхлуклар!

Мин сезгә гашыйкмын, сөюдә ялгызлар!
Бер юләр кыз аркасында
нинди әйбәт карьерадан
Коры калган ачык авызлар!

Бу тормышта шундый чарасыз сез —
Мәхәббәт дип
кар өстеннән,
боз өстеннән
Яланаяк барасыз сез.

Әй, мәхлуклар!
Бу дөньяда бар нәрсәне беләсез сез —
Сез астроном, врач, шагыйрь,
Нефтьче дә, академик, галим —
кылны кырыкка теләсез сез.

Тик бер сыйфат сезгә керми калган,
Ул — нәфрәт.
Аның урынын күңелегездә сөю алган.

Әй, син, кемсә!
Гаҗәпләнмә, әгәр иртәгәсен,
яки берсекөнгә,
яки башка берәр көнне
Минем бу ышанычымда үзгәрешләр булса.
Көн саен үзгәрә ич табигать үзе, дөнья.

Шунсын аңла ләкин:
Һич үзгәрмәс минем күңелемдә
Мәхәббәткә булган мәхәббәтем!

## Сары сагыш төсле сары чәчәк

Урман буйлап атлап бара идем,
Уйлар тулы иде башымда.
Сары сагыш төсле сары чәчәк
Йөгереп чыкты минем каршыма.

Мине күреп кинәт туктап калды,
Моңлы башы аска иелде.
Сары сагыш кебек сары чәчәк
Миңа бертуган күк күренде.

Ул да ахры рухи туганлашын
Танып алды минем йөземдә.
Сары сагыш төсле сары чәчәк,
Карамачы болай күземә.

Йөгереп үт әле сукмагымны,
Тизрәк китче минем алдымнан.

Мин үзем дә инде ничә еллар
Сары сагышларда кабынам.

Кабынам да янам, сула алмыйм,
Эчем тулы ярсу, ялкынга.
Тере чәчәк булып басып торам
Хәтта кышкы ачы салкында.

Ә син йөгер, урман ешлыгында
Ялгызың ян ятып ал чыкка.
Уртаклашмыйк, чәчәк, сагышларны,
Шатлык түгел бит ул тансыкка.

Сары сагыш төсле сары чәчәк
Тып-тын гына торды, дәшмәде.
Керфегеннән яшел үләннәргә
Тамды чаткы-чаткы яшьләре.

●

ОЛЫГАЮ

Мин үзгәрәм,
Төс үзгәртәм —
Чәчләремнең төсләрен...
Уй үзгәртәм,
Хис үзгәртәм,
Үзгәртәм үз сүзләрем.

Җәй соңында
Төс үзгәрткән
Яфрак сыман бугай мин.
Күзен чәчкә аткан гөлдәй
Көлеп сулам бугай мин.

Бер атлыйм да
Борылып карыйм,
Карыйм мин артка табан.
Тәҗрибәсез чакларыма,
Ялгышлы якка табан.

Ә бит хәзер
Бер ялгышсыз,
Шәп кеше мин,
Кара син!
Саф көмешкә
Манып куйдым
Чәчләремнең карасын.

Кара төсләр бетә миндә,
Яктыра бара каным.
Чәчем кебек, торган саен
Агара бара җаным...
...Мин үзгәрәм.
Төс үзгәртәм,
Көзге тугайлар сыман.
Кайчандыр сине куркыткан
Күзләремдә ак томан...

Бер дә куркытмый торган...

## Камил Кәримов

# БЕР АРБАДА

хикәя



Институтка кабул ителгәннәр исемлегендәге һәр кеше дус-ишләре белән шатлыгын уртаклаша иде бүген.

Гөлсинә тулай торакта юк иде. Очрашу турында алдан кисәтеп куймагач, кызлар дигәнең гел өйдә көтеп утыра алмый шул дип, гадәттәгечә, көтәргә булды Ильяс. Вакыт үткәрә торырга тулай торакта да юаныч бетмәгән.

Өч йөз унтугызынчы бүлмә... Бу дүрт катлы йортны шушы бер бүлмә өчен генә салганнар диярсең — бөтен матурлыкны үзенә җыеп тора. Буш вакыт булды исә шушында атлыга Ильяс. Әллә дуслар киләсен гел алдан сизеп тора, әллә Ильяска гына шулай тоела — бүлмә ишеге килгән саен ярым ачык. Казанка елгасына төшкән кояшны үзенә сыйдырган тәрәзә стенадагы һәр нәрсәне алсу фон гына итә бугай. Хәер, Ильяс бүген әнә шул фонда дүрт киштә, ә киштәләрдә кызыктырып укыйсыны китереп торган төрле китапларны да күрде. Элек тә булган ич алар, Ильяс кына игътибар итә белмәгән.

Гөлсинә дә кайтып керде. Таныш сораулар сибелде: «Нихәл?», «Чәй куйыйммы?», «Бәрәңге кыздырыйммы?». Кызык... биш ел буена бу сораулар ничә тапкыр кабатланды икән?!

— Әйдә бакчага, кычкырып сөйләшәсе сүзләр бар бүген.

— Әләй-әләй, чынлапмы?! Җиттек алайса!

Бакча дип иркәләп-зурлап кына әйтүләре инде — Казанка елгасына коенырга килгәндәй, яр читендә суга керәм-керәм, дип торган бер-ике төп имән белән тузгып яткан тал-тирәк кенә ул.

— Тагын берәр көн килми торсаң, вахтершага бөтенләй кертмәскә куша идем инде үзеңне.

— Вакыт тимәде. Сынаулар үтсен дидем.

— Сынау дип инде, синең ел саен ла ул. Август ае җитте исә, отпусканы әрәм итеп куясың.

— Тыңлап бетермәдең. Бу юлы мине институтка алдылар.

— Алсалар соң, шушы яшеңә җитеп, мәктәпне яңа бетереп килгән малай-шалайлар арасында укып йөрмәссең ич?!

— Куанмадың, шатлык уртак түгел, димәк. институт тирәсендә йөрүемә гел битараф идең...

— Конкурстан уза алмассың дидем.

— Көчле икәнемә ышанып тамы!

— Көчнең нәрсә икәнен беләсеңме соң син? Күтәрү-төшерүне аны фил дә эшли. Укуга бөтенләй башка көч кирәк.

— Анысын да табарбыз.

— Кырык ике экзамен, шулкадәр үк зачет бирәсең була.

— Булсын.

— Маркс — Энгельсның кырык алты, Ленинның илле биш томлык әсәрләрен конспектлаштырасы, шуның өстенә әле бүгенге доктор-кандидатлар да тик ятмый — бер-бер артлы дөньяга килгән китапларын өйрәнеп барасы. Түзәрмен дисеңме?!

— Син түзгәнне...

— Алданрак акыл бирүче табылса, гомерем буе гади эшче булып кына яшәгән булыр идем.

— Барыбер укыйм.

— Инде укуым бетте, кавышабыз дигәндә генә...

— Мин биш ел көттем, син дә көтәрсең.

— Дегенерат! Тагын биш елдан пенсиягә чыгар вакытың җитә бит.

— Дегенераты нәрсә тагын?

— Укыганда әйтерләр әле шунда. Ә хәзер бар, кит. Бөтенләйгә кит!

— Хыялыбыз нишли?

— Алып кит.

— Хуш, алайса, исеңә төшкәндә хат яз.

Гөлсинә, башка бер сүзеңне дә ишетергә теләмим, дигәндәй, ике кулы белән колагын томалады.

Бер атнадан ул Ильяска хат язасы кеше. Үпкәләшкән чакта әйтелми калган сүзләр аңа тынгы бирмәс.

«Хуш, шәкерт! Минем арттан ялынып кайтмадың, димәк, чынлап та укырга җыенасың. Бәхетсез булырга күптән үк әзер икәнсең. Утыз яшеңдә диплом аласыңны көтеп торыр хәлем юк. Шулай булгач, хушлашыйк»...

Ильяс, хат кисәген тураклап, кар бөртегедәй җилгә очырыр.

*
* *

Гөлсинә белән танышканнан бирле, кинотеатрга барганда сыңар билет кына алуын хәтерләми Ильяс. Бүген, Гөлсинә белән үпкәләшсә дә, бу гадәт үзенекен итте.

Сәнгать мавыктыру көченә ия шул — билет аласың да сәхнәдәге яки экрандагы вакыйгага килеп керәсең, программа беткәнче мәшәкатьләреңне онытып торасың. Ә Ильяска бүген аз гына булса да онытылып тору кирәк иде.

«Солярис» фильмы экранга яңа гына чыккан көннәр. Сәгать ярым чиратта изаланса да, ниятеннән ваз кичмәде — тәки ике билет алды Ильяс.

Сеанс башланырга әле ярты сәгатьләп вакыт бар. «Татарстан» кинотеатры тирәсендә сабантуй башланырга тора диярсең... Кая карама кеше. Кемдер тыныч кына көнбагыш яра, анекдот сөйли, кемдер, сәгатенә еш-еш карап, танышларын көтә, пошына, йөренә. Тораташтай басып торучылар да бар. Ильяс әнә тегеләрен — төркемгә кеше өстәлгән саен: артык билетыгыз юкмы,— дип бәйләнүчеләрне күзәтте, — араларында, күңел күзенә күренерлек бер кыз бар.

Биек үкчәгә менеп баскан да, кар өстендә тәпие туңган ана каз шикелле әле бер, әле икенче аягына таяна, күзләре гөлт итеп тора. Шулай да артык билет таба алмый тора. Ильяста бар ул барын, тик Гөлсинә килеп чыкмас микән?.. Тилмерә бит теге кыз билет эзләп. Ильяс шыпырт кына килеп аның колагына пышылдады:

— Фәрештәләр теләгеңне ишетте, билет китердем.

— Күпме сорасаң да риза,— дип чат ябышты кызый,— ике бәяме, өчме?!!

Мин спекулянт түгел дигәндәй, кул селтәп китәргә җыенган иде Ильяс, артык билет барлыкны сизеп бүтәннәр дә якыная башлагач, кызый дигәнең култыклап ук алды үзен.

Фойега кергәч, әллә куанычыннан, әллә гадәте шулай — кызый гел елмаеп торды.

— Премьераны алданрак карамасам, соңыннан кеше фикере колакка керә, анализлавы кыенлаша.

— Әллә тәнкыйтьләргә исәп?

— Юк, чирем шундый.

— Ә, ә...

— Кызыгыз киләсе идеме, миңа аның урыны эләктеме?

— Минем дә чирем бар, гел ике билет алам.

— Һәм көн саен яңа таныш... Күптәнме?

— Бүген беренче көн генә әле.

Кыз кеткелдәп көлеп куйды:

— Алайса танышыйк.

Һәм ул ирләрчә шапылдатып кул бирде:

— Эльза.

— Ильяс!

— Хатын-кызның яшен, ирләрнең семья хәлен сорамыйлар ди, монысына вакыт әрәм итмик... Ирләр ике төрле була: я аккуратный, я тормыш итүчән. Сез икенчесенә тартым.

— Сезне күргәч, исерекләр җыры җырлыйсым килә димәгәнеңә дә рәхмәт. Аккуратный булып карарга исәп. Бүген шундый көнемә туры килдең — теге дөньядан бу дөньяга күчеп килешем. Сөялле кулга китап-дәфтәр тотарга исәп. Ә син үзең кайсы районнан?

— Ленинградтан.

— Гафу итегез...

— Минем куллар, киресенчә, китап актарып кына сөялләнде...

Кайтырга чыкканда инде, күзгә текәлеп торган тулган ай тирәсендә йолдызлар әлҗе-мөлҗе килә иде.

— Озатып куяргадыр бәлки?

— Сорап торасы юк. Мин Казанда беренче тапкыр гына әле, кешегә бурычлы булып калырга яратмыйм, няләнгәчрәк үзеңне дә бер озатып куярмын, тагын шулай кинодан кайтышлый дим... Я ничек, фильм ошадымы?

— Үсмер кызлар кулындагы «мәхәббәт уставы» искә төште: беренче көнне кинолар турында, икенче көнне китаплар турында гына сөйләшергә, өченче көнне генә...

— Безнең яшьтә һәр кызның үз уставы. Тик чын-чынлап әйтегез әле, фильм аңлашылдымы?

— Космик станция, фантазия, ә яңалык юк шикелле.

— Бар яңалык, фәнни хезмәткәрләрнең һәр уйлаган уе күзгә күренә барды — яхшысы да, яманы да. Ә уйны йөгәнләп кара инде син!

— Бер дүрт-биш елдан очрашсак, бәлки бәхәсләшкән дә булыр идем, башка нәрсәләр турында пожалысты — машина, электр, техника хакында маңгайга-маңгай килә алам... Күп белгәнегезгә күрә соравым, берәр институттан соң килүгезме?

— Минем уставка беренче көнне барысын да сөйләп бетермә, тыңлыйсы килсә, егетең тагын килсен диелгән... Ярый, хушыгыз. Адресым менә шушы,— диде Эльза, йорт почмагындагы номерга төртеп.

*

* *

Әле кичә генә дигәндәй, диссертация яклап, кандидатлык мәртәбәсенә ирешкән яшь педагог система, концепция һәм башка шуның ише

сүзләр белән жонглерлык итә башлагач, Ильяс тәрәзәгә таба ук борылып утырды. Үзе дәрестә булса да, күңеле әле урамда, әле аудиториядә буталып тик йөри. Аптырабрак торган чагы Ильясның. Әлегә ул үзен кем дип тә атарга белми: студент дияр иде — студент билеты тапшырмадылар әле, югарырак курста укучылар махсус тантана әзерлиләр имеш, билетлар шунда өләшенәсе ди. Группадагы кайбер чаярак егетләр белешкәннәр — ул тантана күңелле кичә кебегрәк нәстә икән, «карт студентлар» әллә кем булып беренче курска килүчеләрне «молокосос» дип үртәп, студент билеты белән бергә аптекадагы биш тиенлек имезлек тә кушып бирәселәр ди. Каян килгән картлар! Диплом алырга вакыты житкәннәре дә Ильястан өч-дүрт яшькә кече бит әле... Хәер, эшче дә түгел инде ул бүген. Сигез ел эшләгәннән соң хезмәт кенәгәсенә: укырга керү сәбәпле эштән азат ителде дип пичәт сугылды. Берәү дә чакырып китермәде, киресенчә, шушы институтка керәм дип кечкенәдән хыяллана иде ул.

...Сагынды Ильяс эш бияләйләрен... Изүләренә тикле сумала сеңгән һәрвакыт көләч хезмәттәшләр, теләсә нинди биеклеккә дә чытырдап ябыша торган «монтер тырнаклары», баганалар, кая сез?!

Дәрес бирүче үз сөйләгәннәренә үзе ышанмый башладымы — тавышы әкренләп йокыны китерә торган изрәткеч бер көйләүгә күчте.

Ә урамда тормыш гөрли. Урамда хезмәт тантанасы. Чуен юллардан тыпырдап электр поезды үтеп китте: якындагы тукталышта резина ишекләрен шапылдатып троллейбус ишеге ябылды. Чатта светофорлар — кемгәдер кызыл, кемгәдер яшел... Урамдагы неон лампалар нурында шәһәр күге гөлт итеп тора.

ТЭЦ моржалары жир белән күкне тоташтырган. Менә сиңа, егет, система! Тенденция-концепция дә шунда. ТЭЦ тәүлеккә өч вагон ташкүмер яга. Колач житмәслек торбалар аңа Иделдән су китерә, өч вагон күмер пар ясый, ә пар өйләрне жылыта, шәһәргә ут бирә. Ут — су китерә, ут — күмер чыгара. Менә шушы чылбырның берәр өлеше өзелсә — шәһәрне көзге суык басып алыр, трамвай-троллейбус ишекләре жансыз калыр. Арча ягыннан килүче апалар каймак-катыкларын иңнәренә алып кала базарына тәпи-тәпи атларлар. Менә бу ичмасам система! Тенденция дә шушында гына — өч вагон күмер ТЭЦның тимер капкасыннан керә дә бер тәүлек эчендә буш бугаз моржалар аша кала өстенә ябырыла. Моржалардан чыккан кара болыт сабын куыгыдай күзгә күренеп өрелә дә, күктә эленеп тора алмыйча, әкрен генә жиргә төшә... Һәм көн саен шулай. Жәнжал чыгарырлык тенденция бит бу. Ә жәнжал чыкмый, ник дисәң, шәһәрнең төн жылысы кадерле.

Дәрес бирүче, алтын балдаклы бармагы белән өстәлгә суккалап, лекциясен бүлде.

— Рәхимов! Язып утырсагыз, ничек булыр икән?

— Язмыйча да бәгырьгә сеңгән,— дип мыгырданды Ильяс һәм дәфтәрдәге система, тенденция, концепция сүзләренең астына сызып куйды.

*

* *

Студент я укуда, я күңел ачуда дисәләр, белегез, ул әле йокыда да булырга мөмкин.

Ильяс ордерда күрсәтелгән егерме тугызынчы бүлмәгә ярым ачык ишектән килеп керде. Керсә — пычрак түфлиең белән биесәң дә эз төшмәслек идән, тәмәке төтененнән ысланган стеналар, мунча тәрәзәседәй сөремләнгән өлгеләр...

Ильясны тагын шунысы хәйран калдырды: койка кырындагы утыргычта тәмәке пыскып тора, койкадагы кеше жәймә белән башыннан ук

бөркәнеп, гырлап йоклап ята — әллә бу йокы аралаш имезлек итеп тәмәке суыра микән, әллә саташып кына кабызганмы? Аңламассың. Сәгать кичке алты — иртәдән уянмаганмы бу, әллә йокларга ятканмы? Көтеп карасаң кайчан уяныр иде икән? Тик кешенең йокы туйдырганын көтеп утырыр чакмы?!

Ильяс өстәлдәге будильникның колагын борды да көйрәп торган тәмәке янына куйды. Тәмле йокыны бүлергә маташкан көчле шалтырауга җәймә астыннан киелмәгән эш бияләе кадәр бер кул чыкты да будильникның төймәсенә басты. Шуннан соң кул эзләнә башлады. Ильяс тиз генә тәмәкене читкәрәк этте һәм өстәлдәге шикәр савытыннан бер шакмак шикәр алып салды. Әлеге кул шикәрне одеал эченә алып кереп китте. Йокы дәвам итте.

Әй кул, ничава, дип уйлап куйды Ильяс, әрәм тамакларныкы хәтле, бармаклары — биш кашык, уч төбе — аш чүмече. Зурлыгы бер хәл, кершән төсле ап-ак бит әле — туганнан бирле физик эш күрмәгән бугай. Студентны әрәм тамак түгел дисеңме?.. Ильяс үз кулларына карады — нәфисләнә бит, сөяләре дә бетеп бара.

Тәрәзәне ачкач, бүлмәгә октябрьның җиләс һавасы кереп тулды. Күптән шулай кирәк икән — җәймә астындагы җан иясе, җылы эзләп бөтерелә торгач, уянды ахрысы — тавышы ишетелде:

— Ябыгыз тәрәзәне.

— Тор да яп.

— Сәгать ничә соң әле?

— Алты.

— Иртәнгеме, кичкеме?

— Барыбер түгелмени,— диде Ильяс, сәерсенеп.

— Кичке булса инде йокларга ятар чак житкән. Ә иртәнге алтыдан торып көтүгә чыгасым юк, йоклыйм,— диде тавыш.

Өстендәге җәймәсен ачып карагач таныды Ильяс: курсташ егет Хөсәен икән. Студент тормышына кушылганга бер ай чамасы гына, әлегә юньләп аралашкан да, танышкан да юк. Шулай да Хөсәеннең тау ягы егете икәнен беренче көннән үк хәтерләп калган иде Ильяс. Йокы белән булышкан икән, дәрестә дә күренмәгән иде Хөсәен. Ул тизрәк группаның профоргы Ильяс алдында акланырга керешге, эзләп килгән дип тә уйлады, ахрысы.

— Җәй буе көтү көттерделәр миңа. Юньләп йокы күрмәдем. Әти инде... укыйсың килгән икән, бераз акча җый,— диде.

— Җыйдыңмы соң?

— Бер ел стипендиясез дә укырга була.

— Болайга китсә, чыннан да стипендия өләшкәндә йоклап калуың бар.

Уңайсыз хәлдән чыгар өчен Хөсәен сүзен шаяртуга борды:

— Йоклаган кешегә чир-фәлән тими ди. Микроблар киләләр дә, уята алмагач, кул селтәп китәләр икән. И гомумән, ялкаулык дөньяны яңартуга китергән ул: кеше җәяү йөрергә иренгәч тәгәрмәч уйлап тапкан, хат язмас өчен — телефон, трактор ясап сабанлы ат артыннан йөрүдән котылган.

— Бәлки парталар урынына да ястыклар гына тезеп чыгаргадыр?

— Гипнозлап укыту бар ул! Чын әгәр! Аудитория гырлап йоклый, ә бер кандидат аларга лекция укып йөри...

— Әгәр ул да йокыга китсә?

— Әй, бөтен кеше көтү көтмәгән лә.

— Тор! Ике ай көтү көткәнсең, ә үзең карт көтүчеләр төсле зарланасың.

— Әти каешыннан котылып, иреккә чыктым дигәндә генә...

— Үги әтиең булырмын, дәрес хәзерләргә өйрәтермен, иренмәм, һич югы унсигез яшең тулганчы гына. Калганын күз күрер...

— Нәчальство дигәч тә, шулхәтле...

— Мин әле абый тиешле кеше буларак кына.

— Абыйларымның институт бетергәненә инде.

— Ә мин ашыкмадым, эшли тордым. Ярый ла синең тәмәкелек акча җибәрүче каешлы әтиең бар. Кыскасы, бер бүлмәдә яшәргә туры киләчәк безгә.

— Ник соң алдан ук шулай димәдең?

Һәм Хөсәен тузанлы телевизор экранына зур хәрефләр белән «уборка» дип сызгалады.

Тәрбия эшендә кешенең шәхси ихтыяҗларын исәпкә алу дигән төшенчә бар. Ильяс та Хөсәенне каланың бер яслесенә төнге каравылчы итеп урнаштырыр. Теләсә йоклар, теләсә дәрес хәзерләр. Монысы инде аның эше... Әлегә, тулай торакның егерме тугызынчы бүлмәсендә узган елгы студентлардан калган тузаннардан котылу ыгы-зыгысы. Иртәгесен бүлмәгә атылып кергән берсе шып тукталып калыр, катларны бутап, башка бүлмәгә килеп эләктемме, дип, ишектәге номерны чыгып карар. Анда егерме тугыз саны күргәч, тиз генә зиһенен җыя алмыйча аптырап торыр. Аннан соң гына, көне буе аяктан салынмаган туфлиенең бавын сүтә башлар.

Яңа урында бөтен нәрсә зураебрак күренә бит ул. Өзлексез ишек шакып йөрүче тулай торак «тукраннарына» күнегеп җитә алмады Ильяс. Язылачы рефератка кырык төрле мәшәкатьләр белән табылган китаптан әяла-әяла гына бер абзац күчереп, нокта куярга өлгермисең — «тукран» шыкылдый: «тек-тек», «тук-тук», «даң-доң». Җавап бирмичәрәк торсаң, бусагаңа ук тибә башлыйлар.

«Утюг биреп тор!»

Китабыңның бер өлешен күчереп икенчесенә тотынганда гына тагын шул ук хәл:

«Артык ручкаң юкмы?»

«Өч кенә сум акча кирәк иде».

«Юылган ак күлмәгең бармы?»

Менә шушындый шартларда китап күчереп, фу черт, реферат язып кара инде син. Түзмәде Ильяс, бирердәй нәрсәләрен биреп, бүлмәне бушаткач, бу казадан котылу чарасына кереште. «Утюгыбыз янды, ручкам үземә генә, акчам беткән чак, күлмәкләр юыласы, сабынны күршегә бирдем, ак җеп үзебезгә дә юк»,— дип зу-ур бер кәгазьгә исемлек төзеп ишекнең тышкы ягына ябыштырып куйды.

*
* *

Җәйге каникулга чыгу бәйрәм булса, укулар башланган көн тагын бәйрәм ул.

Институт ишеге төбендә, фойеда, ашханәдә — кая карама, әле сынау-имтихан сессиясенең йокысыз төннәрен татып карамаган, шуңа күрә дә үзен Ильяслардан мең тапкыр бәхетлерәк санаган беренче курс студентлары күкрәк киереп йөри.

Кыңгырау җәйге каникулдан таралышучыларны аудиториягә чакырды.

Өч ай буена җыйналган яңалык телдән колакка күчә. Юньләп тыңлаучысы гына юк, һәркем җае чыгу белән үзенекен тезә. Беренче дәресне расписаниедә «серләшү сәгате» дип кенә язып куйсалар икән.

«Серләшү сәгате»ндә Ильяс бер нәрсә шәйләп алды. Каникулга киткәнче үк режиссура белгече, куратор Ирина Витальевнаның сылу гәү-

дәсенә әллә нәрсә булган иде. Ә хәзер, хәтта иңбашыннан ук төшә торган җәенке итәкле күлмәк кисә дә тулып килгән йөген яшерә алмаган. Дәрескә дә журналсыз гына кергән ул бүген.

— Сүзнең бетәсе юк,— диде Ирина Витальевна кыяр-кыймас,— аз гына көтеп торыгыз, мин хәзер.

Кафедрадан әйләнеп кергәндә алар икәү иде.

— Инде сер түгел, мин ялга китәм. Бер елсыз күрешә дә алмабыз шикелле, шуңа күрә сезне яңа укытучыга калдырам. Кагыйдә буенча, ул сезгә хәзер куратор да. Таныш булыгыз.

— Эльза К.— диде Ирина Витальевнага ияреп кергән кыз. Ул әлегә шуннан артыгын әйтә алмады. Чөнки бер мизгелдә аның өстенә алтмыш алты күздән утыз өч төрле сынаулы караш килеп төште. Рәхәтләнеп күзәтеп өлгерсеннәр, дигәндәй, пауза озакка сузылды. Ильяс чиктән тыш сәерсенүен яшерергә тырышты, чөнки таныды ул — Ленинградтан күченеп йөрим дигән очраклы кыз — Эльза үзе иде бу.

Ирина Витальевна бүлдермәсә, һәр утыз өчесендә уйланырга уй җитәрлек иде әле.

— Көче белән генә тапшыру килешмәс, умарта оясы түгел. Журналдагы тәртиптә таныштырып барыйм: Аблушев! Бас, Хөсәен.

Тау ягы халкы шул, гел кояшка күнеккән, бигрәк җылы ярата Хөсәенебез, утырган урыны җылыткыч, я мич тирәсендә булыр. Вильданова Миләүшә — староста, группаның иң көчле кешесе — калканы да үзендә, кылычы да. Тамарабыз — Волгоградтан, быелгы җәйдә төзелеш отряды белән Астраханьга барышлый бөтен группаны өенә алып кереп студентлар эшелонына соңга калдырган. Аннан соң тәүлек буе Мамай курганында йөргәннәр... Кадрия — факультетның алтын балыгы — эшли алмаган эше, таба алмаган әйбере юк — кайнанасы зур гына базаның мөдире. Римма — башкорт кызы, елъязмачы... Ильяс — профсоюз вәкиле, группаның аксакалы.

Моңарчы, атаган исемнәргә, хәтерләп калдым дигәндәй елмаерга тырышып сүзсез генә баш изәп торган Эльза түзмәде:

— Аксакалыгызга ничә яшь дисез?

— Егерме жиде.

— Шушы көнгә кадәр кайда йөргән соң ул?

— Багана башында,— диде Ильяс аягүрә басып,— башта ук үземнән генә сорарлар. Институтка кадәр сигез ел электрик булып эшләдем мин...

Ниһаять, таныштыру тантанасы тәгәлләнде.

— Миңа китәргә вакыт. Яңа укытучыга тәкъдим итәр өчен генә килүем иде. Сау булыгыз. Карагыз аны, бер елдан килеп житәм, рәтләрегез сирәгәймәсен.

Эльза группа уртасында берүзе калды.

Юл башына чыгып баскач, сәфәрче кеше биштәрен төзәтә. Эльза да шушы минутка дип әллә кайчан әзерләп куйган сүз башын үзгәртергә ниятләде бугай. Беренче дәресе студент шулпасын бер ел буе чөмергән өлкәнрәкләргә туры килде шул... Патшасы ял иткән арада гына дип, тәхеткә утыртып куйдылар да, теләсәң нидән башла хәзер.

Эльза әйтер сүзен барлаган арада, аудиториядә күңелсез тынлык урнашты. Ул, чылбырлы күн сумкасын ачып, кирәкмәсә дә ручка эзләгән булды, комачауламаса да, маңгай чәчен сыпыргалады.

— Барыгыз да сәхнәгә,— диде ул, ниһаять,— дүрт рәткә тезелеп басыгыз. Темпо-ритмга күнегү. Урында атлау, адымнарның ритмы: беренче рәт бер адымны бер секундта, икенчесе — ярты, өченчесе — чирек, дүртенчесе — сигездән бер секундта атлый. Мин кул чабуга, башлыйбыз. Ягез, и-и!

Башладылар, тик ни дип әйтергә инде моны! Әгәр бу күренешне те-

левизордан күрсә, үзбәк: «Саман әзерләр өчен балчык изә болар»,— дияр. «Юктыр,— дияр молдаван,— эчемлек өчен йөзем таптый», тау ягы халкы карап-карап торыр да: «Көтү кайта бугай»,— дияр.

Эльза көч-хәл белән туктатты аларны. Туктатты да һәрберсенә шар тоттырды.

— Күкрәк киереп сулыш алыгыз да өрегез шарны, бер генә кат... Я, хәзер инде чагыштырып карыйк, кемнең сулышы иркенрәк икән?.. Ильясның шары иң зурысы. Күрдеңме, Миләүшә, гәүдә зурлыгы сулышны кыса икән.

— Бетмәде әле,— дип дәвам итте Эльза, яшьләргә ял итәргә дә ирек бирмичә,— хәзер баскан җиregездә үк утырышыгыз. Син дә утыр, Кадрия, кызганма тәти күлмәгеңне, режиссура дәресенә униформасыз йөрмиләр... Утырыгыз. Тынычландыгызмы? Инде күз алдыгызга китерегез: биеклек... Я, кем ничек итеп күрә биеклекне?

Уфылдап, шабыр тиргә батып, инде башка вакытлардагыча сикерерлек тә, артыгын сөйләрлек тә рәт калмагач, Эльза дәресне башлап җибәрде.

Ирина Витальевна әйбәт кеше иде, дәрескә керә дә эшлисе эшне билгели. Шуннан соң гына, башындагы фантазияне көннекен-көнгә сәхнәләштереп өлгерер өчен һәркем җаны теләгәнчә бии, җырлый, кылана — сәхнә теле белән купшырак итеп әйтсәк, импровизацияли иде. Ә Эльзаның бүгенге кебек тир агызгыч күнегүләреннән соң тиешсезгә һич артык хәрәкәт тә ясыйсы килми, кушканны гына үтисең.

Дәреснең иң кызган бер чагында, аз гына сулыш алырга дип тәрәзә янына килеп таянган Хөсәен (ул инде ял итү дигәндә мизгелне дә кулдан ычкындырмый) урам ягына текәлде.

— Ирина Витальевнаны алырга такси килде! Стоп — кадр!

Бүлмәдәге бар хәрәкәт, гүя, үлеп калды. Ләкин тынлык ул кадәр үк озакка сузылмады. Шул арада, репитициядән дә болайрак ыгы-зыгы куптарып, бөтен группа ишеккә ябырылды. Аларга Ильяс та ияргән иде, ләкин ярты юлдан кире борылып керде. Эльза бүлмәдә ялгызы, тынлык эчендә бер үзе.

— Бәлки сез дә,— дип башлаган гына иде Ильяс, ул аңа шундук ялгап китте.

— Әйе, әйе, Ирина Витальевнаны мин дә озата чыгам.

*

* *

Сәгатьләр шалтырады. Бүлмәләр санының йөз егерме икәнен исәпкә алмаганда, әллә ни шаккатырлык күренеш түгел, әлбәттә... Иртәнге эңгер-меңгерне челпәрәмә китереп лампалар кабынды.

Юыныйм дисәң — торбалардан су агып өлгерми, кырыныйм дисәң — электробритваны көтеп алыр хәл юк. Һәркем ашыга.

Ильяс тулай торакның тугыз катын да бергә ялгап торучы баскычка чыкты да студентлар агымына кушылды. Дәрес башланырга вакыт азайган саен, ыгы-зыгы көчәя барды.

Студентка ике генә нәрсә җитми диләр: берсе — акча, икенчесе — вакыт. Акчага кытлык күрмәде Ильяс, ни дисәң дә, укырга кергәнче аз эшләмәде. Бераз запас та бар, кием-салымы да җитәрлек. Ә менә вакыт дигәне җитми тек җитми инде, тәүлектә егерме дүрт сәгать — кая гына бүлеп бетермәк кирәк.

Группада иң өлкән егет булгач, җитдилегенә ышанып, аны профорг итеп сайладылар, таләпчәнлеген сизеп алып, студсовет члены иттеләр. Профкомның факультет бюросында «көнкүреш мәсьәләләре секторына», яшьләрнең иҗади берләшмәсе «Данко» клубына, бәйрәм комиссиясенә

сайладылар. Кыскасы, төбе-тамыры белән институтка беркетеп куйдылар үзен.

Әгәр әҗәткә вакыт биреп торучылар булса, Ильяс инде муеннан бурычка батасы кеше. «Нихәл, Ильяс?»— дип сорасаң: «пока жырлыйсы килә әле»,— дияр. «Кайчан ял итәрсең икән, Рәхимов»,— дип сораучыларга: «укып бетергәч авылга кайтам да сәгатьләр тукталганчы йоклыйм әле бер»,— ди. Әйтүен әйтә, ләкин алда үзен бүгенгедән дә күбрәк мәшәкатьләр көткәнен белми.

Кулына диплом алган сәгатьтә үк институттан чыгып китәр ул. Дуслары үпкәләп калыр:

«Банкетны ташлап кая барышың, шул хәтле туйдыңмыни бездән?»

«Самолетка билет алып куям, миндәй яшь белгечне зарыгып көтәләрдер»— дияр ул елмаеп кына.

Район культура йортына режиссер итеп билгеләнгәч башланыр инде аның иҗат газаплары... Гамәлгә ашарга теләп тә, күп сәбәпләр аркасында ярты юлда гына калган фантазияләр; югарыдагы житәкчеләрнең чәчләрен үрә торгызырлык яңа таләпләр; саран отчетлар, сәгать ярымлык ял программасын оештыру өчен сарыф ителгән көннәр — атап әйткәндә, конфликтларның тулы жыелмасы көтә егетне. Периферия, провинция, калыма, кышлак, хутор һәм тагын әллә ниткән шуның ише атамалар белән шәһәр егетләренең теленә кергән бер район үзәгендә яңгыратып яшәр ул... Монысы киләчәге. Ә әлегә Ильяс Рәхимов институт баскычында.

Кыңгырау шалтыраса да, соңга калмады ул. Фамилиясе Р. га башлангач, журналда аның исеме иң ахырда һәм Эльза прогульщикларны, ялкауларны, кәефсезләрне барлап Ильяска килеп житкәнче никадәр вакыт отарга була. Хөсәеннең генә, Аблушев булгач читенрәк, исемлектә ул иң беренче, гөнаһ шомлыгы, гел соңарырга ярата ичмасам.

Яңа укытучы Эльза, эшне яңачарак тотарга ошый:

— Сез,— дип башлады ул тавышын күпертеп,— Ирина Витальевна барында артык иркәләнгәнсез. Бүгеннән соң режиссураның һәр дәресе алдыннан оригиналь сюрприз әзерләрсез. Ягъни мин керүгә этюд яки фрагментлар күрсәтергә тиешсез. Уйланырга да иренеп утыручы ялкауларга каршы һөжүм ачам. Иҗади киеренкелек белән яшәргә өйрәнегез.

— Дәрескә дә яртышар сәгать алдан килергәме?

Хөсәеннең ярты сәгатьлек таң йокысы ике пот бал исәбенә тора. Шулай да аның соравына җавапны бөтен группа көтә иде.

— Әйе.

Ильясның дә кәефе кырылды... Ифрат сәер кеше икән бу Эльза К. Ирина Витальевнага һич кенә дә охшамаган. Сыный карагач, әллә ничек кенә, Эльзочка дип дәшәсе килә үзенә. Югославкский джинси чалбарына ничек сыйган диген, ничек балагы шартламый диген?! Шуңа күрәдер әле, ул күп вакыт дәресне аяк өсте генә үткәрә. Утыра калса да, тезен туры тотып, билдән генә бөгелә, нәкъ урталай сынган кебек. Тездән бөгелергә күнекмәгәч, аяклары өстәл астыннан сажен таягыдай алга чыгып тора. Чалбар балагы кыска кунычлы чешский итекләргә кыстырылган. Японский ак свитерын да ертмыйча гына ничек киеп, ничек саладыр,— сыланган, тәненә ябышкан төсле. Хәтта аркасының бер төшендә нәни генә өч сәдәф эзе дә беленеп тора. Матур күренергә телим дип шушы тикле кысан кием эчендә йөр инде син, ә?!

Институтта көн дә әнә шулай үзгәрешсез иде Эльза. Әйтерсең, ул кич житүгә аудиториянең бер почмагында посып тора да, икенче көн дәресләр башлангач, янә килеп чыга. Һич югы берәр төше үзгәрсә икән, ачуың килмәгәе, чәче дә селкенмәгән.

— Барыгыз да сәхнәгә,— диде Эльза, җәһәт кенә.

Сәхнә дигәне уникенче аудиториянең икенче яртысында бер метр чамасы күтәртеп җәелгән ак идән инде.

— Сезгә бу яртыеллыкта эпизодлар эшлисе. Кем кайсы әсәрдән өзекләр ала?

«Гамлет».

«Ромео и Джульетто».

«Король Лир».

— Бигрәк кыю да соң бу студент халкы,— дип бүлдерде аларны Эльза кинаяле итеп,— инде ун елдан бирле академия театры да сәхнәләштерергә тәвәккәлләмәгән Шекспир әсәрләрен тота да сәхнәгә куя. Батырлык бу! Ләкин минем Маяковский, Брехт исемнәрен дә ишетәсем килә. Әйдәгез, декорация, б... форня, реквизитларны — символ, аллегория, шартлылык белән алыштырып карыйк. Хәтта пәрдәне дә юк дип санагыз. Мизансценалар телендә генә сөйләшик.

— Хәрәкәттә бәрәкәт!

— Әйе, Рәхимов, хәрәкәттә.

— Станиславский системасын инькар итергә дә күп сорамассыз сез.

— Сәхнәдә законлашып, үзгәрмәс хәлгә килгән күренешләрне яратмаган Станиславский: «гел әзләнергә, шартлылыкны аңлаешлы итеп бирә белергә кирәк»,— дигән. Мин ышанам, сезнең арагызда да Мейерхольд, Охлопков, Вахтангов, Любимов кебекләрнең эшен дәвам итә алучы кеше үсәр әле.

Мин ул, мин, диешкәндәй, һәркем тураеп басты.

— Ирина Витальевна ишетсә шаккатыр иде.

— Юк, Рәхимов, без уку программасыннан тайпылырга җыенмыйбыз, образларны тудыру юлын гына баетабыз, бары тик шул гына.

Дәрес бетүгә, Ильясны стена газетасы редакторы көтеп тора иде, һәр санда студентлар иҗаты сәхифәсенә авторлардан материаллар җыйнау аның өстендә. Редактор рәхмәтен ишеткәч, фәнни түгәрәк җитәкчесенә консультациягә керде ул. Март аенда студентларның фәнни конференциясендә укылачак доклад җиренә җиткерелмәгән иде әле... Аннан соң ул тиз генә казначейга кереп профсоюз маркаларын алып чыкты. Тулай торакка кайткач, студсовет утырышына ашыкты. Анда, берике студентны шелтәләп, ике параграфлы карар кабул иткәч, ниһаять, көндәлек мәшәкатьләр тирәли бер әйләнеш ясалды дип, бүлмәсенә кайтып егылган гына иде... күршеләре шакыды. Өске катны су баскан да, саркып электр чыбыкларын яндырган — кыска ялганыш инде, билгеле. Ярыйсы гына мазаланды Ильяс.

Эльза сүзендә торды бит тәки. Дәресләр башланса да «Без сезне каршы алырга әзер»,— дип, студентларны килеп чакырмыйча аудиториягә якын килмәде. Озак көттерү дә михнәт булып әйләнеп кайта — дәрес күпмегә соң башланса, шулкадәр соңга калып тәмамлана да. Кыскасы, телисеңме, теләмисеңме «сюрпризны» әзерлисең.

Эльзаны чакырдылар. Группа сәхнә уртасына ромашка чәчкәсе булып түгәрәкләнеп тезләнде. Ильяс уртада, ул бүгенге сюрпризның сценаристы, режиссеры һәм алып баручысы.

Ильяс: тамашада катнашалар: педагогия фәннәре кандидаты Максатов, режиссура кафедрасы мөдире Суганов, Эврика туташ һәм «Сөя-Сөйми» вокаль ансамбле. Кызганычка каршы, тамашада катнашмыйлар: Ирина Витальевна, деканат һәм ректорат вәкилләре... Пролог. Өч педагог яшәгәннәр ди. Икесе бик тә акыллы, ә өченчесе... «Эврика» кушаматлы икән. (Сәхнәгә Максатов чыга, ул ромашка тирәли йөри, түгәрәктәгеләр берөзлексез, «сөя-сөйми» дип кабатлап тора. Ниһаять, «Сөя» дигән сүзгә бер кыз сикереп тора да капка булып Максатовны Ильяс янына үткәрә. Суганов белән дә шул ук күренеш кабатлана. Сәхнәгә чалбар кигән бер кыз чыга, башында зур хәрефләр белән «Эврика» дип язылган таҗ. «Эврика»га эндәшүче юк, ул күңелсезләнеп, китү

ягына борылгач кына түгәрәктән бераү чыга да чалбар төбенә кәгазь-дән киселгән аяк эзе ябыштырып куя...)

Ильяс: Стоп-кадр!

Башка көннәрдә сюрпризларны анализлау өчен биш минут вакытны кызганмый иде, бүген Эльза ике генә сүз белән түгәрәкләде:

— Сүзсез дә аңлашыла...

Ул шундук мәгънәле һәм ясалма елмаю белән журналны ачты. (Сәхнә тирәсендә бөтерелгән халык мондый елмаюны дежур елмаю дип атый, чөнки болай итеп теләсәң кайчан, теләсә кемгә һәм теләгәнче елмаерга була.)

Дүрт пар дәрестә утырып та өйгә таралырга рөхсәт булмады — класс җыелышы башланды... Уф!

— Халтурщик Аблушев, бас! — дип башланып китте җыелыш.

— Мин!?!

Хөсәеннең, аның белән бер бүлмәдә яшәүче Ильясның һәм хәтта бөтен группаның берни белмичә сәерсенеп торуы Эльзаның кәефен генә кырды.

— Син, син, Аблушев. Мех берләшмәсендә концерт куеп йөргән-нәреңне сөйләп бир. Зинһар, оялган булып кыланма, бүрек тотырып зал буенча акча җыйнап йөргәндә оялмагансың.

— Сөйлә, Хөсәен, сөйлә! — диештеләр дуслары, дөреслекне ачыкларга теләп.

— Соң, концерт белән гел йөри идек без.

— Акча җыепмы?! — дип кычкырды колхоз стипендиаты Зөлфия.

— Юк ла.

— Савап өченме? — диде Зөлфия сабырсызланып.

— Без, — дип башлады Хөсәен, үз кайтавазын тыңлап баргандай, өзеп-өзеп кенә, — без дүрт кеше йөрибез. Концерт түгел инде ул — очрашу кичәсе. Оркестрантлар бүлегеннән Шамил дистәләп җыр язган. Менә шуларны популярлаштырып йөрдек.

— Син причем, ни җырга, ни биергә хәвәслегең юк?!

— Дөрес, җыр-биюгә сәләт юк, мин конферансье гына идем. Җае килгән саен үзем язган дүртюллыкларны кушып сөйлим. Дәррәү кутәрелеп кул чабалар, рәхәт...

— Ә акча!!!

— Программаны төгәлләдек тә, бераз юанып утырдык, шунда кайсыдыр килде дә концертыгыз бик күңелле үтте, тагын килерсез, бәлки, кеше башыннан утызар тиен көмеш җыеп алдык, мәгез, чын күңелдән, ди. Егетләр каушап төште. Ну мин алдым да... бүлдем.

— Институттан алкышлап озатырлык булган бу, — диде Зөлфия гайрәтләнеп. — Тау ягыннан бит, акчага хирыслыгы да шуннан, — дип тагын нәрсәләрдер өстәмәкче иде ул, шул чак, Ильясның ачулы карашын күреп, дәшмичә тыелып калды. Өстәвенә Ильястан бер язу кисәге дә килеп җитте үзенә:

«Икенче ел рәттән колхозыңнан стипендия аласың, әйеме? Ә үзең Казанда калыр өчен бер студент белән «алдавыч никах» корырга җыенасың, әйеме? Әгәр авызыңны япмасаң, колхозыңа хат язам, стипендиясез укып карарсың, шунда аңларсың Хөсәеннең хәлен. Әйткән сүзем атылган ук, әйеме!»

Язуны укыгач, Зөлфия битарафлар ягында калды.

— Ничек йөрәгең җитеп алдың ул акчаны! — дип сорады Ильяс, Хөсәенне кызгануын сиздермәскә тырышып.

— Бик кирәк чагы иде.

Һәм дәшми калуның бу минутта ачу гына чыгарасын белепме, Хөсәен әйтеп бетерергә булды:

— Өйдән хат алдым. Бабакай хасталаган. Иөз дә сигез яшьтә генә иде әле ул, авырыр дип кем уйлаган. Кайтып күреп калырга тырыш, дигән әни. Юлга әнидән акча сорап хат язып тормассың ич инде. Җәй көне дә, стройотрядка барып, өйгә кайта алмаган идем. Ара ераграк шул...

Авыр тынлык урнашты, гүя аудитория нәрсәдәндер сагаеп калды. Шушы тынлыктан соң Хөсәенне яклап чыгарга да, журналдагы исемлектән сызып ташларлык хәлгә барып җитәргә дә була иде.

Фикер алышуларны Эльза үз кулына алырга тырышты.

— Кирәкме безгә Хөсәен кебек белгечләр?

Староста Миләүшә сикереп торды. (Хәзер җыелыш кульминациягә җитәчәк).

— Сездән соң әйтерлек нәрсә калмый... күп белгәннәргә соңыннанрак сүз бирик.

— Ә нәрсә пәке белән бүрәнә юнып торырга! Бары да аңлашылды. Вакытында кулына сукмасалар, тәки йөрер иде утыз тиен җыеп. Ярый әле мех берләшмәсеннән вакытында сигнал килде. Бу хәл кабатланып, эшнең зурга китүе дә бик ихтимал иде.

— Юк, Эльза К., Хөсәен бүрәнә түгел ул. Безнең белән нибарысы ике семестр эшләп тә, ничәбезгә инде профессиональ яктан яраксыз дип бармак төртеп күрсәттегез.

— Режиссура — оешканлык, тәртип, аннан соң гына талант дип күпме әйтеп киләм... Сезнең арада әле — йорт хозяйкалары, администраторлар, хәтта кассирлар (!) да бар.

— Алайса табыгыз ул булачак даһины, укытыгыз үзен генә. Ирина Витальевна безгә утыз ике тешем сез минем дия торган иде, ул югында коелып бетәбез инде...

— Миңа да бер-ике сүз калдыр әле, Миләүшә,— диде Ильяс җыелышны йомгаклау нияте белән.— Соңга калучылар, тәртип бозучылар укуда да, эштә дә бар. Табигать дигәнең тигезләп өләшкән аларны... Бригадабызда Женя исемле бер яшь монтер бар иде — әкәмәт кеше. Багана башына менеп китә — келәшчәсе кулыннан ычкына. Келәшчәгә дип, янә төшә, тик монтер тырнакларын багана башында калдырган була. Ярты еллап эш рәтенә төшенмәде... Ә ике елдан аны мастер итеп куйдылар. Менә бит ул ничек... Мин Хөсәен алдында гаепле бүген — бер бүлмәдә яшәп аның хәлен дә сорашырга вакыт тапмаганмын. Моннан соң үземә дә акыл булыр... Тавышка куям: Аблушев Хөсәенне арабызда калдырабыз. Ә профсоюз комитеты материаль ярдәм күрсәтер, артыннан үзем йөрим. Каршылар юкмы?... Ә сез, Эльза?

— Үз фикеремдә калам.

Ул моны шундый тыныч итеп әйтте, гүя әле генә бәхәс түгел, ә ял кичәсе булып узды. Җыелыштан соң шундый ук салкын канлылык белән Ильяска калырга ымлады.

— Нәрсә, герой, җиңдеңме?

— Ник каныктыгыз шул Хөсәенгә...

— Бер ни аңламыйсың — аксакал (!). Тәүбәгә килергә дә ирек бирмәдегез бит кешегә.

Эльзаның йөзендә тагын әзер елмаю чагылды.

Әйткән бер сүзен кинаяле елмаю белән бизәп кенә тора.

— Рәхимов, сине телевизор төзәтә белә диләр, чынмы?

— Кирәк чакта.

— Нәкъ кирәк чагы. Мастер чакыртсам, дәрестән калып, көне буе өйдән чыкмый көтеп утырырга кирәк. Кил әле кичен. Адресымны хәтерлисеңме?

— Онытырлык булмады... Ирина Витальевна группаны сезнең белән

таныштырганда каушавымны күрсәгез. Күз алдымда әле «Солярис» фильмы, әле кулыгыздагы класс журналы...

— Хәтерлим. Мине күргән саен оялган атлы кылана идең.

— Кыланмадым. Ул чакта актерлык курсын үтмәгән идек әле.

*
* *

Биектәге контактларны ялгау өчен җайланган күтәрмә кәрҗинле кызыл махсус машина институт ишеге төбенә килеп туктады. Женя бу...

Дәрестән чыгып китәр өчен мәктәпләрдә, бигрәк тә башлангыч классларда, сыналган ысул бар — сул кулың белән эчеңне тотып бөкрәясең дә уң кулыңны укытучы күрерлек итеп күтәрәсең.

Берәр үсмер булса, бәлки игътибар да итмәсләр иде, ә менә ир уртасы Ильяс, эчен тотып дәрестән чыгып киткәч, аудитория гөжләп калды.

Сюрприз дигәнең матур тартмаларда гына ятмый икән ул. Женя Ильясны ашыктырып алып китте. Больница янына килеп җиткәч, тормоз чыелдады һәм Женя, Ильяска бер сүз дә әйтмичә, каядыр югалды. Бер кавымнан әйләнеп килде ул, ләкин сүз әйтә алмаслык дәрәҗәдә дулкынлана иде.

— Нәрсә булды?— дип гаҗәпләнде Ильяс.

— Күрештермәделәр, ярамый, ди.

— Кемне күрергә, ник ярамый?!

— Әйтмәдем мени әле, малай туды бит минем. Тууын туды, күрсәтмиләр генә. Имеш, миннән мазут исе килә, имеш, инфекция! Өйгә алып кайткач, сумалалы киемнәремдә ятып аунар әле үзе. Ә хәзер — юк, ярамый, имеш. Мондый хурлыкны, кем әйтмешли, унике бала үстереп, эткәй дә күрмәгәндер.

— Кайсы катта, тәрәзәсен күрсәт.

— Бишенче кат, әнә, иң кырыйдагы тәрәзә.

— Кереп бас бишеккә, мачтаны күтәрәм,— диде Ильяс, аның бу минутта Женяга чын-чынлап ярдәм итәсе килә иде.

— Ну баш синдә, Ильяс! Тикмәгә генә институтта укымыйсың икән...

Женя югарыда тәрәзә аша улына карый да комарлы балыкчы төсле Ильяска мактана: «Менә моның буйлык»,— дигән сыман ике колачын җәя: «йөзе мин»,— ди, имән бармагы белән үзенә төртеп: «күзләре, әнә»,— ди, күк йөзенә ымлап...

Әллә кайдан гына милиция лейтенанты килеп чыкмасынмы? Сыбызгысын сызгыртмады анысы, тәртип бозып маташалар дип уйламады, ахры. Килде дә Ильяска сәлам бирде.

— Бала урларга йөрмисездер ич!

— Сез нәрсә, иптәш лейтенант...

— Я, я, шаярам гына.

— Ромео җан кисәге Джульеттасын күрергә килгән, ә тегесе бәбиләп куйган.

— Тик, сез...— дип, нәрсәдер сизенә башлаган иде лейтенант, Ильяс тизрәк тел хатасын төзәтергә ашыкты:

— Мин дә шаяртам гына. Электр кабеленең өзеген эзлибез.

Лейтенант честь биреп китеп барды.

Бәхетле Женя «күктән» төште. Ул нәкъ менә шушы минутта үзен эти кеше итеп тоя башлады бугай. Мачтаны урынына салып, двигательне сүндергәч, Ильяс кабинадан җиргә сикерде — домкрат башмакларын җыештырыр өчен Женяга булышырга иде исәбе, тик җиргә басу белән ул тораташтай катып калды. «ГАЗ-53»нең шассие җирдән алай биек тә түгел инде югыйсә...

Женя хәлне бик тиз аңлап алды:

— Нәрсә, брат, тагын аягыңмы? Гомерлек сызлау бирдем бугай мин сиңа.

— Причем монда син?! Куптән төзәлде инде ул җәрәхәт, ипсезрәк басылды бугай. Менә бит, бер ни юк,— дип, аксамаска тырышып, йөреп күрсәтте Ильяс.

Ильяс институтка кергәнче ике ел элегрәк булган хәл иде бу... Яңа ел алдыннан ашыгыч рәвештә бер культура сарае янына чыршы бизәргә кушылды. Чыршысын әйтерием, умырткасы унбиш метрлы торба, кабыргалары бишәр метрлы ылыслы ботак. Чыршы тирәләрен дә кушып санасаң — алты мең лампочкалы утыз ике гирлянда эләсе. Менә кайда ул культура-агарту эше!

Кәрҗинле мачтаны инде соңгы кат күчереп, ниһаять, эш бетә дигәндә генә... машина кинәт чайкалып куйды. Кәрҗин кинәт аварга иткәндәй тотрыклылыгын югалткач, Ильяс кул астындагы ботакка ябышып калды (ботак дигәне дә тишекле торбага кадап-кадап кына төзелгән бит аның). Ильяс аз гына таяну ноктасы тапты да кинәт сикереп, торбаны кочаклады һәм тезен бәрде. Чыршы төбенә аның саен халык җыела торды. Ильяс куллары белән ботактан-ботакка күчеп, җиргә төште дә, берни булмагандай, рычаглар янына басты. Женя тиз генә чыршы башына үрмәләде. Тамаша күрәбез дип өметләнгән халык берәм-берәм тарала башлады.

Ильяс үзен гаепләде, әлбәттә, югары биеклектә кискен хәрәкәт ясау тыелган нәрсә, ә ул хәрәкәт ясалды бугай.

Женя да хатаны үз өстенә алды, мачта таянып торган домкратларның берсе йомшаграк утыргандыр, игътибар итеп житкермәгәнмендер, диде.

Бер атна дәваланмыйча эшкә чыга алмады Ильяс. Баштарак авыр әйберләр күтәргәндә, биеккә менгәндә янсә ике багана арасында чыбык сөйрәгән чакларда вакыт-вакыт тез капкачы авыртып куя иде...

Машина больница капкасыннан ераклашты.

— Малаеңның тавышын мин дә ишеттем.

— Ничава бит, ә...

— Мин әйтәм, әллә укуны ташлап өйләнергә инде... Гаилә җылысына җилкә терәп... Эх, рәхәте ни торадыр!

— Синең институтка керүеңә горурланып йөрим тагын, җае чыккан саен эштә дә телгә алам... Гөлсинәне күрәсеңме, язамы?

— Араны кистем. Үткәнгә әйләнеп кайту җиңелү ул.

Ильяс йөзендәге сагышны яшерергә тырышты. Әгәр кеше үзенең бөтен үткәнен берьюлы исенә төшерсә — күтәрә алмас иде...

*
* *

— Керергә мөмкинме?

— Дәрескә соңга калган Макаров шикелле ялварып торма, чакырып китердем.

Студент ризыкка талымсыз бәндә, беренче булып өй эчендәге майлы таба исе сизелде.

— Кил, Рәхимов, кулыңны ю.

— Мал кадерле хәзер, кулыңны юмасаң, телевизор да сүттермиләр.

— Эшкә керешкәнче, эремчек шәңгесе белән чәй эчәрсең. Ялындырырга уйлама да, үзең дә студент булып караган кеше.

— Сезнең белән булгач, һәр урын 12 нче аудиториягә охшый, хәтта шушы кухня да...

— Аңлашылды, мин хәзер.

Эльза табын артыннан китеп бер минут чамасы тордымы, юкмы, әйләнеп кергәндә ул инде танымаслык иде: бөркелеп торган чәчләре, зур чәчәкләр төшерелгән озын яшел халаты — күпертеп тегелгән җиң очлары... Бер сүз дәшә алмыйча шактый сокланып торды Ильяс.

— Я, мин хатын-кызга охшамаганмы?

— Әгәр...

— Күп нокталар белән сөйләшмә, Рәхимов, әйтеп бетер.

— Никтер...

— Алайса тагын алыштырам, теләсәң — кыскасын, теләсәң — ертык итәклесен, гипюрын...

— Оялтмагыз.

— Шкафта өелеп ятканчы, хет синңа киенеп күрсәтим. Югыйсә, укытучы бу диден дә сагаеп читкә китеп бастың. Ә бит синен кыю чаклары да бар иде, мине озата кайткан кичне исеңә төшер әле...

— Якынаеп кара хәзер...

— Глупость. Синнән дә яшь бит әле мин. Ну, бәлки барысы да җиңелрәк яулангандыр — мәктәптән туп-туры институтка, ә аннан монда. Эти Ленинградтагы фатирыбызның ике бүлмәсен минем өчен Казанга алыштырды. Бердәнбер кызлары ич. Ләкин көрәшәселәре алда әле.

— Минем, киресенчә, институтта аяк терәп укырмын, дип, эшләп торган идем дә озаккарак китте. Мавыгылган. «Электрик белән режиссер арасында нинди уртаклык бар?» — диләр миңа. Режиссер — ул культпросветчик, шулай булгач, электрик та, режиссер да дөньяны яктыртучы түгелме?.. Шаяртам гына. Бүгенгесе көнгә килү өчен теләсә нинди юлны үтәргә дә әзер идем.

— Бер максатка икебез ике юлдан...

— Ә кайсысы дөресрәк?..

— Белмим, Рәхимов, өзеп кенә әйтә алмыйм... Институт саен рабфаклар ачыла хәзер, димәк, эштә чүкелгән кешеләр кирәктер.

Табын ничектер, рәсмирәк төстә, сәнгатьчәрәк хәзерләнгән иде. Тәбәнәк озын өстәл артында тирән әчле йомшак утыргычлар, алтын йөгертелгән вазада үтә сары салфеткалар, икешәр катлы өлеш тәлинкәләренә куелган касәләрдә итле бәрәңге, серванттан әле яңа гына кузгатылган чокырларда шулпа, бәллүр фужерда «чия компоты» — болар барысы да Ильяс өчен купшы итеп алдан хәзерләнгән иде. Табын артында икәүдән-икәү генә булсалар да, Эльза тостны тантаналы төстә башлады, тавышы горур, логик басымы төгәл, дикция ачык — ни өчен икәнлеге аңлаешсыз. Гамьсез егет төсле беркатлырак, сабыйларчарак кыйлану кирәктер бәлки?

Ильяс күбрәк тыңлап кына утырды. Чөнки аның алдында бөтен тулылыгы, күркәмлеге, шаянлык һәм мәкерлек, наз һәм каты бәгырьлек, усаллык һәм күз яшьләре белән мөлдерәмә тулы хатын-кыз заты утыра иде.

— Группа ярата сине, ә мине юк,— диде Эльза, үпкәләүле төс белән.

Эльза җәһәт кенә торып берничә журнал алып килде.

— Менә «Свиноводство» журналы, сезне укыта башлаганның беренче аеннан ук килә болар. Утыз икегезнең берсе минем адреска подписка ачкан. Хәтеремдә, репетицияне өзгән өчен мин сезгә «бу дуңгызлык була» дигән идем. Шуны гафу итмәвегездер...

— Миннән шикләнмисездер ич?

— Кем дә булса да, группагыз исеменнән эшләгән.

— Каян килгән ул уртак фикер? Һәркем үзен талантка саный, дөньяны шаккаттыру теләге белән яна, шуңа омтыла, башкалардан көнләшә. Шуңа күрә таркаулык.

— Сине тыңлыйлар, мине юк. Син аларны җыя аласың. Ә мин кирәк чакта чакырып та китерә алмыйм. Язмыш рөхсәте белән беренче тапкыр укытучы булдым, тәҗрибә дә аз...

— Вакыт! Ерагайтучы да, якынайтучы да — вакыт!

Ильяс кул сәгатенә күз салды.

— Рәхимов ашыга.

— Тәнәфескә дәшүче кыңгырау авазы профессор лекциясеннән көчлерәк... Соңга калына, унбер тулгач общага ишеге бикләнә.

— Куган кеше юк, икебезгә ике бүлмә.

— Кайтмый калсам, я бирәр мажара туар.

— Син багана башында йөргәндә тулай торагыгыз ничек яшәде икән?!

— Үзем шунда яшәгәндә булышырга иде. Юкса, рейд белән бүлмә саен йөргәндә дә беренче каттан башлап тугызынчы катка менеп житкәнче сигез кешелек студсоветның берсе дә янымда калмый — һәркем дуслары тирәсендә мавыгу таба. Хушыгыз, Эльза К. Телевизорны башка чакта...

— Сау бул, Рәхимов. Бүтән чакырып китермим, теләгәндә үзең кереп йөр. Ачкычның берсе синдә калсын, мә, ал, Ильяс.

*

* *

Студентлык билетын кулыңа алып, зачет кенәгәсен дипломга алыштырганчы гел кирәк икән ул ихтыяр көче дигәнең. Хәтта Хөсәен дә аңлады инде моны. Аңламыйча — җыен студентларны бер арбага утырталар да, телисеңме-теләмисеңме, колхозга шефлык итәргә озаталар. Шулай итеп, кояшлы Ингушетия егете Актаныш ләпегеннән бәрәңге эзләп йөри. Тау аргамагыныкы кебек ярсу йөрәгеңне: түз йөрәгем, түз, дип, гел кисәтеп тормасаң, ай-һай эшләр зурга китәсе... Беренче сынау көнне дә шулай ул: дүрт көн буе, балга ябышкан чебен кебек, үзең язып барган лекцияләрне үзең аңларга тырышып укынасың-укынасың да..., бишенче көнне, соңгы көчләреңне җыеп, иртән иртүк өстәлгә куеласы чәчәк бәйләмәнә ияреп имтиханга килеп керәсең. Як-ягыңдагы шәкертләргә берни дә белмим, дип әйтерлек көч табасың, кыен булса да ярдәм көтәсең. (Шуның өчен әйтәләр аны — беренче имтиханга кергәндә чия кызыл күлмәк-мазар киеп керергә кирәк, оялулы йөз кызыллыгың сизелми, ә икенче, өченче, гомумән, калганнарына инде җете ак күлмәк кисәң дә була).

Иң беренче сынауны биреп чыккач та ихтыяр көче кирәк әле. Портфелеңнән: «Укырга керә алмасаң кая барырга?»— дигән игъланнар тулы гәҗитне чыгарасың да, үз акчаңа алган чия компоты шешәсен тәреп куясың. Кайткач, ярты литрлы күчтәнәчне бүләбез, дип кычкырасың, хәер, кычкырып азапланмасаң да ярый, бу минутта һәркем юк-бар мактау сүзе әйткән булып синең янда бөтерелер. Китап-дәфтәрдән гайре юньле нәрсә күрмәгән өстәл оятыннан шыгыр-шыгыр калтырап торыр. Үзеңне мәҗбүр итми ярамый. Телисеңме, теләмисеңме — анысы синең эш, ә иң беренче дигән һәр нәрсәне «юарга» кирәк икән — өлкәнрәк курстагылар шулай ди...

Әйе, дүрт атнадан каз да бәпкә чыгара дигәндәй, «Койрыклар»ыннан котылырга каникулың да җитмәс идеме әллә, җитә ул?!

Инде, иртәгә уку башлана дигән көнне әти-әниеңә: сынауларны уңышлы тапшырдым, дип телеграмма сугарлык куәт тә калса, киләсе сессиягә хәтле укудан бушаган араларда рәхәтләнеп вагон бушата аласың.

Җиләк-җимеш кенә имеп үскән Хөсәеннең җариялэрнекедәй нәфис гәүдәсен кызганып, аны мебель фабрикасының бер капкасына каравылчы итеп урнаштырды Ильяс. Шулай да каравылдагы йокы житенкерәмәде Хөсәенгә, дәрес араларында, тәнәфесләрдә, тәнәфесне ялгап, кайбер лекцияләрдә дә черем итеп алгалый иде ул. Җае чыккан саен кызлар аны үртәп өлгерә:

— Әйдәгез санайк әле, бу йөк ташучы поездның ничә вагоны бар икән?

— Алтмыш биш!

— Хөсәен, син бушаткан вагоннарны бергә таксаң бер состав була бит, әй...

Режиссура дәресе башланырга тора. Бер-береңне көнләштерер өчен генә киелгән затлы киемнәр теләр-теләмәс кенә униформа белән алышына.

— Хөсәен, Хөсәен!

(Миләүшә бу, эшсез торучыны күрсә, бәйләнми калмый).

— Хөсәен! Хөсәен! Хө-сә-ен!

— Нәрсә инде?— ди тегесе иренеп кенә.

— Хөсәен, ну карама инде бу якка, мин кием алыштырам ич...

Эльзаның аяктан бәреп ега торган комплекслы таләпләренә ияләнелде инде. Сюрприз әзерләү, күнегүләр белән дәрес башлап җибәрү, укулардан соң көн саен диярлек репетиция үткәрүләргә хәзер бераүнең дә исе китми. Хәтта Хөсәеннең дә. Тик менә әллә эшкә ашыга, әллә кайтырга, күзе гел тәрәзәдә.

— Тәмам күзге иттең тәрәзәне, кемне көтәсең шул хәтле?

— Анда әнә Ирина Витальевна килде!

Яшьләр бер дулкын булып Хөсәен күзгесенә, фу, тәрәзәгә ябырылды. Кинәт кенә шушы дулкын икегә бүленеп өлгерде: ярты төркем бер-сен-берсе узарга теләп ишектән атылды, икенче төркем әллә ни сабырсызланмыйча, битараф хәлдә үз урыннарына утырды.

Эльза янында калган төркемне бик җентекләп күзәтте. Аның карашында: «Ныклап уйладыгызмы, сез чынлап та минем беләнме?»— дигән сорау иде.

Институтта яңа бүлек —режиссураның икенче кафедрасы ачылырга санаулы гына көннәр калган иде инде.

Җәй башлана гына. Табигать әле бөтен күркәмлегенә ирешмәгән. Чәчәкләрнең иң матуры бөредә, кошларның да җырланасы җырлары башланды гына.

Тупыллар мамык очыра... Яшел ябалдашларда кояш нурыдай йомшак, сулыштай җиңел ак мамык күпергән. Җил килеп орынуга, алар тузынып тирә-юньгә тарала, кемне дә булса сагалап очып йөри дә, кеше-мазар күренүгә, аңа ияреп китә.

Ильяслар, институтка килеп җитәрәк, чаттагы светофорның кызыл яктысына тукталдылар.

Кулларда зачет кенәгәсе. Нихәтле билге, күпме укытучының имзасы анда. Гөлсинә аеруча басым ясап әйткән кырык өч сынауның яртысы үтелгән.

Ильяс уйланып торган мәлдә зачет кенәгәсенә күбәләк кадәр тупыл мамыгы килеп кунды...

Ул арада светофорда яшел ут кабынды.

1980 ел

# Гарәфи Хәсәнов

## КАРТ САНДУГАЧ

*Сандугачкай сайрый май аенда...*

Халык җырыннан



Гашыйклар җырчысы дип атыйлар сандугачны. Гашыйклар аны сөйгән ярлары турында уйлап, тыннарын алмый, онытылып тыңлыйлар. Сандугач аларның тел белән әйтеп бирә алмый йөргән сөю-иркәләү сүзләрен, бар яну-көюләрен, бар шатлык-сөенечләрен үз теле белән сөйләп ярларына җиткерә кебек. Әле бу мәшһүр кошны шагыйрьләргә илһам бирүче дип атыйлар. Чыннан да, аның турында үз сүзен әйтмәгән, аны җырламаган, аның өздереп сайравы белән рухланмаган бер генә шагыйрь дә булмагандыр. Халык үзе үк бүтән бер генә кош турында да шундый күп, шундый күңелгә үтеп керә торган, шундый җылы һәм матур җырлар иҗат итмәгәндер. Һәм халык аны «былбыл» дип шигъри исем белән юкка атамагандыр.

Кечкенә генә гадәти бер кош үзе. Ләкин шул кечкенә генә, күрексез генә бер кош та шундый көчле, шундый санап та бетергесез, шундый гүзәл һәм тылсымлы авазлар чыгара алыр икән! Үз кайгысы үзенә җиткән, дөньядан ваз кичкән, боек күңелле нинди генә кеше булмасын, шуларның һәммәсен елмаймас җирләреннән елмайдырып җибәрә, һәммәсен терелтә, һәммәсенә яшәү көче бирә аның сайравы. Хәтта туң йөрәклегә дә дару-бәлзәм була аның сайравы. Әйе, чын мәгънәсе белән бер дигән җырчы, чын тылсым иясе ул сандугач.

Мин аны беренче мәртәбә кайчан һәм кайда күрдем соң әле? Мин аны беренче мәртәбә үз-үземне белә башлауга ук күрдем.

Сай гына тар елга буен куе тал-тирәк каплаган, шунда, бер өске ботакка кунып, сандугач сайрый иде. Анда мин беренче мәртәбә үз аягым белән килеп, бу мәшһүр кошның оста сайравын тыңладым. Аны шуннан соң күрми һәм тыңламый калган бер генә язым да булмады. Хәер, күп иде алар, мәшһүр җыр осталары. Алар кыр һәм авылга ишеттереп, әйтерсең, үзара ярыш ачып, өздереп сайрыйлар иде. Әмма чын сайрау остасы, гүя хор дирижеры — арадан берсе, шул башлап ишеткәнем, карт сандугач иде.

Аның карт икәнлеген оста сайравыннан белдем мин. Ул озак яшәгән һәм яшь чагында ук яхшы җыр юллары да откан. Һәр буын — юлга үзгә аһәңнәр дә өстәгән, шулай отканын берен тыңлап туймас-

лык биеклеккә житкергән. Хәзер аның үз мәктәбе бар, хәзер аның талантлы шәкертләре дә җитәрлек. Алар яз саен шушы карт сандугачны тыңлап, аның һәр аһәңен отып алалар, отып кына калмыйча, үзләреннән дә бизәкләр өстәп җибәрәләр. Сәнгать кошлардан булып кошлардан да чиксез күнегүләр сорый. Карт һәм талантлы кошкай үз мисалында шушы турыда искәртә кебек. Ләкин карт һәм талантлы кошкай шундый сайланып та сайраучан. Җырларын ул бирәр дистәдән һич тә арттырмый. Таныш җыр юлларына яңаларын да өсти ул, әмма сайраган саен бирәр дистәдән дә арттырмый. Сайрапмы-сайрый бирә шундый талымлылык күрсәтеп! Бары иң яхшы дигәннәрен генә, бары кәефенә карап кына сайрый ул. Яшь кошларга да ул, сез дә шулай итегез, дип таләпчәнлек үрнәге күрсәтә шикелле. Сәнгатьтә таләпчән булып кына осталыкка ирешергә мөмкин дип искәртәдер сыман.

Әйе, шушы карт сандугачны сабый чагында ук күрдем мин. Үсә төшкәч тә оста сайравына таң кала торган идем. Әйе, беренче мәртәбә күңел күзе белән күрү, моңлы һәм шул ук вакыт шат һәм дәртле сайравын күңел биреп тыңлау — мәңге йөрәк түрендә саклана, мәңге онытылмый икән. Аны маңгай һәм күңел күзе белән кайчан күрдем, күңел биреп кайчан тыңладым соң? Инде сабыйлык чорыннан да, малай чагымнан да чыккач. Үземне типсәм тимер өзәрлек яшь егет итеп сизгәч, ахры. Анымы, улын-варисынмы күрдем мин, әмма һаман да бер үк өске ботакта очраттым; һаман да карт бер кошкайны тыңладым. Аның карт икәнлеген оста сайравыннан белдем мин. Бусы, кем белә, бәлки, мин башлап күргән, мин башлап ишеткән теге карт сандугачның талантлы оныгы ук булгандыр. Чөнки һәр яңа буын туган урынына кире кайта ич.

Әйе, горур кош үз дәрәҗәсен үзе дә белде, юл буе, күпер яны дип тә тормады, сайрапмы-сайрый бирде узган-барганнан да тарсынмыйча! Аны, карт сандугачны, күңел биреп, беренче кат тыңлагандай аерылалмыйча тыңладым мин. Әйләнә-тирәдәге барлык яшь кошлар һәммәсе дә шушы карт сандугачка колак салды, җыр гыйлеменә шушы остазларыннан өйрәнде, инде алар ук... Инде алар ук оста сайраулары белән аны уздырып та җибәрде бугай. Әйе, яшь сандугачлар булып яшь сандугачлар. Алар карт сандугач эшкәрткән җырга күркәм төсмерләр өстәделәр. Алай гынамы соң! Әле алар җыр юллары санын шактый арттырып та җибәрделәр. Алар карт сандугачны шуның белән гүя сайрау ярышына чакырдылар. Карт сандугач исә... юл буыннарны бары кәефенә карап сайлый торган иде. Бүген ул яшь сандугачлар җырын шундый көнләшеп тыңлады. Әйе, карт һәм талантлы кошкай үз дәрәҗәсен үзе белә иде, ә менә шул ук вакыт яшьләр җырын көнләшеп тыңлады. Кинәт кенә гүя буа ерылып китте. Карт һәм талантлы кошкай өздереп-өздереп сайрый башлады. Көнләшү хисе шулай өздереп сайратты бугай карт кошны. Инде көнләшү хисе көрәш коралына әйләнде. Яшь кошлар кичке шәфәкъкәчә сайрады, карт сандугач исә... ул көн һәм төнозын томшык йомуны белмәде. Гадәттән гадәт итеп, һаман бөкрәя төшеп сайрады. Һәр ике канатын аска салындырып, нәни томшыгын өскә каратып, бирелеп, онытылып, очынып сайрады да сайрады.

Көчле һәм матур җыры нәфис сызгырудан башланды:

«Фиү... ит, фиү... ит, тиү, тиү, тиү, тиү».

Һәм китте шуннан соң...

«Тү-лит, тү-лит, тү-лит».

«Сисистувит, тү-вит, тү-вит».

«Юу-лит, юу-лит».

«Пиү, пиү, пиү, пиү».
«Юу-лит, чочочочорррррс».
«Си-вит, клүи, клүи».
«Чричу-чу, чричы-чу, чричи-чу».

Матур җыр юлларын ул ике дистәгә үк җиткерде. Бүтән язларны бары бер дистә белән генә чикләнә иде, быел менә һич көтмәгәндә, ике дистәгә үк җиткерде. Сызгыру һәм чутылдап кую да, гөрләү һәм көмеш челтерәү дә калмады. Шулай өч-дүрт дистәгә — соңгы мөмкинлегенәчә җиткерде. Инде шуннан соң юллар саны күпме сайраса да артмады. Төгәл дүрт дистә... Әйе, артык та, ким дә түгел. Аның шушы күп юллы матур җыры күздән йокымны качырды.

Төгәл дүрт дистә... Әйе, аз да түгел, күп тә түгел. Җыр юлларын ул шундый камил, шундый тыңлап туймаслык иттерде, яңадан яңа төсмерләр өстәде.

Төгәл дүрт дистә... Ә бит бер юлны икенче кат сайрап, кабатлап та тормады. Һәрбер юл-буынны ул шактый әкренәйтеп, чак ишетерлек итеп бетерде. Нәни тукталыштан соң гына юлның икенчесен җырлый башлады. Һәрбер юл-буын шундый чиста, бертигез, нечкә хиссиятле булып яңгырады. Алай гынамы соң! Әле янәшә ике юлның матур урнашуына да таң калдым. Юлның шат авазлысы моңлы, сагышлыга кучте, тын һәм нәфис юлы көчле сызгыруга... карт һәм талантлы кошкай әнә шулай җырында һәрбер юл-буынның матур чиратлашуын да кайгырта иде.

Ни өчен соң әле остаз кошкай бүген генә бөтен белгәнен сайрап күрсәтте.

Читлек тоткынлыгын белмәгән кошның дөньяга бөек мәдхия җырлавы идеме, табигать теләген кешеләргә җыр телендә аңлатып бирүе идеме — ни генә булмасын, мин аның җырыннан карт өянкеләр шикелле уйга калдым.

Бәлки бу аның соңгы тапкыр сайравы булгандыр...

Хәйдәр Гайнетдинов

# ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

хикәя



Гөлҗиһан әби, буявы уңган рәшәткәгә сөялеп, бер авык торды да авылга таба атлады. «Алтын йөгерткәнмени үзләренә. Яфрак коярга да өлгермәгәннәр», — дип уйлады ул, зираттагы агачларга карап. Алтынсу яфраклар исә: «Бөтен дөнья саргайган мәлдә каян килгән яшеллек бу?» — дип, карчыкның яшел яулыгыннан көнләшкәндәй, шыбырдашып куйдылар.

Гөлҗиһан әби үзе моны сизмәде дә. Уйлары тынгылык бирми иде аңа. «И раббым! Дөньялыкта күрешергә насыйп булмагандыр инде... Кыямәт көннәрендә теләгемә ирештерерсең микәнни?..»

Зиратның теге дөньяга алып чыгучы капка түгеллеген бик яхшы белә ул. Теге дөнья дигәннәре әллә бар, әллә юк дигәндәй... Кем барып күргән дә, кем әйләнеп кайткан аннан. Кыямәт көннәре дип, болай гына әйтә инде.... Дөньялыкта күрешүгә ни җиткән? Зираттагы агачларга сокланып йөрүе дә теге дөньяга ашыгудан түгел. Алай юрамый Гөлҗиһан әби. Юраган юш килә, ди... Аннары, үлгән кеше белән кавышырга җыенмый бит ул. Исән кеше белән!

Тракторлар гөрелтесен тыңлый-тыңлый кайтты Гөлҗиһан әби. Игеннәрне җыеп алгач, туңга сөрәләр. Тавышлары көчле булса да, күңелгә шом салмый бит, әй! Әллә улы Хәлим тракторда эшләгәнгәме икән? Алай дисәң, элек тә колакка ятышсыз тоелмый иде. Җанга ниндидер якын аваз, моңлы аваз чыгаралар бит, кара инде, ә...

Тракторлар кыр ягыннан тырышып-тырышып киләсе ел уңышы турында хәбәр сала иде.

«Дөньялар үзгәрде. Мондый да имин елларда нишләп исән булмасын ул?! — дип уйлады Гөлҗиһан әби. — Чегәннәр дә исән диделәр бит!»

Чегәннәр юравын берәүгә дә сөйләгәне юк иде әле аның. Дөрестерме, юктырмы, анысын белсә, ахирәте Фатыйма гына белә инде. Сугылып чыгарга кирәк әле Фатыйма күршегә, нишләп ята икән? Хәлимнең кырдан эшен бетереп кайтырына да шактый бар. Оныклары да өйдә түгелләр. Кояш та төшлектән авышты гына.

Рәхәтләнеп чәй эчкән арада, Гөлҗиһан әби җайлап кына узганнарны кузгатырга кереште.

— Карале, Фатыйма, элгәре авылга чегәннәр килерие. Хәтерлисеңдер инде?..

— Хәтерләмимме соң! — Фатыйма әби бал белән майны ахирәтенәрәк этәрде.
— Хәзер бер дә күзгә-башка чалынмыйлар. Кем биздергәндер мескенкәйләрне.
— Шәһәрдә ди алар. Авылга килеп чыкмыйлар шул менә.
— Яңалык була торганые шуларның күренеп китүе.
— Яңалык булмыйни! Башка халык бит инде. Киенүләренә хәтле.
— Башка халык та соң... Безнеңчә дә беләләрие бит алар.
— Әйтмә! Каян өйрәнгәннәр диген, әй.
— Берсе хәтеремнән һаман да чыкмый.
Ахирәтеннән җавап сүзе ишетмәгәч, Гөлҗиһан әби тагын өстәп куйды:
— Берсе хәтеремнән һаман да чыкмый. Күңелгә өмет салды да... — һәм яшел яулыгының почмагына күз яшьләрен сөртеп алды.
Фатыйма әби эндәшмәде. Авырткан җиренә кагылырмын дип курыкты бугай.
— Чегәннәрен дә әйтерием. Күңелгә өмет салдылар да... Шуннан бирле күренмиләр.

... Сугыштан соңгы еллар иде бу. Кызу печән өсте.
Авылга чегәннәр якынлашуын малай-шалай әллә каян ук шәйләде: «Киләләр! Тегеләр!..»
Бу сүздә кызыксыну чагылса да, хәвефләнү дә бар иде. Ничек хәвефләнмисең инде. Чит-ят кеше ни кылмас. Ходай белсен. Нинди ният белән киләләрдер бит әле?.. Ярый ла бәла-казалы булмасалар. Моңа хәтле дә күренгәләгәннәре бар иде, анысы. Кайсыберләре өй борынча хәер сорашып йөриләр. Шунысы кызык: ипи сыныкларына да, бәрәңгегә дә, онга да — һәммәсенә аерым капчык тота андыйлары. Каян табып бетергәннәрдер шул хәтле капчыкны, ничек көчләре җитәдер күтәрергә. Урлап алмагач, рәхмәт инде. Кайсылары вак-төяк белән сату итә. Берсен дә гаепләрлек түгел — тамак туйдырырга кирәк бит. Нишләтәсең инде — тир түгәргә өйрәнмәгән халык шул. Бар белгәннәре җыр да бию, күңел ачу.
Болары нинди хикмәтләр күрсәтер тагын. Эшкә яраклы бөтен кеше болында. Авылда карт-коры, бала-чагадан гайре адәм заты да юк, ичмасам.
Чегәннәр килүен ишетүчеләр капка төбенә чыгып басты. Кулларын каш өстенә куйдылар да басу капкасы тарафын күзәтергә тотындылар.
— Күче белән киләләр.
— Ир-атлары юкмы?
— Әллә балаларын да ияртkәннәр инде.
— Ир-атлары белән йөрми бит алар.
— Нигә икән?
— Үзләреннән сора, Мәхүбҗамал җиңги. — Монысын Чуар Рәис әйтте.
— Әйбер-фәләнгә кагылмыйлардыр бит?
— Соңыннан әйтермен, Мәхүбҗамал җиңги...
Телен тыя белмәгән Рәисне малайлар чирәмгә тәгәрәттеләр.
— Ходай сакласын...
Бу сүзләрне ишетүгә, малай-шалай җитдиләнеп китте. Алар хуҗа ич авылга! Бер-бер хәл була калса... Олылар күзне дә ачырмас. «Куркаклар икәнсез», — диярләр. «Сезгә моннан ары ышаныч бетте», — диярләр.
— Минем янга! — дип кычкырды арада бер башка калкурак Хәлим исемлесе.
Малайлар гаярьләнделәр. Аннары дәррәү кубып басу капкасына элдерделәр.

— Кертмәскә кирәк аларны.
— Капканы бикләргә.
— Таш белән куабыз.
— Кире борылсыннар!
— Ә сиңа,— диде Хәлим Чуар Рәискә,— әләгер әле...
Ләкин малайларның планы барып чыкмады.
Тегеләр әкрен генә киләләр дә киләләр. Бер чегән малае бозау кадәрле эт җитәкләгән. Юк, мондый бурзайга каршы торырлык эт юк авылда. Торса, тегермәнче Микулайныкы гына каршы торыр. Әмма тегермәнче эте малайларның кан дошманы иде шул.
Ә чегәннәр әкрен генә якыная. Үзара сөйләшәләр. Шул вакыт алгарак йөгереп чыккан кечкенә кызыйлары борыны белән юл тузанына капланмасынмы! Чуар Рәис түзмәде, көлеп җибәрде. Көлүе — көчек ләңгелдәвемени... Бу авазга чегәннәр бурзае колакларын шомрайтты һәм кинәт, хуҗасын өстерәп, малайларга ыргылды. Көчек бар дип белде, ахрысы.
Малайлардан җилләр исте.
Чегәннәр авылга озын итәкләре белән тузаннар туздырып килеп керделәр.
Аларның өй борынча йөрүен малайлар баштa читтән генә карап тордылар. Бераздан кыюлыклары артты. Чегәннәр керәсе йортның ишегалдына кереп тулдылар да капканы бикләп куйдылар. Чиләкләргә, чүмечләргә су тутырып, койма янына барып бастылар.
— Өсләренә сибик, — дип сүз куештылар. Койма ярыгыннан карый-карый чегәннәрне көттеләр.
Менә өлкән генә бер чегән хатыны капка келәсен шакылдатып алды. Ул да булмады, койма өстендә малайларның башлары күренде. Бурзай, аларны күреп, буыла-буыла өрергә тотынды. Котлары очты малайларның, берәм-берәм җиргә сибелештеләр. Акырышкан, чиләк-чүмеч шалтыраган авазларны ишеткәч, чегәннәр, сукрана-сукрана, икенче йортка күчтеләр.
Гөлҗиһан апа печән җыюдан кайтып килә иде. Койма ярыгыннан әнисен күргәч, Хәлимгә җан керде.
— Әнкәй! — дип кычкырды ул.
— Кайда син? — дип, Гөлҗиһан апа башын боргалады. Койма өстеннән Хәлимнең башы калыкты.
— Нишләп йөрисең анда, чит кеше каралтысында?
— Чегәннәрдән качтык.
— Нигә качасың. Нигә куркасың? Алар кешегә тими бит.
— Тимәс! Бурзайларын гына кара син аларның.
— Әйдә, улым, кайтабыз.
Атаманнары киткәч, бүтән малайлар да әкрен генә таралыштылар.
Хәлим күргәннәрен әнисеннән җебенә чаклы әнисенә сөйләде.
— Шул Чуар көлеп җибәрмәсә, — диде ул, — чегәннәр бурзае кумыйдырые да безне.
— Гомерләре озын булыр боларның. Әнә, безгә дә керәләр, — диде Гөлҗиһан апа.
Чынлап та, кап-кара чәчле, җәйге челлә булуга карамастан, шактый ук керләнгән калын яулык бәйләгән, чәчәкле озын күлмәк кигән бер чегән хатыны җилкапканы ишегалды ягыннан ябарга азаплана иде. Бу халыктан бик шикләнмәсә дә, Гөлҗиһан апа аны өйгә кертергә теләмәде — каршысына чыкты.
Чегән хатыны керешли авыз эченнән нидер мыгырдана, ялт-йолт тирә-ягына карангалый иде. Гөлҗиһан апаны күргәч, кулын сузды да аңлашылмаган телдә нидер сөйләргә тотынды. Гөлҗиһан апаның сәерсенеп торуын күргәч, татарчага күчте.

— Синең чәчең коела икән. Чәчеңне җыеп йөр. Бозганнар сине, коелган чәчеңне табып алып сихерләгәннәр.

Гөлҗиһан апа тораташ булды. Әйе шул, чәче коела. Каян белә ул аны?..

— Кара минә бу көзгегә, әйбәтләбрәк кара. Ике дошманың бар синең, шуларны күрерсең!

Монысын ук көтмәгән иде Гөлҗиһан апа. Чит кеше була торып, каян белә диген. Бигрәкләр туры китерә бит!

— Син курыкма, — дип тынычландырды чегән хатыны, курыкма миннән. Мин сиңа бәхет юрыйм бит.

Гөлҗиһан апа чигенә-чигенә өйгә керде. Авыз тутырып сыңар сүз әйтергә өлгермәде, чегән хатыны бөтен ипи сорап алды. Һәм ипигә тиз-тизниләрдер сызгаларга кереште.

— Ирең сугышта булган икән. Ул исән. Кайтачак. Аны дошманнарың бозган. Кабат чәчеңне җыеп йөр. Ныклабрак кара, әнә, ипи дә читлек күрсәтә, — дип сөйләнде чегән хатыны, үзе сызган аркылы-торкылы сызыкларга ишарәли-ишарәли. — Котылыр ирең. Тик ипи миндә булырга тиеш.

Аңлаштылар. Әллә нинди сызыклар сызгаласа, мондый яхшы күңелле күрәзәчегә түгел, гап-гади хәерчегә дә бирерсең ипиеңне.

— Ал! — диде Гөлҗиһан апа. — Кайтсын гына берүк.

Чегән хатыны югалды.

Өмет калды.

Әлеге өмет һаман да сулмый, һаман да саргаймыйча яши бирә.

Кайтачак, кайтачак! Улы да көтә бит аны. Хәлим исемле улы барлыгын да белми бит әле әтисе. Кайларда йөридер шул гомер?!

Гөлҗиһанның ире сугышта булуын, аның исән калуын каян белгән диген чегән хатыны? Дусларын, дошманнарын каян белгән?

Фатыйма әби эндәшмәде. Гөлҗиһанның ире сугышка китүен дә, дусларын-дошманнарын да чегәннәргә ул сөйләгән иде... Фатыймадан сорашканнар иде. Әмма исән калуын берәү дә белми. Исән калуы — чегәннәр күңелгә салып киткән өметтә генә. Алар берәүгә дә начарны юрамый шул.

Гөлҗиһан әби чыгып китте. Фатыйма әби серне ачмады, өнсез генә карап калды. Өй каршындагы саргайган юкә агачы да Гөлҗиһан әбине яшел яулыгына карап калды... Күпме күз яшьләре дә уңдыра алмаган, кайчандыр ире бүләк иткән, иренең төсе буларак сакланган яшел яулык ул...

## Хәмзә Кашапов

# АК ӘБИ

НӘСЕР

Җәй азагының кояшлы көннәрендә безнең Кама аръягының тау итәкләрендә әбиләр чәче дулкынлана. Көмешләнеп чаларган ул кылганнарны тибрәндерү өчен саба җиленең аз гына кагылып үтүе дә җитә: аннары уйнаклый әбиләр чәче, уйнаклый! Туктатам димә инде син аларны!

Былтыр көзен шул кылганлы тау итәгенә кадәр безне озата килгән иде әниебез. Шуннан торып кул болгап калды.

Мин, хатирәләргә чумып, атлый бирәм...

«Бу тау итәгенә утырып ак әбиләр чәчләрен тараганнар, улым. Кылганнар — алардан коелган чәч бөртекләре икән...» Боларны миңа кечкенә вакытта әнием сөйләгән иде. Ә менә ак әбиләр башына ак чәчләр кайдан төшкән? Анысын әйтми әни. Үзең белерсең әле, ди. Әйе, үсә төшкән саен мин аларны төшенә барам...

...Алты улының иң зурысы мин булгангадырмы, әнием бөтен серләрен, кайгы-шатлыкларын иң элек минем белән уртаклаша иде. Ул миңа киңәшчесе, ярдәмчесе итеп эндәшә иде. Сугыш елларында берсеннән берсе кечкенәрәк булган алты малай үстерүне кем җиңел дип әйтә алыр?! Җиденчегә сугыштан яраланып әти кайтты. Аның тишкәләнмәгән, кискәләнмәгән берәр төше бар идеме икән?! Капчыкка салып күтәреп йөртмәле генә булып ябыгып, кечерәеп калган иде ул. Без аны шулай күтәреп йөртәдер дә идек. Мунчага да күтәреп алып барабыз. Язгы кояш нурларына да күтәреп чыгарып утыртабыз. Хәзер менә шуларны уйлыйм да аһ итәм: шул чакларда да әниемнең йөзендә бернинди сыкрану билгеләре күренмәде бит! Киресенчә, барысы да әйбәтләнер, менә күрерсез, әтиегез дә терелер, сез дә үсеп җитәрсез, бәйрәмдәгечә яшәрбез әле, бәйрәмдәгечә, дип безне юата иде.

Балачак хатирәләре арасында мәңге җуелмастайлары бар. Январь урталарында үгез җигеп урманга барганны ап-ачык хәтерлим. Көне буе билдән кар ерып утын хәзерләдек. Күреп торам, әнинең җеп өзәрлек тә хәле калмады. Кайткан җиргә аны колгасар карт-бригадир көтеп тора иде инде. Әнигә төнгелеккә ашлык суктырырга чыгарга кушты. Мин ярсып-елап каршы төштем: күрмисезмени, урманнан кайтты гына бит әле ул, дим. Күрәм, күрәм, олан, ди, икенче тапкыр да урманга барырлык рәтегез булсынга кушам мин, ди. Сузан карт чыгып китте. Әни авыз ачып бер сүз дәшмәде. Шактый ара үткәч кенә, кайнар чәй эчкәч арыганлык бетә ул, улым, бетә, барырмын, диде. Эш арасында алҗыганлык, арыганлык тизрәк тә чыга әле ул.

Хәзер мин шул көннәргә еллар аша сорау бирәм: ничек түзә алдылар икән безнең әниләр? Кайдан алдылар икән бу кадәрле дә түземлелекне?!

Сугыш тәмамланып озак тормады, язгы матур көннәрнең берсендә этиебез дөнья куйды. Ул инде мендәр авырлыгында гына булып калган иде. Мин бер үзем дә аны ансат кына күтәреп йөртә башлаган идем. Аның тиздән гүр иясе буласын белеп яшәсәк тә, бу көн үзәк өзгеч авыр тоелды. Өйдә кече энебез Рәмил генә еламады. Кайгы дигәннең нәрсә икәнен белми торган чагы иде шул аның. Ә менә кичке якта шул ук Рәмил, этинең гәләфие миңа була, дип әйтеп ташлагач, көне буена тавышсыз гына яшь сыгып йөргән әниебез кычкырып елап җибәрде. Аны бу ярсуыннан бернинди юатулар да туктата алмады, ул әрнеп, өзгәләнеп елады.

Берничә атна узгач кына, Рәмилнең күзләрендә яшь күрдек. Без кичергән кайгының сабый акылына шулай кичегеп барып ирешүе иде бу, күрәсең. Әни аны кочагына алды.

Узган җәйне сабан туена кайткач, әнигә, ничектер җыерчыкларың күбәеп киткән, дигән идем дә, хәзер мин агач төбе шикелле инде, ел саен бер җыерчык өстәлә, дип шаяртып алды. Аннары, нидер искә төшерергә теләгәндәй, уйланып әйтеп куйды: хәтерлисеңме икән, син бит утын хәзерләгәндә киселгән агачның божрасын саный идең, агачның яшен әйтә идең. Мин дә шул агач төбе шикелле инде хәзер.

Сабан туе дигәннән, без алты туган алтыбыз алты якта яшәсәк тә, авылның менә шушы садә бәйрәменә ел саен диярлек кайтырга тырышабыз. Гаиләләр белән. Әнинең, фәлән көнне сабан туе була, дигән кадерле хатын алуга хәзерләнә башлыйбыз. Менә, ичмасам, бәйрәм була! Рәмилнең төпчек улы Рәмис әйтмешли, ак әбинең кечкенә өенә егерме биш кунак тула! Үзе бер сабан туе!

Әни үзе сабан туена чыкмый. Безнең, бер төркем булып, мәйдан буласы болынлыкка юнәлгәнне күзләре талганчы җил капка катыннан карап кала. Мин сизәм: без, Кичү чокыры артына кереп, күздән югалгач та, әле шактый шунда басып торачак ул. Кулларын каш өстенә куеп әллә нәрсә тапкырлар, тагын бер генә булса да күрим әле үзләрен дигәндәй, талпынып-талпынып алачак.Ниләр уйлый икән ул менә шул мизгелдә? Бәхетле хис итәме икән ул үзен? Минем күп тапкырлар аңа шул сорауны бирергә җыенганым бар. Әмма һәрчак мине нидер тотып кала. Эчке бер аваз ярсып каршы төшә. Ярамый әниләргә андый сорау бирергә, ярамый, ди, син аның күзләренә кара, барысын да аңларсың.

Әнә шул эчке авазга ияреп мин ихтыярсыздан кабат сугыш елларына, яшьлегемә әйләнеп кайтам. Еракта-ерактан әнинең ул еллардагы тавышы ишетелә кебек. «...Син минем ничек әйтүемне тыңлап тор, авызыма кара. Телнең очы артка тартыла...» Без шулай хәрефләр, авазлар өйрәнәбез. Дөресрәге, ул мине, беренче класс укучысын өйрәтә. Хәер, хәрефләрне ул үзе дә миннән артык белми, ә авазларны дөрес әйтә. Мин аерым авазларны әйтә алмыйча азапланганда аның артыннан кабатлыйм да күзләренә текәләм: ничек, дөресме? Ул күзләрдә төгәл җавап күрәм.

Сугыш тәмамланып, ничә еллар узган булгандыр, хәзер төгәл хәтерләмим, бер көнне без энеләрем Ренат һәм Илдус белән өйне сипләргә булдык. Сипләү дигәннән, тәрәзә асларындагы черек бүрәнәләр урынына тазаларны тыгарга уйладык. Ул елларны өчебезнең яшен бергә кушсак та, бер ир уртасына җитмәгән чаклар иде әле. Безнең балта тавышы авырып яткан күрше Мортаза бабайны да аякка бастырган булып чыкты. Ул читән тишегеннән күзәтеп торып кына түзмәгән, бакча аша безгә килеп керде. Күзләре-кашлары яман да булып җимерелгән, тыны-хушы капланган. Оланнар, сез нәмә кырасыз, ди. Шәһидә килен эштә чакта өен сүтеп куярга ниттегезме әллә, ди. Алпан-тилпән атлап өйгә кереп китте. Кечкенәләр өйдә дип торам, йөрәгемне алдыгыз, дип аннан кире чыкты...

Шул көндәге эш әйбәт кенә тәмамлангач, кичен Мортаза бабай энигә, аның эштән кайтканын көтеп торып, болай дигән: өчесе тиң балта остасы икән бит, килен, оланнарың! Бар әле, кара әле нәрсә ясап куйдылар бит, дигән. Әни шаклар катып карап йөрде. Бүрәнәләрне тотыптотып карады. Кемнәрне генә чакырып рәтләтермен дип торадыр идем лә, диде әни азактан. Шул чакта аның күзләрендә бөтен дөньяның бәхете берьюлы балкый кебек иде. Шундый тирән мәгънә кайдан килә икән әниләребезнең күзләренә?!

Әле узган кайтуыбызда бугай, сүз ара сүз чыгып, гел актан киенгән әниебездән киленнәренең берсе сорап куйган иде: «Теге алсу җирлеккә кызгылт чәчәк төшкән күлмәгеңне тектермәдеңме әллә?» Әни җавап бирергә өлгермәде, Рәмиснең тиктормас теле ярып та салды: «Әби ак кәҗә сөте эчә, шуңа күрә кызылмы, зәңгәрме, әби киюгә, аның күлмәкләре барыбер агара! Аның чәчләре дә шуңа агарган. Мин сөтле чәй эчмим! Миңа шул!» Көлештек тә, шуның белән моны оныттык. Хәер, шулай микән? Әнидән башкаларыбыз гына оныттык түгел микән аны? Ник дигәндә, шул сөйләшүдән соң әнинең күзләрендә мин моңсулык билгеләрен шәйләп алдым. Элек беркайчан да күренмиләр иде алар. Ни бу? Үпкәме? Рәнҗүме?

Без үскәндә, безгә караганда, төпчек Рәмилне артыграк ярата кебек иде. Унөч оныгы арасыннан — аларның унысы кыз, өчесе малай — әнә шул Рәмилнең төпчеге Рәмисне сөеп туймый. Тик менә кәҗә сөте һәм ак чәчләр турындагы сүздән соң гына әни белән Рәмис арасына ниндидер күләгә килеп кергәндәй булды. Мин шулай сиздем. Сиздем генә дә түгел, мин моны авыр кичердем. Әнә бит ул картлар күңеле нинди! Юктан да хәтерләре кырылучан. Чү, чү, юктан булдымы соң? Андый сүз үтә яраткан заты әйткәнгә шулай булмадымы икән? Әллә, гомумән, андый сүзләрне ишетергә теләмәгәнме ул? Ни генә булмасын, Рәмис әйтте бит аларны! Берсендә минем улым белән дә шундыйрак хәл булган иде ләбаса. Әбисенең кадерләп саклаган медальләрен күргәч: «Моны эшләдек, тегене эшләдек, дип мактанасың, ә үзеңә медальләр генә биргәннәр, минем әтинең ордены да бар!» — дип әйтеп ташлаган иде. Әни медальләрен ашыкмыйча гына төенләп, иске урынына, сандык төбенә салып куйды. Белмисез шул сез, медаль бәясен белмисез, дип көрсенеп алды. Балаларга әбиләрнең чәченә кайдан килеп чал кунуын аңлатырга кирәк булыр. Без, сугыш елы балалары, ул бәснең әниләребез чәченә кайдан кунаклавын үзебез күреп үстек, ә хәзергеләргә аңлатырга кирәктер, мөгаен. Бәлки әнинең фермада мөдир булып эшләгән елларын сөйләрмен мин Рәмискә. Сызаларга су төшеп, юл өзелгән язгы чорда фермасындагы күтәрәмгә калган сыерлары турында сөйләрмен. Беренче көнне, бер сыерыбызга әллә ни булган, тора алмый дип, өйдән ярты чиләк чамасы он алып китүен әйтермен. Ә ярты чиләк онның ул елларда алты балалы семья өчен ни икәнен аналардан да яхшырак кем белә иде соң?! Икенче көнне фермада тагын унлап сыеры тормас булды. Өченче көнне ярты ферма күтәрәмгә калды. Әнинең өстенә гаеп ташланды. Иртәнге якта басулар буйлап кардан ачылган эскерт төпләре эзләп йөрсә, кичке якта тикшерүчеләр алдында утыра. Ул көннәрнең бер сәгате генә дә тулы бер гомергә торырлык иде.

Балаларны кылганлы тау итәгенә тезеп утыртып, тормышыбызның үткәне турында иркенләп бер сөйләргә кирәк әле. Аңларлармы? Аңларлар! Тизрәк язлар гына җитсен дә, ак әбиләренең, кайтыгыз оланнар, дигән чакыру хаты гына килсен!..

# Клара Булатова

## Печән өсте

«Тәрәзәләр ачып бер сызгырдым,
Болын печәннәре кипсен дип...»

Болын печәннәре, әй, кипте инде,
Җыеп алыр вакыт җитте инде.

Болын печәннәре кипте инде,
Сызгыручы, сиңа ни кирәк?
Сызгырганга, белмим, ни кирәктер,
Печәнчегә аяз көн кирәк.

Туктап торсын җәйнең яңгырлары
Без печәнгә төшкән көннәрдә...
Гөрләп-гөлдерәп тора Зәй буйлары,
Яше-карты бүген өмәдә.

Сөтбикәләр туплауларга күчкән,
Көтүчеләр терлек сугара.
Печәнлеккә савымчылар төшкән
Салкын әйрән белән сыйларга.

Кулларында кызның тустаганы,
Күзләрендә... (Әйтмик ул хакта.)
Шаян сүзләр монда, ә калганы
Кич әйтелер, бәлки, аулакта.

Гөрләп-гөлдерәп тора болын өсте,
Җиләк катыш үлән исләре.
Чәчми-түкми генә җыела күрсен,
Каерылыплар уңган печәне.

●

Әллә нинди татлы, тәмле бу хис
Күкләрдәнме шулай иңде дә,
Бик матур бер сүзсез көй шикелле
Үтеп керде бикле күңелгә.

Көтмәгәндә, җанның балкуының
Сәбәпчесе булган кешенең
Батырчылык итеп үземә дә
Әйтә алмас идем исемен.

●

Бу җанымны күпме рәнҗеттең син,
Бу күңелне күпме үртәдең.
Кар суыдай эзсез үтәр диеп
Уйлыйсыңмы җанга үткәнне?

Хәтер бар бит, ә ул чәчми-түкми
Саклый аны хәзер гомергә.
Рәнҗү хисе февраль кары түгел,
Мартка җеру белән эрергә.

●

Бар дөньяны ала урап
Көтмәгәндә болыт килеп,
Ул арада кырлар буйлап
Китә яңгыр биеп-биеп.

Ул да түгел, кыр битләрен
Яңгырдан соң сөртер өчен,
Күтәрә дә күк читләрен,
Кояш суза ал сөлгесен.

●

Син «ярату» дисең. Кем соң белгән?!
Бу тойгылар әле күңелне
Вакытлыча бары җилкендергән
Бер мавыгу гына түгелме?

Бик охшаш бит алар бер-берсенә,
Аеруы шактый кыен бит.
«Яратам» дип уйный кайчак кеше,
Я ярата чынлап «уен» дип.

Чираттагы янудыр бу синең,
Үтәчәген беләм мин аның,
Мин беренче сайлаганың түгел,
Соңгысы дип ничек инаныйм?

«...Таулар кисәр идем... (Бу — синең җыр!)
Диңгез кичәр идем яр булсаң».
Сүзең чындыр, бәлки, ялгышамдыр...
Бик шат булыр идем ялгышсам.

●

Әллә нинди назлы, тымызык көннәр,
Җир куенында эчке кайнарлык.
Җир күкрәге — таулар күккә тигән,
Мәхәббәттән тулып, кабарып.

Табигать тә хатын җаны белән
Тәңгәл булыр икән шулкадәр!
Рус телендә бу — «хатыннар җәе»,
Бездә — «чуак» диеп йөртәләр.

Язлар вәгъдә иткән җылылыкны
Җәйләр үткәч көзләр китергән.
Җыерчыклар биттә юкка чыккан,
Яңакларга ал төс йөгергән.

Бу «хатыннар җәе», үзе дәртле,
Үзе моңлы — кыска гомерле.
Нинди кыса тыеп калсын инде
Бер кузгалса хатын күңеле.

Табигатьнең үзе төсле инде,
Бар булганны юкка күчермәс.
Яратканга җанын ярып бирер,
Яратмаса якын китермәс.

Бер илереп алыр ут уйнатып,
Кайнарланып-янып яратып.
Мәхәббәттән кабат чәчәк атып,
Көндәшләре чәчен агартып.

...Бу — «хатыннар җәе» рус телендә.
Бездә «чуак» диеп йөртәләр.
Табигатькә без — хатыннар җаны
Тиңдәш булыр икән шулкадәр...

## Әхмәт Рәшитов

●

Бәхетсезлек күбрәк булыр иде —
Әле ярый, мин туганмын Җиргә,
Кемнәрнеңдер гади язмышына
Шатлык төсе булып үрелергә.

Ак биләүдә яткан чагымда ук
Мин кемнеңдер зур бәхете булган;
Әти белән әни, хәтәр чакта,
Өмет күргән минем елмаюдан.

Рәхмәт сезгә яшәү исеменнән,
Миңа тормыш бүләк иткән затлар!
Игелекле күңел — асылына
Чын тугрылык хисен мәңге саклар.

Мин сөйгән яр булдым саф җаннарга,
Мин таяныч булдым дуслар өчен, —
Җилгә-давылларга баш бирмичә
Раслап барам җирдә яшәү көчен.

Рәнҗетмәдем бугай беркемне дә,
Һәм кермәдем кеше өлешенә;
Нәфесем зурдан түгел — бик ризамын
Өлешемә тигән көмешемә.

Ялгышамдыр ахры — нәфесем зурдан:
Бәхетләләр күбрәк туалсыннар;
Шатлык чәчәкләре сибәм җилгә —
Моңлы башлар җыеп юансыннар.

Көрәш тә бар җирдә, үлем дә бар —
Хәсрәт буа күпме асыл җанны.
Ә мин китәм — үземдәйләр белән —
Идеалдагы бәхет китерер таңны.

### Кояшка мәҗүси ялвару

*1980 елның урак өсте*

Нигә чыкмыйсың син, кояш?!
Җан өши — суык;

Шушы әрсез болытларны
Таратсаң куып,
Нурга сусаган дөньяны
Көч итер идең,
Чәчәкләрнең рәхмәт сүзен
Ишетер идең.
Инде кайчаннан җир өсте
Гел манма суда,
Комбайннар тилмерешеп
Көтә басуда.
Оптимист ирләрнең хәтта
Йөзләре чытык;
Көттермә эшчән гавамны —
Чык инде...
Чык...
Чык...

## Сөбханалла!

*Мостай Кәримгә*

Сәердер дә бәлки... сәердер дә,
Кемдер хискә ярлыланганда,
«Сөбханалла» диеп сокланулар
Ак биләүдә яткан балага.

Бабайларның сүзен җиңел генә
Себереп түгеп булмый чүп кебек:
Син әйттең дә, менә тирә-юньгә
Иңгән сыман булды изгелек.

Син, дөньяны урап йөри торгач,
Гыйбрәт, акыл җыеп уеңа,
Хозер Ильяс сыман кисәк кенә
Кердең безнең кунак өенә.
Алып кердең Прометейлар утын,
Гүзәллеген Айгөл иленең,
Шуклык — шаянлыгын, сабырлыгын
Һәм гайрәтен Урал иренең.

Бу дөньяның асыл сыйфатлары
Мирас булсын әле дигәндәй,
Олы башың кече итеп шулай
Бер сабыйга башың игәндә,

Уйладым мин: язмыш дулкыннары
Кая илтмәс тормыш көймәсен?..
Һәм үзеңә теләк теләдем мин:
— Сөбханалла! Күзләр тимәсен!

## Яңа Афон

Мәгарә дисәң дә мәгарә —
Бар халкы сыярлык Кавказның,

Тын гына моң ага ташлардан —
Борынгы заманнар авазы.

Гасырлар буена кешеләр,
Ызгышып ничәмә-ничә кат,
Сугышкан, суешкан арада
Могҗиза тудырган табигать.

Эрегән иң асыл сөякләр,
Черегән иң ачы камчылар;
Дәверләр кичкәнне исәпләп,
Тып та тып тамалар тамчылар.

Тамалар ашыкмый, сак кына,
Ниндидер сер сөйләп тамалар;
Таш сыннар, әйтерсең, яудан соң
Бабайлар калдырган балбаллар.

Сталагмит икәнен бик беләм —
Кирәкми аңлату, өйрәтү.
Тик күзгә ташлана һәр яктан
Я җайдак, я кылыч сурәте.

Бах моңы, йөрәккә кагылып
Тибрәтә кылларын органның,
Гүя ул искәртә бүгенгә
Елларның кай таба барганын.

...Мәгарә — таш гасыр чынлыгын
Төшенү өчен бер сәбәпме?
Я ачы гыйбрәтме, сабакмы,
Я туктап уйланыр сәгатьме?

## Мәхәббәт вәгъдәсе

*— Сез монда кара киемле хатын-кызларның күплегенә игътибар иткәнсездер...*

Экскурсовод сөйләгәннәрдән

Кара күлмәк, кара яулык,
Моңлы хәтер, авыр уй...
Әле кайчан әйткән иде:
— Сарры барры бзыйбсбой [1].
Сугыштан, утлар эченнән
Кайтмады илгә кире —
Кара туфракка баш салды
Пәһлеван кебек ире.
Колакта тик назлы сүзе:
«Сарры барры бзыйбсбой»...
Кара күлмәк, кара яулык,
Моңлы хәтер, авыр уй...

Апснида [2] гадәт шундый:
Якыннары хакына
Гомер буе кайгы төсен
Салмый йөртә хатыннар.
Ә яшәеш дәвам итә.
Ә яшьлектә шул ук уй:
«Мин сине яратам», ягъни:
«Сарры барры бзыйбсбой».
И кара каш и зифа буй,
Туй артыннан үтә туй.
Ә вәгъдәләр борынгыча:
«Сарры барры бзыйбсбой».

[1] Мин сине яратам. Абхазча.
[2] Апсни — Абхазияне җирле халык шулай атый.

## Хәмит Төхфи

# ТӨРЛЕ ЕЛЛАРДАН

## Ватан

Артта калды бамбуклы Кытай,
Тянь-Шань чумды зәңгәр томанга.
Алда исә тасма кебек юл,
Илтә мине анам — Ватанга.

Алда Ватан — туган илкәем,
Һәр адымда якын, якты йөз.
Кайнар хисләр тәэсире белән
Ихтыярсыз яшькә тула күз.

И син минем алтын бишегем,
Сагышымнан кайттым мин сиңа.
Туфрагыңны сөртсәм күзләргә,
Гаҗәпсенеп бакма син миңа.

Хаҗәт түгел сәерсенүләр! —
Һич кенә юк аның кирәге,
Чөнки минем бабаларымның
Шул туфракта ята сөяге.

Чөнки шушы мөкатдәс җирдә
Көтә мине бәхет йолдызы.
Артта түгел, фәкать алдымда
Гомеремнең нурлы көндезе.

Калды инде чит ил артымда,
Чигараның [1] аргы ягында;
Анда күргән кимсенүләрне
Күрмәм инде, күрмәм тагын да.

*Фрунзе. 1955.*

## Кирәксә

Һаман да үземнән сорыйм мин шуны:
Түгелме уйларым минем берьяклы?

[1] Чигара — чик ара.

Купшы сүз булмасмы Ватан дигәнем,
Ватанның дәхеле [1] миңа ни чаклы?

Дөрес, мин шигырьләр язам Ватан дип,
Теләмим үземне ләкин алдарга:
Кичмәмме, Ватаным, мәсләкләремнән [2],
Зояны аскандай, илтсәләр дарга?

Мусадай нык тору килерме кулдан,
Әгәр дә башыма төшсә шундый хәл?
Газраил алдында тез чүкмәмме соң,—
Җитәрме батырлык, җитәрме әмәл?

Тәкатем [3] бетмәсме бөтенләй корып,
Жаннаны яккандай яксалар утта?
И Ватан, син диеп үлмәде кемнәр,
Син диеп ятмады кемнәр табутка?

Уйласам, беркемнән артык төшем юк,
Берничек аерылып тормыйм алардан.
Кирәксә, ил өчен яланаяклап
Барырга риза мин уттан, карлардан.

Бу әле шигырьдә язган сүз генә,
Гамәлем аерылмас, дим мин, сүземнән.
Иленнән ваз кичү — мескенлек, зәгыйфьлек,
Аларны мин куам — куам үземнән!

*1976*

## Изге теләк

Гадәт булып әверелде инде
Ел озатып, еллар каршылау.
Килгән саен һәрбер яңа ел,
Борчуы да килә бер олау.

Һәр ел саен куя кузгалып
Йөрәгемнең иске ярасы.
Нигә инде яши алмый, дип,
Тыныч кына адәм баласы?!

О, ялыктым ызгыш, гаугадан...
Йөрәгемне куяр урын юк.
Кирәк иде тату яшәргә!
Мөмкинлеге юкмы шулай ук?!

---

[1] Дәхел — катнашы, йогынтысы.
[2] Мәсләк — дөньяга караш — тоткан юл.
[3] Тәкать — түзем.

Миңа калса, мөмкин барсы да,
Мөмкин булмас нәрсә юк җирдә.
Чын дуслыкта яшәү дә мөмкин,
Талашмый да, сугышмый бер дә!

Барган юлым — кылыч, нечкә кыл,
Авыр йөктәй дәһшәт аркада...
Ә йөрәктә фәкать бер теләк:
Итсен иде акыл тантана!

*1976. Ташкент.*

## Капчагай диңгезе

Басып торам диңгез буенда,
Тик бер генә фикер уемда.

Манзарадан хайран идек без,—
Юк иде бит монда бу диңгез?!

Дала иде бөтен тирә-як.
Үсемлеге — камыл да янтак [1].

Хәзер исә кичә вә көндез
Шаулап тора монда зур диңгез.

Шаулап тора дулкыннар һаман...
Шул шаулауда чагыла заман!

*1975. Алма-Ата.*

## Кызганыгыз

Чәчәкләрне кызганыгыз,
Кызганыгыз лаләләрне.
Яз килсә бит бизи алар
Безнең сәхра, далаларны.

Кызганыгыз, лаләләрне
Өзәргә дип сузганда кул —
Матурлыкка бәхетсезлек
Иярүчән буладыр шул...

*1977. Ташкент.*

[1] Янтак — чүп үлән.

## Булсачы

Кирәк икән, нәкъ битенә
Бәрә алам хак сүземне.
Хаксызлыкны җәзаламау —
Ул җәберләү бит үзеңне.

Әйе, шулай, хакыйкатьне
Ярып салу зур батырлык.
Аһ, булсачы әйткәннәрем
Җансызны да кузгатырлык!

*1977. Ташкент.*

# ШАГЫЙРӘ—АККОШЛАР ИЛЕННӘН



*Роза Хәлиуллина — Актанышта, аның пристаньле, болыннары, су буеның әрәмә, куаклары белән атаклы Әҗәкүл авылында туып, үзе язганча, «Агыйделдә йөзеп үскән» кыз. Чынлап та, Татарстанның гаҗәеп матур бер почмагы ул Актаныш ягы — әллә ничә елга, урман, күлләре, якты йөзле, эшчән, талантлы халкы белән җырларга күчкән шигъри төбәк ул. Элек-электән әдәбиятыбызга, сәнгатебезгә яңа бизәк, үзенчәлекләр алып килгәннәр ул яктан. Әле дә чишмәләр кипмәгән, күлләр корымаган: халык күңеленнән хис, моңнар алып, шигъриятебезгә яңалар, яшьләр килә тора. Роза Хәлиуллина әнә шундыйларның берсе.*

*Ул инде ун-унбиш елга якын яза, вакытлы матбугатта катнаша килә. «Беренче карлыгачлар» сериясендәге китапта да басылды аның шигырьләре, «Беренче адымнар» исемле күмәк җыентыкта да, шагыйрәләребезнең иҗатын туплаган «Кызлар җыры» исемле китапта да. Кечкенәләр өчен «Бөрлегәнгә медаль», «Чүкеч — нәни булышчы» кебек китапларын да чыгарды ул — алар шагыйрәнең эзләну, үсү юлындагы беренче тәҗрибәләре иде әле.*

*Соңгы елларда исә ул иҗатка бик җитди кереште, «Каенана» исемле, әдәби җәмәгатьчелек хуплап каршы алган поэмасын, күп санлы лирик шигырьләрен язды. Узган елда дөнья күргән «Агыйдел—аккош иле» исемле шактый күләмле китабы басылып чыккач, ул Актанышта уздырылган яшь язучыларның зона конференциясе исеменнән СССР Язучылар Союзы членлыгына тәкъдим ителде.*

*Роза Хәлиуллина күп яза, эзләнә. Ул озын-озын поэмаларда да көчен сынап карый. Аларда да үзенең аккош иленә — Актанышка, анда узган балачак хатирәләренә кайта — узган сугыш чорындагы авыл, аның олы рухлы кешеләре, бердәмлек, Ватанга мәхәббәт һәм бүгенгенең матур үзгәрешләре турында яза. Дөрес, поэмаларда озынлык, кайчакта күпсүзлелек, ашыгу, композицион таркаулык сизелә әле, әмма бернәрсә шиксез: алар самими, эчкерсез хисләләр. Билгеле, бу өлкәдә осталыкка ирешү өчен шагыйрәгә образлар, тел өлкәсендә күп эшләү һәм эзләнүләр кирәк булачак.*

*...Аккош иленнән — Агыйделдән килгән шагыйрә үзенең илле яшьлек бәйрәмен каршылый.*

*Аңа яңа иҗат уңышлары телик.*

## Роза Хәлиуллина

## ЯШЕНЛЕ ЯШЬЛЕГЕМ

●

**Күкләр — ять-яшь,**
**Яшеннәре — алмаз,**
**Көчле күкрәү — гүя, Алпамша...**
**Аяз күкне кем соң җиңел генә**
**Болытлы күк белән алмаша!?**

Язлар яшь-яшь.
Яшьнәп яшәр яшь чак.
Ник чатырдап китереп ормаска!
Ник алмашыйк хаклы яктылыкны!
Безнең буын! Безнең җыр ласа!

Җырлар яшь-яшь,
Язгы яшен — алмаз.
Язгы күкрәү — яшь-яшь Алып ла...
Язгы яңгыр!
Туккән яшь тә газиз —
Соңра җирдә Бәхет калыкса!

●

Я кайгы бир, я шатлык бир,
Кирәкми урталыгы.
Күкрәгемә кирәк ахры
Йөрәкнең утталыгы.

Утларына кирәк ахры
Йөрәкнең юкалыгы.
Беләсеңдер йөрәк киткән
Утларга кирте югын?!

●

Яшенле елдыр,
Ялтыр да йолтыр.

...Телләре җордыр,
Җырлары елгыр:
Яшендә туган,
Ташкында йөзгән,

Яшьлегем булып
Каршыма килгән.

Яшен чаткысы,
Җаным яктысы...

Ничек, ничек соң
Җуймый саклыйсы?

●

Кулдан килмәс гамәле юк,
Иңләмәгән галәме юк.
Халык бөек. Адәм бөек.

Чоры биек. Җыры бөек!
Җырчы Чулман — Болгар бөек.
Кирәклесен күзгә карап
Әйтеп биргән телләр бөек.

Туп-турысын, курыкмыйча,
Әйтә торган еллар бөек.

Гаделлектән тайчанмыйча,
Юл алучы уллар бөек!

Корычтай нык заманаы
Күккә чөйгән кыллар бөек!
Җырлар бөек!

●

Малай тай хәтле таш курде —
Тау дип аңа исем бирде.
Төпеч табып алды малай;
Төпеч, тайдай, очындырды...

Аңа һөрни көчен бирде,
Кыя ватар тешен бирде,
Ир-ат диган исем бирде.
Канатлы кош хисен бирде.

●

Аңа һәрни ямен бирде.
Аң-белемен, гамен бирде.
Сөя белү, аерылу,
Сагынулар тәмен бирде...

Егет таудай уй-хәсрәтен
Аттай тартып дөнья күрде.

Санга сукты дөнья ирне,—
Таштай башын моңга төрде...
Таудай җанын утка төрде.
Ә ул яши бизәп Җирне!

●

Арытулар аңны авырайта,
Арытулар башны аңгырайта.

Арытулар... җанны шул картайта.
Ялга, ялга юллар, әй, кай якта?

Аңга ялкын өстәр әмәл кая?
Ялкын эзләп йөрим — гамәл кая?

Гамәлләр — кош... Ә каурыйлар буштыр.
Кәгазьләрем гаҗиз: кыштыр-кыштыр...

Гамәлләрем кәгазь өсләрендә,
Моңнарым көл — йөрәк мичләрендә,

Җегәр кирәк — җылы, җилләр, таулар!..
Көчле каурый-кәгазь, илһам. Даулар!

...Җанның шунда үзгә текәлеге.
Ялкынга кем сала иркәлеген?!

...Арып-талып тапкан ялкыннарым.
Ауган Алып сыман калкынамын!

Гамәл — кояш, каурыйлар көләчтер.
Кәгазь җырлый: — Башкынаең яшьтер?!

●

Алмагачлар кара көйде бу яз,
Ак чәчәк юк, каргыш иңгән гүя.
Куркыныч көй агачларда йөрде —
һәр алмагач Хиросима гүя.

Карау авыр: каралган алмагач,
Ирләр алды балта, чыдамагач:
Утынлыкта инде алмагачлар...
— Инде, агач, кистем түзалмагач,
Җир туңмасын, җаны исән булсын,
Җир сау булса үсәчәк яшь агач.

...Алма ярга тиде ятлар сүзе...
— Кис, каралдым, дип ул балта суздың...
Мин чапмадым алма билләренә,—
Сызды ярым үзе, аягүрә...
Сызды...

Миңа таныш Хиросима сүзе!

●

Ашкынабыз — ташынабыз.
Ашкынуда ачылабыз —
Җир өстенә якты биргән
Җәүһәр булып чәчеләбез!

Ашкынабыз — ташынабыз
Кичәгедән бүгенгегә.
Бүгенгедән... үткәннәргә,
Безне оныт иткәннәргә.

Уйлар чаба, башта ташый
Дөньялыкка... хәзинәсен,
Нәни башта шигъри ташкын...
Ташкынны кем кадерләр соң?..

..................

## Әмир Мәхмүдов

### Бәхетем үзем белән

Тормышың күңелсез,— димә,
Аңлатма күзең белән.
Бәхетем ул — тормыш юлым,
Бәхетем үзем белән!

Миңа шатлыкларым юлдаш,
Сөюеңне дә беләм.
Мәхәббәтсез кеше! — димә,
Бәхетем синең белән,
Бәхетем үзем белән!

### Ал бозлар

Син — үзең бер дөнья,
Мин — үзем бер дөнья.
Син — үзең бер дәрья,
Мин — үзем бер дәрья...

Омтылды дөньялар,
Чайкалды дәрьялар.

Мәхәббәт бирелнмәде,
Мәхәббәт үрелмәде...
Дәрьялар кушылыр чакта
Ал бозлар эремәде.
Ал бозлар эремәде!

●

Килә бер көн: шатлыкларың
Өелеп ята тау кебек.
Килә бер көн: кайгыларың
Кисеп үтә бау кебек.

Килә бер көн: дөнья буйлап
Син агасың сал кебек.
Җирнең иң-иң гүзәл кызы
Каршы ала таң кебек...

### Яшьлек

Ашкынып, күкрәп үтте ул —
Яңгырап үтте яшьлек.
Йөрәккә күз яшьләреңне
Яудырып китте яшьлек.
Мәңгегә мәхәббәт утын
Яндырып китте яшьлек.
Гомерлеккә моң-зарларын
Калдырып китте яшьлек.
...Көйдереп кенә үтмәде,
Яндырып китте яшьлек!

..................

КПССның XXVI СЪЕЗДЫ
КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА

Марсель Зарипов

# ШӘҺӘРНЕҢ АЧКЫЧЛАРЫ

*...Шәһәр төзелеше, тулаем алганда, тагын да зуррак матурлыкка һәм төрлелеккә мохтаҗ.*

Л. И. Брежнев. КПССның XXVI съездына КПСС Үзәк Комитетының отчет докладыннан.



Түбән Каманың хәзер атаклы шәһәр булып китүе бер дә гаҗәп түгел. Җирдән әллә кайда биеккә торба, аппаратлардан әкәмәт корылмалар торгызучы оста монтажчыларның, атом һәм молекулаларның тылсымын белүче аппаратчы мастерларның сокландыргыч эше илгә генә түгел, бөтен дөньяга билгеле. Әле кичә генә беркемгә билгеле булмаган шушы аулак җирдә ясалган сыгылмалы каучукны атаклы индустриаль башкалаларда эшләнгән әйбер кебек үк бик кирәксенеп алалар. Шәһәр советы башкарма комитетының председателе Фәрит Бәдретдинович Баһаветдинов белән бергәләп шәһәр карап йөргәнебезне бик ачык хәтерлим әле: чүп-чар, былчырак эчендә яткан яңа төзелешләрне, яңа гына тормыш корып җибәргән кварталларны карарга вакыт кызганмаган идек. Укучым төшенгәндер, шәт. Яңа туып, төзелеп килә торган бу шәһәрнең бөтен эш-мәшәкате аның җилкәсендә. Андагы барлык кешеләрнең шатлыгы да, кайгы-хәсрәт, борчулары да аның өчен уртак, чөнки алар кай яклары беләндер председательгә дә килеп кагыла, ул кешеләрнең сөенечләре, борчу-мәшәкатьләре аның тырышлыгына, акылына, төн йокламый, ял итми эшләвенә килеп бәйләнә. Баһаветдинов шәһәр турында зур бер җанлы нәрсә кебек итеп фикер йөртә, ул аны күреп кенә түгел, бәлки йөрәге, күңеле белән тоеп эш итә. Үз эшенә вазифа итеп кенә карамый ул. Берәүләр Түбән Кама каласы турында сөйләгәндә күбрәк дан-шөһрәт күрәләр, күбрәк алкыш-тәбрик авазлары ишетәләр, шәһәр башлыгының үендә исә мең төрле кайгы-мәшәкать. Берәүләр шәһәрдәге тормышны, андагы эшне үз чамасы белән чагыштыра, икенчеләре исә, киресенчә, еракка карап эш итәләр, алдагы зуррак мөмкинлекләрне күрәләр.

Шул сөйләшүдән соң байтак еллар узды. Баһаветдинов белән Түбән Кама каласы буйлап әле кичә генә йөргәнбез шикелле. Ә шәһәр бөтенләй танымаслык булып үзгәргән! Биш катлы йортлар салудан туктап, тугыз, унике, уналты катлы итеп төзи башлаганнар, шәһәрнең дан-шөһрәте, атаклы эше, вакытында яуган яңгыр, срогында өлгергән ашлык кебек, табигый бер нәрсә итеп карала. Кайчан гына әле кала урамында беренче кагылган казыкка, беренче салынган йортка, беренче туган балага сөенгән идем мин! Хәзер исә меңләгән кеше яшәрлек зур микрорайон төзү, яңа мәктәп, магазин, балалар бакчасы һәм яслеләр салу гадәти бер эш санала.

Түбән Кама каласына бу килүемдә мин шәһәрнең киләчәге хакында сөйләшәсе җаваплы, җитди бер киңәшмәгә туры килдем. Бу күп халык җыя торган киңәшмә түгел, шуңа күрә кеше аз иде. Фикер алышу идеясен комбинатның генеральный директоры Николай Васильевич Лемаев кузгаткан, киңәшмә аның кабинетына җыелган иде. Зур гына өстәлнең бер ягына генеральный директор, партиянең шәһәр комитеты беренче секретаре Илдус Харисович Садыйков, шәһәр башкарма комитеты председателе Фәрит Бәдретдинович Баһаветдинов урнашкан. Шәһәрне проектлаштыручылар үзләренә бер төркем булып утырганнар: Мәскәүдән «Гипрогор» институтының өченче архитектура мастерскоеның җитәкчесе Лев Романович Шмах, проектның баш архитекторы Юрий Ефимович Беляев, мастерскойның баш архитекторы Юлия Васильевна Коробова. Болар шәһәр әле дөньяга туганчы ук аны хыял итеп күз алдына китергән, киләчәктә, ун-унбиш елдан соң аның нинди булырга тиешлеген дә күздә тоткан кешеләр. Бирегә тагын генеральный директорның капиталь төзелеш буенча урынбасары Рафаиль Григорьевич Глянц, шәһәрнең баш архитекторы Марат Шамилевич Юсупов та бар. Мин, әңгәмәгә комачауламаслык итеп, читкәрәк урнаштым.

Үткен, тапкыр сүзләр күп әйтелгән, шулай да җитдилеген югалтмаган бу әңгәмәнең кыскача язмасы менә болайрак.

— Ягез, каланы ничегрәк итеп төзибез? Аркылыгамы, буйгамы? — дип, генеральный директор, кабинетның хуҗасы буларак, сүзне башлап җибәрә. Аның бу шаярту тонына башкалар да кушыла.

— Кыйгачлап төзергә дигән фикер бар, өлгертүен — начальство кушканча.

— Шәһәр карарга дип кенә килгән идек, нәкъ кызуына килеп каптык — Орелдагыча өзлексез төзү турында уйларга. Бу хакта да монда киләсе көнне самолетка утыргагда гына белдем.

— Бу мәсьәләне инде ике ай буе обком бюросына хәзерлиләр.

— Бюро анысы үзенә башка. Проектлаштыручыларның группасын бермә-бер арттырырга, тагын кырык кеше булдырырга, ике йөз метр торак мәйдан табарга кирәк. Быел йөз кырык мең кв. метр квартир өлгертәбез, киләсе елда — 150 мең, сиксәненче елда — 160 мең кв. метр квартир өлгертәбез.

— Шуннан да артыгына көчәнәсе юк. Бу кадәресе дә стандарт төзелеш ярдәмендә генә булачак. Индивидуаль проектлар эшләргә кирәк.

— Икенче Черемушки буламы?

— Башкалага иярү мәҗбүри түгел, һәр шәһәрнең үз йөзе, үз рәвеше булырга тиеш.

— Шәһәрнең социаль куәтен арттырырга, торак төзелешен елына 200 мең метрга җиткерергә кирәк.

— Ул метрларны кәгазьгә сызу кыен түгел лә. Көч-нама җитәр микән соң?

— Проектчылардан берәрегез Түбән Камага күчеп килегез, автор буларак, эшне күзәтеп барырсыз. Килү белән үк квартир һәм машина бирәбез.

— Барлык акчаның биштән бере генә шәһәргә тотыла, ә аны кырык процентка җиткерәсе иде.

— Программаны җиде-сигез елга алдан төзеп куярга, ихтыяҗлар белән мөмкинлекләрне тәгаенләп билгеләргә иде. Мәскәүгә лимитларны, финанс чыганакларын ачыкларга баргач: «Ишекне теге яктан ябыгыз. Шәһәргә дигән 45 миллион акчагыз бар, шуның утызын гына эшкә тоткансыз!» — диләр.

* * *

Түбән Кама каласы архитекторларның проектларында гына, плановик экономистларның, акча һәм материаль-техник байлыкларны бүлүче белгечләрнең исәп кәгазьләрендә генә яшәгән елларда ук сөйләшеп бетерәсе сүз ни өчен кала төзелә башлавының унтугызынчы елында да әле һаман борчый-дулкынландыра соң?

Хәлне беркадәр ачыклау өчен, иң элек Татарстан Министрлар Советының Түбән Кама шәһәрендәге хезмәт идарәсе вәкиле А. Хәлимовның белешмәсен укып карыйк. «Соңгы елларда Түбән Кама каласына кеше килү 26,6 процентка кимеде. Шәһәрдә

тезүчеләр азая бара. «Татэнергострой» идарәсенең генеральный подрядчигы коллективы 1977 елда өч мең ярымга җитәргә тиеш дип уйланылган булса да, 800 кешегә кимеде»,— диелгән ул белешмәдә.

Шушы саннар турында бераз фикер йөртеп карыйк. Төзү эшендә нигә кеше кимегән, ни сәбәпле шәһәргә кеше әзрәк килә башлаган?

1970 елда Түбән Камадагы бөтенсоюз удар төзелешенә 10856 кеше килгән, шуның 4992 се кире киткән, халык 5864 кешегә арткан. Шуннан соңгы елларда шәһәргә килүчеләрнең саны бер ярымга арткан. Китүчеләрнең саны күбрәк булса да — 6867 кеше киткән, халык саны 8284 кә арткан. Аннан соңгы өч елда да килүчеләр арта барган — 15 979, 16 710, 21 217 кеше. 1974 елда шәһәрдә калучыларның саны китүчеләрдән 10 121 кешегә арткан.

Шуны да истән чыгармыйк. 1969 елда шәһәрдән кырык чакрымда гына зур КамАЗ төзелә башлый. Шуңа да карамастан, Түбән Кама барыбер үзенә яңадан-яңа кешеләрне тарта, нефть химиясенең яңа үзәге автомобиль төзүчеләр, Камада гидростанция төзүче энергетиклар белән тигез ярыша.

Аннары инде — 1975 ел. Унике ай эчендә Түбән Камага 8756 кеше килә, 3503 кеше китә, нәтиҗәдә шәһәрдә 5253 кеше арта. Тормышы җайланган иске шәһәрләр эш көчен демографик баланс, үзендә туып үскән кешеләр исәбенә таба торса, яңа шәһәрләргә читтән килүчеләргә генә исәп тотарга туры килә. Удар төзелешләрдә эш кайный, промышленность мәйданнарында яңа заводлар салалар, реконструкцияләнләр, искеләрен яңарак технологиягә күчерәләр, шәһәр үсә бара. Унынчы бишьеллыкта 2 миллиард сумлык, алдагы биш ел белән чагыштырганда, ике тапкырга диярлек күбрәк эш башкарасы бар иде. Монда һәр кеше алтын бәһасе. Нефтьче-химиклар, шинчылар, кешеләрне эштән алып, бишәр йөз кешелек ике удар отряд төзиләр.

Ә хәрәкәттәге аппаратлар бүгеннән үк дүрт меңләп кеше көтә. Шинчыларга да шул чама эшче кирәк. Төзүчеләргә дә кеше җитми.

Генеральный директор кабинетындагы очрашуга, андагы җитди сөйләшүгә әнә шул хәл төп сәбәп булган иде.

*

* *

Сугышка кадәр булган унөч ел эчендә, 1926 елдан алып 1939 елга хәтле, безнең илдә 482 шәһәр үсеп чыккан. Сигезенче бишьеллыкта тагын 112, тугызынчы бишьеллыкта исә 83 шәһәр барлыкка килгән. Озакламый Советлар Союзында тагын 600 шәһәр үсеп чыгар диләр. Унынчы бишьеллыкның башында безнең илдә 2013 шәһәр бар [1], шунда барлык халыкның дүрттән өч өлеше яши иде. Урбанизация (галимнәр авыл халкының шәһәргә күчеп тора башлавын шулай дип атыйлар) шундый хәлгә китерәчәк — шушы гасыр азагында шәһәр халкы 85—90 процентка җитәчәк. Ә безнең гасырның башында исә, киресенчә, шул хәтле халык авылда яшәгән, шәһәр халкы унбиш кенә процент булган.

Түбән Камадагы, җир асты тамырлары белән Идел, Урал, Себер промыселларына барып тоташкан нефть химиясе индустриясенең яшь бер үзәге, куәтле реакторларында нефтьне кан урынына куган йөрәк кебек, башка шәһәрләргә, зур промышленность комплексларына да тереклек һәм эш бирә. Элекке тын, аулак бер җирдә үсеп чыккан Түбән Кама каласы Комсомольск, Магнитка, Братскиларның җилкәсенә басып калыкты. Бу шәһәр үзеннән алда салынган калаларның ялгышларын кабатламады, хәтта шәһәр төзү сәнгатенең уңышлы бер мисалы булды.

Иртәгәсе, киләчәге нинди булырга тиешлеген күз алдына китермичә салына башлаган шәһәрләрдән үзгә буларак, Түбән Каманың киләчәге, бәхетле баланыкы кебек, алдан ук ачык итеп билгеләнеп куела. Ярты меңләп шәһәрнең «атасы» булган «Гипрогор» институты Түбән Кама каласының генераль планын төзи. Алтмышынчы елда, каланы төзергә керешүче беренче энтузиастлар баракларга, якын тирәдәге

---

[1] Г. Куцев. «Молодежь и молодые города», М., 1977, 341 б.

авылларга урнашып, эшкә башлаганда, бу проект ВДНХның (Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең) алтын медаленә лаек була. Сирәк хәл бу, бик сирәк хәл. Проектчылар, бу уңыштан канатланып-дәртләнеп, шәһәрнең эш сызымнарын сызарга керешәләр.

Ә генплан — эшнең башы гына әле. Иң мөһиме — аны чынга ашырырга, шәһәрне вакыт сынавы аша, һәртөрле ведомство киртәләре аша уздырырга кирәк. Шәһәрләрнең ведомстволар белән, ведомстволарның шәһәрләр белән еллар буе талашып-көрәшеп килүләре һәркемгә мәгълүм. Шәһәр эчендә «хосусый мәнфәгатьләре» булган бик күп министрлыклар, аларның төрле тармаклары үзләрен коммуналь йортта күршe уты яктысында газета укырга яратучы кешеләр кебек тоталар. Әйтик, Братск шәһәре ведомстволар тудырган шулкадәр газап вә михнәт эчендә төзелә, моның нәтиҗәләренең мәшәкате әле туачак буыннар өчен дә җитәрлек булыр. Братскиның генпланы шәһәр үзе салына башлап, дүрт ел узганнан соң гына төзелә. Шәһәр үзе һәр ведомство аерым-аерым салган энергетиклар, төзүчеләр, монтажчылар, урман кисүчеләрнең поселокларыннан оеша... Идел буе автомобильчеләренең башкаласы Тольятти шәһәре никадәр заманча, яңача, матур итеп төзелгән булса да, шәһәр советы председателе Борис Самуилович Кашунин барыбер газетада, унбиш министрлыкның ишеге төбенә барып хәер сорарга туры килә, дип зарлана[1]. Берәүләр шәһәргә ярдәм кирәклеген бик яхшы аңласалар да, бирергә акчалары юк, икенче берәүләрнең бар, ләкин шәһәрнең кайгысына аларның исләре китми. Һәр ведомство үз предприятиесе һәм учреждениесе хезмәткәрләренең башкалар салган кинотеатрларда фильм карауларын, суны кеше колонкасыннан алганны, гомумән, башкалар җәйгән тротуардан йөрүне яхшырак күрәләр. Алар өчен күктәге кояш уртак булса, шул җиткән...

Менә шуның яңа бер мисалы. 1978 елның җәендә Байкал — Амур магистраленең башкаласы Тындада СССР Госгражданстрое, РСФСР Госстрое һәм СССР Архитекторлар союзы идарәсе секретариатының читтәге утырышы булды. Кала төзү эшен яхшы белүче бу белгечләр әлеге олы трассаның башкаласында 14 поселокны җылыта торган 38 котельный санап чыгаралар. Бу поселоклар төрле ведомстволарга карый, котельныйлар да шулай.

Түбән Каманы күп кеше бәхетле кала дип саный, ул төрле ведомстволның талашызгышларыннан азат, кайбер башка шәһәрләр, зур төзелешләр, яшь булса да, инде илгә танылып өлгергән кайбер промышленность үзәкләре кебек, акча кыенлыгын да күрми. Шәһәрнең бердәнбер заказчысы, дөресрәге, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе промышленносте министрлыгы йөзендә бердәнбер хуҗасы бар, аның өчен барлык финанс чыганаклары ачык — бюджеттан ссуда да, кредит та бирәләр. Акчаның һәр сумының кая тотыласы Госплан тарафыннан алдан ук билгеләп-язып куелса да, Түбән Кама өчен акчаны табу түгел, бәлки аны ничек тотып бетерү мәсьәләсе каршыга килеп баса! Бик күпләрнең төшендә генә күрерлек, хыялында гына йөртерлек бәхет бу!

Заказчы, проектчы һәм төзүчеләрнең көчле бер триумвират булып берләшүе шәһәрне салганда, зур нефть химиясе комплексын төзегәндә уртак стратегия һәм бердәм тактика сайларга мөмкинлек бирә.

Башка урыннарда бүген хәл итеп булмый, киләчәктә генә өмет ителә торган мәсьәләләрне ансат кына тормышка ашырса да, Түбән Кама каласы алдына тагы да катлаулырак, тагы да авыррак яңадан-яңа бурычлар килеп баса тора. Аларны башкарып чыгу өчен алга карап күрә белергә, вак-төяк уңышка алданмаска, төп максатны күздә тотарга кирәк. XXVI съездда Леонид Ильич Брежнев әйткәнчә, халык хуҗалыгының зур мәсьәләләрен тормышка ашырганда экономик үзгәртеп корууларның социаль нәтиҗәләрен алдан ук күрә белергә, шуларның кешеләр тормышына, кешеләр язмышына нинди тәэсир — йогынты ясаячагын чамалый белергә кирәк.

---

[1] «Шәһәрнең яшьлек еллары». «Комсомольская правда» газетасы, 1978 ел, 18 январь.

Түбән Кама каласы элек-электән бәхәсле булып килгән бер зур мәсьәләне дә — иң элек заводларны сала башларгамы, әллә шәһәрнең үзенә керешергәме дигән мәсьәләне дә хәл итте. Гадәттә бик күп социаль, экономик һәм психологик сәбәпләр аркасында беренчесен төп эш итеп саныйлар. Түбән Кама башта ук акыл белән исәпләп эшкә тотынды.

Алай да индустриаль Кама аръягында куәтле промышленность үзеге төзү бурычын үз өсләренә алган ике министрлык: нефть эшкәртү һәм нефть химиясе промышленносте министрлыгы белән Энергетика һәм электрификация министрлыгы да иң элек заводларны төзергәме, әллә шәһәрнең үзеннән башларгамы дип, ике юлның берсен сайлау кыенлыгы алдында калганда, башка мөмкинлекләрне эзләп тормастан, ахыр нәтиҗәсен ныгытып уйламастан, беренче юлны сайладылар. 1967 елда Түбән Камадагы нефть химиясе промыселлардан килгән чималны эшкәртә башлаганнан соң, шәһәргә тотылган чыгым ике тапкыр гына тулай чыгымның биштән бер өлешеннән артыграк була. Шуннан соң инде «өлешләр» чагыштырмасы үзгәрә, «санкультбыт» өлеше унөч-унбиш процент чамасында гына кала.

Матур-матур шәһәрләр күз ачып йомган арада әкиятләрдә генә барлыкка килә ул, чынлыкта исә алар бик акрын үсә, бик күп көч-тырышлык куеп, унар, йөзәр еллар буена төзелә. Тарих өчен егерме ел ара ул — диңгез буендагы Ѣер ком бөртеге кебек кенә. Заманча итеп төзелгән проспектлары, урамнарындагы яшеллек, чәчәк түтәлләре, магазиннардагы неон утлары, шау-гөр килгән бала-чага тавышлары белән бергә, Түбән Кама каласының күзгә ташланырлык башка яклары да бар. Моннан ун ел элек микрорайоннарда салына башлаган сәүдә комплекслары төзелүдән туктап калган. Автостанция кыр вагоннарында гына. Яңа микрорайоннарның беренче биләгесе — парикмахерскийлар, ипи кибетләре, ателье, саклык кассалары торак квартирларга урнашкан.

Шәһәрнең киләчәген хыялларында күрүче архитекторлар кайбер объектлар өчен урынны алдан билгеләп куйганнар. Каланың үзәген Совет йорты, ике театр — олылар һәм балалар театры, цирк, Спорт сарае, концерт залы, Пионерлар сарае, балаларга сәнгать тәрбиясе бирү мәктәбе, күргәзмә заллары һәм китапханәсе белән иҗат оешмалары йорты, танцы мәктәбе белән яшьләр үзәге, бөтен шәһәр күләмендәге культура сарае, яшь техниклар йорты һәм башкалар тәшкил итәчәк.

Бу кадәр эшне, билгеле, ике-өч елда гына башкарып чыгып булмый, шулай да күздә тотылган бу объектларның күбесен төзеп бетерергә вакыт инде, бу йортларның кайберләре планга, йөкләмәләргә дә кертелгән булган, ләкин төрле сәбәпләр аркасында ул эшләр һаман тормышка ашырылып бетми кала килә.

1975 елда, төзелеш башланып ун ел үткәч, Түбән Камада ике йөзләп күчмә вагоннан торган вакытлы бер поселок оеша. Төзелеш башлыгы Евгений Никифорович Королев, Амур буендагы атаклы Комсомольск шәһәрен төзешкән кеше, безгә ике-өч тәрәзәле, бер катлы зәңгәр йортлардан туп-туры, төп-төз урам төзелеп, суын, җылысын «сузып» яткан бер урынны күрсәтте. Әлбәттә, вакытлыча гына эшләнә бу эш, чын торак йортлар җитешкәнче генә.

Эш никадәр зурданрак кубып, кызурак башланса, вакытлыча торыр урын да шулкадәр күбрәк кирәк. Анысы аксиома!

КамАЗ һәм Түбән Кама нефть химиясе төзелешләре башланган чакта вакытлы поселоклар барлыкка килүнең үз сәбәбе бар. Кама аръягында моңарчы булмаганча зур төзелешләр башлангач, бу эшкә катнашырга ашкынып килүчеләр күп була. Әлбәттә, бу кадәр халыкны берничә ай эчендә генә бөтен шартын китереп каладагыча салынган яхшы таш йортларга урнаштырып бетереп булмый. Ләкин андый вакытлы поселоклар эшне башлаган чакларда гына котылгысыз. Атаклы Магнитка турында Борис Ручьев: «Без кечкенә генә яшел палаткаларда яшәдек»,— дип яза. Ул еллардагы бер генә шәһәр дә барак дәверен читләтеп үтә алмый. Палатка, бараклар, төзүчеләр фатир төшкән авыллар — әлбәттә, болар барысы да вакытлыча гына, шулай да, французлар шаяртып әйтмешли, вакытлыча дигәнең иң даими бер нәрсә булып чыга.

Түбән Кама шәһәре, беренче көненнән үк башлап, үз алдына зур социаль программа куеп, барак һәм вагоннардан башка гына үсә. Андагы кешеләр калага торыр өчен әйбәт шартлары, җайлы квартиралары, магазин, ашханәләре, мәктәп һәм

балалар бакчалары бар дип кенә карамыйлар, бәлки шәһәрнең бик әйбәт планлаштырылуын, йорт, урамнары, артык чуарланмыйча, гади һәм матур итеп салынуын күреп, тоеп яшиләр. Түбән Кама каласы әнә шул ягы белән дә кешеләрне үзенә тарта, үзенә иярләштерә.

Беренче кварталлар төзелә, беренче чәчәк түтәлләре һәм агачлар күренә башлаганнан бирле мин Түбән Кама каласына килгән саен, ул күз алдыма сирәк очрый торган бер могҗиза кебек килеп басар дип көтәм, ләкин бу тансык сөенеч һаман әле чынга ашып бетми. Шәһәр әле һаман да макетта күрсәтелгән рәвешенә кереп җитми, аның соңгы елларда үсеп чыккан башка шәһәрләрдән кай яклары, нәрсәсе белән аерылып торуын әйтүе кыен. Биек йортлары беләнме? Бүгенге көндә ул бөтен шәһәрләр өчен дә уртак күренеш. Шәһәр эчендә бәрнинди завод-фабрика булмавымы? Хәзер күп җирдә завод-фабрикаларны шәһәр эченнән читкә чыгарып салырга тырышалар. Элекке еллардагы кебек аерым йорт, бина гына түгел, бәлки зур бер кала төзергә алынган кешеләр өчен яхшы мөмкинлекләр бар.

Социалистик дәүләтнең иҗтимагый һәм политик оешу формасы, халык хуҗалыгының планлы булуы, Түбән Кама шәһәрендәге конкрет социаль-экономик шартлар совет чорында шәһәр төзү практикасының беренче елларында һәм сугыштан соңгы елларда үсеп чыккан калалар төзелешендә булмаган зур һәм үзенчәлекле фикерләрне чынга ашырырга мөмкинлек бирде. Хәзер инде һәр каланы,— олысын да, кечесен дә — кешеләргә көн күрер урын итеп кенә түгел, бәлки архитектура йөзенең камиллеге, рәвеш һәм үлчәмнәрнең төрлелеге, төс һәм яме белән кешеләрнең күңелен тартырлык итеп төзергә көч тә, мөмкинлек тә бар. «Гипрогор» архитекторлары, Түбән Каманы төзүчеләр, минемчә, андый уңай шартларны файдаланып җиткермиләр әле.

Түбән Кама каласы зур елга буена, ямь-яшел урманлы, нефть һәм газга бай бер төбәккә салынуы белән генә түгел, бәлки борын-борыннан ук шәһәр төзү буенча атаклы милли традицияләре булган бер җиргә урнашуы белән дә бәхетле. Кама елгасы буйлап бераз аскарак төшсәң, син теләсә нинди юл яки сукмак белән, ике зур елга — Идел белән Кама кушылган төштәге Болгар шәһәре калдыклары — Шәһре Болгарга — моннан меңь еллар чамасы элек яшәгән көчле бер дәүләтнең башкаласына барып чыгарсың. Болгарлар — батыр сугышчы, тырыш игенче һәм оста ташчылар булганнар. Алар чуен койганнар, дастаннар язганнар, торбалар буйлап су китерткәннәр, хәрби ныгытмалар кора, матур-матур калалар сала белгәннәр. В. Н. Татищевның рус дәүләте тарихында әйтелгәнчә, шуңа күрә Суздаль, Юрьев-Польской, Бөек Устюг кебек борынгы шәһәрләрне төзү һәм бизәү өчен болгар осталарын чакыра торган булганнар.

Россияне яңартырга тырышучы Петр патша Идел буйлап сәяхәт кылганда борынгы Болгар башкаласы урынын карап киткән, Кече манараның башына менеп караган да «Шушы җимерелгән-таланган кала урынына, зарарланган, ишелергә торган бина һәм монументларны төзәтү өчен җитәрлек ак балчык алып, хәзер үк берничә ташчы җибәрергә, аларны саклау турында кайгыртырга... киләчәктә мондый хәл дәвам итмәсен өчен ел саен кеше җибәреп торырга»[1] боерган. Бу указга ике йөз ел ярым инде.

Петр патша фикеренең файдалы ягы шул: ул борыннан калган бина һәм монументларны һәйкәл итеп кенә түгел, бәлки туасы буыннар борынгы осталарның эш ысулларын тагы да камилләштерсен, бүгенге көндә тагын да ишәйтсен өчен үрнәк итеп сакларга куша. «Элгәре» белән «бүгенгене» кушып, матур-матур калалар салганда күп милләтле дәүләтебезнең архитектура сәнгате никадәр баер, үсәр һәм яңарыр иде!

Түбән Кама каласының әнә шул мөмкинлекләрдән файдаланмавы, милли үзенчәлек һәм матурлык — ямьлелек якларын киләчәккә калдырып, шәһәрне гадирәк, арзанрак һәм ансатрак итеп төзергә тырышуы, кызу барышыннан беркадәр туктый төшеп, көзгегә карап үзенә күз салмавы кызганыч, билгеле. Түбән Кама шәһәрен төрле җиргә — Обь елгасы буена да, Уралга да, Ярославль тирәсенә дә, Ерак Көнчыгышка яисә янәшәсендә КамАЗ янына да күчерергә мөмкин — ул стандарт ар-

---

[1] А. Формозов. «Очерк по истории русской археологии». М., 1961, 28 бит.

хитектура җимеше, аны теләсә кая куеп була. Ни дисәң дә, бөтен җиргә ярый торган бер төрле стандарт — архитектураны бизәми инде!

Архитектура — фикер-карашлар көрәше, чын сәнгатьчә зәвык белән архитектураны билгеле бер практик максатны тормышка ашыру чарасы итеп кенә санаган карашлар, характерлар бәрелеше ул. Моның мисаллары бик күп. Моннан йөз илле еллар элек Ватаныбызның зур бер фән йорты булган Казан университетының язмышы хәл ителгәндә Казан уку-укыту округы попечителе Магницкий, үзенең катгый карарын чыгарып, патшага болай дип яза: Казан университеты «юк ителергә тиеш, аны ике төрле юк итәргә мөмкин: а) университетны төзүдән туктатырга, б) җимереп, ишеп ташларга. Мин соңгысын кулайрак күрәм»,— ди[1].

Хәзер бөтен дөньяга танылган атаклы Казан университетын ул чагында архитектор Петр Гаврилович Пятницкий коткарып кала. «Кул көче һәм йөрәк җылысы салсак, Казанда иң беренче, иң яхшы бина (университет бинасы — М. З.) килеп чыгачак[2]», дип каршы чыга ул кодрәтле попечитель Магницкийга.

Дөнья бер урында гына тормый. Тормыш үзгәрә бара. Заман дигәнең әйберләрне, шигъриятне, сәнгатьне үзе бәяләп сайлый, архитектурада да үз алымнарын, үз формаларын тудыра. Стильләр камилләшә бара, биналарны пыяла белән бетоннан шакмаклап, туры сызыклы итеп кору, заводта коелган әзер деталь, блок, секцияләрдән төзү архитекторлар иҗатына да эз сала; алар үзләренең оригиналь табышларын контроль экспертизалар иләге аша уздырып булмый дип зарланалар. Шунысы кызык: берәүләр һаман шулай, машина конвейерындагы шикелле гел бер төрле, стандарт йортлар проектлаштырабыз дип зарлана, икенче берәүләр исә үзенчәлекле, матур-матур йортлар салалар. Вильнюс шәһәрендәге Лаздинай дигән яңа район матурлык белән уңайлыкны куша белүнең уңышлы бер мисалы. Литва архитекторларының хыялда гына калмыйча, чынга ашкан бу иҗади эше Ленин премиясенә лаек булды!

Хәер, моңарчы Түбән Кама каласыннан үлчәм һәм рәвеш төрлелеген көтүе авыр иде. Аның үзендә йорт төзү комбинаты 1978 елда гына эшли башлады. Бирегә бөтен Союздан — Чабаксар, Тольятти, Чаллы, Мәскәүдән әзер йортлар китерделәр; архитекторлар, баш күтәрми эшләп, һәрбер художникның кулыннан килә торган гади бер эшне генә башкардылар — стандарт тартмаларны «берсе-берсенә бәйләделәр». Йортларның кайдадыр читтә ясалып, поезд белән бирегә китерелүе начар нәрсә түгел (ихтимал, алай кыйммәткәрәк төшкәндер), хикмәт шунда: ул «тартмалар» бөтенләй башка җир өчен эшләнгәннәр, Түбән Камага алар «килешми-ярашмыйлар».

Мин бу хакта башкачарак уйлыйм. Безнең илебез хәзер көч һәм мөмкинлекләре ягыннан бик күп алга китте инде. Түбән Камадагы социаль һәм эстетик таләпләр әле кайчан гына зур төзелешләр өчен бер хыял гына иде, ә бүген инде күңел бу шәһәрдән башкасын да,— ямь, матурлык, күркәмлек тә сорый.

Һәр кеше тормышта нинди дә булса бер файдалы эш эшли. Без ни белән генә шөгыльләнсәк тә,— шигырь яки проза язабызмы, рәсем ясыйбызмы, шәһәр төзибезме яисә иген игәбезме — ул эшебезне кешеләр өчен дип эшлибез, ахыр чиктә безнең эшебезгә үзебез түгел, башкалар бәя бирә. Син яшь кешеме яки өлкәнме, эшеңдә бәхетлеме яки бәхетсезме, шат холыклымы яки төксеме икәнлегеңдә башкаларның эше юк, әнә шул китабың, рәсемең яки ялан җиргә китереп салган калаң әйбәт, уңышлы булганда гына кешеләр аны кабул итә, теге сәбәп, бу сәбәп дигән сылтауларны барга да санамыйлар.

*
* *

Бер карагандa кешеләрнең кайбер эш-гамәлләре аңлашылмаслык сәер кебек тоела. Алар инде, ничә ел яшәгән, иләшеп беткән җирләрен ташлап, алдагы көндә яхшыны өмет итеп, тормыш шартлары җайланмаган-көйләнмәгән бер калага китеп

[1] Н. П. Загоскин. «История Казанского университета». Казан, III том, 1903, 504—565 битләр.
[2] В. В. Егерев. «Архитектор П. Г. Пятницкий». Тормышы һәм иҗаты турында. Казан, 1961, 7 бит.

баралар. Алар килгәндә анда әле йортлар урынына бараклар гына була, аяк асты ерып йөргесез былчырак, төп транспорт — өсте брезент белән ябулы вахта машиналары гына, ашханәләрдә тыгыз чират. Ә инде менә өмет иткәннәре чынга ашып, якты, зур тәрәзәле йортлары, яшел агачлары, шау-шулы бала-чагалары белән шәһәр төзелеп житкәч, бирегә килүчеләр азая бара, аннан да бигрәк — каладан кире китә башлыйлар... Бик гажәп-сәер хәл, билгеле. Шәһәрдә уртача тормыш шартлары башка жирләрдәгедән начаррак булмаса да, элекке еллар белән чагыштырганда, шәһәр хәзер кешеләрне үзенә азрак тарта. «Начаррак түгел» дигәнебез — башка жирләрдәге шикелле үк дигән сүз. Ә энтузиастлар килүенә исәп тоткан яңа кала башка жирләрдән кызыклырак, яхшырак булырга тиеш бит.

Бөтенсоюз күләмендәге бу удар комсомол төзелешенә һәрвакыт кеше житешми. Анда эшләр бик зурдан кубып башланды, һәр көнне кичәгесеннән күбрәк эш башкарырга кирәк, монда эшкә килгән һәр яңа кешене тансык кунак урынына кочак жәеп каршы алалар. Алтмыш өченче елдан башлап, промышленность мәйданында, шәһәр объектларына бирелгән кадәр акчаны бер елны да эшкә ашырып бетерә алмыйлар. Шул ук вакытта төзелештә бер кеше ике кешелек эш башкара ала торган Злобинча эшләү ысулына бик югарыдан борын чөеп кенә карыйлар, акыл һәм осталык белән түгел, бәлки кеше саны белән жиңеп чыгарбыз дип уйлыйлар, күрәсең.

Кеше эшчәнлегенең иң четерекле, катлаулы өлкәсе саналган күп кеше массасына идарә итүдә төп отыш экономик нәтижәләргә генә кайтып калмый. Кызганычка каршы, мораль-психологик факторларны исәпкә алып бетермиләр шул әле. Энтузиастлар кыенлыклар тулы яңа, ялан бер жиргә килгәндә торыр урын, яшәү шартлары әле бөтенләй жайланмаган икәнлеген белеп киләләр, бу авырлыкларга вакытлыча түзәргә карар кылалар. Үз-үзләренә шундый таләп куйган кебек, алар башкалардан да тырышлык таләп итәләр, эшнең оешмаганлык, ашык-пошык чыгарылган карарлар аркасында тукталып, төртелеп калмыйча, алга үрләвен телиләр.

Түбән Кама нефтьче-химикларының төп бурычы, мактанычлы эше — агрегат һәм заводларның эшен срогыннан алда проекттагы графикларына житкерү. Бу эшне алар беренче объектны — үзәк газ фракциясе жайланмасын исәпләнгән график буенча унбишенче тәүлектә эшкә кертүдән башладылар. Ә аның срогы алты ай иде! Әмма зур тырышлык белән срогыннан алда проекттагы графигына житкерелгән көчле реакторлар жылылык алу мәсьәләсендә «ачлы-туклы» яшиләр — ТЭЦ агрегатларының куәте житеп бетми. Промышленность мәйданында этилбензол заводын төзеп бетерергә ашыгалар, төп көчне шунда туплаганнар, торак төзелеше программасын көчхәл белән яртылаш кына үтәгәннәр.

Түбән Кама кешеләре — күпне күргән, бөтенесе читтән килгән халык, аларның күбесе бер генә түгел, берничә удар төзелештә эшләгән, чагыштырып та карый, нәтижә дә ясый беләләр алар. Котылгысыз кыенлыкларына түзәргә риза булсалар да, ашык-пошыклык, рәт-башсызлык һәм ялгышларны гафу итә алмыйлар. Бу халыкның күпчелеге ике уйлап тормый торган тәвәккәл кешеләр: документларын шундук алалар да гаиләләре белән икенче бер төзелешкә китеп тә баралар. Әнә шулай шәһәр исәбенә промышленность мәйданында алган «отыш» соңыннан тагын да зуррак оттырышка әйләнә. Төзелешкә, эшкә торган саен кеше күбрәк кирәк.

Шин, этилен әчесе, техник углерод, мономер, изопрен, каучук заводларында эшләр бик ашыгыч, шәһәр төзелешендә дә элеккечә үк хәл киеренке. Эшлисе эшләр арта, ә төзүчеләр кими бара. Энергетика һәм электрификация министрлыгы эш күләмен билгеләгәндә «Татэнергострой» идарәсе төзелеше генеральный подрядчыгының производство программасын 34 миллион сумга киметергә мәжбүр була.

Нишләргә? Бу хәлдән ничек котылырга? Шәһәр иң соңгы чарага керешә — шин заводларында, «Нефтехим» берләшмәсендә эшләүчеләрдән бишәр йөз кешелек ике удар отряд төзи, икешәр хезмәт хакы — берсе иске урында, икенчесе — төзелештә түләячәге белән исәпләшеп тормыйча, боларны «яңа торган» төшләргә жибәрә. Сүз дә юк, тиз чара күрә белү яхшы, әмма идарә эшендә килеп туган хәлне тиз генә төзәтүдән бигрәк, аларны бөтенләй булдырмау хәерле.

һәр нәрсә үзенең асылына кайта дигәндәй, тормыш та боларны үз урынына кайтара. Башта белгечләрне шәһәр объектларыннан промышленность мәйданына алган булсалар, хәзер исә ашыгыч рәвештә аларны эшкә керешкән заводлардан алып, шәһәр төзелешенә күчерәләр. Шәһәр хакына керү — ул кешеләр хакына керү, ахыр чиктә, аннан берни-нди файда — экономик, политик, социаль отыш та, әхлак ягыннан да файдасы юк дигән гыйбрәтле сабакны ничәмә-ничә төзелештә кабатладылар инде. Мәгънәсе тиз генә төшенеп җитәрлек түгел, күрәсең; аны башкалар узган сабакка карап кына үзләштереп булмый, үз башыңнан кичерергә кирәктер!

*

* *

— Моннан ары ничек эш итәргә уйлыйсыз соң инде? — дип сорадым мин Баһаветдиновтан.

— Безнең инде бер генә юлыбыз бар: өйрәнергә кирәк.

— Нәрсә өйрәнергә?

— Яңача эшли белергә өйрәнергә кирәк. Яңача эшли белмибез әле. Хәзер шәһәр төзелешенә бөтенләй бүтәнчә идарә итү принципларын эшләргә вакыт.

Иң төп мәсьәлә шул — шәһәрне төзегәндә торыр җир булса ярар дип кенә эш итәргә кирәкми, бәлки ул үзенең йөзе-кыяфәте, тормыш итәр өчен уңайлы яклары белән телисә нинди шәһәргә тиңләшерлек булырга, кешеләр анда килгәч гомерлеккә төпләнеп калырга тиеш.


— Егерме еллап вакыт узды бит инде.

— Узды шул. Әлбәттә, ул гомер эчендә күбрәк, файдалырак итеп эшләргә дә мөмкин булгандыр, шулай да ул елларны бөтенләй сызып ташларлык сәбәп юк. Шәһәрне аны йөзәр елларга исәпләп төзиләр, егерме ел — ул шәһәр әле туа гына башлаган дигән сүз, һәрхәлдә, аның ачкычы безнең кулда.

Безнең машинабыз Кама буеннан, пристань, көймә станциясе, пляж яннарыннан, шәһәргә уңайлы трамвай юлы белән тоташкан ял урыны — урманлы җирләрдән узып китеп бара; каршыбызда биек ак ташпулатлары, туп-туры яшел урамнары белән шәһәр калка, гүяки ул, килəчәгенә карап, олы-олы адымнары белән зур, күәтле Чулман дәрьясына таба атлап-җәелеп бара иде.

# ЕРАКТАН ТӨШКӘН КИЛЕН

*КПССның XXVI съезды делегаты*




Очрашуга һәр ике яктан да бик тәфсилләп, бөтен нәрсәне җиренә җиткерергә тырышып хәзерләнделәр. Өйне кат-кат җыештырдылар, чәшке-чынаяклар ялтырады, мендәрләстык, җәймәләрнең гел яңасы, кабарып тора торганнары гына куелды. Ишегаллары себерелде. Авылда мондый чакта хәтта капка баганаларын да сабынлап юалар дип шаярталар. Бу көнне Зирекле авылының Габетдиновлар йортында кунак көтүләрен бөтен авыл белгәндер. Гади кунак килү генә түгел, ә килен төшә. Ерактан, Украинадан... Ворошиловград өлкәсенең Артемовск шәһәреннән. Гаилә башлыгы Салих ага өчен бу исем бер дә чит яңгырамый. Чөнки ул Украина җирен, аның халкын Бөек Ватан сугышы елларында фашистлардан азат итүдә кулына корал тотып катнашты. Аның күп шәһәрләрен күрде ул, озын һәм тузанлы юлларын үтте, азатлык китерүче Совет солдатының күкрәгенә капланып, «рәхмәт» сүзен дә әйтә алмыйча куанычыннан үксеп елаган украин кызларын, балконнардан яуган чәчәкләр яңгырын, башларына милли чигелеш төшкән озын тастымалга куеп ипи-тоз китерүче картларны күп очратты ул, Салих солдат.

Шуңадыр, булачак килене Алланы, әле бер тапкыр да күрмәсә дә, әллә кайчан үз иткән. Карчыгы Мөхтәрәмәнең генә күңел чите, нигәдер, китек кебек күренә. Ничек итеп сөйләшермен, аңлашырмын дип уйлыймы икән? Балалар исә хәзерге заманда үскән — дөньяны һәм кешеләрне үзләренчә таный, исләре дә китмәс. Аларга кем дә ярый. Әнә, кызлары шәһәр кызларыннан ким бизәнмәгән. Күлмәге дисеңме, оегы, туфлие, чәч бәйләмнәре — һәммәсе модалы, фасонлы. Бер дә авыл кызы димәссең. Аермаларның бетә баруы шундадыр инде ул, дип уйлый Салих Габетдинович. Үзе, хатыны, балалары шулай, ә монда бит әле 104 яшьлек әнисе бар...

Кыскасы, чәчәкле Украинадан бик озак көттереп төшкән киленне һәркем үзенчә күз алдына китерде, һәркем аңа бу якларга аяк басмас борын, капкадан атлап кергәнче үк, үзенең нинди мөнәсәбәттә булырга тиешлеген билгеләп куйды.

Хәзерлекнең башка якта — килен ягында ничек булуын да бераз күз алдына китерик. Алла инде белә: ишле гаиләгә киләчәк. Алты балалары бар.

Малик Салихович хатыны Аллага авылга кайтканда аягына озын оек кияргә, күлмәкнең дә түшне каплый торган якалысын сайларга, башта яулык булырга тиешлегенә читләтеп кенә булса да ишарә ясады. Калганын үзең чамаларсың,— диде ире.

Чистай урманнарын үткәндә дә, авыллар аша кайтканда да Алла бу яктагы матурлык үзенчәлекләрен төсмерләргә тырышты. Күрер күзгә үк бәрелеп тора: Украина түгел. Шау чәчәккә күмелгән, йортларны каплап алган бакчалар юк. Ләкин һәр якның үзенә генә хас матурлыгын тоя белергә кирәк диләр. Монда калкулыклар, алар артына сыенып, бергә оешып утырган кечкенә авыллар диңгездәге утрауларны хәтерләтә.

Һәммәсе уңай килеп чыкты. Аны каршылаган бер кешенең дә йөзендә нурсызлык, кире кагу чаткылары шәйләмәде Алла. Аны башта йөз яшьнең өске ягына чыккан әби каршына алып килделәр. Ул ерактан төшкән киленне аягыннан алып башына кадәр сүзсез генә карап чыкты. Канәгать иде булса кирәк. Бер генә дә шәрә, күзгә бәрелеп торган җире күренми. Җыерчыклы куллары белән башыннан сыйпады, аркасыннан какты һәм, Алла хәзер үзе әйткәнчә, «ма-

тур кизим» дип ике кулын битенә китерде. Барысы да тын калдылар. Бу инде имтиханның иң олысы иде. Кайнанасы Мөхтәрәмә, булачак киленен нәкъ шулай күз алдына китергәндәй, беренче күрүдән үк ошатты. Үзе ягымлы, үзе эшчән. Уртак телне тиз таптылар. Нәни Марат кулдан-кулга күчте, уртак куаныч булды.

Шуннан соң авылда берәүләр: «Туры килеп торуын кара син Салихларга,— дип сөйләгәннәр имеш.— Шулай инде, ерактан төшкән килен якын була». Икенче берәүләр исә моңа: «якын гына түгел, уңган да булсын иде ул», дип тә өстәгәннәр икән. Нәрсә бу, шик белдерүме, кирәкмәгәнгә үчекләүме? Табигый хәлләр. Килен төшкән көннәрдә андый сүзләр булмый калмый. Чөнки, мәкальдәгечә әйтсәк, акылыңны күрсәтү өчен акыл тешеңне күрсәтеп елмаю гына җитмәгән шикелле, уңганлыкны да матур күлмәк киеп кенә күрсәтә алмыйсың. Уңганлык — хезмәттә генә исбатлана. Бары тик шуның белән генә, «әйтмә дә генә инде, уңган да булды инде» дип халык теленә керәләр. Киленнәргә исә бигрәк тә четерекле имтихан туры килә. Көянтә-чиләген асып, беренче тапкыр су юлы күрсәткән кыз артыннан чишмәгә барган көннән үк сине сыный башлыйлар: суы чайкалып түгелмиме? Атлавы ничек? Биле сыгыламы? Көянтәне җилкәсенең кай төше белән тота, чыныкканмы? Хәтта сулы чиләкне ничек итеп көянтәгә эләктерүенә, күтәреп алуына, кайтып җиткәч, ничек итеп, эскәмиягә куюына кадәр күзәтеп торучылар бар икән. Алла ничек булгандыр, хәзер инде ул боларны үзе дә хәтерләми, төп йортта да искә төшермиләр. Әмма уңганнармы соң киленнән бу йортта — Чистай районының Зирекле авылында? Уңганнармы соң Казанда, ул эшләгән фотожелатин заводында?

Бусы инде үзе бер хикәялек.

*

* *

Без рәссам, архитектор, җырчы, музыкант һәм башка иҗат кешеләре кебек талант ияләрен «бу аңа тумыштан бирелгән, табигать бүләк иткән сәләт» дип бәялибез. Боларга, һич сүзсез, кешеләрнең оештыру сәләтен, җәмәгать эшләрендә катнашу булдыклылыгын да өстәргә кирәк. Алла Максимильяновна соңгысына туры килә. Менә сигезенче елын инде ул берөзлексез 250 дән артык коммунистны берләштергән фотожелатин заводы партия оешмасына җитәкчелек итә. Шуның 150 гә якыны партия сафларына ул эшләгән чорда кабул ителгән.

«Секретарьның ниндилеген беләсең килсә, коммунистлардан сора», диләр. Чыннан да шулай икән. Заводта чакта төрле дәрәҗәдәге партия членнарыннан үзләренең секретарьлары турында берничә сүз әйтүен үтендем.

**Надежда Алексеевна Сержантова.** 5 нче кассеталар җыю цехы эшчесе, «Почет билгесе» ордены кавалеры.

— Без аның белән барлык уйларыбызны бүлешәбез. Кайгысын да, шатлыгын да. Секретарь, җитәкче шулай булырга тиеш тә. Бервакыт без смена начальнигы И. Иштирәковны эштәге кимчелекләре өчен «Комсомол прожекторы»на яздык. Ә ул без юкта торган да листокны алып ташлаган. Бу бит бернинди тәртәгә дә сыймый. Без партбюрога — Алла Максимильяновна янына киттек. Ул бик игътибар белән тыңлады һәм безгә ияреп цехка килде. Смена начальнигын да чакырды. Аның хаклы түгеллеген аңлатты. Безнең үзебездә дә гаеп булган икән. «Прожектор»га бик үк [illegible]ле булмаган сүзләр язылган. Мондый хәл цехта бүтән кабатланмады.

**Нина Борисовна Дунина.** План бүлегенең өлкән экономисты. 1952 елдан партия члены.

— Мин аны заводка беренче килгән көннәрдән үк хәтерлим. Кайберәүләр коллективка озак ияләшәләр. Бу кыз үзен тиз күрсәтте. Бирелгән заданиене шундук төшенеп ала. Ул вакытта әле без Щекино экспериментын кертү өстендә эшли идек. Ул, экономист буларак, хезмәтне фәнни оештыру бүлегендә эшләде.

Бервакыт безгә директор тарафыннан ашыгыч задание җиткерелде. Техпромфинплан кирәк срокка өлгермәгән булган. Ө югарыдан сорыйлар. Кирәк документларны бер тәүлектә икәүләп өлгерттек һәм раслату өчен төн уртасында директор-

ның өенә киттек. Инде транспорт туктаган. Бөтен шәһәр буйлап җәяү барырга туры килде. Кул куйганда директор «Мондагы саннарның дөреслегенә иманыгыз камилме?» дип кенә сорады. «Башыбыз белән җавап бирәбез», дидек. Иртән сәгать биштә инде шул планны илтү өчен самолетка утырдым. Эш сәгате башланганчы Мәскәүдә идем. Һәммәсе дөрес булып чыкты. Эшкә сәләтлеген әнә шулай күрсәтте безнең яшь экономистыбыз. Аннан соң Алланы хезмәт һәм эш хакы бүлеге начальнигы иттеләр.

Коммунист буларак, 1969 елда мин аңа һич тә икеләнмичә партиягә керергә рекомендация бирдем. Ул минем ышанычымны аклады. Гомумән, рекомендация биргән кешеләремнең һәркайсы эштә, тормышта үзләрен чын коммунистлар итеп күрсәттеләр. Алла инде бигрәк тә. Аның Татарстан өлкә партия оешмасыннан делегат булып сайлануы минем өчен генә түгел, бөтен коллектив өчен горурлык.

Валентина Ивановна Швецова. Өлкән инженер. Левченко поселогында депутатлар группасы җитәкчесе. Партиясез.

— Аны күп еллардан бирле күзәтеп киләм. Завод, коллектив мәшәкатьләре, кеше ихтыяҗлары Алланы тулысынча үз кочагына алган. Депутат буларак, аңа бик еш мөрәҗәгать итәләр. Ул кабул итәчәк көнне махсус көтеп алалар. Чөнки игътибарлылык, һәркемгә булышырга әзер тору, кайсы да булса хаксыз икән, түземлелек белән аңлату — аның матур сыйфатлары.

Александр Александрович Кириллович. Завод директоры.

— Секретарь буларак, кеше буларак дип аерып куеп булмый аны. Алла Максимильяновна үрнәгендә бу төшенчәләр нык булып бергә үрелгән. Анда төрле сыйфатлар синтезлана: партия җитәкчесе буларак кешеләр белән эшли белүе, экономия өлкәсендәге югары белеме, эрудициясе, заводта алган практик эш тәҗрибәсе, партиячел принципиальлеге, политик сизгерлеге, әнә шулар белән ул коллективта ихтирам казанды. Минә 40 ел инде төрле предприятиеләрдә директор булып эшлим. Төрле секретарьларны очраттым. Алла Максимильяновнаны аларның иң яхшысы, иң эшлеклесе дип әйтергә батырчылык итәм. Фәкать шушы эш өчен генә яратылган диярсең.

... Алла Максимильяновна турында завод коллективының төрле дәрәҗәдәге вәкилләре әйткән бу сүзләргә тагын «Ул кешеләрне аңлый белә. Хатын-кыз буларак та, экономист-белгеч буларак та», дигәннәрен дә өстик тә, бу күркәм сыйфатларның чыганакларына тукталыйк, аларны анализ күзлеге аша үткәрик. Каян килгәннәр алар, кем тәрбияләгән, ничек тәрбияләгәннәр аларны, кайда?

— Тумыштандыр,— дип елмая Алла Максимильяновна үзе. Һәм урта мәктәпне көмеш медаль белән тәмамлавын, шулай да институтка кергәндә төп фәннән — химиядән имтихан тапшырганда 13 нче билет туры килеп, төртелеп калуын, имтиханга кереп утырган газета корреспонденты сорауларына кыюлык белән җавап бирүен һәм шушы кыюлыгы аны бәладән, яки институтка эләкми калуы куркынычыннан коткаруын яшьлегенең бер матур истәлеге итеп хәтеренә төшерә. Әйе, кыюлык ул — булдыклыларга гына юлдаш.

Әмма булдыклылык нәселдән килми. Ул тормышта, эштә, кешеләргә карата булган мөнәсәбәтләрдә тәрбияләнә. Дөрес, Алланың әтисе экономист булган. Ул ике вуз тәмамлаган: Одесса элемтә һәм Харьков инженерлык экономия институтларын. Соңгысында Максимильян Ефимович Глущенко тау-руда промышленносте белгечлеге алып чыккан. Яңа күмер чыганаклары ачуда катнашкан. Бөек Ватан сугышының дәһшәтле елларында фронт[illegible]ән. Күп еллардан соң Алла әтисенең исем-фамилиясен Курск шәһәренең туганнар [illegible]рлегендә ире Малик белән бергә эзләп тапкан. Әнисе Анастасия Кирилловна заводта эшләгән. Хәзер дә исән. Малик Салиховичны «иң яраткан киявем» дип йөртә.

— Мин Харьков инженерлык-экономика институтын тәмамладым, — дип дәвам итә Алла Максимильяновна. — Химия промышленносте инженер-экономисты белгечлеге алып чыктым. Миңа укытучыларым «син математик булырсың» дип һаман саен әйтә килделәр. Минем күңелем исә экономикага тартты.

Көчле дулкыны ил буйлап таралган стахановчылык хәрәкәте алар торган җирдән берничә чакрым ераклыгындагы шахтада туган. Күпме шахтерларга җиңү

белән котлап чәчәк тоттыргандыр ул, күпме алкышлар ишеткәндер. Ул вакыйгалар сабый күңелендә тирән сеңеп калганнар, киләчәктә шундыйларга охшарга теләп хыяллануы шул вакыттан ук башлангандыр.

Институтта укыган елларда да җәмәгать эшләреннән башка яши алмаган. Югары уку йортын тәмамлап, Рубежный шәһәрендәге химия предприятиесендә эшләгәндә булачак ире — Казан химия-технология институтын тәмамлап бирадә эшләүче татар егете Малик белән дә нәкъ шулай җәмәгать эшләре башкарганда танышканнар. Казанга күчеп килгәндә Алланың куен кесәсендә киләчәк язмышы өчен борчылган остазының — завод директоры урынбасарының фотожелатин заводы директоры булып эшләүче дустына язган шәхси «записка»сы да кайта. «Бу кызның ташып торган энергиясен дөрес файдаланган, ул күп нәрсәләргә сәләтле», диелгән була кәгазьдә. Предприятие җитәкчесе хезмәт сынавын уңышлы үткән Малик Салихович турында да онытмаган. Ләкин Татарстан егетен үз республикасында тагын да җаваплырак урында — «Органик синтез» производство берләшмәсендә көткәннәр. Хәзер ул бирадә берләшмәнең генераль директорының производство буенча урынбасары. СССР Министрлар Советы премиясе лауреаты.

Заводта Алла «үз урынын» тиз таба. Комсомол комитеты секретаренең производство мәсьәләләре буенча урынбасары. «Темп һәм сыйфат өчен» дигән стена газетасы редакторы ярдәмчесе, соңга таба КПССның Казан шәһәр комитеты каршындагы НОТ җәмәгать секциясендә экономик темаларга лекция укулар... Һәммәсенә вакыт табарга кирәк. Шуның өстенә гаилә, бала тәрбияләү... Ләкин Алла Максимильяновнаның бер генә зарлану сүзен дә ишетмәгәннәр.

Һәм завод коммунистлары 1973 елда аны, партиядә тору стажы дүрт ел да тулмаган яшь коммунистны, үзләренең җитәкчесе итеп сайлыйлар. Яшь секретарь беренче көннәрдән үк киеренке эшкә чумган. Бу эшнең төбендә, беренче чиратта, кешеләр белән туктаусыз аралашу, аларның тормыш һәм хезмәт ихтыяҗларын өйрәнү ята.

Алла Максимильяновна секретарь булып эшли башлаган елны заводка «Коммунистик хезмәт предприятиесе» дигән исем бирелгән. Һәм шушы югары бәя һәр ел саен расланып килә. Завод уннынчы бишьеллык планны үткән елның 30 нчы ноябрендә тутырды. Ву елларда җитештерү күләме 50 процентка үсте. Элекке елларда нибары 3 төрле продукция җитештергән предприятиенең хәзерге ассортименты инде 40 тан күбрәк. Шуның 10 нан артык төре — ягъни барлык продукция күләменең 32 проценты — дәүләт Сыйфат билгесе белән чыгарыла. КПССның XXVI съезды хөрмәтенә бишьеллык планга өстәмә итеп 2,5 миллион сумлык продукция җитештерделәр. Быелның ике айлык планы съезд ачылган көнгә үтәлде. Бераз гына алга китеп булса да әйтик, Алла Максимильяновна бу турыда телеграмманы Мәскәүдә, Кремльнең Съездлар сараенда партиянең XXVI съезды ачылган көндә, 23 февральдә кич белән алды.

КПССның XXVI съезды делегаты Алла Максимильяновна Габетдинованың Мәскәүдән съезддан кайткач очрашу вакытында сөйләгәннәрен тулысынча язып бетерү мөмкин түгел. Мин өзекләрен генә китерәм.

— Меңләгән кеше җыелган бу бинада — Кремльнең Съездлар сараенда кирәк кешеңне тиз генә эзләп табармын дип уйлама. Очрашулар, танышулар очраклы килеп чыга. Туган шәһәремдәге шахтадан килгән делегат трибунадан сөйләвен күргәч мин урынымнан ук сикереп торганмын. Тәнәфестә аны эзләп таба алмадым. Безне, бер төркем делегатларны — фотокорреспондентыбыз Наил Курамшин Георгиевск залында летчик-космонавт Павел Попович белән фотога төшерде. Бездән ерак түгел тагын бер төркем бар иде. Шул төркемнән берәү фотокорреспонденттан аларны да фоторәсемгә алуларын үтенде.

— Мин сезне ничек табармын соң? Фотоны кемгә җибәрергә? — дип сорады Н. Курамшин.

— Адрес калдырабыз: Украина ССР, Ворошиловград өлкәсе. Өлкә партия комитеты. Зверев Родион Астаховичка җибәрерсез.

Минем туган ягым кешеләре бит алар. Араларында беренче секретарь Леонид Васильевич Романенко да бар. Мине онытмаганнардыр әле. Кочаклашып күрештек. Шахта, күмер, рекордлар, таныш-белешләр турында сөйләштек. Алар миннән: «үзең кайда?» — дип сорыйлар. Татарстанда дим. «Менә кая очкан безнең кошыбыз. Әйдә, үзебезгә әйләнеп кайт»,— диләр. Юк инде, мин әйтәм, Татарстан — икенче туган җирем. Мин аның законный килене. Төшкән җирен ташлап кайткан киленгә ничек карарлар? Я уңмаган, я яратмаган дипме? Мин Татарстаннан килгән 60 делегатның берсе — химия промышленносте вәкиле. Чакыруыгыз өчен рәхмәт. Кунакка дәшсәгез — барырмын.

Шәйлисезме, Алла Максимильяновна «кунакка кайтырмын» димәгән, ә «барырмын» дигән. Димәк, ул инде Татарстанны, Казанны, Чистай районының Зирекле авылын үз иткән.

Монда гомерлеккә килгән, төпләнгән. Ул инде шушы республиканың лаеклы вәкиле булып, Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең иң зур форумында катнашты, аңа зур ышаныч белдерделәр, ул ил күләмендәге мөһим эшләрне тикшерә.

Сүзне «ерактан төшкән килен якын була» дип башлаган идек. Уңган да булып чыкты, дип нокта куям. Язылып беткәч кенә соңгы хәбәр: СССР Верховный Советы Президиумының 1981 ел, 6 апрель Указы белән Казан фотожелатин заводы партия оешмасы секретаре Алла Максимильяновна Габетдинова Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

Мирхәт ХӨСНИМӘРДӘНОВ.

# ЯННАРЫНА ҮЗЕМ БАРАМ

Карт белән карчык, уллары белән киленнәрен кинога озаткач, иркенләп бер чәй эчик әле дип, самовар янына утырдылар. Шул чак, өйдәге тынлыкны сискәндереп, телефон шылтырады. Солтан абзый, чынаягын авызына якын ук китергән булса да, өстәлгә кире куйды да авырсынып кына урыныннан кузгалды. Саимә апа күптән телефон янында өзгәләнә, картының тизрәк килеп, телефон трубкасын алуын көтә. Карты гына һаман шул — кабаланмас, тыныч, әкертен. Саимә апа үрелеп трубканы алды да әтиләренә сузды.

— Тыңлыйм.

Солтан карт трубканы кысыбрак тотты, бер колагыннан икенчесенә күчерде, димәк, сөйләшү ерактан. Шулай булуын йөрәге белән сизенгән ана якын ук иелде, таныш тавыш...

— Әти, әти дим, исәнме? Улыбыз туды... Әни кирәк! Әнине бир әле!

Чаллыдан Дамир шалтырата. Әни кирәк, әнигә генә әйтер сүзем бар, ди. Әтиләренең хәтере калырга шул сүз бик җитте: трубканы нык иттереп өстәлгә куйды да башы белән сүзсез генә карчыгына ымлады. Саимә апа сөйләшә башлады, бүлмәгә аның җылы, йомшак тавышы таралды. Солтан абзый өстәл янына барып утырды да суына башлаган чәен йотып куйды, карчыгына көнләшүле караш ташлады. Ничек шулай килештереп сөйләшә бу! «Әтиләр — ата каз, әниләр — ана каз», — дип, белми әйтмәгәннәр шул. Солтан абзый, анысы, үзе дә гел ысылдап кына тормады, коры булды булуын, исереп йөрмәде, кеше алдында да, уллары каршында да дәрәҗәсен саклый белде. Шулай да әниләре башкачарак шул, йомшак булды, барысын да үз канаты астына җыйды, болыттан да, кар-бураннан да ул саклады.

— Дамир, бәбекәем, улыбыз бар дисеңме? Тәүфигы, бәхете белән килсен. Исән-сау котылуы яхшы булган... Шулай дисеңме? Гөлсинәгә әйтә тор, бер дә борчылмасын, була ул андый хәлләр. Үзем барам, әйе, яныгызга үзем... Җаен тапмый калмабыз. Хуш, улым, хушыгыз... Абыеңнарга, балаларга сәлам...

— Нәрсә ди?

— Бәбиләре елый, Гөлсинәнең сөте юк икән.

— Нәрсә, киленеңнең сөте юк, дип, Чаллыга чыгып китәргә җыенмыйсыңдыр бит? Тегесе дә — әни кирәк дип ятмаса... Анагыз сезнең балагызны барып имезмәс!

— Ярый, әтисе, ярый, менә бергәләшеп уйлашыйк әле, рөхсәтең булса, балалар белән киңәшкәч, бармый да булмас. Үзең дә ишетеп, күреп торасың бит: әни кирәк ди. Дамир акылсыз бала түгел, кирәксә-кирәкмәсә мине борчымас. Күрәсең, алыштырырлык кеше юк.

Солтан абзый тәрәзә төбендәге күзлеген алып киде дә, беренче тапкыр күргәндәй, хатынына карап куйды. Картаймаса да картаймас икән бу хатын-кыз дигән адәми зат! Ун бала табып үстерде, яше алтмыштан узды, һаман яшьләрчә, һаман җиңел гәүдәле, озак уйлап тормас, тәвәккәл, балалары артыннан каф таулары аръягына да җиде төн уртасында җәяү чыгып китәргә әзер. Ярый әле балалары Та-

тарстаннан читкә таралмадылар. Күңелләренә ошаган эшне сайлап, өчесе Арчага, дүртесе Казанга, берсе Түбән Камага, икесе Чаллыга урнашты,

Һәр икесе үз уйларына чумганнар иде, күзләре очрашты, әйтерсең лә, кырык елдан артык гомер узмаган. Саимәнең зәп-зәңгәр күзләре һаман якты, Солтан бик озак эзләп тапкан ышанычлы күзләр. Үзбәкстанда хезмәт итүче һәм өйләнергә дип туган якларына кайткан хәрби киемле, озын буйлы, киң җилкәле Фазлыевка җиңгиләр, башкодалар күп кызлар күрсәтеп карадылар. Ул исә үз дигәнен эзләде.

Беренче тапкыр Солтан Саимәне «Спартак» фабрикасының почет тактасында күрде.

Я — шул,— диде Солтан,— я — өйләнмим!

Очраштылар, сөйләштеләр, кавыштылар. Вак-төяген исәпләмәгәндә, тату гомер иттеләр.

Солтан абзый утырды-утырды да көзге янына килеп басты. Аның күз төсе үзгәрә башлаган, ләкин бирешергә исәбе юк әле, җитмеш тулып килсә дә, эштән туктап тормый.

— Картым, Маратлар кинодан кайтканчы, әллә Дариннарга менеп төшимме, белмичә калмасыннар.

Саимә апа алдан Дариннарга барып килмисеңме дип әйтергә уйлаган иде, көзге, караңгы пычракта карты килештермәс дип әйтмәде. Үзем барып килим дигән булды. Кырык елдан артык яратышып, тату гомер иткән кеше берсенең күңелендәгене икенчесе аңламыймы инде! Дариннарга әтиләре китте.

Солтан абзый килеп кергәндә, улларын йокларга яткырып Дарин дәфтәрләр тикшерергә, Әлфия планнар төзергә утырганнар гына иде. Яшь укытучылар мәктәп балаларыдай торып бастылар. Мондый кичтә әтиләре тикмәгә йөрмәс, бик кирәкле сүзе бардыр.

Хәл-әхвәл сорашкач, самоварга килеп тотынган Әлфияне кайнатасы туктатты.

— Кайнашма, килен, чәй яныннан яңа гына торып килдем, сезгә сүзем бар. Дамирның улы туган, анагыз Чаллыга җыена, кош-корт, кечкенә бала бер үземә кала, килен эштә, онытып бетермәгез.

Даринның аптыравы йөзенә чыкты.

— Әти, абыйның хәле авырайганмы әллә?

— Ник алай дисең әле син, улым? Абыең авырмыйдыр бит?

— Өч көн элек абыйларның хәбәре юк дип шылтыратсам, Мәдинә апа, «Абыеңны эшеннән больницага алып киттеләр», ди.

— Авария-фәлән булмагандыр бит?!

— «Куркыныч юк, әниләргә әйтми торыгыз», ди. Менә шундый әле анда хәлләр, әти. Бүген әни янына кереп чыксам да әйтмәгән идем. Әти, юлга чыгар алдыннан әнигә әйтми торабызмы соң әллә?

— Эшләре дә бигрәк куркыныч шул безнең абыйларның,— дип, Әлфия сүзгә кушылды.

Солтан абзыйның ике улы әтиләренең һөнәрен сайладылар — янгын сүндерүчеләр. Әтиләренең горурлыгы алар. Төп йортта кунак кына булалар хәзер. Рафис Чаллыда, Нарын Түбән Камада, Радис Казанда, ике майор, бер капитан кайтып төшә, малайлар бергә йөрергә яраталар. Бөтен Арча халкы танып тора тагын үзләрен, хәбәр тиз тарала. «Солтан Саимәсенең «генераллары» кайткан», диләр.

Өзелгән сүзне Солтан абзый дәвам итте:

— Эшнең аның җиңеле юк, килен. Җиңел булса, эш тә димәсләр иде. Эшләмичә яшәп кенә булмый. Син менә көне буе балаларны музыкага өйрәтәсең, әллә бик җиңелме? Минем кулдан гомер килә торган һөнәр түгел. Анагыз да гомер буе сменалы эштә эшләде, арыдым, туйдым дигәнен хәтерләмим.

— Әни әни инде ул безнең,— диде Әлфия.

Шулай булмый мөмкин дә түгел шул: әнисе — кайнанасы — күпме акыллы киңәш бирде аңа. Җитмәсә, яшь килен булып йөргән чагында бик тиз каушап төшә, үпкәли торган гадәте бар иде Әлфиянең.

— Киленкәем,— дияр иде Саимә апа җайлап кына,— ирең, кайнатаң алдында бер дә куркып калма, әни шулай кушты дип кенә җибәрә торган бул. Тормыш үзе көйли, тозын чамаларга да, башкасына да бик тиз өйрәнерсең.

Беркөнне мәктәптә педсовет иде. Ашык-пошык әзерләнгән. Әлфияне Даринның көтеп торасы килмәде, уенын-чынын бергә кушып: «Югары белемлеләргә генә барырга, сезгә бармасагыз да була»,— дип куймасынмы!

— Ярый соң алай булгач,— диде дә Әлфия, мич арасына кереп елый башлады. Саимә апа бакчага чыгып йөреп керде. Иркенләп еласын әле.

— Килен, әйдә, кызык итик әле үзләрен, Фәридә дә институтка читтән торып керәм дип йөри, бер-берегезгә иптәш тә булырсыз, син дә барып кара әле.

— Син дә юкны сөйләп торасың, әни, бала белән кем укып йөри инде?! Фәридә бит ул кыз кеше.

— Баланы үзем карармын.

...Солтан абзый озаклап кич утырып кайтты да тирән сулап йоклап та китте. Саимә апа ятса да, күзенә йокы кермәде. Күңеле күптән уникенче оныгы янында, тизрәк күрәсе килә. Ята торгач, бала тапкан, авызландырган, күкрәк сөтен имезгән чаклар хәтеренә төште. Унысын да, бал белән май каптырып, үзе авызландырды. «Кешегә, ата-анага бал кебек татлы, май кебек йомшак телле, шәфкатьле булыгыз», дип теләде. Теләкләре әлегә кадәр кабул була килде, уникенче оныгының колагына да шул сүзләрне әйтер. Хәзер нишләп ята икән, сабыем? Әнисенең сөте юк ди бит. Аның үзенең дә икенче баласы Рафисны имезергә сөте булмады. Сугыш вакыты белән хәзергене чагыштырырга мөмкинме соң? Ул чакта да җаен таптылар, Рафис күкрәк сөте ашап, таза, зур булып үсте. Килендәшенең яхшылыкларын гомер онытасы түгел, Казан базарына барып, әчтерхан чикләвегенә кадәр алып кайтты, сөтле чәйне гел кайнар килеш эчертте.

Еллар авыр иде. Сугыш башланды. Зур кызлары тәпи йөри иде инде, аны ияртеп, Рафиска йөкле килеш Арча районының Иске Пошалым авылындагы ишле гаиләгә, кайнана-кайната, килен янына кайтып төшкән Саимә оча алмаган кошка охшап калган иде. Бигрәк артык кашык булып кайтып керделәр шул. Ире бит: «Туган якта калсагыз, миңа җиңелрәк булыр, туган җирдә чыпчык та ачка үлми, әни әни инде ул»,— диде.

Улларыннан хат килми торганда, кайнананың кәефе кырылыр иде.

— И әни, бу бит безне сынарга гына бирелгән җәза, үтәр дә китер, улларың кайтып килер. Әгәр ямьсезләшеп куйсак, алар күзенә — безне саклап утка кергән кешеләргә — ничек күренербез?— дип, Саимә кайнанасын көйләр иде.

«Сөйдергән дә бала, көйдергән дә бала»,— диләр. Бала булган җирдә гайбәткә, ызгыш-талашка урын калмый. Фәния белән Рафисның әбиләре итәгенә менеп утырулары булды — дөньялар түгәрәкләнде. Баланың баласы балдан татлы шул.

Бер йорттан ике килен колхоз эшен төпкә җигелеп тарттылар. Килендәше Гайникамал Саимәгә сүз тидермәде: бергә көлделәр, бергә еладылар. Авыр эшкә түзәргә була, фронт хәбәрләре генә үзәкләрне өзә. Кешеләрне уртак кайгы берләштерә, якынайта, бер-берсенә ярдәм-

чел итә. Сугыш хәлләре бер үз башыңа төшкән кайгы булса, ялгыз башың күтәрә алмас идең. Саимә иренең яралануы, Мәскәү тирәсендәге госпитальдә дәвалануы турында хәбәр алды. Ике көн күзен дә йоммады, өченче көнне кайнатасына:

— Барып, алып кайтсак ничек булыр? Сиерның сөте, базда бәрәңге, суларга саф һава бар, үзебез тәрбияләрбез,— дип сүз кушты.

Шулай эшләделәр. Солтанны башта Казанга, аннан соң авылга алып кайттылар. Тизрәк тазару һәм яңадан китү көтеп ятканда, сугыш бетте. Илгә тынычлык кайтты, төзелеш еллары башланды. Солтан абый гаиләсе белән Арчага килеп урнашты. Фәния беренче класска укырга йөри башлады. Саимә апага күңелендә йөрткән изге хыялын тормышка ашырырга вакыт җитте. Бик авырлык белән булса да, мул уңыш җыеп алдылар. План үтәлде, алдынгыларга бүләкләр бирделәр. Саимәне 10 килограмм бодай белән бүләкләделәр. Кайнана шул оннан Саимәгә бәйрәм күмәче пешерергә рөхсәт итте. И, ул ләззәтле минутлар! Үзе пешергән пар күмәчкә Саимә озак карап торды. «Сугыш бетеп, муллык килсен иде, гел ипи генә салып тор идең!»— дигән иде ул Гайникамал килендәшенә.

Менә бит, ул көн дә килеп җитте. Саимә ипи салучы эшенә урнашып кайтты, сөенеченнән беренче көннәрендә нишләргә белмичә йөрде. Көненә бер үзенә ничә тонна ипи пешерә бит ул. Табыннарга аның хуш исле икмәкләре куела, ничә мең кеше шул ипине ашый.

1947 елда Дамир туды. Бер-бер артлы Нарын, Дарин, Радис дөньяга килде, исемнәрен әтиләре кушты. Кайсы дустының исеме, кайсы елга исеме. Күп мәшәкатьләр олы кызлары Фәниягә йөкләнде. Бакчада эшлисе, каз-үрдәк карыйсы, Дарин борынын канатканга, Нарын көлмәк җиңен ертканга да аңа җавап бирәсе. Әниләре көне буе эштә, апалары — командир. Энеләрен тезеп бастыра да нарядлар бирә. Рафис — «ефрейтор», димәк, Нарын, Дамир, Дарин аңа буйсына. Радис апасының ярдәмчесе. Марат исә күзәтүче, утырырга тиеш.

Саимә апага балаларына эш кушып чиләнергә туры килми, чүлмәкчедән күрмәкче, бер-берсеннән эшкә өйрәнде алар.

«Тишек тамак тик тормый, гел ашарга сорый»,— ди халык. Тәмле итеп туйганчы ашыйсы, матур киенәсе килә егет булып җитүче малайларның.

— Нинди эштә бик күп акча төшә икән?— ди Нарын.

— Иң авыр эштә,— ди Дамир.— Иң авыр эш — бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр Арча көтүен көтү ул.

— Әйдә, көтү көтәбез.

Кыш буе Дамир белән Нарын көтүче булырга хыялланалар, дәресләргә, көтүне үзләренә ышанып тапшыруларын телиләр. Кыш көне бигрәк тә тырышып укый алар ул елны, чыбыркы ишеп куялар, яз җиткәч, теләкләрен поселок Советына барып әйтәләр. Күпер баганасыдай, теләсә нинди авырлыкны күтәрергә әзер егетләргә поселок Советы председателе текәлеп, сынап карый. Ризалык сиздерергә ашыкмый.

— Уйлашырбыз,— дип озата ул аларны. Үзе исә мәктәпләренә барып сөйләшә, укуларын сораша, тәртипләре белән кызыксына. Әтиәниләрен күреп киңәшә. Солтан абзыйның исе дә китми: «Эшнең ниндие булса да, хурлыгы юк, эшләп ашасаң гына ипи тәмле»,— ди.

Саимә апаның күзләре яшьләнә. Бер яктан, балаларының кул арасына керүләренә сөенсә дә, икенче яктан, борчыла ул. Улларын каршысына тезеп утырта да:

— Дәүләтләрем,— ди ул кайнанасыннан откан иркәләү сүзе белән.— Кеше балалары кебек тәмле ашатып, матур киендереп йөртә

алмадым. Күбәү булдыгыз, бәхетле итә алмадым,— ди, күз яшьләренә буылып.

Балалар тып-тын калалар. Кемдер, кайсысыдыр әниләрен юатырга тиеш бит инде. Ул сүзне Дарин әйтә, әнисенә генә түгел, туганнарына да икенче мондый сөйләшүләргә урын калдырмаслык итеп әйтә.

— Әни! Йөрергә сез биргән аякларыбыз, эшләргә сез биргән кулларыбыз, дөнья матурлыгын күрергә күзләребез бар. Без бик бәхетле. Безнең Әти бар, безнең Әни бар. Безнең класста бер малай укый, әбисе аны бик тәмле ашата, матур киендерә, ләкин аның беркайчан да «әни» дип әйткәне юк, аны әнисе ташлаган, мин ул малайны кызганам... Әй, Марат, алып чык әле гармуныңны, бию көен сиптер, бүген концертны әни хөрмәтенә куябыз.

— Рәхмәт, балалар, күрше әбиләрегезне дә чакырыгыз, алар барыбер тәрәзә артына килеп тыңлап торалар. Мин тыңлый-тыңлый сезгә коймак пешерәм.

Фәридә апасы белән Ләлә кайтып кергәч, концерт дәвам итте. Ләлә үзенең зәңгәр күзле, ак чәчле курчагын биетте. Аны дәү абыйсы Казаннан алып кайткан иде.

Алмагачлары бик күп иде, уңыш бирә торганы гына да егерме төптән артык. Күршедә генә балалар бакчасы, аларга да өлеш тиде... Саимә апа койманың астагы бер тактасын алды да зур агач табакны шунда куйды, уңыш вакытында шуннан алма өзелмәде. Әгәр салырга онытkан булса, балалар искә төшереп, «Алма апа!» дип кычкыралар иде. Алмагачлар корып бетте, Саимә апага тагылган кушамат калды. Үзләре әти-әни булган балалар очрашканда һаман: «Исәнме, Алма апа!»— диләр.

Малайлар яздан ук көтү алдылар. Ике сменада укулары да ярап куйды, берсе төшкә кадәр, икенчесе төштән соң көтте. Җәй көннәре бергә-бергә сизелми дә узды. Малайлар кояшта каралып, үсеп киткәндәй булдылар. Баштарак арып, авыртып интектергән аяклары да соңга таба күнегеп җиттеләр. Саимә апа баштарак улларын уята алмыйча аптырый иде, соңрак, иртәнге дүртенче яртыда үзләре торырга өйрәнделәр. Әниләре алардан соң ятты, алардан алда торды. Беркөнне исә кеше урынына өченче сменага калган иде. Кичтән нығыттырып әйтеп, ашарларына әзерләп китте.

— Үзебез торабыз,— диделәр. Күңеле сизенеп, әниләре йөгереп кайтса, тәгәрәшеп йоклап яталар, аяк тавышына сикереп торган Дамир, кояшны күргәч:

— Юк ла, әни, синнән башка көтү көтеп булмый,— диде. Киленнең балаларын карап өйдә утырган бер кайнана, киленемә пенсиягә чыгарга стаж эшлим дип әйткән ди. Кырга чыкмаса да, Саимә апа көтү көтте, кайгырды, сөенде.

Дамир белән Нарын эшләгән акча гына да ике мең сумнан артып китте. Шул елны инде әниләре бөтенесен бергә җыйды да кибеткә алып барды. Сораган бөтен әйберләрен алып бирде. Калган акчаны кассага салып куйганнар иде, апалары кияүгә чыкты, зурлап туй ясадылар. Солтан абый белән Саимә апа, кызларын кияүгә биреп, «әби-бабай» булырга йөргәндә Саимә ут белән су арасында калды, ул унынчы баласына авырга узды. Башкаларында сөенеченнән нишләргә белми йөри, рәхәтләнеп аш сайлый иде. Бу юлы әллә ничегрәк. Балалардан яхшы түгел, киткән кызың, бүген тотып өйләндерерлек малайларың барында бала табып ят, имеш. Киңәш бирүчеләр дә табылды тагын, больницага кереп өч көн ятсаң, сизми дә каласың икән. Күңел кабул итмәсә дә, аяклары больницага илтте, курка-курка, «Кеше очрамаса, кеше күрмәсә ярар иде» дип

барды. Әнисе ундүртне тапкан, дүртәве генә исән калган, хәсрәт аңа үзе килгән. Саимә үзе хәсрәт эзләп йөри.

Больница коридорында Галя Измайлова очрады, Саимә апа күренмичә узып китәргә чамалаган иде — булмады. Гөлсем (Саимә апа яратып шулай дип йөри)— җиде баласының көндек әбисе, башлап кулына алып сөйгән кадерле кеше. Шундый чакта очрап торуын күр әле син аның! Саимә апаны кочаклап та алды, җилтерәтеп үз бүлмәсенә кертеп утыртты. Врач ханым балаларның һәрберсен аерымаерым сорашты. Саимәнең теләген белгәч, алдан ачуланды, аннары үпкәләде.

— Тугызны үстергәнне, берне үстерә алмам дисеңме? Юк иткәнче, тап та миңа бир!

Озак сөйләштеләр алар ул көнне. Тагын җиде ай узгач, зәп-зәңгәр күзле, сап-сары чәчле кыз бала дөньяга килде. Гөлсем ханым үзе кабул итте, сөенеченең чиге-чамасы булмады: ул бит, ул саклап калды аны! Больница тәрәзәсеннән Ләлә белән Фәридәгә күрсәткәннәр иде, Ләлә: «Лена, Лена»,— дип үз курчагының исемен кабатлады. Бәбигә курчак исемен кушмый чара калмады. Бала кулдан да төшмәде, әле берсе, әле икенчесе күтәреп йөрде. Дүрт ай тулгач, әниләре эшкә китте. Берәз өйдә утырырга да булыр иде, директор үзе килеп чакырды: «Камыр куярга осталарым юк, өйрәткәләп кенә торсаң да, яхшы булыр иде»,— диде. Герой-ана алай итеп йөрүне килештермәде, кешедән аерыласы килмәде, Ленаны ашатырга да йөгереп кенә кайтты ул. Эш күрсәткечләре яхшы, иптәшләре белән тату эшләгәч, эшкә йөрисе килеп кенә тора.

Саимә апаны гомерендә беренче мәртәбә мәктәпкә чакырттылар: Марат кеше кыйнаган. Ана көне буе ут йотып йөрде, хәле китте. Үзе гаепле: Маратны башка балаларыннан аерды. Бер кулы кечерәк иде малайның. «Кимлек сизмәсен, кимсенмәсен», диделәр. Сораган бер әйбер аңа булды. Үзе гаепле, мәшәкатьләр арасында мәктәпкә барырга бөтенләй истән чыккан. Күптән дәресләренә кереп утырганы, Маратның укытучыларын күргәне юк икән бит. Юл буе ул үзүзен тиргәде. Үзе генә гаепле, өлгерә алмады!

Марат укытучылар бүлмәсендә басып тора, кайгылы кыяфәттә, башы аска иелгән, авызыннан бер сүз алышлы түгел. Әнисе килгәч, яклаучысын күргәндәй, йөзе яктырып китте. Саимә апа укытучылар белән исәнләште дә улы янына үтте.

— Нишләдең, Марат?

Укытучылар инде ярты көн шул сорауга җавап көтәләр.

— Сигезенче класстагы Миңлегалимне кыйнадым... Үенга чиратсыз кермәкче була. Этеп җибәрде... «Син, инкубатор, өеңә кайтып уйна», ди. Суктым, ә ул әләкләргә йөгерде.

Марат абыйлары арасында да кечкенәдән аерылып торды. Укымый иде әле — тузынып кайтып керде. Кибетче белән бер хатынның сөйләшкәнен тыңлап торган.

«Бердәнбер балам иде, начар кешеләр белән йөреп, харапләр гына булды. Саимәнекеләр, әнә, сарык көтүе санынча булса да, шылт иткән тавышлары да чыкмый!»

Ямьсез чагыштыру ошамаган Маратка, ничек инде аның абыйлары сарык булсыннар! Әнисе яхшылап сөйләшмәсә, турыдан узган апага таш ыргытырга әзерләнеп утыра.

Мәктәптә малайларның бәргәләшеп алу очраклары бар. Укытучыларның әти-әниләрне чакыртулары да беренче мәртәбә түгел. Кайбер әниләр килеп керәләр дә балаларына кычкырырга тотыналар, бәргәләргә дә күп сорамыйлар. Саимә апа балаларына кул күтәрмәде.

Мәктәптән кайткач, Марат әнисен килеп кочаклады,— үзенчә гафу үтенүе.

— Улым, Миңлегалим белән яхшылап аңлаш, мине кайгыга салып, сугышып йөрисең.

— Башка сугышмыйм, әни, яхшы малайлар белән генә уйныйм.

— Яхшы кеше усал малайлар янында да яхшы була белә ул.

...Кияүгә китеп, ярты еллар вакыт узгач, Фәниясе еш кайткалый башлады. Төшке ашка да әниләренә генә керә, кич тә озак-озак утырып китә. Беркөнне бөтенләй кунарга ук калырга җыена башлады. Саимә апа ничек сүз башларга белми йөрде-йөрде дә:

— Тукта әле, кызым, кияү кайтып кетеп торадыр бит?

— Соң кайта ул, әни, кайткач та рәтләп сөйләшми.

— Кайтканын җылы ашыңны пешереп көтеп тор, ул кайтмыйча ашама, утыңны сүндермә, үзең сөйләш, хәлен сораш. Мин бит сиңа, кызым, ашыкмыйсыңмы дигән идем, үзең ашыктың, ул яхшы кеше, яратам дидең. Бар, кызым, кайт. Син ир хатыны хәзер. Фәрит килсә кил, ул килмәсә — килмә!

Фәния, әнисенә үпкәләп, елый-елый кайтып китте, үзе тагын өйдә әнисе кушканнарны эшләп караган иде, бик матур яши башладылар, уллары туды. Лена белән бергә уйнап үстеләр.

...Иртән аязган, яңгыр туктаган иде, Саимә апаны Чаллы яларына карты озатып калды.

— Озаклама, өч кенә көнгә җибәрәм,— диде Солтан абзый.

Саимә апа Чаллыга Гөлсинә иртәгә больницадан чыгасы дигән көнне килеп төште. Бәби каршыларга әзерләнде, өйләрне ялт иттерде, бәлеш пешерде. Керә-керешкә үк бәлеш исен сизгән Гөлсинә:

— Дамир, әни килдеме әллә?— диде. Әниләре әйтми торырга кушкан иде, кинәт белсен, шатлансын, шат булсаң, сөт төшә,— диде. Чыннан да, бәлеш белән сыйлап, чәй эчерткән иде — Рамил имеп өлгерә алмады.

Рафисның хәлен белергә бардылар. Бүгенгә кадәр янына кереп кенә йөргән булганнар. «Әни» сүзен ишеткәч, үзе чыкты, каршы очраган врач ханым бармак селкегәч, шатлыгын уртаклашты: «Әни килгән, болай булгач, терелән инде».

Саимә апа, өч баласында берәрне кунгач, кире борылды. Казанда дүрт баласы, юл уңаеннан аларның да торган җирләрен, иптәшләрен күреп кайтырга булды.

Фәриданең эшли торган җиренә керде. Саимә апаның Фәридә әнисе икәнен белгәч, нишләргә белмәделәр, димәк, кызын яраталар. Бик изге йорт инде бу Саимә апа өчен. Фәридә шунда эшли дә, шунда укый да, Әлфия килен дә шунда килеп укып китә. Ләлә торып, көндезгедә укый. Лена да химия укытучысын бик яраткан иде, химик булам диде. Химия-технология институтына укырга керде. Әнисе килгәнне әйткән булсалар да, ул тиз генә кайта алмады. Комсомол җыелышы булган, Лена группаның комсомол секретаре икән. Кайтып утырган гына иде,— бер-бер артлы кызлар кереп тулды.

— Лена, сөенче, егетеңнән хат бар.

— Бер дә көткән кешемнән түгел әле.

Хатны әнисе кулына алган иде, солдат хаты икәнен аңлады, маркасыз.

— Бүген үк җавап яз,— диде әнисе.— Көттермә!

— Ярый, әни.

— Лена, күлмәк тегәргә машинаңны биреп тормассыңмы икән?— диде икенче бер кыз.

Бүләк машина бит ул, әтисе Ленага унсигез яшь тулган көненә алып биргән иде, Саимә апа шуны уйлап куйды, үзе исә күршедән кергән кызга:

8*

— Кызым,— диде,— сиңа эти-әниеңнәр бүләк алганнары бармы?

— Миңа егерме тулганда әни — алка, эти йөзек алып бирде. Алтынны!— диде кыз мактанып.

— Ник алар сиңа машина бүләк итмиләр?

— Мин тегә белмим шул, апа.

— Сусыз җирдә йөзәргә өйрәнеп булмый ул.

Лена бу кызны яратмый, бер тапкыр машинасын ватып та керткән иде, җитмәсә, алтыннары белән мактана. Ленаның да калышасы килмәде, ул:

— Миңа әти тегү машинасы бүләк итте, әни тегәргә-чигәргә өйрәтте. Алтын алкамны үзем җәй көне төзелеш отряды белән Молдавиягә барып эшләп кайткач алдым. Сиңа да «әйдә!» дигән идем бит, бармадың, барсаң, машина алыр идең!

Лена күрше кызына машинасын бирми чыгарды, Саимә апа йомышка кергән кешене кире борганын хәтерләми. Кемдер дәрес сорап кергән иде, аңа да аңлатмады.

— Азрак йокларга өйрән,— диде.

Әнисе:

— Ник аңлатмыйсың? — дигәч, кыз аптырамады. «Дәрескә йөрсеннәр»,— дип, кырт кисте.

Кунарга Радисларга киттеләр. Анысы яңа алган квартирын «ялт» иттергән. Өйләндерәсе, башлы-күзле итәсе дип, күптән әзерләнеп йөри Саимә апа, сөйгәне ялындыра. Югыйсә, Саимә апа кызның кылларын тартып караган иде, бер дә каршы кебек түгел, укуы да дүртенче курста.

— Улым, курчак өедәй фатирыңда ялгыз ятмассың бит инде! Өйлән!

— Әти-әниләре каршы бит, Лена риза да...

— Яман атыбыз чыкмаган, азып-тузып йөрмәгән, ник ялындыра бу кодагыйлар? Кайту белән барып сөйләшәм, туйны тизләтергә кирәк.

— Әни тотынса, өйләндерә инде үзеңне!

Саимә апа сөенә-сөенә планнарын сөйли:

— Утыз баш казым бар, егермесен суеп сатам, шәһәр кызлары бик матур киенә икән. Лена белән Ләләгә тун алып бирәм.

...Кышка туй уздырабыз.

...Язга алмагачлар утыртабыз.

Радис, чәй яңарткач, әнисе янына килеп утырды.

— Әни, тагын нинди планнарың бар?

— Алар күп, улым. Җәйгә бөтен оныкларымны кунакка чакырам.

— Әни, мин сине иртәгә көне буе кибетләрдә йөртәм, сиңа нәрсә кирәк,— шуны алып бирәм.

Лена абыйсына яратып елмайды да әнисенә:

— Әни, әйт инде, синең үзеңә нәрсә кирәк?— диде.

Балалары — Дарин, Фәния, Рафис, Фәридә, Марат бертуктаусыз шулай диләр.

Саимә апа дәшми, аналарга балалардан нәрсә кирәген бер сүз белән тиз генә әйтеп буламыни?

Икенче көнне иртән үк карчыгын каршы алырга Солтан абзый да Казанга килеп җитте. Алар бергә кайтып киттеләр. Бергә-бергә юл күңелле. Хәер, Саимә аларны бергә дә, ялгыз да күп узды. Юлдан арынганы-туйганы юк, чөнки ул барасы юлның бер башында үзе булса, икенчесендә балалары көтеп тора. Алда — кавышу шатлыклары.

Фәния ХУҖИӘХМӘТОВА

Тәүфикъ Әйди

# МӘРЗИЯ ХАНЫМ ИСТӘЛЕГЕ

Әзербайҗан башкаласындагы үзәк мәйданнарның берсе. Даулы көннәрнең гайрәтле каһарманнарына һәйкәл. Монда исәннәрнең үткәнгә хөрмәте һәм мәхәббәте булып Мәңгелек ут яна. Декабрь ахыры булуга карамастан, һәйкәл тирәсендәге агачларның бөдрәләре әле һаман яшел. Каршыдагы йортның ачык тәрәзәләреннән моңлы мәкам ишетелә. Мәңгелек ут, яшел төс һәм моң.

Хагани урамы буйлап таш диварлар арасындагы асфальт тротуардан Әзербайҗан театр җәмгыятенә таба барганда Әстерханның Тияк бистәсе искә төшә. Анда бөтенләй башкача. Мондый гүзәл корылмалар — мәрмәр баганалы сарайлар, купшы бакчалар, түшәмнәрен затлы кандилләр бизәгән метро, мәһабәт һәйкәлләр дә юк. Тәрәзәләре капкачлы, такта белән тышланган тәбәнәк балчык өйләр, камыш ихата, буявы уңган капкалар, киез түшәлгән шикелле аякка йомшак сукмаклар. Әмма һәвәскәр тарихчы, йөзе салам кебек саргайган, маңгаена буразналар салынган Гатаулла бабай Әхтәмев, Тияк тәэсирләрен күзеңнән «укып» Әстерхан ягының дәрәҗәсен күтәрерлек нәрсәләр хакында сүз кузгата:

— Бирегә милли театр 1906 елда барлыкка килгән дип саныйлар. Ә безнең шәһәрдә татарча спектакль беренче мәртәбә аннан өч ел элегрәк уйналды. Сез кызыксынган Мәрзия ханым Тияк бистәсендә туган!..

Мин Бакуда әнә шул Тияк кызы эзләреннән йөрим. Театр җәмгыятенә бару да аның сәхнәдәш дусларын күрү өчен. Аларның берсе — СССР халык артисты Шәмси Бәдәлбәйли.

— Мәрзия ханым белән беренче тапкыр 1928 елда «Ут килене», «Севил» спектакльләрен куйганда очраштым,— ди ул.— Мин тара[1] уйнап, спектакльне музыкаль яктан бизәргә тиеш идем. Унҗиде яшьлек консерватория студенты өчен бик җаваплы бурыч иде бу, әмма ул чакта ук инде күренекле артистка булып танылган Мәрзия ханымның уены эшемне дә оныттыра язды...

Бәдәлбәйли сөйли дә сөйли, ә мин үземне тамаша залында утыргандай хис итәм.

Әнә... Севил — Мәрзия Даутова. Иренең хыянәтенә бик озак ышанмый ул. Күзләрендә шөбһә уты яна, шул хис кайнар дәрткә әйләнә һәм бераздан нәфрәт белән алышына. Аның мәхәббәте һәм нәфрәте сүзсез дә күренә. Менә ул, гаҗәп тәвәккәллек белән чадрасын салып атып, баласын күрергә килә, иреннәре баласына булган мәхәббәттән тартыша, яшьле керфекләре улының яңакларына орына...

Артистка образ үсешен хәрәкәттә һәм табигый күрсәтеп, тамашачы дикъкатен үзенә шул кадәр тарта кебек, залдагы әзербайҗан хатыннары ике-өч сәгатьлек тамаша вакытында бөтен гомерләре буе изелеп яшәүнең газаплы фаҗигасен тоялар. Шул хис-тойгы белән ялкынланган хатыннар кинәт сикереп торалар да, үзләрен җәберләп, изеп торган караңгылык символы, урта гасыр хорафатларының берсе булган чадраларын Севил-Мәрзиягә ияреп салып ыргыталар. Сәхнә белән тамаша залы, сәнгать белән тормыш менә шулай берләшә! Спектакль үзе дә тормышның реаль бер күренешенә — бәйрәмгә әйләнә. Мәрзия Даутова исә шушы спектакльдән соң Әзербайҗан драма театрының иң гүзәл башкаручысы булып танылa. 1938 елда «Севил» Мәскәү һәм Ленинградта күрсәтелә. Әзербайҗан телен төшенмәгән тамашачылар да Мәрзиянең гаять тәэсирле, хисле тавышын ишетеп, уенына әсир булып, күзләреннән яшь тамчылары тәгәрәвен тыя алмый икән. Севил ролен уйнар өчен әрмән, яһүд, рус театрлары үз сәхнәләренә чакыралар.

— Соңрак Мәрзия ханым Әзербайҗан республика театр җәмгыятенең рәисе булды, мин исә шуның президиум әгъзасы итеп сайландым,— дип Ш. Бәдәлбәйли мине тагын чынбарлыкка кайтарды.— Тагын бергә эшләргә туры килде. Ә 1956 елда без аның белән Казанга, Татар академия театрының юбилеена бардык...

[1] Тара — милли музыка коралы.

Еллар пәрдәсе аша күңел Татарстан башкаласына сәфәр чыккан ике юлаучыны күрә. Берсе — музыкаль комедия театрының җитәкчесе Бәдәлбәйли. Икенчесе—олы иҗади юл узган сәхнә йолдызы Мәрзия ханым. Сәнгатьнең төрле өлкәләрендәге хезмәтләре белән Бакуны сөендерергә өлгергән Бәдәлбәйли аңа зур ихтирам белән эндәшә:

— Мәрзия ханым, Казанга баргач без инде сәнгать эшлеклеләре белән очрашырбыз, әңгәмәләр корырга туры килер. Шул чак татар мәдәниятын бераз белүемне күрсәтсәм...

— Әйбәт булыр, өлкән буын әзербайҗан артистлары татар театрының үз кешеләре булып яшәделәр,— дип хуплый аны Даутова.

— Хәбәрдар булуым чамалы шул. Бәлки сез булышырсыз, юлыбыз озын ич әле?— ди Шәмси.

— Мөмкин. Татар театрының тарихы «Сәйяр» труппасыннан башлануын беләсездер инде. Менә шул «Сәйяр» 1908 елда Кавказга гастрольгә килгәч, Тифлистә әзербайҗан артистлары белән очрашып бер кунакханәгә урнашалар. Әзербайҗан театры шактый элегрәк барлыкка килсә дә, актрисаларга кытлык кичергәнлектән, Х. Гарәблинский яшь татар театрының уңышларына, бигрәк тә труппада хатын-кызларның җитәрлек булуына шатлана һәм җәйге гастрольләрне бергә уздырырга тәкъдим итә. Моңа «Сәйяр» артистлары да риза була һәм алар озакламый бергәләп Н. Вәзирзаденең «Мөсибәте Фәхретдин» пьесасын куялар. Гарәблинский татар дусларына әзербайҗан теле, гореф-гадәтләрен өйрәтә, чөнки Кавказда спектакльләрне әзербайҗан телендә уйныйлар. Әстерханнан башлап исә татарча куя башлыйлар, монда инде әзербайҗан артистлары татарча өйрәнә. Берләшкән труппа «Надыйршаһ», «Бәхетсез егет»һ. б. әсәрләрне сәхнәләштерә. Бу иҗади дуслык артистларда да, тамашачыларда да бик матур тәэсир калдыра, «Сәйяр» артисткасы С. Гыйззәтуллина-Волжская соңыннан: «Гарәблинский гаять сәләтле артист иде, ул репетиция ясаганда йөрәгең тетрәп тора...»,— дип сөйли. Ганҗә шәһәрендәге әзербайҗан гәзите исә: «Гарәблинский партнеры (Гыйззәтуллина) шул кадәр яхшы уйнады ки, хәтта Гарәблинский үзе югала язып калды»,— дип хәбәр итә. Ике театр арасында дуслык менә шулай башлана.

— Сезгә Гарәблинский уенын күрергә дә насыйп булдымыни?— ди Шәмси әсәрләнеп.

— Әйе. Хәтта бергә уйнадык та. Гарәблинский 1918 елда иптәшләре белән бергә тагын Әстерханга килде. Җәй көне татар һәм әзербайҗан артистлары бергә берләшеп труппа оештырдык һәм көзгә кадәр егерме ләп спектакль куйдык.

Төрле вакыйгаларга чиксез бай була ул 1918 елның җәе! Әстерханга татар сәхнәсенең мактанычы булган Зәйни Солтанов, Мохтәр Мутин, Кәмал I кебек артистлар җыела. Аларга Сара Байкина, Габдулла Уральский, Камал III, Җәләл һәм Зөлкарнәй Байкиннар, Исмәгыйль Күгешев һ. б. кушылып, җыелма группа төзиләр. Сухово-Кобылинның «Кречинский туе»нда Солтанов, Мутиннар белән бергә Мәрзия дә уйный.

Аннары сәхнәгә Мольерның «Саран» комедиясе һәм Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясе куела...

Яшьләрнең һәм тәҗрибәле артистларның профессиональ белемнәрен күтәрү өчен З. Солтанов җитәкчелегендә студия ачыла. Монда театр сәнгате тарихы, дикция һәм декламация, мимика һәм пластика, сәхнә төзелеше, роль өйрәнү һәм грим салу фәннәренә хәтле укытыла. Студиядә сабак бирергә Әстерхан рус театрының күренекле артистлары һәм режиссерлары чакырыла. Камал I, С. Байкина, Г. Уральский һ. б. җөмләсеннән Мәрзия дә әнә шул студияне тәмамлап, атаклы артистлар белән бергә уйнап, чын сәхнә мәктәбе үтә. Әмма М. Горькийның «Тормыш төбендә» драмасында Настяны уйнарга тәкъдим ителгәч, инде шактый осталыгы булса да, аптырап кала ул. Садә җанлы, өмет һәм хыял тулы зат. Бәлки Мәрзия тирәсендә дә мондый кешеләр бардыр? Ул эзләнә, Горькийның башка әсәрләренә мөрәҗәгать итә. «Мин кешенең табигатьтән әшәке булуына ышанмыйм — табигате белән ул гел яхшыга омтыла, тирә-ягындагы яхшыны күрергә ашкына. Кешене пычраткан нәрсә — дәүләтнең сыйнфый төзелеше». Горькийның шушы сүзләренә юлыккач, Мәрзия үз роленә дә ачкыч тапкандай була...

Мәрзия ханым юлдашының әле һаман да аңа төбәлеп утыруын абайлагач, уйларыннан аерылды. Настяны Бакуда уйнады лабаса, күрче, истәлекләр кая алып кереп киткән аны!

— Беләсезме, Шәмси, татар театры бер Казанда гына түгел, төрле шәһәрләрдә үсте,— дип дәвам итә ул өзелгән сүзен. Аның күренекле бер эшлеклесе Зәйни Солтанов Әстерхан егете иде. Ул туган шәһәрендәге һәвәскәрләргә, шул исәптән миңа да беренче иҗади ярдәмне күрсәтте. Зәйни абый Хөсәен Гарәблинский белән дусларча мөнәсәбәттә булып, спектакльләрдә бергә уйнап, ике милли театрның дуслыгын ныгытуга да зур өлеш кертте.

— Ни өчендер, леди Макбетыгыз исемә төште әле,— диде Бәдәлбәйли,— бу образ Гарәблинский иҗат иткән көчле характерларга охшагангамы?

— Шекспирның байтак пьесаларында уйнадым,— ди аңа Мәрзия ханым елмаеп,— әмма аларда леди Макбет төсле дәвамлы эзләнеп барлыкка китергән ролем булмады. Бу рольне иҗат итү миңа тапшырылгач, бөтен тынычлыгымны югалттым. Шекспир пьесаларын гына түгел, «Макбет» фаҗигасе тасвир ителгән заманны да өйрәндем. Шөһрәт сөючән, мәгърур, шул ук вакытта үзенең һәм иренең мәнфәгате өчен теләсә нинди мәкерле эшләргә катнашып, һичбер җинаятьтән баш тартмаган бер хатын сурәтен барлыкка китерергә кирәк ич.

театр сәнгатен махсус уку йортларында өйрәнмәгәнлектән, актерлык осталыгын баш рольләрдә уйный-уйный үзләштерергә туры килде.

Макбет — шөһрәт сөюче, политика белән кызыксынучы шәхес. Ул король хакимлеге белән кискен көрәш алып баручы акыллы сәясәтче. Мәрзия мелодрама уйнамады, ә кешелеклелек хисләре көрәшен гәүдәләндерде. Вакыйга барышында Макбет кешелеклелектән ераклашып, иблискә якынайды, аннары йокысыннан уянып, үз җинаятьләренең авырлыгын аңлагач, күңелендә барган үткен көрәш аркасында ул газапланып һәлак булды. Фаҗигабенең иң кискен җире — леди Макбетның йокыдагы күренеше, кан хакындагы монологы иде. Монда Макбетның кешелекле хисләре, вөҗданы уянды, аның аңында рухи көрәш дөрләде. Кулына шәм тотып авыр адымнар белән сәхнәгә чыгуы искиткеч дәһшәтле манзара булды. Ул әкрен-әкрен атлап үз куллары, бармакларына күз салганда, аларда кан таплары күрде. Даутова, рус театры горурлыгы булган Ермолова шикелле, бу күренештә хисләр давылы һәм гайре табигый бер хәлне — пакь кулларында кан эзен күрсәтте.

— Әмма мин әзербайҗан тамашачыларына Макбеттан алда Гөлтәкинне уйнап таныштым,— ди Мәрзия ханым режиссер юлдашына.— Сез әле, Шәмси, ул чакта бала гына булгансыздыр.

— Әтием үзе дә һәвәскәр спектакльләрдә катнашканлыктан, мин яшь чактан ук театр хакында күп нәрсә ишетеп үстем,— ди Бәдәлбәйли.— Җәфәр Җаббарлының «Айдын» пьесасындагы ул рольне гаҗәеп осталык белән башкаруыгызны сокланып сөйлиләр иде.

Гөлтәкин. Башка каһарманнар сүзеннән аның ата-анасын ташлавы, шашкын бер мәхәббәткә тап булуы аңлашыла. Менә кыз, авыр сулап, кулындагы хатка күз сала. Хатның кемнән, ни хакында икәнен чамалавы кыен, әмма Гөлтәкин-Мәрзия, салмак адымнары, утлы карашы хатның я һәлакәт, я бөтен бер гадәттән тыш нәрсә якынлашу хәбәре икәнлеге турында сөйли... Башта ул Дәүләт бинең аңа белдергән гыйшкын әдәп белән кире какты, аның әрсезләнүенә кискен каршы күтәрелде, үз-үзен бәладән коткара алмагач, фаҗигага гасабиланып зар елады. Гөлтәкин язмышының иҗтимагый табигатен күрсәтүгә шундый басым ясала.

— Гөлтәкин безнең театрда уйнаган беренче ролегез идеме?— ди Бәдәлбәйли юлдашына.

— Юк. Баку сәхнәсенә мин беренче мәртәбә 1920 елның язында «Аршин мал алан»да Җәһан хала ролендә чыктым. Әле әзербайҗан телен камил үзләштерергә өлгермәгәнлектән, режиссер суфлерны кисәтеп куйды. Бары спектакль башлангач кына дулкынлануым басылды, үземнең сәхнәдә икәнемне онытып, суфлер пышылдавын да ишетмәс булдым. Каһарманымның хис, тойгылары үзенә бөтереп алды да яңа хәятка чумдырды мине.

— Сез катнашкан ул беренче спектакльнең бик уңышлы узганлыгын сөйләүләре хәтеремдә,— ди Бәдәлбәйли.

— Бакудагы уңышлы чыгышыма Әстерхан татар театрында «Аршин мал алан»ны уйнаган булуыбыз ярдәм итте. Мин анда Гөлчәһрә ролен башкарган идем.

— Ә без сезнең Әстерхан чоры иҗатыгызны бөтенләй диярлек белмибез бит әле,— ди Шәмси.

— Гареблинский мине Баку сәхнәсенә менә шул спектакльне күргәч чакырды,— дип дәвам итә Мәрзия ханым.— Әзербайҗан театры әле һаман хатын-кыз артистларга мохтаҗ иде. Әмма ул чакта мин туган шәһәремне, татар театрын ташларга батырчылык итмәдем.

— Хатын-кызларын бикләп, чадра бөркәндереп тоткан караңгы Әзербайҗан икеләндердеме?

— Әстерханда да хөррият бик зурдан түгел иде.— Көлемсери Мәрзия ханым, аннары җитди дәвам итә:— Татар театры да авырлыклар аша дөньяга килде. Островскийның пьесасын сәхнәләштерүебез әле дә хәтеремдә. Миңа Варвара ролен тапшырдылар. Рус тормышы, гореф-гадәтләрен өйрәндем, фаҗигабенең социаль сәбәпләрен аңларга, шуны күңелемнән кичерергә тырыштым. Добролюбов мәкаләләре белән таныштым. Миңа бу эштә рус актрисасы Кирсанова да ярдәм итте. Үземне инде тәмам әзер санап, караңгылыктан яктылыкка омтылучы кызны гәүдәләндерергә исәпләп, сәхнәгә чыктым. Бер заман спектакль барганда шау-шу купты. Мәчет картлары, төрле искелеккә тешләре-тырнаклары белән ябышып ятучы мөселман агай-энеләр җыелып, без «азгыннар»ны туздырырга килгәннәр икән. Вакытында арткы ишектән чыгып өлгермәсәк, чын туфаннан ничек котылыр идек, белмим.

Мәрзия Тияк бистәсендә 1901 елның 25 ноябрендә дөньяга килә. Икмәк пешерүче әтисе аны «Җәмгыяте хәйрия» мәктәбендә укыта, сабакка бик һәвәс Мәрзия шәһәрдә әледән-әле оештырыла торган «Шәрыкъ кичәләре»нә дә атлыгып кына тора. Шундый тынгысызлыгы аркасында ул 1911 елда бер әдәби ахшамда Әстерханга кунакка килгән Габдулла Тукайның халык әдәбияты турындагы чыгышын да, «Идел» газетасында эшләгән Сәгыйть Рәмиевне дә тыңлый ала.

Әстерхан зыялылары да «шәрыкъ кичәләре»нең берсен дә калдырмый йөрүче кызны күреп алып, «Беренче театр» спектаклендә уйнарга өндиләр. Мәрзия Гафифә роленә ризалык бирә. Кызыксынучан булуы, яктыга, мәгърифәткә омтылуы, әмма олылардан, «кеше сүзе»ннән бераз шүрләве белән дә Гафифә бик якын була Мәрзиягә. Шуңа күрә ролен ул ярыйсы ук кыю «ермачлап» чыга. Билгеле, бу уенда, сәнгатьчә осталыктан бигрәк, тормышка нәру өстенлек иткәндер. Шулай да Әстерханда яшәгән кеннәр Мәрзиягә бик-бик кадерле, чөнки гомеренең ул кисәге кайнап торган яшьлек дәрте, исерткеч

хыяллары белән үсмерчактан өлгерү чорына күпер булып сузыла бит.

— Кыска гына чор эчендә нинди зур үзгәреш! — диде Бәдәлбәйли,— әле кайчан гына мәчет картлары сезне сәхнәдән күсәк белән куганнар. Хәзер исә Бакуга килүчеләр Даутованы күрмичә китмәскә тырыша. Меңнәр теленнән төшми торган артистка булуыгызны Казанда беләләрме икән?

— Әйтә алмыйм,— ди Мәрзия ханым.— Әстерханда мена искә алучылар бардыр...

Казанда да аны сагынып искә алучылар байтак була. Зәйни Солтанов еш кына яшьлек елларын, шул чорда сәхнәгә аяк басып, уңышлы атлап киткән шәкертен башкаларга үрнәк итеп искә алырга ярата:

— Мәрзия сәхнәдә табигый яши белә,— ди ул,— халыкны үз уены белән әсир итә торган көчкә ия иде.

— Әйе, Мәрзия Даутованың уены сокланырлык,— дип раслый Солтанов сүзләрен Камал III.

1948 елда Ә. Мәмәдханлының «Шәрыкъ иртәсе» әсәреннән Гөлзар образын иҗат иткән өчен СССР дәүләт премиясе белән бүләкләнгәч, 1949 елда исә СССР халык артисты исемен алгач, кайчандыр Тияктә бергә торган күрше малае — язучы Габдрахман Минский:

— Халкыбызның горурлыгына әйләнде Мәрзия ханым,— дип әеруча шатлана.— Аның сәнгатькә ихлас куеп, татарча спектакльләрдә катнаша башлавын күреп үстем мин. Сылулыгына, сәхнәдә үз-үзен тотуына сокланып туймый каравым истә.

Мәрзия ханым Татарстан башкаласында үзе турында шушындыйрак сүзләр кузгатылуын, әлбәттә, белмәгәндер. Чөнки ул Татар академия театрында уйнарга күпме хыялланса да, язмыш аны һаман Кавказда йөртә: 1927-28 елларда Тбилиси әзербайҗан театрында эшли, 1930-31 елларда Баку төрек эшче театрында чыгышлар ясый, ә калган барлык тормышы М. Әзизбәков исемендәге Әзербайҗан академия театрына бәйләнеп уза. Монда ул Җ. Җаббарлының «Сулган чәчәкләр»ендә Гөлниса, Х. Җәвиднең «Шәех Сәнган»ында Хумар, Островскийның «Яшенле яңгыр»ында Кабаниха, Шиллерның «Юлбасарлар»ында Амалия, Мольерның «Дон Жуан»ында Елвида, Бальзакның «Үги ана»сында Гертруда һ. б. дистәләрчә образлар иҗат итә. Тәнкыйтьчеләр Мәрзия Даутованың Хумарны гәүдәләндергәндә романтик сәләте, Дездемонаны уйнаганда трагик таланты, Любовь Яроваяны тудырганда реалистик сыйфатлары калку ачылды, дип билгеләр һәм аны әзербайҗан театры тарихына исемнәре алтын хәрефләр белән язылган Х. Гәрәблинский, Г. Шәрифзадә, У. Рәҗәбләр янәшәсенә куеп саныйлар.

Шәмси Бәдәлбәйли юлдашының көчле характерлар, тирән хисләр актрисасы икәнен шулай ук яхшы белә иде. Бергә спектакльләр куйганда ул Мәрзия ханымның зурмы, кечкенәме — һәр рольгә олы җаваплылык белән каравын, һәр образны армый-талмый эзләнеп иҗат итүен, һәр сүзне җиренә җиткереп әйтер өчен көчен кызганмавын, җитмәсә, үз роле белән генә мавыкмыйча, ансамбль корып уйнарга тырышуын, тәҗрибәсен яшьләр белән юмарт уртаклашуын башкаларга үрнәк итеп күрсәтә. Ул аның «Фәрхәд вә Ширин» пьесасында Ширин образын лирик планда гәүдәләндердә. Кылыч алдында баш имәгән, Иран шаһы Хәсрәүнең мал-мөлкәтенә алданмаган, үз гыйшкын сүндермәгән әзербайҗан кызының күркәм образында аның бөтен яме, гүзәллеге белән ачыла алуын яхшы хәтерли...

Ш. Бәдәлбәйли белән юлга чыккан Мәрзия ханым Казанга шатланып һәм дулкынланып бара. Юлдашы белән әңгәмә әзелеп торган минутларда ул үткән тормышын күз алдыннан кичерә. Чөнки Татарстан башкаласына бу сәфәрне ул туган халкы алдында хисап бирү шикелле кабул итә. Якташлары алдына оялмыйча чыгып баса да алыр, әлбәттә. Гастрольләр вакытында Тбилиси, Ереван, Ташкент, Ашхабад һ. б. шәһәрләрнең тамашачылары юкка гына алкышламагандыр. «Хаҗи Кара», «Бер мәхәлләнең ике улы», «Чын дус», «Баку нурлары», «Бәхтияр», «Куруглы» һ. б. фильмнарны караган кино сөючеләр аңа тиктомалдан мәхәббәтләрен белдермәгәндер. «Почет билгесе», ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары белән бүләкләнүе, дәрәҗәле исемнәр алуы, Әзербайҗан ССР Верховный Советына инде ничәнче мәртәбә депутат итеп сайлануы һәм, ниһаять, Казандагы юбилейга Әзербайҗан республикасының вәкиле итеп җибәрелүе дә шул хакта сөйли. Бакуда да бит ул үзен туган халкыннан аерым санамый — Әзербайҗан сәнгатенә хезмәт итүче якташлары Фатыйма Кадри, Суфыя Басыйрзадәләргә булдыра алганча булыша, Баку татар профессиональ театрының таянычы була, үзешчәннәргә бердәмлексез ярдәм итеп килә.

Берничә сәгать буе самолетта әңгәмә корып барганда Бәдәлбәйли Мәрзия ханымның татар культурасы дөньясын яхшы белүен тоеп, тагын бер кат гаҗәпләнде. Рәшит Ваһапов, Илһам Шакировлардан алып драма артистларына кадәр, язучы һәм композиторларга кадәр бик күп эшлекләрне атап сөйләшә Даутова.

1929 елда сәяхәткә чыккан татар язучылары белән Бакуда танышу, Ш. Камал, һ. Такташ, К. Тинчурин, С. Сәйдәшев, Ш. Шамильскийларне кунак иткәндә дуслашып калу нәтиҗәсеме бу? Әллә тагын да электәнрәк килгән бәйләнешләре булганмы? Казанда исә ул бу белемнәрен тагын да тирәнәйтергә, татар китаплары, патефон тәлинкәләрен җыярга ашыкты. Театр әһелләрен ике милли сәнгать арасындагы дуслыкны ныгытырга, репертуар алмашырга, алмаш гастрольләр ясарга өндәде.

Саубуллашканда СССР халык артисты Шәмси Бәдәлбәйли миңа:

— Мәрзия ханымның кызы Фирәнгизә Шәрифева да, сәнгать дөньясына ышанычлы рәвештә атлап кереп, Әзербайҗан халык артисткасы булып үсте. Аның үсешенә үземнең дә булыша алуым белән горурланам,— диде.

Мәрзия ханым Парнисның «Афродита утравы» пьесасын сәхнәләштергәндә соңгы ролен башкара. Ул монда кызы белән бергә уйный. Фирәнгизә үзе бу хакта:

— Ул спектакль мәңгегә хәтеремдә калды,— дип искә ала.— Мин кыз ролен башкарырга тиеш идем. Беренче күренештә әни белән очраштык. Ул күзләрен тутырып карап, кырыс кына итеп миңа: «Әниеңне чакыр!»— дип эндәште. Мин инде бу вакытта Әзербайҗанның атказанган артисткасы, сәхнәдә ундүртенче ел уйный идем. Әмма академия драма театры сәхнәсенә беренче тапкыр чыгуым. Әнинең зур күзләреннән бүтән вакытта да курка идем. Монда ул шул кадәр кырыс карап, җилле эндәшкәч, бөтенләй югалып калдым. Пауза озакка китте. Минем хәлемне сизеп алгач, әни мизансценаны үзгәртергә мәҗбүр булды. Баскычтан яныма рак төште дә яңадан: «Әниеңне чакыр!»— дип мөлаем кабатлады. Шунда гына мин һушыма килеп: «Авырый»,— дип әйтә алдым.

М. Әзизбәков исемендәге Әзербайҗан академия драма театрыннан ерак түгел бер мәйданда һәйкәл бар. Чадра салучы хатын. Күккә ашып торган бу сында М. Даутова гәүдәләндергән Севилне чалымнау кыен түгел. Мәрзия ханым иҗаты халык йөрәгенә шул кадәр тирән сеңгән, атаклы артистканың Севиле һәйкәлчегә шул кадәр илһам биргән ки, азатлык символы итеп әллә нинди шаккатыргыч формалар эзләүнең хаҗәте дә калмаган.

Һәйкәл итәгендәге чәчәкләр Мәрзия ханым истәлегенә куелган төсле. Мәйдандагы төрле авазлар арасыннан атаклы артистканың замандашлары эндәшүен ишеткәндәй буласың.

— Мәрзия сәхнәдәге рухи тормышы — халәте белән бөтен тамаша залына тәэсир итә торган гаҗәеп бер сәләткә ия,— ди драматург Җәфәр Җаббарлы.

— Бакуга килгәч Мәрзия апа мине үзе чакыртып алды. Әстерхан, татар культурасы, Бакудагы якташларыбыз турында рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык. Шунда мин аның үз тирәсендә һәрвакыт балачагыннан ук күнеккән тел, сәнгать, тормыш үзенчәлеген югалтмаска тырышуын тоеп алдым һәм аны үзем элегрәк эзләп тапмавыма пошындым,— ди язучы Габдрахман Минский.

— Мин дөньяның һәр кыйтгасында Отелло ролен күп кенә Дездемоналар белән бергә башкардым. Парижда унҗиде кич тоташтан Отеллоны уйнадым. Тик Мәрзия кебек сизгер, мәгънәле гәүдәләндергән Дездемонаны әз күрдем,— ди СССР халык артисты Ваһрам Папазян.

— Урамда татарча сөйләшүчеләрне очратса, туктап исәнләшә, «сезнең белән бер-ике сүз алышсам, җаным рәхәтләнә»,— дия торган булган Мәрзия. Хәле авырайгач, «татар пәрәмәче ашыйсым килә, пешерегез әле!» дип үтенгән,— ди Әстерханның мәгариф ветераны Кәрим Каниев.

— Мәрзия Даутова әзербайҗан сәхнәсенең горурлыгы. Искиткеч трагик диапазонга, кайнар дәрткә, зур сәхнә хосусиятләренә ия бу актриса тамашачылар күңелендә уелып калган образларның бөтен бер галереясен иҗат итте,— ди режиссер, Әзербайҗан халык артисты Александр Александрович Туганов.

— Мәрзия ханым инде безнең арабызда булмаса да, аның якты образы халык күңелендә яши. Аның исемен йөртүче Мингәчевир Әзербайҗан дәүләт театры — сөекле артисткабызга тиң һәйкәл,— диләр якташыбыз иҗатына табынучылар...

Колакта яңгыраган авазлар көчәйгәннән-көчәя, аларга Баку белән Әстерхан арасында чайкалучы Хәзәр диңгезе дулкыннары да куәт өстәгәндәй тоела. Әйтерсең дулкыннар да ике халыкның сөеклесенә әйләнгән Тияк кызын сагынып шаулыйлар.

Ж. Миндубаев,
Ж. Трофимов

# ЯКТЫЛЫККА ТАБА

*В. И. Ленинның атасы — Илья Николаевич Ульянов турындагы яңа документаль повестьтан бер өзек тәкъдим итәбез. Анда Илья Николаевичның Казан университетында укыган чагы тасвирлана. Педагог һәм бөек мәгърифәтче И. Н. Ульяновның Казан чоры моңарчы бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Повестьта Казан университетының Россиядәге фән үсешендә үткән гасыр урталарында тоткан урыны, анда укыткан галимнәр турында да мәгълүматлар күп.*

## Үз хисабына укучы студент

Илья Николаевичның биш еллык Казан чорын чал тарих вакыт пәрдәсе белән каплаган. Дөрес, ул пәрдә аша бәхәсләшү авазлары ишетелгәли, тонык кына шәүләләр күренгәләп китә. Тарихи документлар белән бәйләнешкә керә икән, пәрдәнең авыр-калын тукымасы, әйтерсең лә, нечкәреп, үтә күренмәле булып кала: актерларга тамаша залын күзәтү өчен театр пәрдәләрендә махсус калдырылган тәрәзәчекләр кебек. Ләкин шул кечкенә тәрәзәчекләр аша, киресенчә, сәхнәгә карасаң, андагы вакыйгаларның тере шаһитына әйләнәсең төсле. Мондый мөмкинлекне безнең чорларга килеп җиткән документлар бирә.

Ләкин икенче юл да бар. Узган гасырдагы Казан университеты — ватаныбыз фәне тарихында әһәмиятле урын били. Анда укыган һәм укыткан күп кешеләрнең данлыклы исемнәре хәзер һәркемгә билгеле. Университет һәм аның кешеләре турында сакланган истәлекләр, хатирәләр, язмалар күп. Аларны укып, өйрәнеп, чагыштырып карасаң, студент Илья Ульянов тормышында күп нәрсәне ачыкларга мөмкин.

Бу мәгълүматлар күзгеләр системасын хәтерләтә. Алар ярдәмендә безнең туры караш үтеп керә алмаган төбәкләргә дә күз төшереп була...

Я, нәрсә бар соң ул пәрдә артында?

Астрахань гимназиясен тәмамлаган Ульянов 1850 нче елның 5 августында Казан университеты ректоры канцеляриясенә кыюсыз гына килеп керә. Аның кулында бөтен рәвешләрен китереп язылган гариза.

«Казан Император университетының математика факультетында фәннәр курсы тыңлап, тулы белем алу теләге белән, университетка керү өчен билгеләнгән сынауларны тапшыргач, Сез Галиҗәнабларның мине үз хисабына укучы студентлар арасына кабул итүен үтенәм».

Мондый гаризалар ректорда алтмыш ике. Университетка Идел буе һәм Урал гимназияләрен тәмамлаучылар гына түгел, ерак-ераклардан килгән абитуриентлар да керергә тели. Хәтта Иркутск һәм Тобол губерналарыннан. Искитәсе дә юк, чөнки университет империянең көнчыгышында. Бөтен Идел буена, Уралга, Себергә бердәнбер. Казанга булачак студентлар әнә шул иксез-чиксез киңлекләрдән җыелалар да инде.

Ректор — танылган астроном һәм сәяхәтче И. М. Симонов И. Н. Ульянов гаризасын зур кызыксыну белән карый. Моның үз сәбәбе бар: Симонов үзе дә Астраханьнан, шунда яшәгән, шул ук гимназияне тәмамлаган. Ул белә: данлыклы университетка имтиханнар тапшырырга Астрахань яшьләре бик сирәк батырчылык итәләр. Ягез, сез анда, Астраханьда, ничек укыдыгыз икән, галиҗәнаб Ульянов?..

Барыннан да бигрәк аны абитуриентның белеме кызыксындыра. Ләкин канцелярия эшләрен алып баручыга башкасы мөһим. Барлык кәгазьләре дә тәртиптәме, дөрес төзелгән, теркәлгәнме? Һәм уяу канцелярист тәртипсезлекне бик тиз таба: Астрахань мещаннар җәмгыяте тарафыннан бирелгән таныклыкта И. Н. Ульянов җәмгыятьтән университетны тәмамлаганга кадәр түгел, ә солдатка алынучы катламнарның чираттагы санын алганчы гына җибәрелүе турында әйтелә. Ә бу исә кабул итү имтиханнарына кертмәскә дию белән бер.

Бу турыда ректорга хәбәр ителә. Моның Астрахань шәһәр думасында документлар тутыруга җиңел карау гына түгеллеген ректор аңлый, билгеле. Мещанны укырга җибәрмәүдә мәгънә бар, чөнки аның урынына шобага буенча кемдер солдатка барырга тиеш, өстәвенә тагын аның өчен җан башыннан билгеләнә торган салымны да түләргә кирәк.— Аны дүрт елга җибәрерсең дә, ә ул укый алмаса? Куып тот син аннары дала җилен? Юк инде, бер елга гына җибәрергә кирәк, киләсе сан алуга кадәр генә. Араларны тоташтырган җеп күпме кыска булса, ул шулхәтле ышанычлырак.

Әмма җәмгыять нинди генә хәйлә кормасын, ә законны барыбер үтәргә кирәк. Шуңа күрә Астраханьга «киләчәктә уку йортларына керергә теләүче яшьләргә документлар әзерләгәндә билгеле тәртипләрдән чыгып эш итү зарури» дигән язу җибәрелә.

Ә Ульянов белән ни эшләргә соң? Теләсә кая китеп, документларын тәртипкә кертеп килсенме? Ректорның моңа тулы хокукы бар. Тик Ульянов гаризасына башка төрлерәк резолюция куела: «Юлның үтә ераклыгын искә алып, Астрахань думасыннан җибәрү турында рөхсәт таныклыгы сорарга».

Шулай итеп, Илья Ульяновка университетка кабул итү имтиханнарын тапшыру мөмкинлеге бирелә. Әле ике генә ай элек гимназиядә сыналган предметлардан белеме яңадан тикшерелә. Ничек кенә тикшерелә әле! Ректор үзе җитәкләгән башкарма комитет эшне бик катгый тота. Барысының да диярлек баллары гимназиядә куелган билгеләрдән түбәнрәк. Ульянов белән дә шундый ук хәл. Әмма тапшырылган уч имтихан билгеләреннән уртача балл — дүрт. Башкаларныкына караганда артыграк. Һәм 31 нче августта университет Советы, билгеләнгән барлык таләпләргә туры килгән буларак, Ульяновны студентлар сафына кабул итәргә дигән карар чыгара.

Әмма шатланырга иртәрәк икән әле. Ульянов алдында яңа каршылык — җәмгыятьтән рөхсәт кәгазе әле дә булса килеп җитмәгән. Физика-математика факультеты үтенече белән ректор аңа лекцияләргә йөрергә рөхсәт бирә, тик ирекле тыңлаучы буларак кына. Шулай итеп, Ульянов, рөхсәт кәгазе килгәнчегә кадәр, студент булып шартлы рәвештә генә йөрергә мәҗбүр.

Шундый билгесезлек хәлендә озак йөри Илья Николаевич. Ә Астрахань чиновникларының ашыгырга уйларында да юк. Октябрь, ноябрь, декабрь да узып китә. Бергә имтихан тапшырган бүтәннәрнең бер кайгылары да юк. Аның хәле — билгесезлек. Вакыт исә уза тора.

Яшьтәшләре инде рәхәтләнеп Яңа ел каршылыйлар — ә аңа нинди шатлык? Әллә, чыннан да, әйберләрне җыеп, Астраханьга кире кайтып китәргәме соң? Январь да узып китте. Инде соңгы өмет өзелде дигәндә генә кирәкле документ килеп төшә. Бары 1851 елның 8 февралендә генә университет идарәсе уку округы попечителенең Ульяновны шушы уку елын исәпкә кертеп, студент итеп раславын сорый.

Менә хәзер куансак та була инде. Әмма Илья Николаевичка мещан катламының хокуксызлыгын күп сизәдерәчәкләр әле. Әле 1855 елга кадәр абыйсы Василий аның өчен «җәмгыять»кә салым түләп торыр, аңа егерме биш елга солдатка алы-

ну куркынычы озак вакыт янаячак. Ел саен ул, Казан император университеты студентлары өчен булдырылган «Кагыйдә»ләрнең егерме сигезенче параграфы таләп иткәнчә, «Казанда иркле рәвештә яшәү өчен рөхсәт» кәгазен вакытында тапшырырга тиеш. Әгәр дә вакытында өлгерми икән, ул чагында Ульянов университеттан чыгарылачак...

Ул «мещан катламыннан» дигән тамганы биш ел буе йөртә. Астрахань казна палатасы мещан катламыннан аны 1854 нче елның 5 ноябрендә университетны тәмамлап, кандидатлык диссертациясе яклагач кына чыгара. Аның шул катламнан булуы турында кандидатлык дипломында да, башка документларында да язарга онытмыйлар. Ул елларда Россиядә кемнең кем булуы бик төгәл билгеләнә.

1850 нче елның көзендә — Казан Император университетына укырга керү шатлыгы белән канатланган көннәрдә бу турыда бик аз уйлый ул. Яшерен генә булса да, чиксез горурлана. Иң әһәмиятлесе — теләге тормышка ашты: ул хәзер студент.

## Казан Император университетындагы гореф-гадәтләр

Россия университетлары эшчәнлеген патша һәм аның ялчылары нык күзәтү астында тота. Император әмере белән эшләнгән 1828 һәм 1835 еллардагы Уставларда монархиянең көчле изүе тулысы белән чагылыш тапкан. Уку йортларында фән түгел, ә патша тарафыннан билгеләнгән чиновниклар өстенлек итә. Белемгә омтылу урынына яшьләр аңында «православие, самодержавие» кебек төшенчәләрне күбрәк расларга тырышалар.

Казарма тәртипләре университетларда бик тырышып һәм төрле юллар белән урнаштырыла. Властьлар үз хисабына укучы студентларга аеруча шикләнеп карый. Казна хисабына укучылар көне буе инспектор һәм надзирательләр күз алдында булсалар, ә үз хисабына укучылар исә читтә яшиләр, үзләренә-үзләре хуҗа. Өстәвенә аларның күбесе разночинецлар. Университетларны андыйлардан арындырсаң яхшырак булмасмы? «Югары власть иясе»нең дә аларны һәр уку йортының барлык факультетларына 300 дән дә артык кабул итмәскә дигән әмере бар. Мещан һәм крестьяннар катламыннан чыгучыларга исә стипендия бөтенләй билгеләнми, ә уку өчен түләү тагын да арта. «Алла законнарын» өйрәнүгә вакыт күбрәк бирелә, чөнки ул — «төрле файдалы укуның бердәнбер төпле нигезе».

И. Н. Ульянов университетка керергә бер ел кала, ректор һәм деканнарның котын алып, алардан программадан сен-симончылар, фурьечылар, социалистлар һәм коммунистларның алдынгы идеяләрен таратуда ярдәм итәрдәй бар нәрсәне дә уку программасыннан алып атуны таләп итәләр. Тәртип булгач, тәртип булсын инде ул! Әнә шулай итеп, политик фәннәр белән үзара бәйләнештә булган статистика курслары кыскартыла. Философия белән якынайта дип, логиканы да укытмый башлыйлар. Һәм, ниһаять, философия кафедралары бөтенләй юкка чыга.

Әйе, 1850 елга университетның элеккеге автономиясенең эзе дә калмый. Элек ректор университет Советы тарафыннан дүрт елга сайланып куела торган булса, хәзер исә аны халык мәгарифе министры чикләнмәгән вакытка үзе билгели.

Баш администратор, тәртип һәм дисциплинаның тугры сакчысы, студентлар язмышын үз кулында тотучы кеше — инспектор. Ул ректорга түгел, ә уку округы попечителе һәм аның урынбасарына гына буйсына. Яшел тукымадан тегелгән мундир, чалбар, жилетлы һәм ике чалбарлы форма, көрән материядән тегелгән шинель, өчпочмаклы эшләпә, кыска итекләр, калошлар, биш пар ярым оек, портупея, перчатка, бер пар эчке күлмәк, ике кульяулык өчен тегүчегә 64 сум 61 тиен көмеш түләп, тиешле форма кигәндә университетларда тормыш әнә шундый була.

Һәм менә барлык студентлар да округ попечителе — генерал-майор Владимир Порфирьевич Молоствов белән танышу өчен университетның мәһабәт актлар залында җыелалар.

Генерал турында Казанда күп нәрсә билгеле: округ попечителе булганчы, ул Урал казак гаскәрләренең наказлы атаманы вазифасын башкара. Укымышлы, әдәбиятны бик ярата икән. Силезиядә яшәгәндә Гете белән очрашкан. Мәрхәмәтле, гадәттән тыш тәркау. Яше дә шактый. Студентларга мөнәсәбәте дә ярыйсы гына икән.

Студентлар алдында ул сүзне кыска тота: фәннәрне тырышып үзләштерергә чакыра, ни әйтсәң дә, шпага, мундир һәм өч кырлы эшләпә кигәч, алар инде гади кешеләр генә түгел, әзме-күпме чиновниклар да.

Аннары университет инспекторы Владимир Иванович Ланге сүз ала. Элек рота командиры булган бу кешенең беренче сүзләреннән үк студентлар арасында ярымхәрби дисциплина урнаштыру теләге аңлашыла.

— Минем өчен бигрәк,— ди ул бөегып калган студентларны бер кат күздән кичереп,— сезнең югары властьларга зур хөрмәт күрсәтүегез һәм начальниклар белән тиешенчә исәнләшүегез зарур. Попечитель, ректор, губернатор, генераллар һәм инспектор, ягъни минем белән очрашканда кулны эшләпә читенә куеп исәнләшергә. Алар белән әңгәмә вакытында баш киеме салынган һәм уң кулда булырга тиеш. Урамга шпагасыз чыгарга беркемнең дә хакы юк.

Йөзләрдә киеренкелек, бер генә селкенүче дә күренми. Ланге шул ук тонда кагыйдәләрне санавын дәвам итә. Театрга бары ата-аналар белән генә барып, тик ложеда яисә кресլоларда гына утырырга. Югары ярусларга утыру, кул чабу яки артистларның чыгышын башкача хуплау тыела. Ә инде трактир, ресторан, сыраханә һәм бильярд уйный торган җирләргә йөрү — күз алдына китермәслек эш.

Университетта укучы студентларның һәр адымы күз алдында. Үтәүләре авыруча зарури булган яки, киресенчә, кагыйдәгә сыймаган бар нәрсә дә уйланган кебек. Ял көннәрендә, бәйрәмнәр алдыннан чиркәүгә йөрү каралган, дини йолалар һичшиксез үтәлергә тиеш. Лекцияләрдә билгеләнгән урыннарга гына утырырга. Һәм менә тагын уку турында:

— Авыру сәбәпле ярты еллык яки еллык сынауларны тапшырмаганнар имтиханнарга округ попечителе яисә университет Советы рөхсәте белән, билгеләнгән вакытта гына кертеләләр. Бер курста ике елдан артык уку рөхсәт ителми.

Кагыйдәләрнең иге-чиге юк. Нинди өс киемен кайчан һәм ничек киярга, тантаналы җыелышларда үзеңне ничек тотарга — аларда барысы турында да әйтелгән. Хәтта озын чәч һәм бакенбард-мыек йөртү дә тыела. Зонтик тоту яки сигарет тарту рөхсәт ителми. Күбәү бергә җыелып ял итү, шәһәрдә йөрү дә яхшы түгел, әнә шуңа күрә үтә тәртипле һәм күндәм булырга кирәк.

Аз гына вакытка булса да шәһәрдән читкә чыгу бары тик бәйрәм вакытларында һәм инспектор рөхсәте белән генә мөмкин. Үз хисабына укучы студентлар исә берәр җиргә барулары турында фатир хуҗасына язу калдырырга, ә кичке уннан соң барысы да өйләрендә булырга тиешләр. Әгәр нинди дә сәбәп белән тоткарланалар икән, язуда бу турыда аңлатылган булсын.

Уф! Әле ул гына да түгел. Казна стипендиясе алып, университет бинасында яшәүчеләргә инспектор рөхсәтеннән башка кунаклар кабул итәргә яки кая да булса барырга, самавар, шырпы, тарту әйберләре саклау тыела. Ашханәгә билгеләнгән вакытта йөрергә һәм билгеле бер урынга гына утырырга. Соңга калучылар анда бөтенләй кертелми.

Ә тәртип бозучылар өчен җәзалар нинди соң? Гыйбадәт кылуда яки лекцияләрдә булмаучылар аерым исемлеккә кертелеп, беренче очракта тәртиптән, икенче очракта тәртип һәм өлгерештә балларының суммасыннан беренче тапкыр ярты, икенчесендә бер, өченчесендә ике, дүртенчесендә дүрт балл алына. Ел дәвамында суммасында бер баллдан да азрак калучы турында попечительгә хәбәр ителеп, әлеге студент сынауларга кертелми. Тәртип бозучыларны тагын да катырак җәзалар көтә: беренче кабат шелтә белдерелеп, исем-фамилиясе аерым китапка теркәлә. Икенчесендә шундый ук шелтә һәм кулга алу, өченчесендә инде җитәкчеләрнең әмерен үтәмәүче һәм кагыйдәләрне тупас бозучы буларак, университеттан бөтенләй куыла.

Күзәтеп тору эше яхшы куелган. Инспектор Лангенның дүрт ярдәмчесе бар: Иванов, Холмогоров, Львов, Зоммер. Өчесе ярыйсы гына кешеләр кебек. Ә менә

Зоммер усал педант, куркак әләкче — студентларның бар тормышын агулап, каннарына тоз сала...

Менә шул чор күренешләреннән берсе. 1853 елның 18 январенда медиклар П. Дилекторский һәм В. Нагаев театрга барып «төшереп» баралар. Инспектор Ланге полиция сагы астында аларны университет карцерына озата. Ә аннары эчке эшләр министрлыгыннан бу ике дусны түбән медицина чинында хезмәткә җибәрүләрен сорый.

«Житәкче полицмейстерлар» тиз арада П. Дилекторскийны Пермь, ә В. Нагаевны Енисей губерналарына лекарь өйрәнчекләре итеп җибәреп, университетта укыган һәр ел өчен анда ике ел хезмәт үтәргә мәҗбүр итәләр. Шулай итеп, дүртенче курста укыган Нагаев сигез ел хезмәт итәргә яисә казна хисабына 826 сум 19,5 тиен күләмендә бурычын кайтарырга тиеш.

Казан университетының ул чорында гореф-гадәтләре әнә шулай кыргый була. Хәер, университет инспекциясенең кырыслыгына карамастан, югары катламнардан чыккан студентлар даими рәвештә күңел ачалар. Берәүләрдә типтерәләр, икенчеләрендә эчү мәҗлесләре, баллар оештыралар, өченчеләре исә спектакльләргә, ат чабышларына йөри. Профессор Н. П. Загоскин әйтүенчә, университетка ни өчен килгәннәрен белмәгән андый кешеләр бигрәк тә юридик факультетта күп була.

Казан университетының елъязмачысы сөйләвенчә, «скандалчылар» һәм «аристократларга» карамаган студентларның тагын өченче төрлесе дә бар. Болары — университетка фән хакына килүчеләр, фәннәрне тырышып үзләштерүчеләр. Ләкин, әйтергә кирәк, бу төр студентлар саны азчылыкны тәшкил итә.

Илья Николаевич шулар арасында булмыйча кайда булсын?! Тарту яки кәеф кору дигән нәрсә аның холкында бөтенләй юк. Хәер, моңа аның акчасы да җитмәс иде. Абыйсы Василий җибәргән акчага гына әллә кая бара алмыйсың. Төрле йортларда дәресләр бирү акча табу өчен уңай булса да, ул фән белән шөгыльләнәсе алтындай вакытны күп ала. Әмма максатчан Ульянов фән биеклекләрен яулауга искиткеч тырышлык куя. Кемдер: «Иң яхшы китаплар чардактагы кечкенә генә бүлмәләрдә язылган»,— дигән бит. Студент Ульянов андый китаплар язмаган. Ул аларны укыган гына. Һәм, әйтергә кирәк, искиткеч күп укыган. Хәер, аның университеттагы дүрт елын зур бер китап дип әйтергә була. Белем китабы дип. Илья Николаевич тырышып укый, күп өйрәнә. Ә Казан университетында үрнәк алырдай кешеләр, укыр, өйрәнер нәрсәләр күп була.

## «Сихри лампа яктысы»

1853 елда Казан университетының ишек алдында кичләрен моңарчы күз күрмәгән искиткеч якты лампа кабызалар икән,— дигән хәбәр тарала. Халык, кичләрен бу сихри лампаның кабынуын көтеп, университет янындагы калкулыкка җыела.

Һәм алар яналар да. Аеруча физика корпусы түбәсендәге лампа комета кебек якты яна. Сөйләүләренә караганда, яңа яктырткычлар электр дугасыннан кабына икән.

Күп вакыт электр дугаларыннан янган лампалар янында бер ук кешене күрәләр. Ул ике кара таяк арасындагы ялкынны күзәтеп озак басып тора. Бу — университетны сихри электр лампалары белән яктыртырга уйлаган физика профессоры А. Савельев үзе.

Талантлы галим, ялкынлы лектор, сәләтле педагог университетта уку дәверендә студент Ульяновның остазларыннан берсе була. Аның лекцияләрен түземсезлек белән көтәләр. Дәресләрдә Савельев теорияне тәҗрибәләр белән бәйләп, тегәл математик законнарга буйсындыра. Ул тынгысыз кеше була. 21 яшендә Петербург университетын тәмамлагач, фәннәр академиясенең Төньяк поляр экспедициясендә катнашып, анда географик координатларны тегәл исәпләү һәм магнит күзәтү эшләре алып бара. Шуның өчен Рус географик җәмгыятенең действитель-

ный члены итеп сайлана. Казанда исә Александр Степанович физика кабинетын фәнни-тикшеренү лабораториясе дәрәҗәсенә күтәреп, аны тулысынча яңабаштан җиһазландыра. Һәм шунда ялкынланып эшли. Петербург, Мәскәү һәм илнең башка университетларында физика кабинетлары әле яңа гына булдырыла башласа, Казанда исә, А. Савельевның тырышлыгы нәтиҗәсе буларак, инде төрле-төрле тәҗрибәләр, эзләнүләр алып барыла. Шул исәптән электр яктылыгы өлкәсендә дә. Профессор фән белән берүзе генә шөгыльләнеп калмый, ә студентларда да әйләнә-тирәнең серләренә төшенүдә зур кызыксыну уята. Россия һәм Европаның иң яхшы университетларын уннарча елларга узып китеп, ул университет тарихында беренче тапкыр үзенең студентлары өчен физикадан лаборатор дәресләр керткәндә, Илья Николаевич өченче курста гына укый әле. Билгеле, Ульянов һәм аның курсташлары, үзләренең укытучылары белән чиксез горурланып, тәҗрибә ясаучы күнекмәләренә тырышып өйрәнәләр. Соңрак укучыларына физикадан төрле тәҗрибәләр күрсәткәндә укытучы Ульянов күп тапкырлар үзенең профессорын җылы сүзләр белән искә алыр әле. Физика һәм физик география кафедрасы мөдире, Петербург университетында Х. Ленцның танылган укучыларыннан берсе булган Александр Степанович Савельевның студент Илья Ульяновның киләчәк тормышында нинди зур роль уйнавын аңлатып бетерүе кыен.

Профессор А. С. Савельев Илья Николаевичтан кабул итү имтиханнары алган, аннары физика һәм географиядән лекцияләр укыган. Н. И. Лобачевскийның «Һәрбер галим соңгы курс студентларына шефлык итсен» дигән алдынгы карашына җавап итеп, ул студент Ульяновны төрле фәнни проблемалар, бигрәк тә табигать һәм һава торышын өйрәнүгә тарта. Илья Николаевич университет обсерваториясендә һава торышын күзәтүләрдә профессорның якын ярдәмчесенә әйләнә. Губерна метеостанцияләрен тикшерү өчен дә еш кына бергәләп юлга чыгалар.

Үзенең фәнни җитәкчесе ярдәме белән Илья Николаевич физиканы (ул вакытта физиканың бер кисәге буларак өйрәнелә) шулкадәр яхшы үзләштерә ки, ул аның иң яраткан фәненә әйләнә. Соңыннан, төрле урта уку йортларында математика һәм табигать белеме белән бергә, аның физикадан укыган лекцияләре дә зур уңыш казаныр.

Әйе, Илья Николаевичка талантлы, сәләтле остазлар һәм укытучылар очрап кына тора. Көнчыгыштагы бердәнбер һәм иң өлкән уку йортларының берсе булган Казан университетын ябарга теләгән надан фанатик «Магницкий чоры»н кичергән фән сарае «Лобачевский эрасы»нда рухи күтәрелеш кичерә. Николай Ивановичның якты гение университет кафедралары һәм аудиторияләрендәге караңгылыкны куып тарата, аның фән үсешенә куйган көчләре даими, дәртле һәм максатчан була. Хәтта Магницкий да бу искиткеч кешенең күпкырлы сәләте белән хисаплашмыйча булдыра алмый.

Илья Николаевичка Н. И. Лобачевскийның лекцияләрен тыңларга туры килми, чөнки ул, округ попечителе ярдәмчесе буларак, бары тантаналы җыелышларда гына күренә. Ләкин аның күп еллык укытуы, унтугыз ел буена ректор булып эшләве берничә буын студентларына уңай йогынты ясыйлар.

Китапханә бинасы, физика кабинеты, химия лабораториясе «Механика йорты», астрономия һәм магнит обсерваторияләре, анатомия театры, клиника һәм ботаника бакчасының оранжереясе кебек үк мәһабәт булган төп корпусның да яхшы сыйфатлы итеп, фән һәм техниканың өр-яңа казанышларын искә алып, Н. И. Лобачевский җитәкчелегендә төзелүе һәр студентка мәгълүм.

«Халык мәгарифе министрлыгы журналы»нда 1849 нчы елда физик А. С. Савельев үз уку йортының материаль базасы турында: «Илдәге бер генә университет та Казан университеты кебек бай һәм яхшы дәреслекләр белән дан тотмый»,— дип яза. Ә профессор И. А. Кнорр исә мондагы физика кабинетының Европадагы иң яхшы кабинетлардан да өстен торып, бары француз коллегиясе (Париж) һәм Вена университетыныкыннан гына бераз калышуын әйтә.

Казан Европа белән Азия арасына урнашкан. Шуны искә алып, Н. И. Лобачевский катгый рәвештә тарих-филология факультетында көнчыгыш телләре бүлеге булдырырга тырыша. Бер көнчыгыш кафедрасы урынына барысы алты кафедра эштырыла: гарәп-фарсы, гарәп-төрки, монгол, санскрит, кытай-манчжур һәм әр-

мән кафедралары. Шулай итеп, көнчыгыш кафедрасы әкренләп күп кенә көнчыгыш телләрен берләштергән тулы институт булып, университетның горурлыгы сanала.

Ректор инициативасы белән башта Казанда, аннан соң искиткеч зур уку округының барлык губерна гимназияләрендә дә метеорология күзәтүләре, шулай ук этнографик тикшеренүләр, геологик эзләнүләр, крайның табигатен өйрәнүләр башланып китә.

Китап-журналлар бастыру эше дә сизелерлек җанлана. Казан университетының Н. И. Лобачевский җитәкчелегендә чыга торган гыйльми язмалары фәнни журналларның иң яхшыларыннан берсенә әверелә.

Лобачевский талантларны эзләп табу, аларны тәрбияләп үстерүгә күп көч куя. Аны китап кибете приказчигы Иосиф Больцанининың математикага сәләте нык кызыксындыра. Һәм ул аңа дәресләр бирә. Нәтиҗәдә И. А. Больцани физика профессоры дәрәҗәсенә күтәрелә. Лобачевский кулы астында Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров бөтен дөньяга танылган бөек галимнәр булып үсәләр. Көнчыгышны өйрәнүчеләр В. П. Васильев һәм И. Н. Березин, технолог М. Я. Киттары, филолог И. Н. Булич, математик һәм механик А. Ф. Попов, медиклар Н. А. Скандовский, Д. И. Протопопов һәм башка зур галимнәр аның шәкертләре.

Илья Николаевич укыган еллар — Казан университетының фәнни даны гөрләп чәчәк аткан чор. Ул елларда университет кафедраларында һәм лабораторияләрендә иң зур галимнәр, талантлы фән эшлеклеләренең тулы бер йолдызлыгы эшли һәм аларның чагылышы Илья Николаевичның эшендә, уй-фикерләрендә, тормышында һәрчак сизелә. «Чыннан да, бу искиткеч лампаның яктысы миңа Чулпаннан да зуррак йолдыз булып күренә»,— дип соклана профессор А. Савельев университетта янган электр дугасына карап. Илья Николаевич һәм аның яшьтәшләренә университет үзе дә нурларын төрле фән өлкәләренә чәчкән көчле яктырткыч кебек тоела.

Ул елларда әдәбият һәм математика факультетлары ныгый һәм алга китә. Математика факультетында, мәсәлән, А. Савельев белән тагын күп кенә танылган галимнәр эшли. Университет ректоры астроном И. М. Симонов үз вакытында Антарктиданы ачкан атаклы Ф. Беллинсгаузенның дөнья тирәли экспедициясендә астрономик күзәтүләр алып бара. Университетның барлык биналарын һәм Сембердәге атаклы Успенский соборын төзеп, академик дәрәҗәсенә күтәрелгән профессор И. Коринфский математика факультетында архитектура курсын укый. Бөек Лобачевскийның шәкерте танылган математик, профессор А. Ф. Поповны студентлар ачык һәм аңлаешлы сөйләве, тирән эрудициясе һәм педагоглык таланты өчен хөрмәт итәләр. «Аның фикере ачык, аңлатмалары төгәл, бер генә нәрсә дә күз уңыннан читтә калмаган, яңа эзләнүләр белән тулыландырылган,— дип искә ала студентларның берсе.— Шуңа күрә математика безгә җиңел бирелә. Моның белән без А. Ф. Поповка бурычлы». Чыннан да, кырык яшьлек профессор лекция укыган аудиторияләрдә һәрвакыт тирән тынлык урнашу бер дә гаҗәп түгел. Физмат факультеты деканы профессор П. Котельников, математика адъюнкты М. Мельников, химик К. Клаус яшьләрнең таләпчән һәм белемле остазлары булалар. Университетта укуның беренче көннәреннән ук Илья Николаевич Александр Михайлович Бутлеров лекцияләрен тыңлый. Химик төзелеш теориясен чыгарган бөек галим студентларга органик булмаган химиядән дәресләр бирә.

Яшь Ульяновка белем дөньясына юлны белемле, үз эшләренә бирелгән, максатчан кешеләр ача. Аларның күбесе, көчләреннән килгәнчә, гениаль коллегалары Лобачевский принципларына таянып эш итәргә тырышалар. Бөек галим: «Тәрбия кешегә хас булган дәртне, теләкләрне бетермәскә тиеш. Бөтен нәрсәнең дә үз урынында калуы зарури, юкса аның табигатен бозып, киләчәген сызып атачакбыз. Дәрте, илһамы көчле булган саен, кешенең җәмгыятькә файдасы күбрәк»,— дигән сүзләрне еш кабатлый.

Әйе, Казан университеты профессорлары үзләренең укучыларында белемгә омтылу, кызыксыну, Ватанга һәм фәнгә хезмәт итү теләге кебек кешелекле сыйфатлар үстерергә һәм ныгытырга тырышалар. Рус гыйльми фикер тарихының иң гүзәл битләре нәкъ менә Казан университеты галимнәре тарафыннан языла. Лоба-

чевскийның гениаль «Геометриянең яңа нигезләре». Органик синтезга нигез салган бөек «Зинин реакциясе». Аның шәкерте А. М. Бутлеров тикшереп өйрәнгән матдәнең химик төзелеше теориясе. Астроном М. А. Ковальскийның Галактиканың закончалыклы хәрәкәт итүе турындагы математик идеяләре. Зоолог Эверсманның Урта Азияне өйрәнүе. Уннарча бөек фәнни ачышлар, кызыклы зур шәхесләр... Әйе, узган гасырның урталарында прогресс һәм фән байрагын Казан университеты югары тота.

Ләкин хәлнең икенче ягы да бар әле. Университетта коры формализм, искелеккә ябышып яту, рәхимсез рәвештә буйсындыру рухы да яши. Моны бередә башка кешеләр урнаштыра. Алар фәнгә түгел, ә һич кая ашыкмаучан, үз-үзе белән канәгать булган мәгънәсез җәмгыятькә, самодержавиегә хезмәт итәләр.

1848 елгы революцион чыгышлардан соң царизмның уку йортларына яңа репрессияләр яудыруы билгеле. Патшаның «Аңлатмаска, ә боерык бирергә»,— дип шашынып кычкыруын, Николай 1 нең «Алла законы барлык файдалы тәгълиматләрнең бердәнбер ныклы нигезе» дигән тәкъбирен аның ялчылары бик тырышып гамәлгә ашыралар. Инде әйтелгәнчә, И. Н. Ульянов Казан университетына укырга кергән 1850 елны барча югары уку йортларында философия тыела. Бу урта гасырларга хас кыргыйлыкны нигезләп, мәгариф министры П. А. Ширинский-Шахматов:

— Германия галимнәре тарафыннан бу фәннең яшәп килгән законнарга каршы юнәлештә үстерелүе, аларның хикмәтле фәлсәфә сатулары һәм әр-яңа философик системалары философияне Россия университетларында укытуны файдалы итми,— дип, чын мәгънәсендә «фәнни» аңлатма бирә.

Николай патшаны Германия революциясе бик нык куркуга төшерә. Аны ничек тә булса тынычландыру өчен, университетларда һичсүзсез буйсынучанлык һәм тәртип урнаштыра башлыйлар. Шуңа да карамастан, университет үз эшен эшли: яшь буынны тәрбияли, аңа төпле белем бирә.

## Рухи туганнар без...

Студент тормышы патша һәм аның ялчылары чикләгән кагыйдә рамкаларына гына сыешырга теләми, билгеле. Вакыт агышы шулкадәр тиз, кайчак аны кагыйдәдә каралган һәрбер пунктка кысып кертү гаять читен.

Көндез университетта дәресләр, ә кичләрен тоныкут ут яктысына күмелгән кечкенә генә студент «почмагында» лекцияләрнең язмаларын тәртипкә салып, чистага күчерергә кирәк.

Чөнки яхшы дәреслекләрнең булмавы, яки бик аз санда гына булуы аркасында барысын да укытучы сүзләреннән генә тотып калып була. Уку заллары яки шәхси китапханәләр шәһәрдә аз. Хәтта газета-журналлар да университет китапханәсенең профессорлар бүлегенә генә алдырыла. Студентлар бүлегендә исә, башлыча, кулланма әсбаплар һәм искергән дәреслекләр генә.

Инспектор Ланге һәм аның ярдәмчеләре студентларның барлык яшерен серләрен беләбез дип шапырыналар. Ләкин бу шапырыну юкка гына. Арзанлы тукымадан тегелгән мундир кигән, пөхтә итеп алдырылган чәчле, күрер күзгә «тәртипле» генә разночинец студентларның шимбә көнне кичләрен самавар янында яшерен җыелышлар оештыруы турында алар берни дә белми. Ни турында бәхәсләшә, уйлана, укый соң алар бередә? Нинди җырлар җырлый, нинди шигырьләр өйрәнә, цензура тарафыннан тыелган, шуңа күрә кулдан-кулга күчереп язылган Лермонтов, Рылеев, Плещеев, Некрасов шигырьләрен кемнәр һәм кайдан алып килә? Соңгысы — Некрасовны — студентлар бигрәк тә ярата, хөрмәт итә. Халыкның моң-зары, протесты турында җырлаучы бөек шагыйрьнең иҗаты белән Илья Николаевич Ульянов та нык кызыксына. «Илья Николаевичның яраткан шагыйре Некрасов,— дип искә ала Анна Ильинична.— Ул журналлардан аның күпчелек шигырьләрен күчереп ала да яттан өйрәнә, матур итеп сөйли иде».

Бу кадерле дәфтәрне ул Пензада һәм Нижний Новгородта да дәвам итә. Соңыннан ул дәфтәр Ульяновлар гаиләсендә ядкарь кебек саклана. 1848 елда профессор

Д. Мейерның университет кафедрасыннан кыю рәвештә крепостное правоның цивилизацияле җәмгыятьтә кыргыйлык һәм хурлык икәнлеге, аның һич кичектергесез бетерелергә тиешлеге турында әйтелгән сүзләрен төрле кичәләрдә студентлар бер-берсенә кат-кат сөйлиләр. Гаделсезлек һәм башбаштаклык, халыкның хокуксызлыгы, Россиянең киләчәк дәүләт төзелеше — студент киеме кигән яшьләрнең бәхәсләрендәге төп мәсьәләләр әнә шулар. А. И. Герценның Лондон шәһәрендәге «Ирекле рус типографиясе» бастырган һәм яшерен юллар белән Казанга кайтарылган «Крещенная собственность» дигән китабы кулдан кулга күчеп йөри. Студентлар аны башыннан ахырынача кат-кат укып чыгалар.

«Синең белән рухи туганнар без...» дип җырлый дуслар акрын гына һәм бу туганлык рухы, университетка тугрылык рухы Илья Николаевич һәм аның яшьтәшләренең күңелендәге изге теләкләр уяткан бу чын дуслыкны какшату теләгенә караганда көчлерәк була. Ул дуслык торган саен ныгый бара, үсә. Әледән-әле чыгып торган бәхәсләр киләчәк тормыш һәм шәхеснең андагы роле турында. Карашлар төрле. Ләкин күбесенең язмышы бер үк төрле — гимназияләрдә укытучы булу. Чөнки университетта Устав буенча барыннан да элек гимназияләр һәм башка урта уку йортлары өчен укытучылар әзерләнә. Ә икенчедән, дворян катламыннан булмаган фәкыйрь студент шул эштән башка кая бара алсын соң? Берәүләр моны саф яшьлек хыялларының җимерелүе дип кабул итәләр, ә икенчеләре исә укытучы хезмәтен дөньядагы иң изге эшләрнең берсе саныйлар. Күпләре инде төрле өйләрдә дәресләр биреп, әкренләп үзләренең педагогик сәләтләрен үстерәләр. Илья Николаевич та шулар арасында.

Педагогия мәсьәләләре психология һәм логика курсларында да бераз өйрәнелә. Ә 1856 елга инде кайбер университетларда педагогия кафедралары эшли башлый. Казанда да бу кафедраны Петербург педагогия институтын тәмамлаган Карл Ленстрем җитәкли. Яшь укытучы өченче, дүртенче курс студентларын педагогиканың өч бүлеге — тәрбия турындагы фән, укыту һәм педагогика тарихы белән таныштыра. Чорына күрә алдынгы карашлы Карл Ленстрем яшьләрне тәрбияләүдә уңышка төрле җәзалар, куып чыгарулар һәм башка шундый юллар белән түгел, ә ягымлы мөгамәлә, балаларны ярату, аларның холык-фигылен һәрьяклап өйрәнү, төрле җитешсезлекләрне вакытында кисәтү — кыскасы, аларның аңында гаделлек тә тәрбияләгәндә генә ирешергә мөмкин дип саный. Шуңа да карамастан, К. Ленстрем төзегән практик дәресләр программасында кимчелекләр дә шактый була. Анда язма күнегүләр барча факультет студентлары өчен дә бер үк төрле. Шуңа күрә физика-математика факультеты деканы П. И. Котельников, үзенең коллегалары фикерен белдереп, 1852 елның маенда К. И. Ленстремга киләчәктә математика һәм башка төгәл фәннәр өйрәнүчеләр белән педагогика буенча филология факультетларында укучылар юнәлешендә түгел, ә, нигездә, үзләре укытасы фәннәргә кагылышлы рәвештәрәк шөгыльләнергә тәкъдим итә. Факультет советы карары нигезендә студентларның математика һәм физикадан педагогик практикалары белән шул фән профессорлары гына җитәкчелек итә.

Казан университеты галимнәре арасында күбесенең бик яхшы педагог булуларын да әйтеп үтәргә кирәк. Аларның дәресләре — үзләре үк укытуның матур үрнәкләре. Укыту, фәннәрне дөрес, аңлаешлы, логик эзлеклелектә бирүнең ачык үрнәкләрен Илья Николаевич Ульянов П. И. Котельников, А. Ф. Попов, М. А. Ковальский, А. М. Бутлеров һәм А. С. Савельев дәресләрендә ала. Бу талантлы галимнәр үзләренең укучыларына методик күнекмәләр өйрәтүгә дә игътибар бирәләр.

Булачак педагогларга П. И. Котельниковның «Математикага каршы тискәре мөнәсәбәт» дигән чыгышы аеруча зур тәэсир ясый. Үзенә генә хас дәрт белән ул бары үз хезмәтеңне түгеп тупланган акыл байлыгы гына тулы көчкә ия булуын искәрә. Аннары ул гомуми өндәмәләрдән аерым мәсьәләләргә күчә. Мәсәлән, балалар математика мәсьәләләре чишкәндә барыннан да элек нәрсәгә әһәмият бирергә кирәклеген җентекләп аңлата. Исәпләүләр ялгышса, фикерләр ачык, төгәл, күп сүзсез тулы һәм логик эзлеклелектә булсын ди ул.

М. А. Ковальский телдән күрсәтмәләрнең күнегүләрсез онытылуы, шуңа күрә, башка төгәл фәннәр белән беррәтән, астрономияне өйрәнү практик дәресләр белән

ныгытылырга тиешлегенә басым ясый. Танылган галим һәр студентны университет обсерваториясендә йолдызлы күк йөзен күзәтү алымнарына бик тырышып өйрәтә.

Яшь магистр Бутлеровның да үз алымы бар. Ул үгет-нәсихәт белән мавыкмый. Лекцияләре тирән эчтәлекле һәм кызыклы була, аларның һәрберсе тыңлаучы күңелендә мәңгегә кала. Н. И. Лобачевский һәм Н. Н. Зинин традицияләре дә яңадан калка: профессорларның ачык лекцияләре җирле халыкны практик механика, техник химия һәм технология яңалыклары белән даими таныштырып бара. 1851 елдан башлап «Казан губернасы хәбәрләре»ндә басылып чыккан расписаниедә күрсәтелгән вакытта П. И. Котельников, К. К. Клаус, А. М. Бутлеров кичке сәгатьләрдә химия лабораториясе бинасында үзләренең курсларыннан лекцияләр укыйлар һәм бер үк вакытта тәҗрибәләр дә ясыйлар.

Педагогика фәне акыл иярәндә торган саен күбрәк кызыксыну уята. Дусты Владимир Стржалковский университеттан киткәндә, Илья Николаевич икенче курста укый. Хыялый романтик холыклы Владимир халыкка тагын да якынаю, бөтен барлыгы белән аңа хезмәт итү өчен Казан губернасының караңгы өязләреннән берсенә чыгып китә. Әмма ике арада булган чын дуслык югалмый. Алар әледән-әле Казанда очрашып торалар. Соңрак Сембер халык училищелары дирекциясендә дә бергә эшлиләр.

Университетта Илья Николаевич Александр Георгиевич Горизонтов белән дә ныклап таныша. Алар Пенза дворяннар институтында бергәләп укыталар. Бу сәләтле педагог соңрак Н. А. Добролюбов кайнар хуплаган табигать тарихы дәреслеге авторы булачак. Шул ук дәреслектән гимназиядә Илья Николаевичның кызы Анна да укыган.

Илья Николаевичны Казан университеты тагын бер булачак педагог белән таныштыра һәм дуслаштыра. Ул — Николай Курбатов. Медицина факультетында укыса да, мәктәп турында хыялланa, балаларны ярата, күңеле белән укытучылыкка тартыла. Бу шөгылен ул Сембер һәм Самарада врачлык практикасы үзганда да ташламый, гимназияләрдә табигать тарихыннан дәресләр алып бара.

Тормыш юллары билгеләнә, офыклар ачыклана. Билгеле, бу авыр, ләкин бәхетле студент еллары үтеп китәчәк. Казанның Воскресенская урамындагы ак мәрмәр колонналы университет, күпме төннәр шунда узган обсерватория дә бәхетле бер төш кенә кебек еракта калачак. Ләкин кыенлыклар да, тормыш ыгы-зыгысы да, административ изү дә, полиция күзәтүе дә студентлык рухын, яшьлек дәртен, ззләнүләр һәм өметне юкка чыгармаслар. 1876 елда халык училищелары директоры И. Н. Ульяновның көрәштәше публицист В. Назарьев «Вестник Европы» журналы редакторына болай дип язачак: «Студент елларында нинди булса, хәзер дә шулай сакланган бу карт студент кайчандыр Тургенев бик оста тасвирлаган шәхесләрнең берсе. Ул — чын мәгънәсендәге студент».

Тагын шуны да өстәргә кирәк: ул — үзенең бөтен гомерен укытучылыкка багышлаган һәм шунда бәхетен тапкан студент.

## Комета кая оча?

Уку тәмамланып килә инде.

Һәр елны физика-математика факультеты советы университетны фәннәр кандидаты дәрәҗәсендә тәмамларга теләүче студентлар өчен фәнни эш темаларын раслый. Темалар арасында 1853 елда астрономия буенча «Ольберс алымы һәм аны 1853 елгы Клинкерфюс кометасының орбитасын исәпләп чыгару өчен куллану» дигәне дә була. Әлеге теманы профессор Мариан Альбертович Ковальский тәкъдим итә. Һәм бу тикмәгә генә түгел. 1853 елның 10 нчы июненнән 11енә каршы төндә Геттинген обсерваториясеннән күзәтелгән бу кометаны Казанда да бик яхшы күрәләр. Августта аның иң көчле яктырту чоры була. Аннары ул акрынлап сүнә башлый һәм 1854 елның январенда күздән югала.

Аның хәрәкәт юнәлеше Зур Аю йолдызлыгыннан Арыслан йолдызлыгына таба Ләкин бу «койрыклы йолдызлар»ны юкка гына «адашып йөрүчеләр» дип атамыйлар. Аларның кайберләре парабола буенча, икенчеләре эллипс, ә өченчеләре гипербола буенча хәрәкәт итә. Ә 1853 елгы комета нинди орбита буенча сәяхәт итәчәк соң? Безнең күк гөмбәзенә ул тагын әйләнеп кайтырмы? Әгәр кайтса — кайчан?

Бу сорауларга җавапны кометаны ачучы Геттинген обсерваториясе ассистенты Эрнест Клинкерфюс бирер. Әмма күк йөзендәге меңнәрчә йолдызларның төгәл урыннарын исәпләп чыгаруда күп эшләгән Казан университеты профессоры М. А. Ковальский өчен космик объектларның орбита хәрәкәтен билгеләүнең классик алымнарына үзе керткән төзәтмәләрнең дөреслеге яңадан исбатлануы мөһим. Шул исәптән Ольберс алымы өчен дә.

Кечкенә генә чигенеш. И. Н. Ульянов турында язучы әдәбиятчылар һәм тикшеренүчеләр, аның кандидатлык диссертациясен искә алганда, күп вакыт ул чорда диплом эшләре шулай аталган дип аңлатма бирәләр.

Бу алай түгел. Узган гасырның 50 нче елларында кандидат дәрәҗәсенә, беренчедән, барлык фәннәрдән дә өлгереше яхшы булган, икенчедән, факультетта алдан билгеләнгән фәнни эшкә җигелүче студент кына ирешә алган.

Уртача яки начар укыган студентлар университеттан кандидат булып чыгу турында уйлый да алмаганнар, билгеле. Башлыча, 1854 елгы чыгарылышта, математиклар арасында кандидатлык дипломнары биш кешенең бары өчесенә — Илья Ульянов, Пасмурнов һәм Алексей Урванцевка гына бирелә, ә Виктор Замочников һәм Андрей Заурих моңа лаек дип танылмыйлар.

1853 елның көзендә Илья Николаевич керешкән эш күп белем һәм сабырлык таләп итә. Иң элек Ньютон, Гевелий, Лаплас, Лагранжларның кометалар хәрәкәте теориясенең үсешенә керткән өлешен өйрәнеп, ә аннары шуңа кыска гына тарихи очеркта аңлатма бирергә, әлегәчә билгеле булган иң гади һәм уңай ысулның XVIII гасыр ахырында немец астрономы Генрих Вельгельм Ольберс тарафыннан уйлап табылуын исбат итү өчен орбита исәпләп чыгаруның төрле алымнарын чагыштырып карарга кирәк. Кометаларның физик төзелешенә карашын Ольберс үзенең 1797 елда Галла шәһәрендә дөнья күргән «Комета орбитасын исәпләп чыгаруның иң гади һәм уңай алымы турында»гы язмасында бирә.

Күп астрономнар, бигрәк тә танылган Иоһанн Франц Энке һәм Карл Фридрих Гаусс ватандашларының «Комета астронмиясе»н җентекләп өйрәнделәр һәм аңа үзләренең төзәтмәләрен, өстәмәләрен керттеләр. Ә тулаем алганда, И. Н. Ульянов фикеренчә, Ольберс алымы вакыт сынавын уңышлы уза. Аның практик яктан караганда башкалардан мөһим өстенлеге исәпләүнең кыска, уңай булуында.

Ульянов дәртләнеп, илһамланып эшли. Укытучысы профессор М. А. Ковальский чыгарган формулалар ярдәмендә ул кометаның ихтимал орбитасы ничек исәпләнүен исбатлый. Гамбург обсерваториясе астрономнарының Клинкерфюс кометасы хәрәкәтен күзәтү нәтиҗәләре белән таныша. Һәм шуннан соң гына эшнең иң мөһим өлешенә — кометаның төгәл орбитасы элементларын исәпләп чыгаруга керешә. Ихтимал, студент Ульянов Казан астрономия обсерваториясендә кометаны үзе дә күзәткәндер.

Ничек кенә булмасын, билгеләнгән вакытка, чыгарылыш имтиханнары башланыр алдыннан, факультет деканы П. И. Котельниковка ул 38 битлек диссертациясен тапшыра. Ә Котельников исә бу эшне бәяләүне баш астроном М. А. Ковальскийга йөкли. Профессор, Илья Николаевичның хезмәтенә уңай бәя биреп, болай дип яза: «Дүртенче курс студенты Ульяновның хезмәте Ольберс ысулы белән кометаларның параболик орбитасын исәпләүдә Энке һәм Гаусс төзәтмәләрен куллануга багышланган. Узган ел гади күзгә дә күренгән кометаның элементларын исәпләп чыгаруда бу ысулны куллану студентның астрономик исәпләүләрнең асылына төшенүе турында сөйли. Бу хезмәте белән ул, һичшиксез, математика фәннәре кандидаты исеменә лаек». Математика фәннәре докторы П. И. Котельников, ми-

нерология һәм геогнозия фәннәре докторы П. И. Вагнер, математика һәм астрономия фәннәре докторы А. Ф. Попов, физика һәм химия фәннәре докторы А. С. Савельев, профессор П. С. Гесс та шушы ук карашта. Аларның И. Н. Ульяновның фәнни эшендәге автографлары безнең көннәргәчә сакланган.

1854 елның май көннәре. Чыгарылыш имтиханнарының кызган чагы. Әлегә Ульянов аларны әйбәт кенә бирә: аналитик геометрия һәм тригонометрия белән алгебрадан — дүрт, астрономия — биш, геодезия — биш, каты матдәләр механикасы — дүрт. Шулчак Илья Николаевич кисәк кенә авырып, университет клиникасына керә. Курсташы Н. Пасмуров белән дә шул ук хәл.

Калган имтиханнар көзен тапшырыла. Болары да уңышлы: физика һәм физик географиядән — биш, ә дифференциаль, интеграль, вариацион исәпләүләр һәм сыек матдәләр механикасыннан — дүрт.

1864 елның 16 сентябрендә профессор П. И. Котельников университет ректорына физика-математика факультеты советының карарын җиткерә. Анда «Мөһим предметлардан уртача билгеләре «5»ле булып, диссертацияләре уңай бәяләнгән И. Ульянов һәм Н. Пасмуровка математика фәннәре кандидаты дигән фәнни дәрәҗә бирелә» диелгән. Шушы датаны Илья Николаевич Ульяновның университетны тәмамлаган елы дип карарга кирәк.

## Лобачевский ярдәме белән

Кайчак кеше биографиясенең төрле чорлары гаҗәеп рәвештә кабатланып тора. Гимназияне бетергәч тә, Илья Николаевич билгесезлек белән тулы озак һәм газаплы атналар кичерә: аны университетка казна стипендиаты итеп алырлармы, юкмы! Ә инде университетны тәмамлап, чыгарылыш имтиханнарыннан соң һәм математика фәннәре кандидатлыгына диссертация яклагач, бу атналар озак айларга әвереләләр. Тагын билгесезлек, тагын борчылулар, тагын акчасызлык.

Ульянов эш урынсыз кала. Беркайдан һичнинди эш хакы яисә пособия алмый. Югары белем алган яшь кешене эшкә урнаштыру турында уйлау беркемнең дә бурычы, вазифасы түгел. Кайда да булса сызымчы булып, казна яки контроль палаталарында, акцияләр идарәсендә һәм башка җирдә берәр эш табып була, билгеле. Ләкин Илья Николаевичны чиновник карьерасы кызыксындырмый. Бар теләге — урта уку йортында укытучы булу.

Андый вакансияләр бик аз. Халык мәгарифе министрлыгы «үзенең» илдәге бердәнбер Петербург Баш педагогия институтын тәмамлаучыларны урнаштыру белән дә кыенлыклар кичерә. 1855 елны аның физика-математика факультетын нибары дүрт кеше генә тәмамлый, шул исәптән Д. И. Менделеев та. Начальниклар алар өчен дә әле урынны ярты ел эзлиләр.

Астрахань белән булган вакыйга да кабатлана. Кандидат Ульянов казна палатасыннан үзенең мещаннар җәмгыятеннән чыгарылуы турында таныклык көтә. Бу кәгазьдән башка ул киләчәктә берни эшли алмаячак. Аның туган шәһәрендәге чиновниклар артык ашыкмый. Таныклык бары тик ноябрьдә генә килеп җитә. Шуннан соң гына укыту округы попечителе университет Советының аның физика-математика факультетын фәннәр кандидаты дәрәҗәсендә тәмамлавы турында карарын раслый. Тагын бер айдан —13 декабрьдә — университетның ректоры һәм факультет деканы кандидатлык дипломына кул куялар.

Әйтерсең, тормыш, махсус рәвештә, Ульяновның түземлелеген, чыдамлылык, ихтыяр көчен сыный. Гүя ул аның коңгырт күзенкәй, тирәнлегендә киң күңел, мәрхәмәтлелек чагылган акыллы карашыннан бу яшь кешенең зур киләчәген шәйли. Дөньяның кырыслыгын, кешеләрнең инде яхшылык көтүдән ваз кичеп усаллануын, якты киләчәкнең әле ерак булуын тормыш кат-кат искәртә тора. Башка берәү мондый даими искәрүләрдән соң таш бәгырьгә, туласка әйләнер, карашлары үзгәрер иде. Ә Ульянов киләчәккә өмет, ул гына да түгел, ышаныч

белән карый. Бәлки аның карашында ару, газап чигү чагыладыр, әмма югалып калуның әсәре дә юк. Шундый зур кичерешләрдән, каршылык, авырлыклардан соң да Илья Николаевич оптимист булып кала ала. Дәүләт халыкка хезмәт итү өчен белем биргән үз гражданнары турында уйлап та карамый, империя законнары һәм гадәтләре күкрәк тутырып киң сулыш алырга ирек бирми. Тик ничек кенә булмасын, алда яктылык чагылып китә.

Һәм менә язмыш әкренләп Ульяновка да елмайгалап ала. Пензаның дворяннар институтында математикадан өлкән укытучы урыны бушый. Илья Николаевич озак уйлап тормый. 1855 нче яңа елга керергә бер көн кала үзен шушы эшкә сынауларын үтенеп, уку округы попечителенә мөрәҗәгать итә. Кандидат булса да, имтиханнар тапшыру мәҗбүри. Сынаулар рөхсәт ителә, һәм Ульянов шуңа әзерләнә.

Шул ук вакытта Пензада аның киләчәк язмышына кагылышлы кайбер вакыйгалар булып ала.

Ул барасы дворяннар институтында метеостанция бар. Аннан укыту округына даими мәгълүматлар килеп тора. Һәм менә бервакыт округ попечителе ярдәмчесе Н. И. Лобачевский кулына Пензадагы метеостанция термометрының ышык урында кояшлы җиргә караганда температураны шактый югары күрсәтүе турында мәгълүматлар килеп эләгә. Күзәтүләр алып баручының мондый саксызлыгы һәм эшкә салкын каравы Лобачевскийның ачуын китерә, билгеле. Галим институт директоры исеменә «Метеорологик күзәтүләр эшенә салкын каравы өчен җаваплы кешегә шелтә белдерергә һәм аны һич кичекмәстән ышанычлы һәм белемле булган башка бер кеше белән алыштырырга» дигән әмер җибәрә. Әлеге эшкә җаваплы булган физика һәм математика укытучысы Н. И. Попов күзәтүләрдән читләштерелә. Институт директоры бу турыда округ идарәсенә хәбәр итә һәм институт укытучыларының берсенең дә метеорологик күзәтүләр белән шөгыльләнергә теләмәүләрен әйтә. Инде утыз елга якын Идел буе һәм Урал гимназия, институтларының һәммәсендә дә метео-күзәтүләрнең фәнни оештырылуын теләгән Н. И. Лобачевский өчен зур күңелсезлек була бу. Пензада күзәтүләрне кем оештыра алыр икән соң?

Менә шунда инде попечитель ярдәмчесе үзен Пензага җибәрүләрен үтенгән кандидатны исенә төшерә. Өстәвенә ул бит берничә ай профессор Савельев җитәкчелегендә университет обсерваториясендә дә күзәтүләр алып барган. Кызык, эше ничек бара икән аның? Профессор үзенең элеккеге студентының эшчәнлегенә уңай бәя бирә. Бик яхшы!

— Ульянов Пензада булырга тиеш,— ди попечитель ярдәмчесе.

Шул ук вакытта Ульянов математика укытучысы буларак сынаулар уза. «Коник киселешләрнең аналитик аңлатмасы» дигән лекциясе ачык һәм төпле, ә «коник киселешләргә орынма сызык уздыру» дигән темага фикер йөртүе канәгатьләнерлек дип табыла. Ә менә физикадан сынауларны Комитет канәгатьләнерлек түгел дип таба.

Көтелмәгән күңелсез абыну. Инде нишләргә? Һәм менә җиденче апрельдә ул үзенең физика белән даими шөгыльләнүен, сынауларга әзер булуын, шуңа күрә бу фәннән аны яңадан тикшереп карауларын үтенеп, Н. И. Лобачевскийга мөрәҗәгать итә.

Ә Лобачевскийга Пенза дворяннар институтында метеорологик күзәтүләр алып барырга сәләтле укытучы кирәк. Ул яңадан округның баш метеорологы профессор А. С. Савельев белән киңәшләшә.

Нәкъ ике атнадан соң Комитет Ульяновның «Гальваник ток теорияләре» һәм «Яшерен һәм чагыштырма теплород турында»гы лекцияләрен тыңлый. Һәр икесе «яхшы» билгесе белән бәяләнә. Савельев үзенең элеккеге укучысын өлкән укытучы дәрәҗәсенә лаек дип табып, аны Лобачевскийга тәкъдим итә һәм җиденче майда И. Н. Ульянов попечитель ярдәмчесе боерыгы белән өлкән укытучы итеп билгеләнә. Бер үк вакытта Н. И. Лобачевский халык мәгарифе министры А. С. Норов-

ка үзенең карарын раслау өчен җибәрә. Ә 25 нче майда исә, Петербургтан җавап та көтеп тормастан, ул, профессор Савельев кулы астында университетның метеорологик обсерваториясендә күзәтүләр алып барган И. Ульяновның эш белән тәэмин ителүен таләп итеп, Пенза дворяннар институты директоры исеменә хат җибәрә.

Инде барысы да тәртиптә, барысы да яхшы шикелле. Ләкин алда тагын бер каршылык. Министр А. С. Норов И. Н. Ульяновның Лобачевский җибәргән метрика таныклыгын һәм кандидатлык дипломын Казанга кире кайтара. Аның әйтүенчә, Пензадагы урынны Петербург пединститутыннан килгән кеше алачак. Шуңа күрә попечитель ярдәмчесенең үтенече кире кагыла икән.

Бер килмәсә килми бит. Ульяновның киләчәге тагын икеле, кабат сорау астында. Әмма Лобачевскийга әлеге эш белән яхшы таныш булган белемле укытучы кирәк. Ул үзе дигәнен итә. Пензада Ульянов эшләргә тиеш, ә башкала пединститутын тәмамлаган яшь кешегә округ кайдан да урын табар.

Округ попечителе ярдәмчесе кандидат Ульяновны үз янына чакыртып, эшендә зур уңышлар тели һәм укытучылык белән бергә институт метеостанциясен җитәкләүне йөкли. Әнә шулай итеп, бөек галимнең җиңел кулы белән Илья Николаевич эшкә урнаша.

1855 елның 31 нче маенда Н. И. Лобачевский Казан университеты кандидаты И. Н. Ульяновның попечитель канцеляриесеннән юл акчалары алгач, шуны айның егерме сигезендә эш урынына китүен хәбәр итеп, институт директоры исеменә хат җибәрә.

**Г. РӘКЫЙП** тәрҗемәсе

Гариф Ахунов

# ЯҢАРЫШ

Кеше гомере бик күп вакыйгаларга, үсеш-үзгәрешләргә шаһит була ала икән. Мин моны әдәбият-сәнгать дөньясына кагылышлы рәвештә, үзем күргән-кичергәннәрдән чыгып әйтәм.

Университетның тел-әдәбият бүлегендә укыган елларны хөрмәтле галимнәребез Гази Кашшаф, Хатип Госман, Мөхәммәт Гайнуллин безгә татар поэзиясенең зурлыгын, борынгылыгын Кол Галинең «Йосыф-Зөләйха» кыйссасыннан башлап аңлаттылар. Без Мөхәммәдъярларны, Габделҗәббар Кандалыйларны, Утыз Имәниләрне өйрәнеп, Каюм бабайга, Тукайга килеп җиттек.

Тукай — безнең өчен чиксез зур дөнья. Тукай белән без телебезне чарладык. Тукай белән бездә туган җиргә, туган халкыбызга ихтирам хисе тәрбияләнде.

Аннары Такташ заманы килде.

Такташның зәңгәр теннәре, Мокамайлары, Зөбәйдә һәм Алсулары, утызынчы елларның каршылыклы көрәш утларында янган Мохтар картлары безнең күңел күгебезне киңәйттеләр, рухыбызны романтик иттеләр.

Без белгән шигъриятнең барысын да әйтеп бетердем дисәм хата булыр. Яшьлектә без Пушкин белән тилереп яшәдек. Жамбулның думбра чиртеп җырлаган җырларын яшьлеккә юлдаш итеп алдык. Алар без ирешкән бәхеткә бик тә туры киләләр иде.

Сугыштан соңгы елларда Әхмәт Фәйзи, Фатих Кәрим, Шәйхи Маннур, Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким исемнәре яңа бер көч белән шаулый башлады. Алар янына Шәрәф Мөдәррис, Зәки Нури, Зыя Мансур, Әнвәр Давыдов килеп кушылды. Илленче еллар башында шигырь мәйданына Хисам Камал, Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев, Әхсән Баяннар килеп керде. Халыкның талантлар бирә торган чишмәсен сугыш ялкыннары киптермәгән булуын алар үз иҗатлары белән бик матур расладылар. Озакламый Хәсән Туфан, Муса Җәлил поэзия сафына кайтты. Өлкән буын, урта буын, яшь буын кулга-кул тотынып эшли башлады.

Менә шушы зур, киң колачлы, җитди сүзле татар поэзиясе җирлегендә Равил Фәйзуллиннар буыны шагыйрьләре ирешкәнне күздән үткәрү һәм поэзиябезнең киләчәк көненә күз ташлау минем өчен кичектерелмәс мөһим бер эш булып тора.

Фәйзуллиннар буыны дигәннең чикләре соңгы ун ел эчендә инде шактый ачыкланды. Роберт Әхмәтҗанов, Радиф Гатауллин, Ренат Харис, Рөстәм Мингалимов, Гәрәй Рәхим, алардан бераз соңрак һәм әдәби алымнары белән дә үзгәрәк булып мәйданга чыккан Зөлфәт һәм Мөдәррис Әгъләмовлар алтмышынчы-җитмешенче елларда үзләренә карата игътибарны җәлеп итеп өлгерделәр. Тормышның көтелмәгәнрәк якларына кагылып, дөньяга һәм эстетик кыйммәтләргә олырак таләпләрдән килеп, поэзиянең алгы сызыгына килеп чыктылар.

Сибгат Хәкимнең гыйбрәтле бер сүзе бар. Шагыйрьнең әдәбиятка кирәкмеюкмы икәнен аның исемен поэзиядән алып ташлап тикшереп була, ди ул. Әйдәгез,

шул принциптан килеп тикшереп-сынап карыйк: Фәйзуллиннар буынын әгәр бүген әдәбиятта юк дип исәпләсәк, татар поэзиясе берәр нәрсә югалтамы? Югалта! Әгәр Фәйзуллиннар буыны булмаса, бүгенге татар поэзиясе тулы булмас иде, күңелдә поэзиябезнең киләчәге өчен хәвефләнү, борчылу уяныр, буыннар эстафетасы өзелер иде. Һәм без, буш урынга төбәлеп, авыр тойгыларга бирелер идек. Шөкер, алар бар, алар безнең заман поэзиясенең үсеш дәрәҗәсен, яңалыгын, ил күләмендә барган ачыш-табышларын билгелиләр. Алар рус поэзиясендәге Юрий Кузнецов, казакълардагы Олҗас Сөләйманов, Украинадагы Иван Драч, үзбәкләрдәге Абдулла Арипов, белоруслардагы Рыгор Бородулиннар белән тоташалар, илебездә барган алтмышынчы-җитмешенче еллар поэтик агымының саф чишмәләре булып китәләр. Әлеге буын тирәсендә күп төрле бәхәсләр булды. Берәүләр аларны Такташ-Туфаннардан соң татар поэзиясенә шартлау — яңару китергән буын дип; икенчеләре андый шартлауны китермәгән буын дип бәхәсләштеләр. Мин үзем бәхәс барган мәйданның уртасына кереп, кемнеңдер якасыннан урап алырга җыенмыйм. Әмма фикеремне ачыктан-ачык әйтеп узу кирәк.

Бу буын максатны олыдан куйды. Аңа поэзиябез язмышын ил һәм дөнья күләмендәге поэзия язмышы белән бәйләп карау хас. Нәтиҗәсен, әлбәттә, киләчәк көн күрсәтер, әмма тотынулары ихлас, белеп. Кимчелекләре дә күзгә күренеп тора: төрле чыганаклардан — рустан, чит ил поэзиясе тәрҗемәләреннән ризыкланып, алар вакыт-вакыт үз телебезнең табигый агышын, аның моңын, аһәңен тоеп бетерә алмыйлар. Бу нисбәттән Равил Фәйзуллин, Роберт Әхмәтҗанов, Ренат Харис шигырьләренең татарчадагы яңгырашын мин соңгы елларда күтәрелеп чыккан кайбер атаклы җырчыларыбыз иҗаты белән чагыштырыр идем. Тавышлары искиткеч! Мәскәүдә русча җырлыйлар — таң калалар, үзебездә татарча җырлыйлар — бигүк егылып китүче юк. Ник? Чөнки татар телендәге сүзләрнең логик басымын, табигый агышын, аһәңен сизеп бетермиләр, шунлыктан, тавышлары никадәр көчле һәм матур булса да, татар тыңлаучысының йөрәгенә «сары май булып ятмый». Фәйзуллиннар буыны шагыйрьләренең кайберләре шундыйрак. Русча тәрҗемәдә бик әйбәт яңгырыйлар, татарчада юк-юкта колакны тырмап, күңелне рәнҗетеп китәләр. Бу нәрсә, әлбәттә, юрамалый, кешене шаккатырыр өчен эшләнми, бу — әлеге буынның бәласе, алгы көндә алардан соң киләчәк яшьләрнең, ихтимал, тагын да зуррак бәласе булыр.

Бу мәсьәләдә безгә, мөгаен, бер тайпылыштан сакланырга кирәктер. Кайбер тәнкыйтьчеләр еш кына әлеге шагыйрьләрнең тел чатаклыкларына ябышып, алар күтәргән олы фикерләрне дә инкарь итәлиләр. Моннысы инде дөрес булмас, моның өчен тарих безне гафу итмәс, чөнки, халыкча әйткәндә, юган суы белән баланы да чыгарып ташларга ярамый бит. Инде фикеребезне ахырынача өзеп, төгәлрәк итеп әйтеп бетерик: чын шагыйрь, чын оста уй-тойгыларын укучы күңеленә ятышлы итеп, тел кануннарын бозмыйча әйтеп бирә белергә тиеш. Шагыйрь исемен йөртәсең икән, шигырьне рәнҗетмә, телне бозма. Улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла дигәндәй, моннысы Равил Фәйзуллиннар буынына гына түгел, киләчәк шагыйрьләр колагына да әйтелә...

Әгәр янә дә Фәйзуллиннар буынының уңай сыйфатларына әйләнеп кайтсак, авыз тутырып шуны әйтә алабыз: нәкъ менә шушы буын үзенең ныклыгы, һөҗүмчән көче, кыю рәвештә экспериментлар үткәрүе белән сугыштан соңгы тыныч агышлы, хәтта әйтер идем, киң Иделдәй салмак агышлы татар поэзиясенә тынгысызлык алып килде, яңалыкка, моңарчы күрелмәгән, кабатланылмаган поэзиягә сусаган яшьләргә үз позициясен, үз шигъри принципларын тага алды, аларны үз артыннан ияртеп алып китте; укучылар моңарчы булган классик поэзиябез үрнәкләренә ул хәтле үк мөкиббән китеп, табынып яшәми башладылар, тышкы матур бизәкләргә төренгән, әмма эчтәлеге буш булган дистәләгән шигырьдән (шагыйрьләрнең түгел, шигырь чыгаручыларның тезмәләреннән) баш тарттылар. Әйбәт күренешме бу? Һичшиксез! Алай гына да түгел, әлеге яңа буынның әле тау чишмәседәй баштүбән ташланып аккан шарлавыклары, әле ялкынлы плакат-лозунг дәрәҗәсенә күтәрелгән өндәмәләре, көрәш мәйданына чакырулары моңарчы булган өлкән һәм урта буын шагыйрьләр иҗатына да яңа күз белән карарга, ул иҗатны таләпчәнрәк бәя белән бәяләргә мәҗбүр итте.

Бу буынның һәр шагыйре инде әдәбиятта ныклы үз урынын алды, үз тавышын тапты. Ренат Харисны Радиф Гатауллин белән, Роберт Әхмәтҗановны Зөлфәт белән,

Равил Фәйзуллинны Гәрәй Рәхим белән һич кенә дә бутый алмыйсың. Дөньяны күрүләре һәркайсысыныкы үзенчә, төсләр сайлавы башка, шигырьнең мускулатурасы, җегәре бүтән.

Әллә әхлакый-эстетик максатлары ачыграк, шигъри көче һәм иҗат активлыгы зуррак булганга, әллә шәхес буларак ныклыгы беренче планга килеп чыкканга, Равил Фәйзуллин шушы буын өчен алдан юл ярып бара башлады. Ул соңгы елларда республикабызда гына түгел, ил күләмендә дә танылды.

Хәзер аңа 37 яшь, ул инде татарча — 10, русча 5 китап чыгарырга өлгерде. Шуның өстәвенә аның аерым шигырьләре илебез халыкларының байтак телләренә тәрҗемә ителде, шулай ук чит илләрдә дә басылды, берничә шигыре дөнья халыклары әдәбиятының 200 томлыгына керде. Поэзиядәге уңышлары өчен ул Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе һәм Муса Җәлил исемендәге комсомол премиясенә лаек булды.

Аңа карата шундый зур ышаныч белдерелү, аның шигърияттен шулай зур бәяләүнең хикмәте нәрсәдә соң? Моның сәбәбенә төшенергә тырышып карыйк.

«Шигырь китапханәсе» сериясендә чыгарыла торган бер томлыкта шагыйрьнең «Яшьлек дәфтәреннән» килеп кергән берничә шигыре бар. Җитди таләпләрдән килеп караганда, алар әле зур поэзия исәбенә кертелә торган әсәрләр ук түгел, алар әле унбиш яшьлек үсмернең сукмакка төшү, эзләнү чорының үрнәкләре. Алар моңарчы башкалар язып килгән өлгедә, тел ягыннан шактый ук кытыршы, үзе кичергәннәргә түгел, башка әдипләрдән прокатка алган «чималга» таянып язылган шигырьләр.

Шуннан соң тагын биш ел, нибарысы биш ел вакыт уза — бераүне дә кабатламаган өр-яңа шагыйрь дөньяга чыга. Равил Фәйзуллинның 1963—65 елларда иҗат иткән шигырьләре яңалыгы белән таң калдыра, һәм без моның нидән икәненә сәбәп таба алмыйбыз. Күрәсең, Мостай Кәримнең Равилгә карата, ул яшь һәм башлап язучы шагыйрь чорын кичермәде, әдәбият мәйданына җитлеккән шагыйрь булып аяк басты, дигән сүзе дөрестер.

Равил төсләр сайлый, авазлар сайлый; кояш нуры, ай нуры, яр керәшәсе белән сөйләшә; ләкин болар үзмаксат итеп язылган табигать этюдлары гына түгел, шагыйрь дөньяның гүзәллегенә каршы сугыш җимергән харәбәләрне китереп куя. Җанны кузгатып, дулкын кагып узганы шул: болар яңгыравыклы сүзләр түгел, болар өндәүләр түгел, болар акварель буяу белән, тирән фәлсәфә салып язылган картиналар. Шагыйрь гүяки: кешеләр, күрәсезме, табигатьтә купме нәфислек бар, табигать нинди игелекле һәм саф, сез аның шушы бинниһая мәһабәтлеген җимерерсезмени? — дип әйтергә тели. Табигатьне ул телле итә, сөйләштерә, кешелек дөньясының намусын кузгатырга тели, вату-кыру тарафдарларын табигатьнең үз теле белән гаепләтә. Табигать авазларына гади кешеләрнең, җир йөзендә хезмәт белән яшәгән кешеләрнең самими авазлары килеп кушыла. «Күмәч пешерүчеләр», «Минем әти», «Балыкчы карт», «Җилфердәүче керләр җыры» шигырьләрендә халкыбызның хезмәт яратуы, дуслык-туганлык хисләре, үткәнебез һәм киләчәгебез белән горурлану бар. Болары да үзмаксат белән язылмаганнар, табигать белән әңгәмә темасына килеп кушылалар. Халыкларның тыныч яшәве, көндәлек эштән, тезү, иҗат итүдән тәм табуы — әлеге дә баягы гасырлар буена җимерүче көч булып килгән сугышка каршы куела. Үзе пешергән күмәчне чип-чиста кәрзингә салып, тар урамнарны киң итеп, ризыгын мактап җырлап килгән кешене күрүдән дә ямьлерәк күренеш бармыни дөньяда? Яки «кычкырсаң да таралыр күк» иске көймәсе янында уйга калып, «җилкән киереп ерак юлга барырына» әле һам[illegible]чтен өзми басып торган балыкчы карт безнең көннәрдә аңа карата зур ихтирам [illegible] уятмыймыни?! Мондый шигырьләр, шагыйрьнең мондый табышлары беренче чорда гына түгел, егерме еллык иҗатында әледән-әле килеп чыга, кешеләрне матурлыкка, зирәклеккә, узган сугышлардан, җимерү-кырулардан ваз кичәргә, дөньяның һәм табигатьнең төрле хәлләреннән гыйбрәтләр алырга чакырып, нәфис авазлы көмеш кыңгырауны кагып торгандай, үзәк лейтмотив булып яңгырап бара.

Инде бу шигырьләрнең язылу алымнарына, җанга ятышлы ипле булуларына килсәк, алар дөнья әдәбиятындагы Роберт Бернс, Джанни Родари, Самуил Маршак поэзиясе белән тоташалар. Гадиләргә гимн җырлау, халыкның иң күркәм сыйфатларын

олылау, гуманлы булырга өндәү — болар бөтендөнья әдәбиятындагы прогрессив язучыларның иң матур сыйфатлары бит.

Җир өсте түмгәкләрдән, упкыннардан, мәгърур таулардан торган кебек, шагыйрьләрнең иҗаты да бер яссылыкта гына бара алмый. Аның диңгез суы кебек күтәрелгән һәм кимегән, алга ашкынып чапкан һәм хәтта ялсезләнеп чигенгән чаклары була. Шагыйрь күңеле олы һәм кече шатлыклардан, дөньяның борчу-бимазаларыннан тукыла.

Равил Фәйзуллинның байтак әсәре ак шигырь яки ирекле шигырь белән язылган. Бездә «бу — яңалык» яки «яңалык түгел», дип озак бәхәсләштеләр, бәхәс мәйданында кылычлар озак чыңлады. Ак шигырь дә, ирекле шигырь дә татар әдәбиятында соңгы елларда юктан бар булган, күктән төшкән нәрсәләр түгел. Ак шигырь бездә Фатих Әмирханның татар хатыны турындагы хикәясеннән, гражданнар сугышы чорында Мәхмүт Максуд язган нәсерләрдән, Бөек Ватан сугышы дәверендәге Гадел Кутуй иҗатыннан килә. Ирекле шигырьне Сәгыйть Рәмиевтән, Такташтан һәм Әнвәр Давыдовтан теләсәң күпме табып була. Сүз бирелә яңа форма ачу хакында түгел, табылган форманың эчке мөмкинлекләрен файдалана белү хакында гына бара ала. Зур ил мәйданына ничек чыгып була? Фикер белән. Тарихны перспективада, җәмгыять үсешен социаль оптимизмда күрә белү белән. Башка халыклар өчен дә кызыклы, гыйбрәтле хәлләр, проблемалар күтәрү белән. Р. Фәйзуллинның төрле алымнар белән язылган шигырьләре, башкаланың «Молодая гвардия», «Советский писатель» «Современник», «Советская Россия» нәшриятларында русча басылып чыккан китаплары моңа дәлил була алалар.

Егерме ел буе поэзиядә эшләү дәверендә шагыйрь кыска формаларга да еш мөрәҗәгать итте. Бу да күктән төшкән форма түгел. Теләсә кайсы халыкның фольклорында яки язма әдәбиятында гасырлар буе яшәп килгән форма бу. Поэзиянең җәмгыятьтә тоткан урынына һәм традицияләргә бәйле рәвештә кыска поэтик форма төрле халыкта төрлечә аталып килгән: хокку, танки, робагый, газәл, такмак, табышмак, хикмәтле сүз, тапкыр сүз... Гадилеккә, кыскалыкка, тапкырлыкка ни җитә? Беренче карашка ифрат та җиңел тоелган кыска үткен сүз автордан зирәклек, зур акыл, бай тормыш тәҗрибәсе таләп итә. Кыска шигырьдә җәелеп китеп рифмалар тезеп булмый, чачаклы-чуклы метафоралар өя алмыйсың. Кыска шигырь, авторның үз сүзләре белән әйткәндә, маск-халатсыз, япа-ялгызы япан кырда атакага барган солдат кебек! Ул тәвәккәл, төгәл, куркусыз булырга тиеш.

Шагыйрьнең 1965 елны «Казан утлары» журналында «Нюанслар иле» исеме белән басылган кыска шигырьләре үз вакытында гаять каршылыклы фикерләргә дучар булган иде. Моның сәбәпләрен мин үземчә болай аңлыйм: беренчедән, безнең колак язма әдәбиятта кыска шигырьләргә күнекмәгән диярлек, икенчедән, мондый көтелмәгән форманы кабул итү өчен билгеле бер әзерлек кирәк, өченчедән, поэзиянең барлык төрләрендәге кебек, кыска шигырьләрдә дә һәр ялтыраганның алтын булып бетмәве дә мөмкин бит әле. Әмма кыска шигырьләр иҗат итү кирәк. Халыкны шул юнәлештә, тапкырлык юнәлешендә тәрбияләү, башка халыклардагы шул кыска үткен форманы тәкъдир итү, алга таба да үстерү, янә дә килеп, киң колачлы зур поэзия өчен алдан ук телне чарлау, фикерне үткенәйтү, мөмкин кадәр тыгыз итеп язарга өйрәнү өчен кирәк. Шуңа күрә Равил Фәйзуллинның бу өлкәдә ирешкәннәрен кире кагу түгел, объектив рәвештә бәяләү дөресрәк булыр.

Шагыйрьнең поэмаларына тукталганга кадәр, мин аның җыр жанрында, публицистикада эшләвенә карата берничә җылы сүз әйтергә уйлыйм. Җыр жанрында, бер дә яшерен-батырын түгел, тәссез текстларны арттыручылар сугыштан соң аеруча күбәеп киткән иде. Тәнкыйтьчеләр аларны тиргәп тә карадылар, зур җыелыш трибуналарыннан да фикерләрен белдерделәр, аңа карап тәссез текстлар бик әллә ни кимемәде әле, чөнки халыкның җырга, моңга сусавы зур иде. Җитмешенче елларда Роберт Әхмәтҗанов, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, Фәннур Сафин җыр жанрына лаеклы өлеш кертә башладылар. Хикмәти хода — тәссез җырлар бермә-бер кимеде. Димәк, халык әйткәнчә, чөйне чөй белән генә сугып чыгарып була! Равил Фәйзуллинның «Сагыш», «Тимим күңелемә», «Аккошлар», «Менә без дә үсеп җиттек, әни» һәм башка җырлары Җ. Фәйзи, Р. Яхин, Ф. Әхмәтов. Л. Хәйретдиновалар тарафыннан көйгә салынып, музыка канатларында халыкка барып иреште һәм популярлашып китте.

Хөрмәтле композиторлар һәм музыкантларыбызның, үкенечкә каршы, шигъри мирасны әлегәчә белеп бетермәүләре яхшы җырлар тууга беркадәр киртә булып килде шикелле. Инде кулларына килеп кергән яңа заман шагыйрьләрен алар ычкындырмаслар, яңа сулышлы поэзияне үз иҗатлары өчен алга таба ныграк файдаланыр дип ышанырга кирәк.

Тормышка, әдәбият-сәнгать проблемаларына багышланган публицистик мәкаләләрендә Равил Фәйзуллинның акылы, материалны белеп һәм яратып язуы үзен бик нык сиздерә. Алар — безгә мирас булып калган классик әдипләр турында, каләмдәшләре, бүгенге әдәби хәрәкәтнең үсеш юллары, тенденцияләре хакында уйлану.

Равил Фәйзуллин поэмаларны күп язуы белән дан алган шагыйрь түгел. Сан исәбе ягыннан поэмалар өчәү, ләкин алар, зур колачлы эпик әсәрләр буларак, үзенчәлекле, яңа.

«Көрәшчеләр» поэмасы күренекле татар совет шагыйре Әхмәт Фәйзинең «Туу сулышы» кебек патетик поэмасы белән күпмедер дәрәҗәдә аваздаш. Өлкән шагыйребез, планетада фашизм өянәге котырган бер дәвердә, илләр буйлап үлем уены йөргән бер чорда, планетада яшь баланың тууын дөньяның иртәгесе көне, киләчәге итеп, гаять зур эмоциональ көч белән сурәтләп биргән иде. Равил Фәйзуллин исә бөтен кешелек язмышына бәйле социаль каршылыкларның йомгагын поэманың үзәгенә алып, көрәшче образын алгы планга, мәйдан уртасына чыгарып куя.

**Бөтен**
**планета буйлап**
**вакансия!**
**Көрәшчеләр кирәк!**
**Көрәшчеләр!**
**Беләклеләр җитә,**
**Йөрәклеләр кирәк!**
**Куәтлеләр җитә,**
**Теләклеләр кирәк.**
**Көрәшчеләр кирәк!**
**Көрәшчеләр!**

Шагыйрьнең әлеге поэмада ирешкәне — көрәш мотивларын, гуманизмны калку итеп куюында гына түгел, бу сыйфатлар да аның поэзиясенә хас: ул фәлсәфи уйланулар тарафдары, күренешләрнең, вакыйгаларның рухи асылына үтеп керергә омтылган, күпчелек очракта шуңа ирешкән шагыйрь. Әмма ак һәм иркен шигырьләренең кайберләрендә ритмны ватып, гади бер прозаизмга төшеп җиткән чаклары да булды аның. «Көрәшчеләр» поэмасында исә музыкаль аһәң, төрки халыклар поэзиясенә аеруча хас булган корыч ритм нык сакланган. Әнә шул корыч ритм шигырь юлларын сафка тезелгән солдатлар кебек дисциплиналы итә, көрәшче итә. Русча тәрҗемәсендә әлеге ритм бигүк сакланып җитми, шуңа күрә сүзләр, Назыйм Хикмәт әйткәнчә, «мылтык көпшәсендә әлегә тын яткан пулялар» булып түгел, лозунг булыбрак чыкканнар, шуңа күрә алар, ихтимал, рус укучысын оригиналдагы көче белән дулкынландыра алмыйлардыр.

Көрәш мотивы «Гадиләргә гимн» поэмасына да хас. Әмма бу поэмада көрәшче образы, кулга корал тотып баскан солдат булудан бигрәк, илнең, дөньяның иминлеген тыныч хезмәттә күрүче кеше булып күз алдына килә. Шагыйрь әнә шул кешеләр: күпер салучылар һәм ат караучылар, көмәч пешерүчеләр һәм корыч коючылар, күмер чабучылар һәм сал агызучылар, чәчәк үстерүчеләр һәм бала тәрбияләүчеләр, чалгы көйләүчеләр һәм тире иләүчеләр, пыяла өрүчеләр һәм җирнең ясалма юлдашын галәмгә очыручылар белән әңгәмәгә керә, аларның аңына, намусына дәшә. Биредә автор табигатьнең нәфис авазларын язгандагы акварель буяуларны «Көрәшчеләр» поэмасындагы лозунг-ритм белән табигый рәвештә бергә берләштерә алган. Шагыйрь дөнья поэзиясендәге барлык төшенчәләрне — намус, тугрылык, дуслык-туганлык, рух азатлыгы, коммунарлар, Буратино, ырымнар, аллага табыну, палач балталары, матдә-төш, лазерлар, асылташ-бриллиантлар, тәхетләр, сарайлар, хакимдарлар, акчалар, власть, ятимнәр-толлар, үлем-фаҗига һәм яшәү-сәгадәт, өмет-ыша-

нычлар, биеклек һәм түбәнлекләрнең барысын-барысын поэмасына алып керә, әңгәмәне киң полифоник планда алып бара, шуның белән татар шигыренең төшенчәләр географиясен киңәйтә, масштабын үстерә, вакыт-вакыт ул төшенчәләрнең татарча терминын таба алмыйча, үзе ясый алмыйча, интегеп тә калгалый. Әйтик, русчадагы «память» төшенчәсен «хәтер» дип кенә алу акылга да, җанга да берни бирми.

**Күпме алар! Күпме алар!**
**Фаҗигаләр! Фаҗигаләр!**
**Тарих үзе буйдан-буйга**
**торамыни фаҗигадан!**
**Кем соң әйтә ала алдан**
**Килмәс диеп ул яңадан!**
**. . . . . . . . . . . . .**
**Җир өсте чак күтәрерлек**
**байлыклар тудырып та,**
**артык булып йөрүчеләр**
**ачлыкта һәм хурлыкта —**
**алар бит сез,**
**алар бит сез,**
**Галиҗәнап**
**гали җаннар!**

**Фаҗигаләр, фаҗигаләр!**
**Җиңел, эзсез үтмәсеннәр!**
**Театрлар уйналалар**
**башларыгыз лепкәсендә.**
**Менә кайчан кирәк хәтер!**
**Хәтер!**
**Хәтер!!**
**Хәтер!!!**

Биредәге «хәтер» русчаның «память» сүзеннән ясалган калька гына, ул безгә аңлашылып җитми, шигырьнең агышыннан үсеп чыкмый. Ә бит менә нәрсә сорала:

**Менә кайчан кирәк безгә**
**Үткәннәрне онытмау!**
**Үлемнәрне онытмау!!**
**Сугышларны онытмау!!!**

Ул чагында шигырь аңлаешлырак, гадиләргә дәшкән сүз-әңгәмә үтемлерәк була, йөрәктән чыккан йөрәккә барып керә ала. Шагыйрьнең тел-инструменты бу урында аеруча үткен, аеруча чын, аеруча төгәл булырга тиеш.

«Сәйдәш» дип исемләнгән күләмле өченче әсәрнең жанрын, миңа калса, поэма дип түгел, шигъри повесть дип билгеләү дөресрәк булыр иде. 10—9 иҗекле, тигез һәм салмак агышлы бу тезмә әсәрдә повестька хас төп сыйфат бар: татар культурасына бөек Тукайдан соң килгән олы шәхес Сәйдәшевнең үсеш эволюциясе биредә хроникаль эзлеклелек белән тасвирлана, геройның җаны аша, аның халыкка булган мөнәсәбәте аша, фәлсәфи-психологик уйланышлар-кичерешләр аша сурәтләнелә. Илебез тарихының төрле-төрле катлаулы чорлары эстетик аң аша кабат үткәрелә. Талантның халык байлыгы булуы, аны сакларга кирәклеге автор тарафыннан гражданлык кискенлеге белән куела. Минемчә, бу — дөрес, мәсьәләгә коммунистларча якын килү. Әйткәч, әйтеп бетерик: минемчә, шигъри повестька җитмәгән бер нәрсә бар — ул да булса, баш геройның, ягъни бөек композитор Сәйдәшевнең үз даһилыгын ачуы, көннәрдән бер көнне үзенең шуны тануы, шуннан соң гаять зур җаваплылык хисе белән көрәш мәйданына ташлануы. Ә бу югарыгы, кульминацион нокта хәзерге әсәрдә юк әле, аны әле шагыйрьнең күңеленнән үткәреп, ак кәгазьгә төшерәсе бар. Әгәр автор шул хисләрне тапса, Сәйдәш күңеленә тулаем кереп җитә алса, әсәрнең ар-

хитектоникасы тәгәлләнер, ул камилләшә төшәр иде. Ә болай, гомуми агышына карағанда, күңелдә баш геройга карата җылылык, теләктәшлек һәм аның белән горурлану тойгылары уятуына карағанда, бу әсәр «Көрәшчеләр» һәм «Гадиләргә гимн» поэмаларыннан югарырак күтәрелгән.

Әйе, поэма әлегә тәмам камилләшеп җитмәгән, шулай да аны хәзергә сынау, халык хөкеменә кую бик зарур. Фикерне җыйнап әйткәндә, халкыбызның йөз аклыгы булган Тукайлар, Сәйдәшләр турында көн саен әсәр язылмый, инде күп эшләнгән шигъри повестьны талантлы шагыйрьгә без теләгәнчә язып бетерергә булышу — язучылар җәмәгатьчелегенең мөһим бурычы булып кала.

Безнең заман аяусыз бәрелешләр заманы, тарихның барлык кискен борылышларындагы кебек, ике идеологиянең бугазга-бугаз, пычакка-пычак килгән заманы. Димәк, беренче планга көрәшче поэзия чыгарга тиеш.

Шагыйрь үзе поэзиядә көрәшче төшенчәсенә менә нинди мәгънә сала:

**Көрәшче шул —**
**Кеше дигән бөек затны олылаучы,**
**шәхесенә дан җырлаучы.**

**Көрәшче шул —**
**бүгенгене кадерләүче.**
**Киләчәккә ышанычны ныгытучы.**

**Көрәшче шул —**
**матурлыкны арттыручы**
**җир йөзендә һәм кешеләр күңелендә,**
**илаһи көч — мәхәббәтне**
**кояштан да биеккәрәк күтәрүче.**

**Көрәшче шул —**
**бүтәннәрнең бәхете өчен**
**үз гомерен яндыручы,**
**үлгәч тә яши алучы.**

Күрәбез, Равил Фәйзуллин иҗат программасын ачык итеп әйтеп биргән. Әгәр шагыйрь шушы программаны ахыргача башкарып чыгарырга тели икән, аңар талантлы булу гына җитми, ул һәрдаим халык һәм ил язмышының үзәгендә торырга, үз дәверенең, үз халкының, үз иленең чын улы булып кала алырга тиеш.

Мин үзем Равил Фәйзуллинның ныклыгына, алга таба да яңа эстетик кыйммәтләр тудыра алачагына нык ышанам. Яшьли ил күләм мәйданга чыга алуы, табигать биргән сәләте, җиптәшлеге, хезмәт яратуы, үз принципларын үткәрүдә ахыргача көрәшә алуы һәм, ниһаять, вак-төяк бәя-сүзләрдән өстен тора белүе безне моңа нык ышандыра. Мин аның зур дингездә зур кораб булуын бик телим.

Халык бүгенге әдәбиятта Тукайлар эстафетасын лаеклы дәвам иттерердәй зур шагыйрьләрне зарыгып көтә.

Салих Маннапов

# МИН СЕЗГӘ ЫШАНАМ

*Вакыйф Нуруллин иҗаты турында*



Һәр авыл читендә диярлек яшел чирәм белән капланган иске чокырлар була. Ташланган нигез урыннары гына түгел алар, күбесе — сугыш елларында казылган окоп эзләре. Халкыбызның бөек Җиңүгә ышанычы ерак тылдагы әлеге окоплардан да калкып чыккандыр төсле. Дәһшәтле еллар авырлыгын үсмер иңнәрендә күтәргән буыннар яшьлеге дә җирнең әнә шул иске яраларына охшаган.

Сугыш чоры балаларының бик табигый һәм самими, әмма гадәттән тыш җитди кичерешләре, гыйбрәтле язмышы онытылырга тиеш түгел. Алар, барыннан да бигрәк, сугыштан соң туган һәм туачак яшьләр өчен кирәк. Шуңа күрә ул буын язучыларын — Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баянов, Мөхәммәт Мәһдиев һәм башкаларны иң әүвәл үз кордашларының аманәтен үтәү миссиясе мәйданга алып чыккандыр кебек. Язу стильләре белән бер-берсеннән бик нык аерылып торсалар да, язмышларына Бөек Ватан сугышы баскан уртак мөһер якынайта аларны. Геройлары төрле-төрле булса да, асылда, бер чор, бер буын вәкилләре, шул буынның әхлакый йөзен билгеләүче кешеләр. Димәк, бу авторлар әсәрләрендәге уртаклыкның нигезе — тема якынлыгы гына түгел, аларда гәүдәләнгән тормыш дөреслеге, гуманистик юнәлеш бердәмлеге, тормыш сөючән рух бөтенлеге.

Сугыш елларындагы авыл хакында язылган әсәрләрнең күбесен әнә шундый сыйфатлар берләштерә. Монда аларның һәммәсен дә атап-санап чыгу максат итеп куелмый. Ләкин тагын бер автор, тагын бер әсәр һичшиксез телгә алынырга лаек. Юк, сүз сөрешенең алга таба әлеге язучы турында барасына бәйле рәвештә генә түгел. Киресенчә, язучының бүген игътибар үзәгенә куелуы үзе нәкъ менә шул — беренче әсәре белән үк укучыларын тапканга, тәнкыйтьтә дә «боз кузгалу» дип югары бәя алганга күрәдер әле. Шул беренче табышларын үстерү нәтиҗәсендә иҗатының матур дәвамына ирешкәнгә күрәдер.

Табышмак ясап тормыйк: сүз Вакыйф Нуруллинның «Шинельсез солдатлар» дигән мәгълүм повесте турында бара. «Шинельсез солдатлар» безнең прозада яңа этап башлануы — «боз кузгалуы» хакында сөйли»,— дип үз вакытында Рафаэль Мостафин язып чыккан иде.

«Шинельсез солдатлар» минем өчен — әниемнең бик иртә чаларган чәчләре һәм авылыбыз читендәге окоп эзләренең телгә килүе булды. Бу буын кейгән икмәк кебек балачагы һәм йомшак күңелле, сөялле куллары белән хәтеремә уелып калды.

«Шинельсез солдатлар» — авыр сынаулар басымына ахыргача түзә алмаган яшь хатын фаҗигасен ачкан повесть. Язучы төгәл һәм тыйнак буяулар белән сугыш чорының драматик тормышын тасвирлый. Шул ук вакытта әсәрнең мәгънәви офыгы, перспективасы киңрәк: ул күпчелек геройларның әхлакый сафлыгы, фидакарьлеге һәм рухи ныклыгына таяна.

«Шинельсез солдатлар» — балачак турында хикәят. Аның яшь геройларына уен гына түгел, уку да авырлык белән эләгә. Бик иртә җитдиләнергә, тәртә арасына керергә туры килә аларга.

Язучы шушы ике юнәлешне Равил исемле үзәк герое күңелендә кисештерә. Вакыйгаларга алты-җиде яшьлек малай күзе белән карауның отышлы яклары һәм үз кыенлыклары бар. Әдәби тәнкыйть В. Нуруллинның тормышны шомартып сурәтләү, яки авырлыкларны артык күпертеп бирү кебек чиктән-чиккә ташланмавын бертавыштан диярлек билгеләп үтте. Беренче повестенда ук язучының үз башыннан, үз күңеленнән кичергәнне генә тасвирларга омтылуы күренде, алдагы әсәрләрендә исә ул шушы сыйфатларның табигыйлек һәм тормышчанлыкка ирешү юлы булуын раслады. Шулай да, «Шинельсез солдатлар»дагы монолог алымы әсәрнең ихласлылыгын самимилеген арттырса да, өлкәннәр язмышын фәлсәфи тирәнлеге, катлаулылыгы һәм, димәк, бөтен дереслеге белән сурәтләү мөмкинлеген чикләгән. Моның төп сәбәбе, күрәсең, геройның яшеннән һәм «мин» дип сөйләвеннән бигрәк, авторның иҗат тәҗрибәсезлегендә булгандыр.

Вакыйф Нуруллинның үз балачагы да төрле әсәрләрендәге яшь геройлары — Равил һәм Сафиуллалар кебек үк сугыш елларына туры килә. Кама буе болыннарында ат көтеп, колхоз эшенә йөреп үсә, зур кыенлык белән белем ала. Язмыш уртаклыгы белән генә түгел, үзенең холкы-фигыле белән дә ихлас күңелле, төпле-җитди, эшкә батыр геройларына охшаган бугай ул. Ләкин язучы кешенең бәхетле язмышы да шунда — ул бер тормыш, үз тормышы белән яшәми, укучы күңелендә калырлык геройлары булып та яшәү хокукы ала. Шунлыктан биографик хатирәләргә таяну, аның өчен үзмаксат дәрәҗәсендә калмыйча, шәхеснең рухи дөньясын, әхлакый асылын өйрәнү алымнарыннан берсе — иң беренчесе булып аңлашыла.

Бу үзенчәлек «Әгәр син булмасаң...» повестенда бигрәк тә ачык күренә. Утызкырык ел элек барган вакыйгаларның мәгънәсе, әһәмияте сугыштан соң туган буын укучыларын дулкынландыра ала икән, моның сере дә беркадәр шунда — авторның үз яшьлегенә бүгенге акыл белән, дәвамлы хәрәкәтнең, зур тормышның җанлы бер кисәге итеп карый алуындадыр. Шуңа күрә ике әсәрнең дә төп эчтәлеге аерым күренеш-вакыйгалар киртәсендә генә калмый. Аларның тормышчан пафосы сагыш белән өретелгән. Әмма бу — якты сагыш. Кадерле кешеләреңне, кадерле хисләреңне сагынып сагышлану. Ул укучыны сафлыкка, пакьлеккә, яшәеш һәм рух чишмәләребез башланган нигезгә алып кайта. «Әгәр син булмасаң...»да шул яктылык тәвәккәл һәм беркатлы Равилнең озын толымлы чая Рухиягә мәхәббәте сурәтендә тартып тора. Көтмәгәндә бөтен барлыгын биләп алган шушы хис егетне тагын да матуррак һәм көчлерәк итә: әгәр ул булмаса, бөтен кыенлыкларны җиңә алыр идеме икән, зур максатларына ирешә алыр иде микән Равил?! Шуңа күрә язучы үзенең яшь героеннан чибәр кызның хыянәтен дә гафу иттерә. Чөнки мәхәббәт чынлыгы сөйгән кешеңне кичерә белүдә дә сынала.

Әйе, «Шинельсез солдатлар» һәм аның мөстәкыйль дәвамы булган «Әгәр син булмасаң...» повестьларының үзәгендә — фаҗигале язмышлар һәм авыр елларда бөреләнгән беренче мәхәббәт. Ләкин әлеге әсәрләр ул хакта гына түгел. Алар кешелеклелек турында, адәм баласының дөньяны яңабаштан үзләштерү чоры турында уйланырга мәҗбүр итәләр. Әйдәгез, күңел күзе белән дә укып карыйк: бу әсәрләрнең төп геройлары — алты-җиде яшьлек малай, яшүсмер егеттән дә бигрәк, аларга тормыштагы мөнәсәбәтләр катлаулылыгын ачып биргән кешеләр түгелме? Кырыс һәм кайгыртучан мәктәп директоры, түзем һәм сабыр әнисе, бәхетсез Нәсиха җиңгәсе, «Намус» романындагы Нәфисәнең сеңелесе кебек намуслы һәм гадел Фәйрүзә... «Шинельсез солдатлар»да нәни геройның үзеннән бигрәк, аның әхлакый үзәге тамырлана торган туфрак күбрәк кызыксындыра язучыны. «Әгәр син булмасаң...»да әлеге юнәлеш тагын да эзлеклерәк төс ала: анда без яшь егетнең характеры формалаша барган чорга тап булабыз.

Килешмәүчән иҗтимагый көчләр бәрелешен, масштаблы, кискен драматик вакыйгаларны үз эченә алган «Яшьнәп үткән яшьлек» повесте, беренче карашка әлеге әсәрләрдән бөтенләй аерылып тора кебек. Ләкин аның төп каһарманы — шактый тормыш тәҗрибәсе тупларга өлгергән һәм революцион көрәштә зур чыныгу алган

Миңнуллага әле нибары унсигез генә яшь. Аның яңа давыллы вакыйгалар уртасында чыныгуы укучы күз алдында дәвам итә. Димәк, бу әсәр дә чор белән герой арасындагы эчке бәйләнешләрне эзләү рухында иҗат ителгән.

«Яшьнәп үткән яшьлек»тә Вакыйф Нуруллин иҗатына хас яңа бер үзенчәлек сакланып һәм көчәеп килә: ул да булса — әсәрнең үзәге итеп тормышта булган реаль вакыйгаларны алу. Бу очракта без документаль материалларга таянып иҗат ителгән повесть белән очрашабыз. Үзе өчен бөтенләй яңа чорга мөрәҗәгать итсә дә, язучы көрәш һәм яңарыш романтикасы белән сугарылган көннәрне кызыклы ракурста чагылдыра алган. Көрәшләрнең зур тизлек белән алышынуы, геройларның бер вакыйгадан икенчесенә кискен күчеше чор сулышын шактый сизгер тоеп, җете һәм мавыктыргыч итеп сурәтләнә. Әсәрдә күп санлы геройлар катнашуы да язучыны аптырашта калдырмаган, ул әлеге характерларны, язмышларны һәркайсын бер төенгә туплап күз алдына китерергә омтыла. Төрле кыяфәтләргә кереп йөргән контрреволюционер Хәйруллин, мәсәлән, әнә шулай төгәл генә берничә штрих белән фаш ителә. Шул ук вакытта Зәйнәп, Зәйнулла кебек кайбер персонажлар очраклы гына чагылып киткәндәй булалар. Мондый кимчелектән Миңнулла образы да бөтенләй үк азат түгел. Йөгереклек, эскизлык, маҗаралылык белән мавыгып алу аның характер үсешен күзәтергә комачаулый. Нәтиҗәдә, аерым күренешләр һәм детальләр әсәрнең төп җирлегеннән бүселеп-бүселеп китә, анда сурәтләнгән катлаулы вакыйгаларның мәгънәсе ачылып җитмәгән кебек тәэсир кала. Моның төп сәбәпләреннән берсе, күрәсең, әсәргә артык җитди, документаль төс бирергә омтылудадыр. (Бу хакта үз вакытында Атилла ага Расих та бик урынлы кисәтеп үткән иде). Тарихи мәгълүматларга таяну, бер яктан, ярдәм иткән булса, икенче яктан, язучы алдына өстәмә таләпләр куя. Әлеге очракта «материал каршылыгы»н җиңеп бетерә алмау, әдәби әсәрне «оештыру алымнары»на җитәрлек игътибар итмәү дә шактый аяк чалган шикелле.

«Шинельсез солдатлар»да, мәсәлән, тормыш авырлыгын әле нык тоеп җитмәгән нинәренә күтәргән яшь геройларын тасвирлаганда, язучы тормыш дөреслегенә тугрылыклы кала алган иде. Равил һәм аның дуслары үз яшьләренә карата зуррак, җитдирәк күренсәләр дә, балалык бары-бер үзенекен итә, үен дигәндә дөньядагы әллә нинди хәсрәтләрне дә оныттыра... Чулак Самат образы да бөтен өшәкәлеге һәм мескенлеге белән хәтердә уелып калырлык. Ләкин кайвакыт автор ашыга төшә, әсәрнең бусагасында ук безне кисәтеп, акка-карага аерып куя, аннары инде шул бәйләмәсен дәлилләргә генә керешә кебек. Геройларның асылы болай алдан ук билгеләп куелган очраклар каерып ачылган йозакны хәтерләтә, инде шул йозакка ачкыч эзләп маташу безне кызыксындырмый башлый. Әнә шуңа күрә Равил Нәҗметдиновның зур мәртәбәләргә ирешкәч Рухиядән алган хатын яки Миңнулланың кайбер ситуацияләргә ачык максатсыз килеп керүен укучы буларак кабул итүе кыен.

Шулай да, тулаем алганда, «Яшьнәп үткән яшьлек» язучының үз алдына куйган катлаулы бурычны уңышлы гына башкарып чыгуы турында сөйли. Ул тынгысыз хезмәт, җентекле өйрәнүләр нәтиҗәсендә туган. Аның революцион романтика белән сугарылган үзенә генә хас һавасы, җирлеге, безнең чорны кыйренке вакыйгалар һәм тәвәккәл геройлар язмышына тоташтырып торган «детонатор җебе» бар. Һәрхәлдә, әлеге әсәрнең үзенә игътибар җәлеп итүе һәм телевизион спектакль итеп эшләнүе очраклы хәл түгелдер.

Аерым кимчелекләренә дә карамастан, «Яшьнәп үткән яшьлек» повесте — Вакыйф Нуруллинның иҗади үсеше өчен дә әһәмиятле бер күрсәткеч булып тора. Тормышыбызның рухи нигезен, әхлакый эчтәлеген ил-көн тарихыннан, халык язмышыннан эзләргә омтылуы белән ул үзенең язучы буларак яңа бер баскычка күтәрелүен раслады. Заманга хас сыйфатларны үзендә туплаган каһарманнар, мәгънәви асылы белән бүгенге көнгә юнәлгән тарих алдагы әсәрләрдә тагын да кыюрак сүз алырга тиеш иде.

«Аккан су юлын табар» дигән повестегызны укып, чын мәгънәсендә рәхәтлек, хозурлык кичердем... Минем башыма хәтта, автор әллә үзе колхоз җитәкчесе булып эшләдеме икән?— дигән уй килде».— «Түбән Кама» совхозы директоры Габделхак Шакировның язучыга ачык хаты менә шулай башланып китә.

Авылның тарихи язмышын нечкә тою, гомумән, безнең әдәбиятның бер үзенчәлеге булып тора. Аксакал язучыларыбыздан Гомәр ага Бәширов иҗатын гына искә төшерик. Халыкның күңел хәзинәсен шагыйрәнә нәзакәтлек белән тасвирлаган «Туган ягым — яшел бишек», авыл кешесенең олы җанлы, тырыш табигатен ачкан «Намус», җир-су, нигез язмышын күңеленә якын алып кайгыртышкан «Җидегән чишмә» әсәрләре... Аларда табигать һәм тарих үзе көчле әхлакый факторга әверелә, аларның үзәгендә — иңнәренә дөнья баскан чакта да рухын саф көе саклап калган игенче образы.

Соңгы еллар прозабызда «авыл» мәсьәләләрен еш кына хуҗалык җитәкчесе аша гәүдәләндерергә омтылу да күзгә ташлана. Әсәрләребездә урын алган колхоз председательләре, уенын-чынын бергә кушып әйткәндә, кечерәк бер районның бөтен хуҗалыкларын тәэмин итәрлек санга җитте бугай инде.

А. Расихның «Язгы авазлар», С. Рафиковның «Авыл иртәсе» романнарында үзәккә алынган мәсьәләләр соңрак Г. Ахуновның «Чикләвек төше», Х. Хәйруллинның «Канатлар талмасын» повестьларында, М. Хәбибуллинның «Чоңгыллар» романында һ. б. әсәрләрдә киң яктыртылды. Әмма шунысы да бар: авыл проблемаларын күтәргән әсәрләрдә вакыт агышы аеруча ачык сизелә һәм тәнкыйтьчеләрнең аларга карата ара-тирә «кечкенә авыл», «кечкенә җитәкче» дип канәгатьсезлек белдерүе дә тикмәгә генә түгел.

В. Нуруллинның «Күпер чыкканда» повестендагы Өлфәт Хәкимов, «Чикләвек төше»ндәге Халик Саматов кебек үк, илленче елларда буын ныгыткан председатель. Аларның икесенә дә кыюлык һәм эшлеклелек хас, икесе дә төрле каршылыкларны җиңеп, авылның тормыш хәлен яхшырту өчен тырышалар. Шул ук вакытта бу геройларның иҗтимагый һәм шәхси тормышын сурәтләү нисбәте төрлечә булуы да мәгълүм. Ягъни гаилә мәшәкатьләренә баш бирми торганрак булып күренгән «дәүләт кешесе» Саматов белән чагыштырганда, Өлфәт күбрәк мәхәббәт һәм кешелеклелек мөнәсәбәтләрендә ачыла. Әмма аларны бер-берсенә каршы кую да урынлы микән?! Аерым очракта геройның рухи дөньясын күбрәк шәхси яки иҗтимагый мөнәсәбәтләр аша ачарга омтылу тормыш материалы һәм язучының максаты белән бәйле булырга мөмкин. Чөнки колхоз председателе — әхлаклылык дәрәҗәсенең алдан билгеләнгән бер баскычы түгел.

Билгеле, «Күпер чыкканда» әсәрендә әхлакый әһәмияткә ия булган темалар белән авыл хуҗалыгы проблемалары бергә үрелеп бара. Шуңлыктан, Өлфәткә карата «кечкенә председатель» дигән сүзләр ул хәл итәргә алынган күп кенә мәсьәләләрнең инде көн тәртибеннән төшеп баруын аңлата булса кирәк. Мондый искәртүне хәтта кайбер укучыларыннан да ишетү язучыга тәэсир итми калмаган, ахрысы. «Аккан су юлын табар» исемле повестен ул безгә: «Әнә шул иптәшләрнең теләкләрен истә тотып, шуларга җавап йөзеннән яздым»,— дип тәкъдим итәргә карар кылды. Бусы бер хәл. Тик менә, җитмешенче елны язылган «Күпер чыкканда» әсәреннән соң авыл тормышында зур үзгәрешләр булды, «элекке җиде-ун класс белемле җитәкчеләр урынына махсус югары белем алган, яшь, энергияле иптәшләр килде»,— дигән фикергә ышануы, аны «йотып җибәрүе» инде шактый кыен. Андый кискен үзгәреш җитмешенче елдан соң гына булгандыр дип тә ышанылмый. Ул чакта яңа повестька герой итеп 24 ел председательлек иткән, шул ук Өлфәттән өч-дүрт яшькә генә кече булган Булат Вәлиевне алу акланамы? Әллә шактый штрихлы гына сурәтләнгән яшь агроном Фәгыйт яңа буын җитәкче булып күз алдына басамы? Кыскасы, бу ике әсәрне, гәрчә икесенең дә төп каһарманнары колхоз җитәкчесе булса да, вакыт — чор ягыннан бер-берсенең дәвамы итеп карарга сәбәп юк. Өлфәт белән Булатның характер үсешендә дә, җитди сынауларны кичеп колхозда абруйлы хуҗа булып җитлегү процессында да эчке бер уртаклык сизелә. Алар шактый еллар буе ызандаш колхозларны бергә-бергә җитәкләгән председательләр сыманрак хәтердә кала. Әмма «Аккан су юлын табар» повесте язучының осталыгы тагын да арта төшүен, геройларның табигый үсешен эзлеклерәк күзәтә алуын, характерлар чынлыгы аша катлаулы тормыш фәлсәфәсен ачуга ирешүен күрсәтте. Бу әсәр һәм аның герое язучының үз иҗатында гына түгел, гомумән, прозабыз үсешендә игътибарга лаек вакыйга буларак кабул ителде.

«Аккан су юлын табар»ның яңалыгы яңа авыл, яңа проблемаларда гына түгел.

Аның герое хуҗаларча, һәрьяклап һәм колачлы итеп фикерләргә өйрәнгән кеше, ул зур максатлар, җитди уйлар белән яши, кешеләр арасында намуслы мөнәсәбәтләр өчен көрәшә. Безнең өчен аның менә шундый әхлакый позициясе аеруча мөһим. Әсәрдәге төп конфликт та шул нигездә барлыкка килә. Һәрвакыт шәхси мәнфәгатьләрен генә алга сөргән кара эчле Шәйхи белән булган каршылык үсәннән-үсә барып, яшәү максатлары һәм принциплары арасындагы килешмәүчән конфликтка әверелә.

Булат — Өлфәт кебек үк кичәге фронтовик, язучының бөтен геройларына хас булганча, әзрәк беркатлырак, ләкин үз сүзен итә торган, кыю һәм намуслы кеше. Шул ук вакытта ул коеп куйган фәрештә итеп тә сурәтләнми. Укучы Булатка ышана һәм аның кайвакыт каушап калуын, беркатлылыгы белән кайбер хаталар җибәрүен дә гафу итә, аңа чын күңелдән теләктәшлек күрсәтә. Димәк, язучы үз героен кызыл кара белән тәзәтеп, алдан билгеләп куелган кысаларга гына куеп тасвирлаудан котыла алган. Катлаулы мөнәсәбәтләр бәрелешендә Булатның характеры ныгый, ул, аккан су шикелле, бормалы юллар үтеп булса да, үзенең төп үзәнен таба. Булат Вәлиев председательлек дилбегәсен үз кулында тоткан егерме дүрт ел эчендә колхоз авылы бик күп мәсьәләләрне хәл итә, зур үзгәрешләр кичерә. Шул җирлектә әсәр үзәгеннән бик мөһим бер нерв җепселе булып заманча эш-идарә стиле, җитәкче һәм халык мөнәсәбәтләре турында уйланулар сузыла.

Ләкин, әлеге дә баягы, «автордан» әйтелгән сүзгә әйләнеп кайтсак, бу проблемалар яңа дә «кичәге» булып чыкмасмы соң? (Тәнкыйтьтә инде, «кызганычка каршы, Булат та, Өлфәт кебек, сугыштан соңгы һәм илленче еллар колхоз җитәкчесе» дигән сүзләр ишетелергә өлгерде). «Кызганычка каршы...» Хикмәт нәрсәдә? Язучыга тагын бүгенге председательне эзләп юлга чыгаргамы? Иртәгә аңысы да искермәсме?

Әлбәттә, әдәби әсәрләребездә бүгенге колхоз чынбарлыгын, аның типик характерларын, заманча хуҗалык итү принципларын күрсәтү бик табигый һәм урынлы теләк. Шул ук вакытта көн кадагына сугучы темага алыну язучыдан зур кыюлык һәм намуслылык таләп итә. Ул таләпләр үтәлмәгәндә, оперативлык күрсәткән булып, халтура тәкъдим итүчеләргә дә, әсәремне язып бетергәнче, бу кампания үтеп китмәс микән дип борчылучы һөнәрчеләргә дә юл ачыла. Автор бер көнлек проблемалар белән мавыккан арада (ашлама мәсьәләсеме ул, яки зур төзелешкә киткән яшьләр турында фәлсәфәме), тормыш аларны үзе хәл итеп өлгерә, кичәге геройлар яңа мөнәсәбәтләргә керәләр. Алар шул әсәрдә генә фоторәсемдәге кебек тынсыз-өнсез калырга мөмкин.

«Күпер чыкканда» һәм «Аккан су юлын табар» повестьларын укыганда күңелгә әнә шундый уйлар килә. Колхоз җирлегендә туган кайбер көндәлек мәсьәләләр, бигрәк тә аларның бердәнбер чишелеше белән укучы алдына ачып салынганнары, әлбәттә, кәгазьгә төшкәндә үк «кичәге» булырга өлгерә. Хәзергә «бүгенге» булган кайбер әсәрләрдә геройларны яңа силос манаралары фонында мөнәсәбәткә керту генә коткармаячак. Ә менә «Күпер чыкканда» әсәрендәге Өлфәтнең рәхимсез вөҗдан газабы, «Аккан су юлын табар» әсәрендәге тормыш позицияләренең килешмәүчән бәрелеше кебек әхлакый коллизияләр исә әле алдагы буыннарны да дулкынландырыр дип өметләнергә була. Шуңа күрә әлеге әсәрләрнең декорацияләре, хуҗалык мәсьәләләре күбрәк кичәге авылга караса да, Өлфәт һәм бигрәк тә Булат кичәге көн геройлары түгел. Аларның кешелеклелек дигән олы хакыйкатьнә якланган гыйбрәтле язмышы яңа буын укучылар күңелендә яшәргә хокук ала.

Билгеле, безгә Булатның, мәсәлән, никадәр тәвәккәл булса да, еш кына оборонага күчүе, кайвакыт кисеп ташлаган тырнагына да артык зур әһәмият бирергә омтылуы ошап бетми. (Җилбәзәк хатын белән маҗарасын бик тәмләп сөйләп утыруын гына күрегез сез аның! Илле яшьлек председатель характерына нидер өсти, яки нинди дер иҗтимагый-әхлакый мәсьәлә күтәрә дип буламы инде бу мисалны). Соңгы исәптә, повесть героеның үзе турында бик тәфсилләп сөйләвендә әллә ни гонаһ та юк. Шәхси тормышындагы тетрәнүләр тәэсирендә Өлфәтнең хисләре, сөйләме шактый киеренке булса, Булат җил-давыл узып киткәч кенә башыннан үткәннәрне «көндәлегенә яза». Шуңа күрә аның хикәясе лирик чигенешләр, фәлсәфи уйланулар исәбенә салмаграк тәс ала, фикер җебе эзлеклерәк сузыла. «Аккан су...»ның тирәнлеге, саллылыгы да әнә шуннан — төп каһарманнарның шәхес буларак киң ка-

рашлырак, рухи баерак булуыннан килә торгандыр. Күңелебезгә хуш килгән геройның нинди авырлыклар кичерсә дә, тар күңеллелек күрсәтмәячәгенә ышанасың. Аның Шәйхи кебек типлардан да кешелеклелек чалымнары эзләвен күрәсе килә. Әлеге җәһәттән, Самат, Рәдиф образларына язучы илтифатлырак һәм объективрак булган, ахры. Алар эчке каршылыклары белән, шактый җанлырак килеп чыккан иде. Инде кайчак ул бәндәләр лакмус кәгазе урынына гына файдаланыла башлый икән, ихтимал, моңа әсәрләрне бер герой исеменнән сөйләп барганда автор позициясенең анык булмавы да сәбәпчедер.

«Шинельсез солдатлар»ында ук күренгән хикәяләү рәвешен — вакыйгаларны төп геройларның үзләреннән сөйләтү (исповедь) алымын Вакыйф Нуруллин яратыбрак куллана. Язучыны лирик «мин» исеменнән сүз алырга нинди эчке ихтыяҗ һәм максатлар юнәлтә торгандыр, кистереп кенә билгеләве кыен. Моның, бүгенге поэзиядә лирик башлангыч көчәйгән кебек, укучы белән күзгә-күз калырга, аңа турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә, аның ышанычын яуларга омтылу билгесе булуы да бар. Бәлки ул, вакыйгаларны сөйләп кенә чыгуга караганда, хикәяләүче герой артына «яшеренеп», аларга мөнәсәбәтеңне белдерү мөһимрәк, дигән караштан килеп чыгадыр. Тыштан гына гади тоелган бу алым автор өчен дә, әсәр геройлары өчен дә катлаулы мәсьәлә: чама тойгысын югалтма, укучыны җәлеп ит, ышандыр, уйландыр. Күңелгә ятышып бетмәгән очракларның барысы да әнә шул гадилеккә, чынлыкка ышанып җитмичәрәк караудан килеп чыгадыр. (М. Мәһдиев тә бер мәкаләсендә В. Нуруллин образларын табигый агыштан кинәт кенә зур орбитага күтәреп чыгарырга ярата дигән иде).

Ләкин, асылда, язучы үз максатына ирешә дип әйтү хата булмас: автобиографик нигездә язылган әсәрләреннән соң да ул геройларының күңеленә үтеп керү, аларның тормышы белән яшәү осталыгына ия булуын күрсәтте. «Сүз башы урынына», «автордан» дигән кебек кереш сүзләргә кадәр шушы максатка хезмәт итә. Әсәрләрдә чагылган язмышлар тагын да аңлаешлырак, тагын да якынрак була бара. Язучы һәм аның герое укучы алдында бөрганалып маташмый, турысын сөйли. Әдәби модаларга иярмичә, авылның үзе кебек табигыйлеккә, сюжет һәм стиль гадилегенә ирешүнең нигезендә исә тынгысыз иҗади эзләнүләр, маңгай һәм акыл тире ята. Шуңа күрә Булат белән Айсылу кебек, «Шинельсез солдатлар» һәм «Аккан су юлын табар» кебек исемнәр поэтикасы да сокландыра. Шуңа күрә, язучыга килгән күп санлы хатларга кушылып: «Мин Сезгә һәм Сезнең геройларыгызга ышанам!» — дип әйтәсе килә. Бу әсәрләрдә авылны яратып, авыл кешесенең җанын аңлап, телен тоеп, үзе якын күргән темаларга гына һәм чынбарлыкка хилафлык итмичә язарга омтылу өстенлек ала һәм язучының киләчәгенә зур ышаныч уята.

Җиңел түгел Вакыйф Нуруллинга. Башкалар инде азмы-күпме кагылган темалар белән эш итә,— үз сүзен әйтү җиңел түгел. Асылда традицион алымнарга гына таяна,— үз тавышын ишеттерү җиңел түгел.

Аңа бер генә юл кала — кичерешләр чынлыгына, мәгънә яңалыгына омтылу. Сүз-яңгыраш төгәллегенә ирешергә һәм укучыны үзенең фикерләү ритм-интонациясенә буйсындырырга тырышу. Безнең күңелләргә юл тапкан барлык әсәрләре әдипнең әнә шул авыр, катлаулы бурычны башкарып чыга алуы турында сөйли. Аның һәр әсәрен бер бөтен итеп туплаган көч публицистика белән тирән лиризм, документаль төгәллек белән сәнгатьчә гомумиләштерүнең бергә үрелүендә. Алай гына да түгел, автор шәхесенең эзлекле һәм максатчан булуында.

Ерак тылдагы окоплар да җиңү көнен якынайтышкан кебек,— аерым кешеләр язмышы аша язучы буыннар язмышына, халык язмышына алып чыга. Бу юлның һаман киңәя һәм биегрәк үрләргә күтәрелә баручы дәвамы булырга тиеш.

Фоат Галимуллин

# ХИКӘЯ УКЫГАНДА

Әдәбиятыбыз хикәя кытлыгы кичерә дип чаң сугуларның файдасы булды, ахры. Соңгы вакытта роман, повестьлар белән бергә хикәяләр дә шактый еш күренә башлады. Хикәя кебек үтә нечкә табигатьле, сак мөнәсәбәт күрсәтүне таләп итә торган жанрга да үги итеп карамыйлар хәзер язучыларыбыз. Соңгы елларда басылган хикәяләрнең барысын да күзәтүне максат итеп алмыйча, аларның аеруча характерлыларына гына җентекләбрәк тукталасы килә.

Иң башлап, һич шикләнүсез, Әмирхан Еникинең «Тынычлану» хикәясен атарга кирәктер. Бер хикәягә кешенең тулы күңел дөньясын сыйдыру, укучыларны тетрәндерерлек хәл-әхвәлләрне сурәтләп бирү — талантлы әдипләр өлеше. Хөрмәтле язучыбыз бу юлы да үзе ирешкән югарылыктан чигенмәгән. Бик сирәк әсәр әнә шулай күңелне тетрәндереп үтәргә сәләтле. «Тынычлану» хикәясе исә, тәнкыйтьче Р. Мөхәммәдиев әйткәнчә, «тынычсызлыкка чакырып», һаман да сыкратып тора.

Автор бүгенге көннең иң өлгергән мәсьәләләреннән берсен — кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрендәге намуслылык, эчкерсезлек кебек якларны күтәрә. Кеше тормышында никадәр ямьсез, җан өшеткеч финал булырга мөмкин икән, дип уйландыра. Гасыйм Сәләхов утыз еллап үзен фән кешесе, университет укытучысы дип исәпләгән, үзен дөрес яши дип уйлаган. Харамга кермәгән, ялтыравыклы әйберләргә кызыкмаган, алгы планга чәчрәп чыкмаган. Үз гомерендә бердәнбер тупаслык эшләгән — шулай бер чакны, ачуы килеп, малаеның яңагына чалтыраткан. Бу тупаслыгы өчен дә күңел газабы кичерәп йөргән. Шушы әүлия кеше гаиләсендә дә, эшендә дә хаксызга рәнҗетелә һәм көннәрдән беркөнне аның таушалган йөрәге тибүдән туктый.

Юк авыруын бар итеп больницага ятып, төртмәле сүзләре белән иренең бәгырен кимергән, кешедә күреп, импортный апельсин ширбәтләре таптырып бимазалаган Рәмзия ханымга, эти-әнисенә карата балалык хисләреннән мәхрүм булган Радикка, бер төрле уйлап та, икенче төрле эш итүче, икейөзле профессор Шәйхиевка карата укучыда нәфрәт уяна, ул аларны хөкем итә.

Язучының симпатиясе Гасыйм Сәләхович ягында кебек. Ләкин Ә. Еникинең осталыгы шунда — ул картның бу хәлгә төшүенең сәбәпләрен ачып сала. Ә бу сәбәпләр исә Гасыйм Сәләхович файдасына түгел. Картны укучыга сөйкемле сөякле итеп тасвирлап та, әлеге ямьсез финалның котылгысыз булуын искәртә язучы. Өендә аның белән исәпләшмиләр, аңа гаиләнең материаль ягын тәэмин итүче эш аты итеп кенә карыйлар. Ни өчен? Чөнки Гасыйм Сәләхович гомер буе үзенең тынычлыгын (әйе, нәкъ менә тынычлыгын) саклау турында гына кайгырткан. Хатыны белән бәхәсләшеп кәефен бозмас өчен, баштарак әһәмиятсез булып күренгән вак нәрсәләрдә, соңыннан зуррак, җитдирәк мәсьәләләрдә дә чигенә барган, үз позицияләрен хатынына биргән. «Тынычлык хакына дөреслекне, гаделлекне корбан итеп чигенә» килгәч, тора-бара бу аның гадәтенә кергән, характерының үзенчәлеге булып әверелгән.

Галим буларак үсеп китүенә дә әлеге ягы комачаулык иткән булырга тиеш. Кафедра мөдире вазифаларын намуслы үтәү белән бер үк вакытта җитди фәнни проблемалар өстендә эшләү өчен аңарда көчле теләк, тәвәккәллек, үз-үзен мәҗбүр итү кебек сыйфатлар җитми. Чөнки алар барысы да аның тыныч кына барырга күнеккән тормышына үзгәреш, яңалык китереп кертерләр иде. Дөньяга чыккан китабының әлек-электән басылып эшләп килүенең нәтиҗәсе булмыйча, ниндидер бер вакытлы рухлану нәтиҗәсендә генә язылганлыгын исәпкә алсак, аның хәзерге фәнни таләпләргә җавап биреп бетермәве дә гаҗәп түгел. Галим кешенең ныклы иманы, төпле концепциясе булырга тиеш. Ниндидер бер икейөзле кешенең газетада чыккан рецензиясе генә аның инануын какшатырга тиеш түгел.

Әсәрдән алына торган төп сөземтә шул: кешегә олы гомер юлында мондый ял-

ган тынычлык кирәкми. Нәрсәгә дә булса ышан, шуны эзлә, тап, исбатла, моның өчен бүтәннәр белән конфликтка керүдән курыкма. Шундый процесс кына чын галимне формалаштыра. Шулай булмаса, әлеге тынычлыгың котылгысыз рәвештә тынычсызлык булып әверелачәк.

Хикәяләр арасында тагы да игътибарны җәлеп иткәннәреннән берсе итеп Мөхәммәт Мәһдиевның «Таңы ерак төндә» әсәрен атарга кирәктер.

Хикәя ул шундый жанр, кыскалык һәм осталык аның табигатендәге иң беренче үзенчәлек булып тора. Хикәя артык киң җәелгәнне яратмый һәм тәгәлләкне, җыйнаклыкны таләп итә. Шул тар гына мәйданда кеше характерын, кеше язмышын бирергә һәм алар белән укучыны кызыксындыра алырга көченнән килгән язучыга карата талант сүзен һич тә шикләнмичә кулланырга мөмкин. И. Гази, Ә. Еники, Ф. Хөсни кебек күренекле хикәячеләр аның бик матур үрнәкләрен бирделәр. М. Мәһдиев хикәясен дә әнә шундый критерийлар белән бәяләргә мөмкин.

Хикәядә өч дусның табигать кочагында ике җәйге төнне үткәрүләре сурәтләнгән. Тапкан икән кызык, су буенда таң каршылау да булдымы әш, диярләр, бәлки, кайберәүләр. Ләкин бу ике төн арасында җир белән күк аермасы бар.

Сугыш еллары. Алтынчы классны гына тәмамлаган малайлар Фәйзи, Ислам һәм Фатих, көнен дә төнен дә өйгә кайтмыйча, колхоз сыерларын көтәләр. Ләкин көннәрдән бер көнне аш китереп малайларның тамакларын туйдыручы Җәләли агай исереп йөреп кичке ашны китерми кала. Көндез дә бер чүмеч аш белән генә тамакларын алдаган малайларның үтереп ашыйсылары килә. Шулчак әтисе белән бераз Мари якларында торып кайткан Фәйзи исемле малай андагы ашау-эчүнең муллыгы турында, әллә чынлап, әллә арттырып сөйли башлый. Ә бу исә малайларның ашыйсы килүләрен түзә алмаслык көчәйтә генә һәм, ачның ачуы яман дигәндәй, бер гөнаһсыз, үзләре кебек үк ачка тилмергән иптәшләрен кыйнап ташлыйлар... Бу вакыйга укучыга көчле йогынты ясарлык итеп тасвирланган. Аны укыганда малайларның намуслылыгына сокланасың, яхшы күңелле, әмма сыек буынлы Фәйзи белән бергә аларның дуамаллыгын да аклыйсың.

Ләкин язучыга бу әле аз. Ул шушы өч малайны безнең көннәрдә, кырык-кырык биш яшькә җиткәч кабат очраштыра һәм Мишә елгасы буенда тагын таңны каршылата. Бу юлы инде алар өчесе дә директор: Фәйзи — шәһәрдәге зур бер гастроном, Ислам — совхоз, Фатих — элеватор директоры. Күрәбез, өчесе дә ашау-эчү әйберләре үз кулларында булган эре хуҗалык җитәкчеләре. Алларына патша сыедай ризыклар тезеп куялар. Тик тегә чакта бер кабым икмәккә интеккән кешеләр ризыкка рәтләп кагылмыйлар, табынга хәмер чыгарылуын көтеп нәүмиз калалар. Фәйзи иптәшләренә аракы эчәргә рөхсәт бирми. Аның нияте — иптәшләрен тегә сугыш вакытында үткәргән төн турында аек баштан тагын бер кат уйлату. Кызганычка каршы, Ислам белән Фатих нечкә күңелләләнеп торырлык шәхес булып чыкмыйлар. Хәмер эчсәләр төн буе гәпләшеп чыгасы кешеләр, тамак туйдыргач, йокыга талалар. Бары тик Фәйзи генә үткәннәрне нечкәләп хәтереннән уздыра, иптәшләренә рухи җәза бирә.

Укучыны күп нәрсәләр турында уйланырга мәҗбүр итә хикәя. Хәзерге муллыкка канәгать булу, үткәндәге авырлыкларны онытмау, үз эшләреңә аек акыл белән бәя бирү турында. Әсәр кешеләрдә намуслылык, сафлык сыйфатлары тәрбияләргә булыша.

Дөрес, кечкенә генә бу хикәядә артык урыннар да юк түгел. Җыйнаклата төшсәң ул тагын да күркәмләнер иде. Әсәрнең азагында Ислам белән Фатихның бик әйбәт кешеләр булулары турындагы өстәмә мәгълүматлар укучыны кызыксындырмый. Бу очракта аларның совхозга, элеваторга ничек җитәкчелек итүләре әһәмиятле түгел, аларның, барыннан да элек, кеше буларак ачылулары зарур. Вакыйга сөйләү белән мавыгып, автор персонажларның характерларын тиешенчә ачып өлгерә алмый, бу хакта махсус аңлатырга омтыла һәм сәнгатьлелеккә шактый зыян китерә.

Характерларны ачу ягыннан Шамил Маннаповның «Чехолдагы ракеталар» хикәясе дә кызыклы гына чыккан дип әйтәсе килә. Әсәр үзәгендә ракета частенда хезмәт итүче Галимҗан образы тора. Үткен акыллы, саф күңелле, кешеләрне һәм тормышны яратучы егет укучыга да ошый. Алтын пычракка буялмый, һәрвакыт үз

кыймметен саклый. Галимҗан белән дә шул ук хәл. Гаптук кебек кара эчле, кеше уңышларын күрә алмаучылар аңа төрле яла ягып карыйлар, ләкин Галимҗандагы уңганлык һәм үз бурычын төгәл аңлау кебек сыйфатлар аларны һәрвакыт кире кагарлык. Сугышчан постта ул үзенең сизгер солдат икәнлеген исбатлый. Ә инде Нигат кебек аягүрә йоклап, үз күләгәсеннән куркып йөрүче, илнең язмышын хәл итәргә мөмкин булган җаваплы постта да кеше төсле тора белмәгән зат укучыда нәфрәт тудыра. Кечкенә генә хикәядә персонажларга карата әнә шундый симпатия-антипатия барлыкка китерү, шактый үзенчәлекле характерлар тудыра алу Ш. Маннаповның «Әти урманы» исемле җыентыгында да күренде.

Шамил Маннапов бүгенге проблемаларны яхшы тоя. Ракеталар чехолларында гына торсыннар дисәң, сизгерлекне, хәрби хәзерлекне генә түгел, кешеләрнең әхлакый сыйфатларын да камилләштерергә кирәк. Әлеге хикәясе белән автор шундый фикер үткәрә. Шулай да әсәр әле аерым кимчелекләрдән азат түгел. Артык эпизодлар да бөтенләй юк түгел бу хикәядә. Бәрәңге казуга бару, ефрейтор Пенягинның явызлыгы турында сөйләү төп сюжет линиясенә һич ябышмый. Киресенчә, бу күренештә Галимҗанның Гаптук, Нигатлардан да сыеграк буынлы булып чыгуы гына күренә, һәм моның белән характер бөтенлегенә зыян гына килә. Күңеле тыныч булмаганда, нәрсәдер эзлисе, табасы килгәндә, күңелендә бөреләнгән төрле уйлар бимазалаганда гына язучы уңышка ирешә.

Әхәт Гаффарның «Бер йотым су» хикәясенең отышлы ягы шунда — ул темадан читкә чыкмый, аның һәр сүзе диярлек кеше үз гомерен мәгънәле, үткәндәгеләр өчен үкенмәслек итеп яшәргә тиеш дигән фикерне әйтүгә хезмәт итә. Хикәянең герое Тәхау гомерендә бер гөнаһ эшләгән, бала вакытта үзенең әнеләрен бер йотым су өчен рәнҗеткән. Шул хатирә аңа тынгылык бирми, кәгазьгә төшерүне сорап тора. Тик шунысы бар, Тәхау шушы күңелсез вакыйганы көлкеле хикәя итеп язарга тели. Әмма тормышның үз законы бар — шыксызлык кемдер теләге белән генә көлкеле әйберго әверелә алмый. Тәхау да дөресен язарга мәҗбүр. Ләкин аңа көлке белән елауның бер бөтен булып оеша алмасын аңлау җитми. Тәхау бу килештән язучы булып китә алмаячак. Чөнки ул үз тормышыннан тулысынча канәгать, аның күңеле тыныч. Мондый түгәрәклек Тәхауга уйланырга, хикәясенең дәвамын язарга комачаулый, моңа түземе җитми. Ул әсәрнең башыннан шунда ук ахырына күчә. «Тизрәк ахырын язасы килде. Аныңча иң кызыгы ахырда иде. Теләсә нәрсәнең иң кызыгы ахырда дип белә иде ул». Язучы хезмәтенең иң авыр ягы шул да инде, чит чатка чыкмыйча, магистральне туры тотып, психологик тирәнлек белән ахырга килә белү. Ә. Гаффар бу хикәясендә үзе дә шуңарга ирешкән дип әйтергә була.

Автор хикәяне Василий Шукшинның да язучы булганчы тракторчы Вася гына булып йөргәнлегеп искәртү белән очлый. Бу деталь бераз уйлануларга этәрә. Нәрсә, уналты меңнән артык китап укыган янгын сүндерүче Тәхаудан да вакыты белән язучы чыгар дип әйтергә теләүме бу? Янгын сүндерүче булып эшләгән кешенең язучы булып китүе ихтималы да мөмкин, әлбәттә. Ләкин тау-тау китаплар укыган булса да Тәхауның эчке дөньясы шактый ярлы калуы, дөньядс үз өлешен умырып алырга күнеккән табигате безне шикләндерә.

Соңгы вакытта хикәя төзелеш, сюжет корылышы, характерларны үзенчәлекле тасвирлау ягыннан да шактый үзгәреш кичерә. Бу Ә. Гаффар хикәясендә дә ачык сизелә. Форма ягыннан ул традицион кысаларга гына сыймый, иң әһәмиятлесе — форма биредә әсәрнең төп фикерен әйтүгә буйсындырылган. Анда кискен борылышлы вакыйга юк, аның каравы тыгыз фикер киеренкелеге бар. Әсәрне шул кызыклы итә.

Әйе, хикәя жанрында безнең уңышларыбыз бар, аңа төрле буын язучылар мөрәҗәгать итәләр, һәркем үзенең индивидуальлеген расларга омтыла. Тик индивидуальлек бары формада гына чагылмыйча, фикер үткенлеге, максат ачыклыгы белән дә үзенчәлекле булган хикәяләр озын гомерле була. Моның мисалларын татар әдәбиятыннан күпләп китерергә мөмкин.

Калын-калын роман-повестьлар белән бергә, укучыга хикәя дә кирәк. Кайвакытта яхшы хикәя укыйсы да бик килә.

# ЙОЛДЫЗЛАР СҮНМӘСЕН

Бу яңа китабында Гариф Ахунов язучының тормыш һәм иҗат тәҗрибәсен яктырта[1]. Автобиографик әсәрдә әзлекле рәвештә иҗат психологиясен ача бару үзенчәлекле жанр формасы тудырган. Хәер, мондый жанр бетенсоюз әдәбиятында яши инде: Вера Кетлинскаяның «Вечер. Окна. Люди», Валентин Катаевның «Алмазный мой венец», Мариэтта Шагинянның «Человек и время» повестьлары... Үзебездә моның мисалларын Г. Иделле, Ф. Хөсни, Г. Бәширов, М. Әмирдән табып була.

Кайберәүләр мондый әсәрләрнең язылуын әдипнең картаюына сылтамакчы булалар. Имеш, калын-калын романнар язудан талчыккан, тема һәм материал ала торган чишмәләре коргаксыган каләм осталары, яшьләндә яшьнәп калыйм дигәндәй, ашыгып-ашыгып күргән-белгәннәрен хәтер тартмаларыннан җыештырып, укучы алдына куярга ашыгалар. Авторына карап бәлки бу да дөрестер. Ә менә гомер юлы истәлекләре янына иҗат психологиясе дә кушылса, бу инде художникның бирешергә исәбе юк дигән сүз. Димәк, ул билгесез яңа сукмакларга аяк басып карый, әдәби процессның киңлеген иңләргә омтыла, каләм осталарын үзе алдына модель итеп куя, алардан өйрәнә, үзендә булган кимчелекләрне бетерергә тырыша, еректагы офыкларга күз сала. Гариф Ахунов тәкъдим иткән яңа жанрның хикмәте әнә шунда — иҗат үрләренә югарырак менү өчен чираттагы баскыч булуында.

Әдипне кызыксындырган мәсьәләләр шактый күп: әсәрнең төп фикере, сюжеты — композициясе, прототиплары, яңа тип герой, әдәби процесс, жанр, иҗат портретлары. Әйтик, язучы жанрны диалектик каршылыклар берлегендә карый, аның эчке структурасына үтеп керә һәм жанрны хасил иткән сәнгать чараларын игътибар үзәгенә куя. Жанрның эчке мөмкинлекләрен, үзгәрүен анализлаган чакта автор, тарихи принципка таянып, жанрны үсештә, структура алмашынуында карый. «Миңа калса,— ди ул,— социаль каршылыкларга нигезләнгән элекке еллардагы роман, әйтик Ш. Камалның «Матур туганда», К. Нәҗминең «Язгы җилләр», И. Газиның «Онытылмас еллар» романнары — үзләренең формалары белән инде узылган этап. Хәзерге каршылыклар башкачарак: катлаулырак, күзгә бәрелеп тормаучанрак, нечкәрәк. Аны аңлар өчен кеше күңеленә тирәнрәк үтеп керергә, характерларны күп яклырак, катлаулырак итеп тасвирларга кирәк. Шуңа күрәдер хәзерге заманда психологик роман еш кына телгә алына» («Литературная Россия», 12 декабрь, 1975).

Әдип өлкән каләмдәшләренең иҗат портретларын яратып сурәтли. Һәр язучының карашында үзенчәлекле шәхес, кабатланмас талант иясе булып гәүдәләнелә. ...рәмнәрдә була торган мактау белән мавыкмыйча, Г. Ахунов язучыларның ниндидер мөһим сыйфатларын ачып бирергә тели. Әйтик, Гомәр Бәшировны характерлау өчен ул әдипнең халык тормышына, халык иҗатына мөнәсәбәтен, аның иҗат лабораториясен, стиль үзенчәлекләрен сайлап ала. Иҗат лабораториясенә караган күзәтүләр аеруча кызыклы. «Язучылык эше — гаять дәрәҗәдә үзенчәлекле, берәүне дә кабатламый торган, әллә нинди бер сихри хезмәт. Кайберәүләр... зур романнарын язганчы барысын күңелдән кичереп, хыял белән баетып кына калмыйлар, аның геройларын, шахмат

[1] Г. Ахунов. Йолдызлар калка. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980

тактасына тезгән кебек, башта бик җентекләп кәгазьгә язып, планын корып чыгалар» («Казан утлары», 1976 ел, 4 сан, 89 б.).

Г. Ахунов күренекле әдипләребезнең иҗат процессына кагылышлы гыйбрәтле сүзләрен бик җентекләп җыя. «Алар минем үз иҗатым үсешенә ярамас микән?» — дип уйлый. Иҗатка мондый җитди караш укучыга нык тәэсир итә, ә яшь авторлар өчен болар бик тә кирәкле әдәби мәктәп хезмәтен үтиләр.

Публицистикадан, фәнни-тикшеренү алымнарыннан тыш, «Йолдызлар калка» повесте, алда әйткәнебезчә, автобиографик моментларны эченә ала. Әсәрнең үзәгендә — кеше, шәхес, аның рухи дөньясы, характеры. Автор эзлекле, логикалы сюжет коруга ирешә һәм ассоциацияләргә иркен мәйдан таба. Әсәрнең композициясе катлаулы. Анда автор тавышы ялгыз гына зыңлап бармый, аңар башка авазлар килеп кушыла. Лирик агым вакыт-вакыт драматик конфликтларга алып чыга, күңелгә ятышлы юмор агымы кырыс, төгәл, объектив анализ белән чиратлаша, шәхеснең эчке интим дөньясыннан тормышның кояшлы иркен аланнарына күчеш ясала.

Авторның төп максаты — үзе узган юлга күз ташлау, язучылык эшенең, икмәк үстерү кебек, гади дә, авыр да булуын һәм шул ук вакытта иксез-чиксез серләр тулы, тылсымлы, өйрәнүгә бик үк бирелми торган дөнья икәнен аңлатырга теләү. Шушы максатка ирешү өчен язучы яңа, таушалмаган алымнар куллана, герой күңеленең иркенле һәм ихлас ачылуына ирешергә тели. Вакыт-вакыт арттырып та җибәргәли.

Әсәр авторга яңа художестволы ачышларга старт ясарга мөмкинлек тудыра, язучы каләмдәшләрен принципиаль, җитди диалогка чакыра. Билгеле, әдип күп уйланган, күп кенә әдипләрнең иҗат тәҗрибәсен күңеленнән уздырган. Теләсә кайсы әдипнең иҗат арсеналы, иҗат «кухнясы» китапта язылганга караганда күп мәртәбә байрак. Табигыйдер ки, язучы барлык иҗат серләре капчыгын бер китапта гына бушатып бетерә алмый. Андый серләрне ачар өчен күп томлык әсәр язарга кирәк булыр иде. Чөнки иҗат процессы университет узуга тиң. Кем генә бер селтәнүдә әсәр язган дисең? Язган булса да, андый әсәрнең кыйммәте шул кадәр генә. Әдәбиятта да, тормыштагы кебек, ниндидер үзенә күрә бер «конкурс» уздырыла, ярыш бара. Тик югары таләпләргә җавап бирә алган, бөтенсоюз әдәбияты югарылыгына күтәрелгән әсәрләр генә озын гомерле була, авторларына дан-шөһрәт һәм укучылар ихтирамын алып килә. Художник тик шундый әсәрләр язып кына үзенең профессиясен аклый ала.

Инде килеп, «Йолдызлар калка»ның эчтәлегенә, әсәрдә куелган кайбер проблемаларга кыскача гына тукталыйк.

Әсәр җиде бүлектән тора. Баштагы ике бүлектә язучының балачагы, университетта уку еллары сурәтләнә. Өченче бүлектә Гарифны әдәбият юлына алып кергән кайбер язучыларның портретлары бирелә. Дүртенче бүлек Әлмәттәге яшь язучылар эшчәнлегенә багышланган. Бишенче бүлек авторның нефтьчеләр тормышыннан алып язылган производство романы белән бәйле. (Моны әдәби осталыкка ирешү юлындагы газаплар бүлеге дип тә исемләргә булыр иде.) Алтынчы һәм җиденче бүлекләрдә Чыңгыз Айтматов һәм Мостай Кәрим образлары үзәккә куелган. Боларны автор үзе өчен язучылык камиллегенең үрнәге итеп ала.

Автор автобиографик сюжет сызыгыннан тайпылмаска тырыша һәм, башлыча, татар әдәбияты, ә соңыннан бөтенсоюз әдәбияты орбитасына килеп чыга. Тора-бара герой шәхесен башка иҗат кешеләре читкәрәк «кысып чыгара», герой үзе дә, конкрет шәхес булудан бигрәк, әдәби фигурага әйләнә һәм, Чыңгыз Айтматов, Рәсүл Гамзатов, Леонид Соболев, Мостай Кәримнәр белән аралашканда, алар тарафыннан Тукайлы, Такташлы, Җәлилле һәм Ибраһимовлы татар әдәбиятының бер вәкиле буларак кабул ителә.

Автор үзенең малай чагыннан алып язучы дәрәҗәсенә кадәр үсеп җиткән юлын тасвирлый, күп төрле фактларга, вакыйгаларга мөрәҗәгать итә. Аның бу әсәре «Идел кызы» романына бераз охшаган да кебек. Ике әсәр арасында ниндидер уртаклык та бар шикелле. Романдагы Солтан төрле сыйныф кешеләре белән таныша, бу исә аңарда хезмәт кешесенә хас инстинкт — тарихи сиземләү тәрбияли. Ул аерым кешеләрнең эш-гамәлләрен генә күзәтеп калмый, аның үз алдында берничә тарихи көч узара тартыша, берсе-берсенә һөҗүм ясый, берсе-берсен үз ихтыярына буйсындырырга тели. Тарихи вакыйгалар конкрет шәхесне, бу очракта Солтанны чолгап ала. Садыйк һәм

Шәяхмәт һәркайсы Солтанны үз ягына тарта. Беренчесе егетне тирә-якка битараф булып яшәргә үгетли. Икенчесе бөтен ил язмышын кайгыртырга, көчеңне кызганмыйча, дошманнарга каршы көрәшергә, халыкка бәхетле киләчәк яулап алырга чакыра.

Шулай итеп, романда да герой, балачак иленнән олы тарих юлына аяк баса, төрле шәхесләр белән аралаша, алар белән диалогка керә һәм, якты идеаллар өчен көрәшеп актив гражданин булып үсә, чыныга. Димәк, тормышның кайчак мәрхәмәтлелеген, кайчак каты куллылыгын татыган Гариф үзе кичергәннәрдән башка әсәрләрендәге геройларга да икеләнми-нитми өлеш чыгарган.

Киләчәктә Г. Ахуновның бу повестен тикшерүче галимнәр өч моментка тукталмыйча кала алмаслар. Беренче сызык — авторның «мин»е. Икенче сызык — авторның иҗат эшенә карашы. Өченче сызык — замандашларының портреты. Без дә, мөмкин кадәр, кулдан килгәнчә, шул өч моментны күздән үткәрик.

Авторның «мин»е күп төсмерле. Ул үсештә, гел хәрәкәттә, гел тормыш белән тыгыз мөнәсәбәттә ачыла. Ул тормыш юлында очраган зур шәхесләргә соклана, мәкерле, вакчыл, эгоист бәндәләргә нәфрәтләнә, аларга отпор бирә. Герой, бер яктан, табигатьнең җәүһәрләрен күрергә өйрәнә, үзендә матурлык тойгысы, рәссамлык сәләте һәм башка шундый күркәм сыйфатлар тәрбияли. Ягъни, эстетик идеалга ия булуга ирешә. Икенче яктан, герой күп кыенлыклар күреп, характер буларак, ныгый. Сугыштан соңгы уку еллары, Әлмәт якларына күчеңү, язучылар бүлеген үстерү, әсәрләренә карата булган усал рецензияләрдән коелып төшмәү, «Казан утлары»ндагы эшчәнлек, аерым алганда, моңа мисал була алалар.

«Мин» образының художник булып калыплануы күпмедер микъдарда әдипне укыткан укытучыларына барып тоташа. Беренче укытучысы Зәки абый малайны эш яратырга, тырыш булып яшәргә өйрәтә, рәсем ясау осталыгына да күнектерә. Укытучы Һидият Зиятдинов шулай ук малайга йогынты ясамый калмый. Аның эрудициясе, буйсыны, өс-башы, бөтен кыяфәте, малайга дустанә мөнәсәбәте геройның рухи дөньясын баета. Әлеге укытучының портреты Чеховның идеаль кешегә куйган таләпләрен хәтергә төшерә. «Кешенең һәммә нәрсәсе гүзәл булырга тиеш: йөзе дә, киеме дә, күңеле дә, фикерләре дә».

Сүз уңаенда шуны әйтик: автор гади авыл укытучысының хезмәтен хөрмәтли. Чынлап карасаң, авыл укытучысы образын бөтен тулылыгында күрсәткән язучы күпме икән безнең прозада? Булса, бер М. Мәһдиев булыр. Тугандаш әдәбиятларда андый образлар күренгәли кебек (Г. Березко, Ч. Айтматов, В. Тендряков, В. Быков һ. б. иҗатында). Әсәрләребездә авыл укытучысы образын һәрьяклап, тулы иттереп күрсәтергә безгә дә вакыт түгелме?!

Студент чагында Гариф эшчеләр сыйныфы вәкиле Хәкимулла абый белән очраша, аның гүзәл сыйфатларына сокланып туймый. Моңа кадәр инде ул тормыш «университетларын» узып өлгергән була: җир сукалау, ат көтү, кырчылык бригадасында бригадирлык эше, маляр булып эшләп йөрү. Бу хезмәт стажы Гарифның алдагы язучылык эшенә кирәкле материал бирә. Шул ук вакытта булачак әдип интернациональ дуслык төшенчәсен дә аңларга өйрәнә. Укыган чакларда аңарга чуваш егете Коля Ермошкин зур булышлык итә.

Университетны тәмамлап, әдәбият өлкәсендә беренче адымнарын ясаганда аңарга өлкән буын язучылар — Гали Хуҗи, Гази Кашшаф, Ибраһим Гази, Габдрахман Әпсәләмов һәм башкалар ярдәм кулын суза.

Гариф Ахуновның Әлмәттә яшәгән чоры — «мин»нең эволюция үсешендә аеруча мөһим баскыч. Герой яңадан тормыш университетына кереп китә. Бу юлы инде ул әлеге мәктәпкә югары белем иясе булып аяк баса. Аны иҗат таләпләре, хезмәт кешеләре тормышын якыннан белергә теләү максаты иләнгән эш урыныннән кузгата, республиканың ерак көнчыгыш районнарына, Әлмәт якларына алып килә. Автор тормышының бу чоры яшь язучылар өчен аеруча гыйбрәтле.

Язучы хезмәте нидән гыйбарәт? Бу мәсьәлә күпләрне кызыксындыра. Байтак кына язучылар иҗат турында дәртләнеп язалар. Исемнәр күп: М. Алексеев, Ә. Алимжанов, В. Астафьев, Ю. Бондарев, В. Быков, К. Ваншенкин, Е. Винокуров, Р. Гамзатов, Н. Думбадзе...

Гадәттә, язучылар бөтен иҗат процессын колачламыйча, аның аерым якларын ачарга омтылалар, иҗат психологиясе өлкәсенә тартылалар. Ә инде әсәр төзелеше, образлар хасияте, художникның дөньяга карашы, тормышка мөнәсәбәте әдәбият белеме карамагына калдырыла. Г. Ахунов та традицияне бозмый. Әйтик, ул кайбер әсәрләренең ничек языла башлаганы, ягъни башкача әйткәндә, замыселның тууы турында кыскача гына итеп укучыга сөйли.

Ничек туа соң әле бу беренче уй-ният? Ягъни, замысел дигәнебез? Бу сорауга сермачык, төп-төгәл җавап бирү кыен, ди автор. Ләкин, беренче ниятка (замыселга) азык биргән кайбер координатлар билгеле: беренчедән, моның өчен гадәттән тыш вакыйга булуы кирәк, икенчедән, хис-тойгыларны башкаларга да әйтеп, кем беләндер уртаклашасы килү тойгысы булу мөһим. Бу әле башлангыч этап, замысел тууның әдип ике рецептын бирә. Берсе — «амбар кенәгәсе». Андый кенәгәгә язучы ничә еллар буе төрле күренеш-вакыйгаларны, хәлләрне, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, кыланышларын, портретларын, үткен сүз һәм сөйләшү рәвешләрен теркәп бара. Икенче юлы исә — документлар белән эшләү, архивларда казыну.

Ә Гариф Ахуновка замыселлар, аның әйтүе буенча, үзе генә тапкан идеядән килә. Замысел, ди автор, әсәр нигезен тәшкил иткән төп фикернең уянуы ул. Әйтик, язучы ил күләмендә булган социаль үзгәрешләрне сурәтләп бирергә уйлый. Әлеге фикер буш урында тумый. Язучы бүгенге заманны, фәнни-техник революция чорын нечкә сиземли, аның масштабына хәйран кала. Монда язучының таланты һәм дөньяга карашы да, фикер киңлеге һәм акыл тирәнлеге дә зур роль уйный.

«Хәзинә» романында парторг Корбановның гыйбрәтле сүзе бар. Хәзинә дип бездә җир маен, ягъни нефтьне атыйлар. Ләкин иң олы хәзинәбез — кеше бит. Әнә шул олы хәзинәбез исән-сау булса гына җир асты хәзинәсе өскә күтәрелә ала. Кешенең тормышын, аның иминлеген өзлексез кайгыртып торырга кирәк. Күргәнебезчә, төп фикер конкретлаша төшә. «Хуҗалар» романын язарга керешкәнче, язучы замыселга тагын да конкретрак төс бирә һәм шундыйрак юнәлештә уйлана: газ факелләры меңләгән сумлык байлыкны күккә очыра. Арслан («Хәзинә» романыннан «Хуҗалар» исемле романга күчкән герой) промыселлардан газны җыеп алу өчен компрессор заводы салу идеясе белән янып яшәргә тиеш. Авторда әнә шундый беренчел уй туа. Завод ни өчен? Кешеләрнең бәхетле, матур яшәүләре өчен кирәк. Бу замыселның **бар нәрсә халык өчен, халык бәхете өчен** дип партия куйган программа белән аваздаш булуы һәм шуның конкрет тормыш фактларында чагылыш табуы — әсәрнең иҗтимагый әһәмиятен билгели.

Кайбер язучылар замыселны язучы күңелендә кинәт кабынган хис-кичереш дип карыйлар. Алар уйлавынча, замысел — «язучыны ялкынландырган идея, фикер чаткысы» (Ирина Вильде), «Хыялны хәрәкәткә китереп, яңалыкка соклану» (Георгий Березко). Икенче төркем язучылар замыселны акыл эшчәнлегендә күрәләр: «Иң элек тема барлыкка килә» (Валентин Катаев), «этәргеч — акыл һәм кичереш аша уздырылган материал» (Константин Федин).

Замыселны аңлавында Гариф Ахунов соңгылар карашын уртаклаша. Ул, Федин һәм Катаевлар кебек, фәлсәфәгә тартыла. «Идел кызы» романын язарга керешкәнче, әдип сурәтлисе героен күңеленнән, тормыш логикасына туры китереп, дәвер, тарих таләп иткән киңлеккә алып чыга. Автор Мәскәүдә әдәбият институты каршында ике айлык югары курсларда булып кайта. Музей һәм архивларда ул дәвернең атмосферасын күзаллый. Илнең экономикасы турында лекцияләр тыңлый һәм, нәтиҗәдә, заман сулышын күз алдына китерә, язасы китабының җирлеген хыялдан үткәрә. Бу өметле юл. Кайчак язучылар хәтерләренә генә таянып алданалар. Кирәкле материалны җыярга теләмиләр. Ярый, үзәр әле, дип үз-үзләрен юатырга тотыналар.

Иҗат процессында, ди Г. Ахунов, ике төрле алым сайлап була: беренчесе — кеше күңелен язу (Әмирхан Еники, Леонид Леонов). Икенчесе — күбрәк вакыйгалар турында язу (Габдрахман Әпсәләмов, Константин Симонов). Иң яхшысы — бу ике алымны бергә кушып эшләү. Андый юл кыен һәм теләсә кайсы язучы каләменә бирелми. Ә чын мәгънәсендәге мондый каләм Шолоховта бар («Тын Дон» романы).

Тел белү — иҗат иткәндә мөһим шарт. Телне махсус өйрәнергә кирәк. Автор университетта укыган елларында «Намус» романындагы сурәтләү чаралары турында диплом эше яза. Әсәрнең телен классификацияли, аерым карточкалар тутыра (индиви-

дуаль сөйләм, пейзаж теле, геройларга социаль характеристика, динамик вакыйга, тантаналы күренешләрне сурәтләү алымнары, әкият телен куллану, геройларның эчке кичерешләрен эчке монолог аша тасвирлау). Тел, дип фикер йөртә автор, берьюлы берничә функция башкара ала. Алыйк Әпипәнең телен. Бу тел, бер яктан, динамика тудырып, ярсулы характерын күрсәтсә, икенчедән, «җыелыш кебек күңелсез нәрсәгә киеренкелек өсти». Тел шулай ук төрле ритмлы хәрәкәт тудырырга ярдәм итә, үзендә авторның үзенчәлеген чагылдыра. Телгә болай җентекләп анализ ясауны автор тәнкыйтьчеләр эшенең тирәге дип саный һәм әдәби әсәрнең тукымасын белеп тикшерүчеләр бездә әле җитәрлек түгел дигән нәтиҗә ясый.

Телне нечкәләп өйрәнүдә авторга «Тын Дон» романын тәрҗемә итү эше дә булыша. Ә бу, ягъни язучының тәрҗемә эшчәнлеге белән үз телен баетуы, аерым бер проблема булып саналырга хаклы.

Замандашлар... Алар турында язу — кыен һәм җаваплы эш. Әсәрдән моны сизәсең. Китапта күп язучыларның фигуралары күз алдыбыздан уза. Ләкин аларның барысына да бердәй тигез урын бирелмәгән. Мирсәй Әмир, Халикъ Садри, Шәрәф Мөдәррис, Хатип Госман, Сибгат Хәким, Газиз Иделле чагыштырмача аз урында сурәтләнгәннәр. Әмма автор аларның характер сызыкларын, сөйләү үзенчәлекләрен, тавыш интонацияләрен шушы аз урында да хәтердә калырлык итеп сурәтли. Нәкъ Ираклий Андронников кебек. Ә менә тулы образ тудыру максат итеп куелмый. Валентин Катаевның «Алмазный мой венец» әсәрендә мондый фрагментарлык урынлы иде. Чөнки андагы фигураларны киң даирә укучы инде күптән белә. Алар турында йөзләгән китап язылган: В. Маяковский, Э. Багрицкий, Н. Асеев, С. Есенин, Ю. Олеша һ. б. Аларны тәфсилләп сөйләп торасы да юк. Китапның ароматы — авторның ассоциация кылларында уйнавында, нечкә һәм үтә субъектив күзәтүләрендә. Бездә исә башкачарак. Язучыларыбызның исемнәре, аерым художникларны санамаганда, укучы хәтерендә артык уелып калмаган. Моны искә аласы иде, әлбәттә. Кайбер фигураларга автор яхшы перспектива таба белә. Хәсән Туфан белән Ибраһим Газины ул нефтьчеләр, хезмәт кешеләре белән очраштыра. Х. Туфан хәтта вышкага менә, ә И. Гази кайбер бюрократларга карата каты сүз әйтә. Чыңгыз Айтматов белән Мостай Кәрим исә җанлы һәм күпьяклы итеп сурәтләнгәннәр.

Әлегедәй әсәрләргә тотынырга күптән вакыт иде инде. Әдәбият белгечләренең, профессиональ тәнкыйтьчеләрнең йөген кайчак язучылар да тарта ала икән, рәхмәт төшкере. Шулай да, язучылык хезмәте турында әдәбият белгечләре, тәнкыйтьчеләр активрак язсыннар иде. Интервью кулланып, тирән белем багажын җигеп, ил күләмендәге әдәби-эстетик тәҗрибәдән файдаланып язсыннар иде. Андый китаплар кирәк безгә, кирәк! Практика үз чиратында теория белән дә ныгытылырга тиеш бит. Язучыларга яңа перспективалар күрсәтүче, әдәбиятыбызны яңа, югарырак баскычка күтәрергә ярдәм итүче хезмәтләр кирәк. «Йолдызлар калка» повесте мине әнә шул хакта да уйландырды.

**ЭНГЕЛЬ НИГЪМӘТУЛЛИН.**

# ВӨҖДАН БАСКЫЧЛАРЫН САНАГАНДА

Рахмай Хисмәтуллинның «Вөҗдан баскычлары»[1] дигән очеркында яңгырның туктавына өмет өзгән монтажчылар эштән кайтып китәргә җыенгач, эш бармау ачуыннанмы, Харис кулындагы сүс бауны чокырга атып бәрә. Мондый кыланышлары беренче тапкыр гына түгел икән: я үзе ябыштыра торган электродларны пычракка ташлап китә, я саксыз кыланып гипс плитәләрне вата, я эштән киткәндә прожекторны сүндерми.Ләкин тормыш аңа бик гыйбрәтле бер сабак бирә.

Һавалар ачыла төшә, аккордлы премиаль наряд белән әйбәт кенә эшләп, биш катлы йортны бетереп килә бригада. Әмма соңгы подъездда бер бетон баскыч җитми кала. Бригадир Җәүдәт анда чаба, монда чаба. Таба гына алмый бит. Коллектив бүген үк йортның өстен ябып, аккордлы нарядны үтәве хакында конторага хәбәр итәр иде дә, юк, барып чыкмый.

Харис иптәшләренең акча алганын күзәтеп тора: йөзләрендә ризасызлык, ачу. Кесәгә дә, намуска да каты сугылган. Харис өенә кайтса, кызы джемпер сорап теңкәгә тия, чөнки атаның аңа биргән вәгъдәсе бар. Ә кесәдә акча юк. Эштән кайтканда ачудан салып та чыккан була ул.

Харисның ачуы кузгала. Бөтен гаеп аңарда: төнге сменада машинадан бушатканда дусты Кирам белән бер баскычны чокырга төшерәләр дә, кире алдырырга иренеп, чүп-чар белән каплыйлар, аннары аны бульдозер бөтенләй күмеп китә.

Башы чатнап торган Харис иртән эшкә килсә, ни күзе белән күрсен, төзү мәйданы ят кешеләр белән тулы. Чаллыдан үзләре белән ярышучы Рәис Сәләхов бригадасы килгән икән. Баскыч тарихын иптәшләре дә, кунаклар да белеп өлгергәннәр. Вөҗдан газабына түзә алмыйча Кирам сөйләп биргән. Бригада членнарының Харисканинди караш ташлавын күз алдына китерү кыен түгел. Харистан баскычны казытып чыгарталар чыгартуын, әмма өстеннән машиналар йөрү сәбәпле урталай сынган була ул. Тик могҗиза: шул чак йорт янына машина килеп туктый, анда өр-яңа баскыч. Бәлага тарганны белгәч, Рәис Сәләхов китерткән икән аны. Харисҡа бу аеруча тәэсир итә. Ярышучы бригада үзенең көндәшенә авыр мизгелдә ярдәм кулы суза. «Харис өчен бригадир Җәүдәт, хезмәттәшләре һәм Чаллыдан килгән дуслар күтәргән вөҗдан баскычлары иде бу»,— ди автор.

Очеркта сурәтләнгән вакыйганы тәфсилләп сөйләп чыгуның сәбәбе шул: Р. Хисмәтуллин иҗатының төп бер үзенчәлеген, ул яратып куллана торган бер алымны характерлый ул.

Җыентыктагы очеркларның күбесе әнә шулай кеше холкын, аның позициясен ачып, балкытып җибәрә торган кискен вакыйгаларга корылган. Бу җәһәттән «Үземне таптым», «Мәтрүшкәләр», «Икенче мәхәббәт» исемлеләре аеруча характерлы. Әлбәттә, геройны вакыйгалар аша күрсәтү — автор ихтыяры. Әмма, практика раслаганча, бу — иҗат принцибына кагылышлы җитди бер проблема да. Хикмәт шунда ки, кешенең характер сыйфатлары, дөньяга карашы, принциплары, әхлакый йөзе нәкъ менә конкрет хәлләрдә, бигрәк тә кискен хәлләрдә ачыла. Күп очеркларында Р. Хисмәтуллин кискен ситуацияләрдә үз героеның эчке дөньясындагы үзгәрешләргә игътибар итә. Эчтәлеге бәян ителгән очеркта, инде әйтелгәнчә, ике характер, ике төрле тормыш позициясе бәрелешә. Әлбәттә инде, Җәүдәт Халиков позициясе җиңеп чыга, тормышның төп юнәлеше шушы позиция ягында. Харисның күңелендә вөҗдан газабы уяна. Автор героеның төзәлүен сурәтләми. Тик без сизеп торабыз: бу кешенең тормышка, эшкә, коллективка карашы үзгәрәчәк; ул җәмгыятькә, кешеләргә файда китерүдән ямь табып яши башлаячак.

---

[1] Р. Хисмәтуллин. Үземне таптым. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980.

Автор үз очеркларында әйтерсең үз геройларының вөҗдан баскычларын саный. Уңай геройлар шул баскычлардан һаман югарыга үрлиләр, башкаларны үз артларыннан нәртәләр. Тискәре геройлар исә, байтак очракта нульдән тотынып, вөҗдан баскычларыннан кешелек дәрәҗәсе дигән биеклеккә йөз тотып өскә таба атлый башлыйлар, әхлак кыйбласын табалар. («Үземне таптым», «Карлы яңгыр...», «Җир уллары» һ. б.). Ул әхлак темасын гаилә-көнкүреш кысалары белән генә чикләми. Кешенең әхлаклылыгын иң элек аның хезмәткә мөнәсәбәтендә күрә. Р. Хисмәтуллинның осталыгы хезмәтнең, коллективның кешегә, аның карашларын формалаштыруга йогынтысын ышандырырлык итеп сурәтли белүдә. Кешене намуслы хезмәт, бүтән кешеләргә, илгә файда китерә торган фидакарь хезмәт үрләтүдә. Кайбер очеркларында ул хезмәт геройларның күңел ярасын дәвалый кебек. Әйтик, «Ялгыз торна күле» исемле очеркның героинясы Хәлимә Халикова Питрәч районының Шәле авылында сыер савучы. Әсәр Шәле якларында телдән-телгә күчеп килгән бер легенданы бәян итүдән башлана. Авылдан ерак түгел бер күлгә ел саен пар торна әйләнеп кайта торган була. Ләкин бер миһербансызы кызык итеп торналарга ата. Ата торна шушы күлдә ятып кала. Ана торна яз җиткән саен күлгә яңадан килә. Байтак еллар буе йөрәкләргә шулай әрнеткеч моң-сагыш сала ул. Авыл кешеләре әлеге күлне ялгыз торна күле дип йөртә башлый... Автор үз героинясының тормышын шул ялгыз торна язмышы белән чагыштыра. Ил өстенә килгән афәт Хәлимәне ике ел гына бергә торып калган иреннән аера. Фәйзрахман фронтка китеп хәбәрсез югала. Ләкин тол ханымның күңеле моңа ышанмый. Ул көтә, әле һаман да көтә. Хәлимә кайгы-сагыштан бөгелеп төшми, йөрәк ярасына дәва таба. «Хәлимә апа, шул көтү утында яна-яна, иңнәренә төяп тә, өметләренә төяп тә, иң кайнар хисләренә төяп тә колхозны, илне, бөтен җир шарын гомер буе алга, үргә таба тартты...»

Хәлимәләр, сугыш чоры буыны килде-китте генә эшләргә күнекмәгән. Кайда гына булмасын, ихлас күңелдән булсын дип, илгә куәт бирик дип эшләргә тырыша. 1947 елны Хәлимә, иң күп сөт савып, районда беренче урынга чыга. Яше җитеп ялга чыккач та, буыннары сызлауга да карамастан, ул колхоз җитәкчеләренең сүзен екмый — ярдәм итешә. Авыр, әмма игелекле хезмәт, автор сурәтләгәнчә, Хәлимәләрне әлеге дә баягы вөҗдан баскычларыннан югарыга үрләтә. «Гомере буе хезмәтне табыну кыйбласы иткән кешеләр генә вакыт сынавын җиңеп чыкканнар,— ди очеркист героинясына мәрәҗәгать кылып.— Шул исәптән сез дә, Хәлимә апа, колхозның вөҗданына, дан йолдызына әверелгәнсез...».

«Урта буй, озынча матур, нәфис йөз. Коңгырт тыныч күзләр, маңгаена, кашларына һаман да дөнья авырлыгы эленгән сыман. Өстендә бәби итәкле чип-чиста ак алъяпкыч, башында әллә нинди моңлы яулык. Муенында сары тонык гәрәбә төймәләр. Аны хезмәт терелә һәйкәлгә әверелдергән диярсең». Хәтта героинясы портретын сурәтләгәндә дә очеркист публицистик чаралар белән мөһим бер максатка ирешә: безнең алга тыл батырларының гомумиләштерелгән образы килеп баса. Тыйнак та, пакь та, саф та, сагышлы-моңсу да ул образ. Очеркны укып чыккач, сугыш кырларында ятып калган япь-яшь иптәшләребезнең истәлеге яңара. Россияне иңнәрендә күтәреп чыккан әни-апаларыбызның образлары күз алдыннан үтә. Уйлар бүгенге дөнья хәлләренә, бүгенге яшәешебезгә килеп тоташа. Конкрет бер кешегә багышланган кыска гына публицистик әсәр сугышка ачы нәфрәт, дөньяны бутаучыларга кисәтү, совет кешесенең түземлегенә, фидакарьлегенә, хезмәтенә реквием булып яңгырый. Шулай итеп, Р. Хисмәтуллин сурәтләвендә, Хәлимә Гыйбашева хезмәте белән, туган иленә бирелгәнлеге белән, фидакарьлеге белән, фаҗигасе белән вөҗданының иң югары баскычына күтәрелгән. Автор башка геройларның кылган гамәлләрен, әхлакый тәҗрибәсен, фикер һәм уй-хисләренең өлгергәнлеген әнә шул биеклек белән үлчи.

Кайгы-хәсрәт агач башыннан йөрми, кеше башыннан йөри, ди халык. Тыныч шартларда да күңелсезлекләр, көтелмәгән хәлләр, кыенлыклар чыгып кына тора. Әнә кранчы Суфия шәхси тормышында зур бәлагә тарган («Кыр казлары кайтканда»). Тәҗрибәсез кыз Омскида якташларын очрата, шуларның берсе белән гаилә корып җибәрә. Әмма иренең карашлары, психологиясе бөтенләй ул көтмәгәнчә булып

чыга: аңа укуның кирәге юк, акча гына булсын. Хатын эшләмәскә, аш пешереп, бала үстереп кенә ятарга тиеш. Җитмәсә әле эчеп җанны җәфалый бу кеше. Суфия гаиләне ничек кенә саклап калырга тырышмасын — барып чыкмый, иренә сүзе үтми. Аның күңеле эшкә, биеклеккә омтыла, һәм ул тәвәккәл адым ясый: балаларын ала да Чаллыга кайтып төшә. Аны дүрт куллап каршы алалар. «Суфия сынауларны яхшы узды,— ди очеркист.— Биредә ул, барлык хәсрәтләреннән арынып, иркәле, куәтле булып, туган якның зәңгәр күгенә карап, тимер баскычлардан югары күтәрелде».

Яшь булса да Петр Акбашның да үз хәсрәте бар икән («Икенче мәхәббәт»). Таганрогтан техникум бетереп, зур хыяллар белән КамАЗ төзешергә килгән Петр Акбаш вәгъдәләшкән кызыннан хат ала: «Оныт мине, мин башка кеше белән таныштым». Хисләр өермәсе куыра яшь йөрәкне. Бригадасында бергә эшләүче апаларның тормыш тәҗрибәсен, зирәклеген, сабырлыгын күреп, күмәк хезмәттә йөрәк ярасы дәвалана Петрның. Беренче җитди сынаудан кешелек дәрәҗәсен саклап һәм ныгытып чыга ул.

«Мәтрүшкәләр» исемле очеркта «Нефтехим» берләшмәсенең генераль директоры урынбасары Мәсгуть Сибгатов образы бирелә. Заманында район культура бүлеге мөдире, партия райкомында пропаганда бүлеге мөдире, аннары колхоз председателе булып эшләгән бу коммунист зирәк аксакал булып алга килеп баса. Ул гомере буе хезмәт фронтында кайнап, шунда характер сыйфатларын чыныктырып: кеше өчен яну һәм кешеләргә файдалы эш эшләү генә бәхет китерә, дигән хакыйкатьне канына сеңдергән. Гомер буе бөртекләп җыйган әхлак тәрбиясе, коммунистик намусы аны кеше күңелендә бик тирәндә рәхим-шәфкать чишмәләре барлыгын тоярга өйрәткән. Әнә шул чишмәләрне ягту — җитәкче кешенең, коммунист кешенең төп вазифасы, яшәү мәгънәсе дә инде. Аның вөҗдан баскычлары шәхсән үз характерын камиллаштерү генә түгел, ә башкаларныкын рухи яктан камиллаштерү белән дә ул чана. Чөнки эшчеләрнең социаль-политик яктан үсүе җитәкчеләрнең политик өлгергәнлегенә, мәсьәләләргә партиячел карауларына, әхлакый камиллегенә нык бәйле. М. Сибгатов өчен көнкүреш мәсьәләләре квартиралар бүлү, аларны җылыту белән генә чикләнми. Гостиница, балалар бакчасы, ял базасы, фигуралы шуу өчен шугалак, йөзү өчен бассейн төзүне тизләтүне дә, «Яшьлек» җыр-бию ансамбле, яшь язучылар оешмасы, «Кама таңнары» эше, культуралы итеп сабан туйлары оештыруны да кайгыртып йөри ул.

Шул ук вакытта М. Сибгатов гаделлеге, зирәклеге, шәхси үрнәге, бай тәҗрибәсе белән оста тәрбияче дә. Квартира даулап кергән яшь белгечне бик матур итеп «акылга утырта». Тота да завком утырышына чакыра. Анда нәкъ менә торак бүлү мәсьәләсе карала. 63 гариза. Кемнәрнеке генә юк анда — Ватан сугышы ветераннарыннан да, дүрт кешелек гаиләсе белән Актүбәдә ун квадрат метрлы будкада яшәүчедән дә, унсигез яшьлек кызы аварияга эләккән кешедән дә... Тулай торакта торып урыны булган яшь белгечкә зур сабак була бу. Ул утырыш беткәнне дә көтмичә чыгып китә.

— Син, Данил, нишләп утырыштан алай берни дәшми чыгып киттең соң?— дип сорый М. Сибгатов соңыннан яшь белгечтән.

— Кая ди ул анда, квартирам булса, кире кайтарып бирердәй булдым. Түзәрлек рәтем бар бит әле,— ди Данил.

Тәҗрибәле педагогларга гына хас такт белән үткәрелгән әхлак дәресе түгелмени бу?

Кеше турында кайгыртуны төп кыйбла иткән җитәкче генә партияле җитәкче, хәзерге заман җитәкчесе санала. Партиянең XXVI съездында мәсьәлә нәкъ шулай куелды да. Экономик, социаль, политик тәрбия проблемаларын бергә хәл итүче җитәкчеләрнең тәҗрибәсен гомумиләштерү, образларын сынландыру бүгенге көн очеркистларының мөһим бурычы. Р. Хисмәтуллинның әлеге очеркы (шулай ук «Язгы ташкын» әсәре) аның әнә шул тенденцияне дөрес абайлавын күрсәтә.

Автор байтак очеркларында үз геройларының актив тормыш позициясенә басуларын гәүдәләндерә. Совет кешеләрендә актив тормыш позициясе формалаштыру — политик һәм әхлакый тәрбиянең төп максатларыннан берсе. Нәкъ менә шундый позиция генә кешене, гражданин, коллективист, ватанчыл итә, аның коммунизм төзүче

буларак мораль йөзен билгели. Җәмгыять, коллектив файдасын алга куеп эш йөртүче, мәсьәләләргә дәүләт күзлегеннән чыгып якын килүче, яңалыкны яклаучы, кешеләр арасында гадел, гуманистик мөнәсәбәтләрне ныгыту өчен көрәшүче, безнең яшәү рәвешебезгә каршы килә торган күренешләрне кире кагучы кешеләрнең әхлакый тәҗрибәсен конкрет гәүдәләндерү шулай ук хәзерге заман публицистикасы һәм әдәбияты үсешендә мөһим юнәлешләрнең берсенә әверелеп бара. Бу җәһәттән Р. Хисмәтуллинның «Басымсыз ясалмый алтыннар» һәм «Янар яшьлек» исемле очерклары игътибарны җәлеп итә.

Беренче очеркта автор смена начальнигы Хәмзә Галимовның, коллектив хуплавын тоеп, цехта урнашкан гаделсез тәртипләргә кискен каршы чыгуын сурәтли. Җыелышта, ниһаять, бөтен кыюлыгын җыеп һәм үзенең абруен куркыныч астына куеп, күңелендә кайнап килгәннәрне чыгара да сала. Бу тыйнак инженерның, бәлки, беренче тапкыр үз-үзен җиңүе, үзенең һәм коллективның вөҗданын борчып йөргән кимчелекләргә каршы аваз салуы бугандыр. Әмма әлеге адымга аны намуслы хезмәт юлы әзерләгән. Моның өчен аның әхлак тәҗрибәсе дә җитәрлек булган. Ул цехта урнашкан тәртипләрне коры тәнкыйтьләү белән калмый, ә эшне яхшыртуга булышырдай төпле тәкъдимнәр дә әйтә... Әхлакый тәҗрибә туплауны тасвирлау әдәбиятта һәм публицистикада һаман зуррак урын ала бирә. Бу тенденциянең киләчәге дә зур. Чөнки әхлак тәрбиясе — яңа кеше формалаштыруның төп юнәлешләреннән берсе, ул тәрбия эшенә комплекслы якын килүнең аерылмас өлеше. Нәкъ менә эчке инануга әверелгән белем һәм карашлар, гадәткә әйләнгән принцип һәм нормалар, һәр төрле ситуацияләрдә дә тотрыклы булып кала торган сыйфатлар, сүз белән кылган гамәлнең берлеге генә кешенең кешелеге, культуралы булуы, яшәү мәгънәсен дөрес аңлавы турында сөйли.

Әмма әхлак темасына язу — гаять җаваплы һәм четерекле эш. Бу тема автордан сизгерлек һәм күңел нечкәлеге таләп итә. Кызганычка каршы, Р. Хисмәтуллинның аерым очеркларында нәкъ менә шушы җәһәттән чама хисен онытып җибәрүе сизелеп кала. Әйтик, әле генә сүз барган «Кыр казлары кайтканда», «Икенче мәхәббәт» очеркларында геройлары тормышындагы артык интим вакыйгаларга һәм фактларга тукталу, аларның фаҗигасен «публицистик күргәзмәгә» кую белән килешәсе килми.

Аерым әсәрләрендә («Чакматаш», «Кыр казлары кайтканда») ярдәмче геройларның кырыслыгын, күңел катылыгын, тәрбиясезлеген аларның моңарчы туган төбәктән читтә яшәве белән аңлатуны нигезле дип булмый.

Очеркларны герой тормышындагы иң кискен бер вакыйгага кору, әйтелгәнчә, отышлы алым. Ләкин шушы алымны гына төп чара итү әсәрләрне бертөрлерәк итә түгелме? Һәрхәлдә Р. Хисмәтуллин җыентыгын укып чыккач, шундый тәэсир кала. Ә инде образны, «хыялыңдагы төсләр, поэтик детальләр белән тулыландыру» мәсьәләсенә килгәндә, минемчә, аеруча сак булырга кирәк. Кызганычка каршы, җыентыктагы кайбер очеркларда (бигрәк тә «Матрүшкәләр»дә) шундый «тулыландыру» белән мавыгу шактый сизелә. Бу исә ясалмалылыкка илтә, хәтта моның хакыйкатькә хилафлык китерүе дә бик мөмкин. Болар хакында уйланырга кирәктер.

Р. Хисмәтуллин бу җыентыгы белән үз темасын, үз мәсьәләләрен, язу манерасын тапканлыгын раслый. Мин авторның матур-матур шигырьләр язганын беләм, драма әсәрләре өстендә эшләвен дә ишеткәнем бар. Әмма ул, герое кебек, «мин үземне иң әлек публицистикада таптым», дип әйтә алыр иде. Китап шундый нәтиҗәгә китерә.

Флорид ӘГЪЗӘМОВ.

Хуҗи Мәхмүтов,

филология фәннәре кандидаты

# МӘҢГЕЛЕК ЯДКАРЬ

## М. КАШГАРИНЫҢ «ДИВАНЕ ЛӨГАТ-ИТ-ТӨРК» КИТАБЫНДАГЫ ХАЛЫК ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕ

*«Бу китап озак заманнаргача киң таралсын, мәңгелек ядкарь булсын!» — Мәхмүт Кашгари үзенең «Диване лөгат-ит-төрк» («Төрки сүзләр җыентыгы») исемле хезмәтен әнә шундый сүзләр белән тәмамлап калдырган. Авторның бу теләк-өметләре тулысынча тормышка ашты. Моннан тугыз гасыр элек язылуына карамастан, «Диван...»ның фәнни әһәмияте торган саен киңрәк һәм тирәнрәк булып ачыла бара.*

*Дөрес, күп кенә борынгы кулъязма хезмәтләренең уртак язмышын кичереп, «Диване лөгат-ит-төрк» байтак дәверләр фән дөньясында онытылып тора. Урта гасырларда аның исеме бары бер чыганакта — Кятиб Чәләбинең (1609—1658) «Кәшф әз-зүнүн» дигән энциклопедик белешмәсендә генә күрсәтеп үтелә. Һәм менә 1915 елда төрек галиме Али Әмири Әфәнде Истамбулдагы иске китаплар базарында «Диване лөгат-ит-төрк» кулъязмасына килеп юлыга. Бу кулъязма 1266 елда Мөхәммәт ибне Әбү-Бәкер ибне Әбүл-Фәтх исемле кеше тарафыннан Мәхмүт Кашгари үз кулы белән язган нөсхәдән күчерелгән булып чыга[1]. Күренекле немец ориенталисты Карл Брокельман 1928 елда аны немец теленә тәрҗемә итә. 1939—1941 елларда әсәр Бесим Аталай тәрҗемәсендә төрек телендә дөнья күрә. Советлар Союзында ул 1960—1963 елларда Үзбәкстан ССР Фәннәр академиясе тарафыннан (үзбәкчәгә Салих Моталлипов тәрҗемәсе) бастырып чыгарылды[2]. Хәзерге вакытта «Диван...» рус һәм әзербайҗан телләренә дә тәрҗемә ителгән.*

Кызганычка каршы, Мәхмүт Кашгариның үзе турында мәгълүматлар юк дәрәҗәсендә аз. «Кашгари» дигән кушамат йөртүе аның Көнчыгыш Төркстандагы Кашгар каласында туган яки яшәгән булуын күрсәтә. «Диван...»да автор атасының Хөсәен, бабасының Мөхәммәт исемле булганлыгы, Хөсәеннең Иссык-Күл янындагы Барсхан шәһәрендә яшәгәнлеге турында яза. Шул мәгълүматлардан чыгып, Мәхмүт Кашгарины Барсханда өмирлек иткән Хөсәен ибне Мөхәммәт улы булырга тиеш дип саныйлар. Бер урында М. Кашгари «бу китап гомеремне ахырына җиткерде» дип тә яза. Үз сүзләренә үк карaганда, ул сүзлеген һиҗри 464—466 еллар арасында (1072—1074) төзеп тәмамлый. Бу вакытта инде «гомеренең ахырына җиткән» өлкән яшьтәге кеше булгач, димәк, ул XI йөзнең башларында тугандыр дип гөман кылына.

«Диване лөгат-ит-төрк» әсәрен укыганда М. Кашгари зур энциклопедист галим, олы талант иясе һәм искиткеч тырыш, пөхтә, үз-үзенә таләпчән шәхес сыйфатында күз алдына килә. Ул сүзләрне китапта төзек бер тәртиптә урнаштыру, файдаланучылар өчен һәр төрле уңайлыклар тудыру мәсь-

[1] Кононов А. Н. Махмуд Кашгарский и его «Дивану лугатит турк». «Советская тюркология», 1972, 1 сан, 6—7 битләр; М. Шакир Үлкүташир. Бүйүк түрк дилчиси Кашгарли Махмут. Анкара, 1972, 48—49, 56—82 битләр (төрек телендә).

[2] Кошгари Махмуд. Девону луготит турк. Тошкент. I том — 1960, II том — 1961, III том — 1963. Өзекләр һәм мисаллар шул басма буенча биреләчәк. Җәяләр эчендәге санnарның беренчесе том саны, икенчесе битләрне күрсәтә.

әләсенә зур җаваплылык белән карый. Сүзлек өстендә эшләвенең соңгы этабында да М. Кашгари аны (хәзерге басмадагы өч томлык зур әсәрне!) 4 мәртәбә яңадан күчереп, төзәтеп чыга. «Мин төрекләр [1], төркмәннәр, угызлар, чигилләр, ягмалар, кыргызларның шәһәрләрен, кышлак һәм җәйләүләрен күп еллар гизеп йөрдем, сүзләрен тупладым, төрле төркемнәрдәге сүзләрнең үзенчәлекләрен өйрәнеп, ачыклап чыктым. Мин боларны тел белмәгәнлектән түгел, бәлки бу телләрдәге һәрбер кечкенә аерымлыкларны да аныклау өчен эшләдем»,— дип яза автор хезмәтенең сүз башында (1.44).

«Диван...» үзенең төп асылы белән лексикографик хезмәт. Анда М. Кашгари 9 мең чамасы сүз һәм сүз тезмәсе китереп, аларның мәгънәләрен аңлата. Күп санлы төрки телләрнең фонетикасы һәм грамматикасы буенча күп төрле мәгълүматлар бирә, фонетик-морфологик билгеләренә карап, төрки телләрне көнчыгыш һәм көнбатыш төркемнәргә аера. Бу исә төрки телләрне классификацияләүдә беренче уңышлы тәҗрибә булып тора.

Хәлбуки, «Диване лөгат-ит-төрк»кә тел галимнәре генә түгел, әдәбият белгечләре һәм фольклорчылар да, тарихчылар һәм этнографлар да бердәй зур кызыксыну белән мөрәҗәгать итәләр. Чөнки анда бу фәннәргә турыдан-туры мөнәсәбәтле фактик материаллар ифрат күп.

«Мин бу китапны ... хикмәтле сүзләр, сәҗгылар[2], мәкальләр, шигырьләр, рәҗәз[3], нәсер дип аталган әдәби парчалар белән бизәдем,— дип яза автор (1.44—45)... — алардан файдаланучылар тыңлаучыларга, тыңлаучылар исә, үз нәүбәтләрендә, шул телдә сөйләүчеләргә җиткерсен. Шуның өчен дә боларның һәммәсен бу китапта тупладым» (1.47).

«Диван...»да, аерым сүзләрнең мәгънәләрен ачучы контекстлар сыйфатында, барысы 170 дүртьюллык һәм 54 икеюллык шигъри текст теркәлгән. Күпчелек тикшеренүчеләрнең уртак карашынча, аларның күбесе зур күләмле шигъри әсәрләрдән өзекләр, аерым парчалар булырга тиеш. Шигъри парчалар арасында Идел елгасы турында да бер строфа бар:

**Этил суву ака турур,**
**Кыйа түпи кака турур,**
**Балык тәлим [4] бака турур,**
**Көлүң такы кушәрүр [5].**

**(1. 103).**

Текстларга аңлатма биргәндә М. Кашгари һәрвакыт «шигырьдә түбәндәгечә килгән», «шагыйрь болай ди» кебек җөмләләр кулланa. Строфа да үзенең үлчәме, рифмалашу өлгесе ягыннан җырдан бигрәк язма шигырьгә тартым. М. Кашгари да аны җыр дип атамый.

«Диван...»да легендалар һәм риваятьләргә дә шактый күп урын бирелә. «Төркиләр асылда егерме кабиләдер,— ди М. Кашгари.— Алар һәммәсе Нух пәйгамбәрнең улы Яфәскә, Яфәснең улы Төреккә барып тоташалар» (1.64). Шунсы кызык: бу легенда (әлбәттә, үзебезнең тарихка якынайтылып) Казан татарлары арасында әле хәзер дә сөйләнеп йөри. Имештер, Нух пәйгамбәр улы Яфәснең Гази, Төрек һәм Алып исемле өч улы булган. Алар арасында сугыш чыгып, Гази үтерелгән. Төрек белән Алып салкын җирләргә күчеп киткәннәр. Алыпның ике улы туган. Аларга Болгар һәм Бортас дип исем кушканнар. Болгар белән Бортас икесе ике җирдә шәһәр корганнар. Бу шәһәрләрнең даны еракларга таралган...[6]

Ә бер топонимик риваятькә бәйләп, автор үзенә кагылышлы мәгълүмат та биреп үтә: «Барсхан — Афрасияб улының исеме. Барсхан шәһәрен бина кылучы улдыр. Мәхмүтнең атасы шул шәһәрдәндер» (III. 424).

«Диван...»да төрки кабиләләрнең тормыш-көнкүрешенә, гореф-гадәтләренә, йола-ышануларына, им-томнар һәм халык медицинасына кагылышлы материаллардан өзекләр һәм детальләр шактый очрый. Әйтик, сүзлектә төркиләрнең туй йолалары махсус сурәтләнмәсә дә, туй белән бәйләнешле күп кенә атамалар аша бу йоланың кайбер мөһим өлешләрен күз алдына китерерп була. Мәсәлән: «д и д и м — никах кичендә киленгә кидерелә торган таҗ, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән баш киеме» (1. 387); «м е н д и р и — килен белән кияү катнашында төнлә җыела торган мәҗлеснең исеме. Анда аларның өсләренә акча сибәләр» (1. 454) һ. б.

«Төркиләр унике төрле хайван исеменнән унике елга исем куйганнар. Туган елларын, сугыш тарихларын һәм башкаларны әнә шул еллар әйләнешеннән чыгып исәплиләр», — дип хәбәр итә М. Кашгари. Бу календарьның ничек килеп чыгуы турында ул кызыклы гына легенда да китерә. Имештер, төрки хаканнардан берәү берничә ел элек булып үткән сугышны өйрәнмәкче булган. Әмма ул сугыш булган елны аныклый алмаганнар. Бу мәсьәлә буенча хакан үз кавеме белән киңәшкән һәм болай дигән: «Без бу тарихны аныклауда ничек ялгышсак, бездән соң да шулай ялгышырлар. Шулай булгач без инде, унике айга һәм күктәге унике йолдызлыкка нигезләнеп, унике елга исем кушыйк, бездән соң ел исәбе шул елларның әйләнешенә карап алып барылсын...» Шуннан хакан ауга чыккан һәм үз кешеләренә киек хайваннарны Ила [7] дәрьясына таба куарга боерган. Бу бик зур су булган. Хакан кешеләре киекләрне суга куа башлаганнар. Шунда унике киек суны кичеп чыккан. Су аша иң алдан тычкан үткәнгә ел башы аның исеме белән аталган. Калган киекләр суны түбәндәге тәртиптә кичкәннәр һәм аларның да һәрберсе бер ел исеме булып калган: уд (сы-

---

[1] М. Кашгари X гасырда Урта Азиядә төзелгән Караханилар дәүләтендә (яки Хаканиядә) яшәгән төрки кабиләләрне күздә тота.

[2] Сәҗгы — рифмалы проза.

[3] Рәҗәз — батырларның сугышларда күрсәткән каһарманлыкларын тасвирлаучы шигырь.

[4] Тәлим — күп.

[5] Көлүң такы кушәрүр — «яр буйларындагы күлләр, тугайлар су белән тулыр» мәгънәсендә.

[6] 1926 елда Казанда археограф Сәид Вахиди язып алган. Бу турыда: Фәхретдинов Р. Ташлар моңы. Казан, 1978, 100 бит.

[7] Балхаш күленә коючы Или елгасы күздә тотылган булуы ихтимал.

ер) елы, барыс елы, тавышган (куян) елы, нек (крокодил) елы, йылан елы, йунд (ат, елкы) елы, кой (куй, сарык) елы, бишин (маймыл) елы, такагу (тавык) елы, эт елы, тоңуз (дуңгыз) елы (1. 330—331). М. Кашгари хәбәр иткән мондый мәгълүматлар да игътибарга лаеклы: «Төркиләр,— ди ул,— бу елларның һәркайсында берәр хикмәт бар дип уйлыйлар. Мәсәлән, аларча, сыер елы керсә сугыш күп була, чөнки сыер бер-берсе белән сөзешә торган хайван. Тавык елы керсә азык-төлек күбәя, ләкин адәмнәрдә тәшвиш арта. Чөнки тавыкның азыгы ашлык бөртеге булып, аны табып ашау өчен әйберләрне туздырып йөри. Крокодил елы керсә, явым-төшем һәм уңыш күп була, чөнки ул суда яши. Дуңгыз елы керсә, салкын, кар һәм фетнә күп була. Шуның шикелле, һәр елга бер юрау кылалар» (1. 331—332).

Бу урында болгар-татар тарихыннан һәм фольклорыннан кайбер параллель материаллар китереп үтү кызыклы булыр. Әлбәттә, хайваннар исеме белән аталган уникe еллык календарь XI йөздә барлык төрки кабиләләрдә дә, шул исәптән болгарларда да актив кулланышта була. Дунай болгарлары телендә әле дә уникe еллык хайван циклындагы үң елның атамасы саклана: шөюр (сыер), вере (бүре, барс), давшан (тавышган, куян), дилан (елан), тоох (тавык), дохс (дуңгыз) h. б. Казан-татарлары арасында бу борынгы ел исәбе аерым очракларда XIX йөздә һәм хәтта XX йөз башларында да файдаланып киленгән, һәр ел турындагы М. Кашгари әйткән юраулышанулар да татар фольклорында шулай ук байтак: «Куян елы ачлык булыр»; «Эт елы буран була»; «Барс елы — байлык, сыер елы — туклык, куй елы —кытлык, куян елы — йотлык»; «Эт елында мал үсәр, барс елны бар да үсәр» h. б.

«Диван...»да ышанулар, им-томнар да күп, байтак кына халык уеннарына да тәфсилле аңлатмалар бирелә, ә фольклор әсәрләре арасында исә аеруча әһәмиятле урынны халык мәкальләре алып тора. Ләкин биредә «мәкаль» атамасы киңрәк мәгънәдә аңлашылырга тиеш. Чөнки алар арасында саф мәкальләрдән тыш әйтемнәр, ышанулар, антлар, теләкләр һәм башка төр афоризмнар да бар. Боларның барысын берләштереп, «халык тәгъбирләре», «халык афоризмнары» яки шул ук мәгънәдәге «паремияләр» дип атарга мөмкин. «Диван...»ның үзендә алар «сав» дип аталганнар.

Төрек галиме Ферит Биртекнең исәпләвенә таянып, бүгенге фәндә «Диван...»да 290 мәкаль һәм әйтем бар дигән фикер кабул ителгән [1]. Ләкин бу сан беркадәр төгәллек көртүне сорый: Ф. Биртек хезмәтендә паремияләр 291 берәмлек тәшкил итмә. Шулардан берсен ул үзе, шигырьдән өзек булганы өчен, исәптән чыгарып ташлый. Моннан тыш 3 мәкаль анда икешәр мәртәбә кабатланган. Димәк, чынлыкта бу хезмәттәге афоризмнар саны 287 булып чыга. Монысы беренчедән. Икенчедән, Ф. Биртек 18 паремияне исәпкә алмыйча калдырган. Мәсәлән: колдачыка миң йагак, барча билә айрук таяк (теләнчегә мең чикләвек, болар өстенә таянырга таяк бирү тиешле);— камуг киши түз эрмәс (бар кеше дә тигез, бертөрле булмас) h. б.лар. Кыска мәкаләдә аларның һәркайсын махсус тикшереп чыгу мөмкин түгел. Шуңа күрә, конкрет бер сан күрсәтмичә, «Диван...»да 300 чамасы паремия бар дип алу дөресрәк булыр.

«Диван...»дагы халык тәгъбирләренең иң зур күпчелеген мәкальләр тәшкил итә. Аларның тематикасы яхшы ук киң — тормыш-көнкүрешнең, иҗтимагый һәм шәхси мөнәсәбәтләрнең күп төрле якларын колачлыйлар. Мәкальләрнең XI йөздә төрки халыкларда мөһим роль уйнаган булулары ачык аңлашыла. М. Кашгари хәбәр иткәнчә, аларның хәтта махсус мәкаль әйтүче кешеләре дә булган. «Диван...»да мәкаль жанрына кагылышлы башка төрле әһәмиятле мәгълүматлар да очрый. Җөмләдән берсе: тормыштагы берәр кызыклы, гыйбрәтле вакыйгага бәйләнештә халыкта мәкаль чыгарылу. Сүзлектә «Кыз бирлә күрәшмә, кысрак [2] бирлә ярышма» дигән мәкальгә шундый аңлатма бирелә: «Бу мәкаль Хакания кызларыннан берсе Солтан Мәсгут никах кичендә үз ирен аягы белән чалып екканнан соң хаканлыларда барлыкка килгән» (1. 439).

Борынгы һәм бүгенге мәкальләрне шушы яктан чагыштыру жанр тарихын өйрәнү өчен күп кенә кызыклы мәгълүматлар бирәчәк. Мәсәлән, «Нечә йитиг бичак эрсә өзи сабын йонумас» (никадәр үткен пычак булса да үз сабын юнмас) мәкале Кашгари заманнарында «үз эшен эшләмичә башкалар эше хакында сөйләүчеләргә карата кулланылган» (1.366). Бүгенге татар фольклорында исә ул (һәм аңа тәрдәш мәкальләр) туганнар яки үз кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аңлатканда әйтелеп йөриләр: «Пычак ни хәтле үткен булса да, үз сабын үзе юнмый»; «Пычак үз сабын юнмас, карга карга күзен уймас»; «Кылыч үз кынын кисмәс» h. б.

Ниһаять, «Диван...»дагы мәкаль текстлары бу төр халык афоризмнарының яшәүүзгәрү сәләтләрен күзәтү өчен дә зур мөмкинлекләр ача. Бүгенге төрки халыклар фольклорыннан Кашгари язып калдырган мәкальләрнең барысын да яки ким дигәндә аларның вариантларын табып булыр иде. Мондый текстлар татар халык мәкальләре арасында да байтак. Моннан 900 ел элек тә һәм хәзерге көндә дә кулланылышта булган әсәрләрне чагыштырганда төп өч очрак күзгә ташлана.

Беренчедән, кайбер фонетик аерымлыкларны исәпкә алмаганда, текстлар бер-берсенә сүзгә-сүз туры киләләр: Күз келиги йайен белгелүг. (III. 175). — Көз килеше җөеннән билгеле. (I. 440) [3].

[1] Биртек Ферит. Эн эски турк савлары. Анкара, 1944 (төрек телендә); Кононов А. Н. Күрсәтелгән хезмәт, 12 бит.

[2] Кысрак — байтал.

[3] Татар мәкальләре Н. Исәнбәтнең өч томлык «Татар халык мәкальләре» җыентыгы буенча китерелә. Җәяләр эчендәге беренче сан — том номеры, икенчесе — битләр саны.

Икенчедән, текстлар мәгънә ягыннан тәңгәл булып, алар берәр сүзләре белән генә аерылалар. Я архаизм яңа сүз белән, я нинди дә булса бер сүз үзенең синонимы белән алмашынган булырга мөмкин. Мондый мисаллар аеруча күп очрый: Тайган[1] йүгригин тилкү севмәс. (III. 190). — Эт йөгереген төлке сөймәс (I. 711). Сув көрмәкинчә этүк тартма. (III. 431).— Су күрмичә итек салма. (I. 486).

Өченчедән, ике яңашәлектән төзелгән борынгы һәм бүгенге мәкальләрнең берәр яңашәлекләре генә тәңгәл киләләр.

**Бирин-бирин миң болур,**
**Тама-тама көл булыр.**
**[III. 371]**
**Тама-тама күл булыр,**
**Ага-ага сил булыр.**
**[I. 507.]**

Борынгы заманнардан безнең көннәргәчә сакланып калган мәкальләр арасындагы шундый якынлык, хәтта тәңгәллек җирлегендә аларның художество чаралары ягыннан камиллеге дә ачык күренә. Бигрәк тә мәгънәне читләтеп әйтүнең, кинаяле образлар куллануның гаҗәп тапкыр үрнәкләре еш очрый. Табигать дөньясыннан алынган күзәтүләрне, андагы закончалыкларны җәмгыять тормышына күчереп, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә кайтарып файдалану мондый образлылыкның нигезен тәшкил итә. Мәсәлән: «Арслан карыса сычган өтин күдәзүр» — ягъни, арслан картайса тычкан өнен саклар. «Бу мәкаль зур эш кылырга көче җитмәгәч, кечкенә эшкә риза булган картларга нисбәттән кулланыла»,— ди М. Кашгари (III. 279). «Тегирмәндә тогмыш сычган көк көкрәгиңә коркмас — бу мәкаль кыен эшләрдә чыныккан кешене кечкенә бер эш белән куркытмакчы булган кешегә карата әйтелә» (III. 297) һ. б. Мәкальләрдә сурәтлелек тудыруның башка күп төрле чаралары да файдаланыла. Шундый рольне, мәсәлән, гипербола үтәп килә: «Атан йүки аш болса, ачка аз көрнүр» (I.105)—ягъни, бер дөя йөге азык та ач кешегә аз булып күренә.

«Диван...»дагы мәкальләрнең сәнгатьчә үзенчәлекләре турында сүз алып барганда аларның шактый өлеше шигъри әсәрләр булганлыгын истә тотарга кирәк. Бу җәһәттән ул мәкальләр Х. Госманның «Шигырь төзелеше» исемле китабында (Казан, 1975) җентекләп тикшерелгәннәр.

М. Кашгариның «Диван...» сүзлегендә XI йөздә яшәгән төрки халыкларның бай фольклор ядкаре теркәлеп калган. Ул бүген тугандаш халыкларның уртак байлыгы булып санала. М. Кашгари үзе дә «Диван...»ны төзегәндә ул дәвердәге төрки телләрнең үзара нык якынлыгыннан чыгып эш итә. Хезмәтенең керешендә төп төрки сүзләрдә кабиләара аерымлыклар бик аз булуын, сүзләрдәге үзгәлекләрнең башлыча кайбер авазларның алмашынуында икәнлеген әйтеп китә (1.66). Теге яки бу кабилә телендә генә очрый торган сүзләрне автор атап күрсәтеп барган. Андыйлар 500 чамасы. «Диван...»да 9 мең чамасы лексик берәмлек булуын хәтергә төшерсәк, барлык кабиләләр өчен уртак гомум-төрки сүзләрнең анда нинди зур өлешне алып торуы аңлашыла.

М. Кашгари, төркиләрнең күп кенә шәһәрләрендә булса да, Болгарга ук килеп җитмәгән булырга тиеш. Һәрхәлдә, ул бу турыда әйтми. Әмма сүзлегендә Болгар шәһәренең «төрек шәһәрләреннән мәшһүр бер шәһәр» икәнен күрсәтеп үтә (I.425). Ә Болгар иленең икенче зур шәһәре Сувар турында «Сахсын — болгарларга якындагы бер шәһәр. Ул «Сувалдыр» дигән сүзләрне укыйбыз (I.410). Гәрчә Суварны Сәксин белән бер шәһәр итеп караса да, М. Кашгари аның Болгарга якын икәнлеген дөрес әйтә. Шуңа күрә ул «сувар теле» дип китергән мәгълүматлар да Идел буе төркиләре теленә кагылышлы булып чыга. Болгар һәм Сувар шәһәрләре «Диван...»да бирелгән картага да кертелгәннәр.

«Диван...» сүзлегендә кыпчак теле турындагы мәгълүматлар аеруча еш очрый. Дөрес, XI гасырда кыпчаклар гаять киң территорияләрдә таралып яшәгәннәр. Алай да М. Кашгариның Идел буйларын «кыпчак иле» дип атавы бик мөһим. «Этил — кыпчак илләрендәге бер елганың исеме», —ди сүзлек авторы (I.103). Ул аның Болгар (Каспий) диңгезенә коюы, рус җирләреннән ага торган кушылдыгы булуы турында да хәбәр итә. Аннан Идел турындагы мәгълүм дүртьюллык шигырь китерелә.

Төрки телләргә классификация ясап, М. Кашгари алар арасындагы фонетик һәм морфологик үзенчәлекләрне ача, кайбер лексик аерымлыкларны күрсәтә. Бер генә мисал китерик: «Бал — суварлар һәм кыпчаклар телендәге сүз. Угызлар һәм төрекләр аны «ары йагы»[2] диләр» (III.171). «Бал» сүзе Идел буе төркиләренә хас булгач, бу сүзне аңлату өчен автор тарафыннан китерелгән шигъри парча да шушы телдәге борынгы поэзиянең бер өлгесе итеп карала аладыр. Ул түбәндәгечә:

**Барды саңа йөк, утру тутуп бал;**
**Барчын кедибән телү, йувга болуп кал**[3].

«Диван...»да берничә саф болгар сүзе дә күрсәтелә. Бу сүзләр Кашгари яшәгән якларга сәүдә кәрваннары белән барып җиткән булуы ихтимал. Чөнки алар, башлыча, Болгарда җитештерелеп сатыла торган киң билгеле товар атамалары: «а в у с — балавыз» (I.91), «л а в — мөһер басу өчен файдаланыла торган балавыз» (III.169) һ. б.

Кыскача йомгак ясап әйткәндә, М. Кашгариның «Диване лөгат-ит-төрк» сүзлеге, башка төрки халыклар белән бергә, татар халкы өчен дә кыйммәтле культура мирасы булып тора. Анда халкыбызның борынгы телен, әдәбиятын, фольклорын, этнографиясен, тарихын өйрәнү өчен гаҗәп бай материал саклаган.

---

[1] Тайган — ау эте, бурзай.

[2] Ары йагы — умарта корты мае.

[3] Сүзгә-сүз тәрҗемәсе: «Барды сиңа шайтан, каршыңа тотып бал; парчадан киенеп, тиле юка (хәлсез) булып кал». — Шигырь, шайтан коткысына бирелеп, дөнья ләззәтләренә алданудан кисәтә.

# БЕЗДӘ КУНАКТА: УДМУРТ ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

*РСФСР составында Удмуртия башта Вотский (вотяклар) автономияле өлкәсе итеп оештырыла (4 ноябрь, 1920 ел), 1932 елда ул Удмурт өлкәсе дип исемләнә һәм аннары (28 декабрь, 1934 ел) автономияле республика игелә. Идел бассейнында Кама белән Вятка елгалары арасындагы урманлы зонада урнашкан, мәйданы 42,2 мең квадрат километр. Халык саны: барлыгы 1494 мең (1979 ел исәбе), шулардан удмуртлар 582 мең (1970 ел исәбе). Бу тел финн-угыр семьясының Пермь тармагына керә, аның Глазов, Сарапул һәм Алабуга диалектлары бар.*

*Удмурт исемле ыру (кабилә) X-XII гасырларда Кама болгарлары дәүләте составына кергән була. Аны 1236 елда монгол баскыннары җимергәч, удмуртларның күпчелеге Вятка (Хлынь) җирендәге кардәшләре янына күчәләр. 1489 елда ул җирләр үзәкләштерелгән рус дәүләтенең Мәскәү княжествосына кушыла. Руслар белән көчле аралашу барган шул елларда ук бирелә Бемыж бакыр эретү заводы (1775 ел). Ижевск һәм Камбарка тимер эшләү заводлары (1759—1767 еллар), аннары Бондюг һәм Кокша химия заводлары салына. 1773—1775 елларда удмуртлар Пугачев явы көрәшенә актив кушылалар.*

*Удмурт халык иҗаты үрнәкләренең беренче язмалары XIX гасырда гына славян графикасы җирлегендә эшләнгән әлифба белән басыла. 1904—1909 елларда, мәсәлән, Удмурт календарен Казан шулай чыгара. Язма әсәрләр исемлегендәге соңгыраклары М. Можгинның (1890—1929) «Качкын» поэмасы, М. Прокопьевның (1884—1919) «Максим язган әсәрләр» дигән китабы, Кедр Митрей (1892—1949) трагедиясе һәм Кузебей Герд (1898—1941) шигырьләре шул ук әлифба белән китапларда, яки укытучылар семинарияләрендәге кулъязма журналларда чыгарылалар. Октябрьдан соңгы беренче елларда чынбарлыкны романтик рухта сурәтләгән авторлар Д. Майоров (1889—1923), И. Дядюков (1896—1955), шагыйрә Ошальчи Оки (Л. Т. Векшина — 1898—1973) акрынлап реалистик җирлеккә күчә башлый.*

*Хәзерге Удмуртия Камага койган Иж һәм Сива, Вяткага кушылган Чепца һәм Кильмезь елгалары буйлап салларда агызылган урман чималын күпләп эшкәртә, илгә куәтле локомобильләр, кече габаритлы машиналар, катлаулы станоклар һ. б. бирә. Бирелә аларны эшләп чыгарган заводлар илебезнең индустрия гигантлары исемлегендә йөри. Бөтен озынлыгы 30 километрлап булган ИЖмаш конвейерыннан, мәсәлән, һәр 40 секунд саен бер мотоцикл төшеп тора! Республикада бер көндә җитештерелгән промышленность продукциясе күләме 1913 елда бөтен Удмуртия биргән продукциядән өч тапкыр артыграк һәм аны дөньядагы 60 тан артык илдә алалар. Безнең күршеләребез — күпләп торф хәзерләү, кирпеч сугу, җитен үстерү, көн әйберләр эшләү осталары да. Хәзер инде алар үзләренең тирән җир асларыннан «кара алтын» да*

*Әгәр Ватан үзе бер җыр булса,*
*Шул җырда син — гөслә авазы.*
*Россиянең күркәм букетында*
*Бер Италмас — алтын чәчәк син.*

*Кыска һәм оста итеп бер горурлык хисен белдергән җырлардан юллар болар. «Италмас» удмуртча алтын чәчәк дигән сүз — борынгы легендада гүзәл кыз исеме. Хәзер дусларыбызның бөтен илгә билгеле җыр һәм бию ансамбле шулай атала. Димәк, республиканың алтын-куллы уллары-кызлары даны, алар башкарган тиңсез зур эшләр шигърияте инде җыр булып та бөтен илдә яңгырый.*

*Язучыларның удмурт оешмасы хәзер дүрт дистә чамасы каләм остасын берләштерә. Алар гаять тырыш, эшчәннәр, халыклар һәм әдәбиятлар дуслыгы хисен йөрәкләрендә кыю дөрләтеп, тормышның алгы сызыгында торып иҗат итәләр. Иң яхшы үрнәкләрдән өйрәнеп эшләү, бүтәннәр белән дуслашу-туганлашу, хәтта телләрне белеп конкрет аралашу теләге һәркайсында зур һәм, әйтергә кирәк, бу күптәннән килә. Әнә бит Кузебей Герд триолет дигән иң катлаулы форма белән үз шигырен рус телендә язган... Гай Сабитовның исә шактый зур букет итеп эшләнгән сонетлары бар*

*Тукайны, Җәлилне һәм Такташны ул турыдан-туры татарчадан тәрҗемә итә... Беренче хикәяләре белән әдәбиятка 1928 елда килгән Михаил Петров (тумышы белән ул хәзерге Алабуга районының Монашево авылыннан) өч дистәдән дә кимрәк ел гына иҗат итә алган. Ә язганнары аның 1958 елда ук инде рус теленә тәрҗемә ителеп 6 томлы басмада чыга. Шагыйрь буларак ул җырлар, поэмалар яза. Некрасов, Шевченко, Маяковский, Твардовский, Тукай һәм Җәлилне тәрҗемә итә; прозаик һәм драматург буларак фронт хикәяләре һәм повесть, атаклы «Мултан» романын яза, Толстой һәм Островский, Горький, Шолоховларның иң зур әсәрләрен удмуртчага тәрҗемә итә. Бу бит чын мәгънәдә фидакарьлек!*

*Ниһаять, тагын бер мисал китерү биредә урынлы булыр кебек. Бөек Ватан сугышына хәтле Татарстанның Баулы районында өч дус яши: удмуртлар Самсонов һәм Василий Романов, чуваш Алексей Афанасьев. Петр I заманында шушында килеп төпләнгән ата-бабалары кебек ук, өчесе дә үз туган телләреннән кала рус, татар, мордва телләрен яхшы беләләр, бер-берсеннән һөнәргә һәм эшкә өйрәнеп, культура хәзинәләре һәм тел байлыкларын уртаклашып, бәйрәмнәрне бергә уздырып яшиләр. Язучы булырга омтылып, өчесе дә каләм тибрәтә башлый — сугыш алды елларында, мәсәлән, М. Лермонтов «Фаталист»ы һәм Константин Иванов «Нарспи»е тәрҗемә ителә. Сугыш башлангач, алар өчесе бергә фронтка китәләр һәм... анда Романовның гомерен фашист пулясы өзә. Ә Евгений Самсонов белән Алексей Афанасьев хәзер дә Баулыда торалар, икесе дә СССР Язучылар Союзы әгъзасы. Ә удмурт поэзиясендә хәзер шагыйрь Владимир Романов бар. Ул — Василий Романов улы. 1941 елда туган. Инде үзе дә солдатта булып кайткан. Рус, татар, чуваш телләрен белә һәм удмуртчага тәрҗемәләрне оста эшли. 1975 елда чыккан беренче китабы («Әбиләр чуагы») өчен Удмуртия комсомолы бүләгенә лаек була. Икенче китабы («Алан») русчага тәрҗемә ителә. Ул образларны фикер белән тирән сугара, ә фикере бары тик образдан гына табигый яши. Бу — хәзерге удмурт поэзиясенә килгән яшьләрнең иҗатына хас уртак һәм төп сыйфат. Димәк, якын күршеләребез иҗатында алдагы көннәрдә җырлар һәм шигырьләр авазы тагын да көчлерәк, тагын да матуррак яңгыраячак.*

# Кузебай Герд

*1898—1941*

## Уйшора җиленә

ТРИОЛЕТ[1]

Кит, Уйшора — төньяк иле җиле,
Кит, калдыр син минем туган якны!
Күрәсең бит, сиңа үчле мин...
Кит, Уйшора — төньяк иле җиле,
Я чүлгә син, я тауларга юнәл,
Барыбер җиңәм — чөнки көчле мин.
Кит, калдыр син минем туган якны.

Игенемне карың-бозың күмде,
Юк, сүнмәде ләкин йөрәк дәртем!
Чәчәк шиңде, туңды уҗымым.
Игенемне карың-бозың күмде,
Январыңнан һич тә куркасым юк —
Мин бирешмәм, җитәр түземем!
Юк, сүнмәде ләкин йөрәк дәртем.

Кисәрмен дә калын чытырманны
Куе иген тагын чәчәрмен мин...
Тик бүреләр торган җирләрдә
Кисәрмен дә калын чытырманны
Урын әрчеп иген игәргә,
Тагын җиңәр минем тырыш хезмәт!
Куе иген тагын чәчәрмен мин!

---

[1] Канонлы поэзиядә 15-гасырда кабул ителгән цыклы шигъри форма (французча «өчле», итальянча «өч» сүзеннән). Җиде юллы строфада (метрик цикл) беренче юл тагын дүртенче һәм җиденче юллар итеп, ә икенче юл, тема үсеше өчен кирәкле алым буларак, җиденче юл итеп тә кабатлана. Россиядә аны беренче булып Н. М. Карамзин, соңыннан Ф. Сологуб һәм И. Рукавишников куллана. Кузебай Герд исә бу шигырен рус телендә язган.

# Ошальчи-Оки (Векшина)

*1898—1973*

## Искә төшәсең

Су буенда — кара карлыган .
Су буенда — минем эзләрем.
Су буенда җиләк җыйганда
Искә төшә синең күзләрең.

Уттай яна гөләп чәчәге,
Шуңа аны мин бик яратам.

Күрәм кебек синең йөзеңне,
Шул чәчәккә әгәр карасам.

Язлар җитсә — чыгам кырларга,
Эчем поша кырда булмасам.
Мин хәтерлим синең тавышны,
Тургай җырын шунда тыңласам.

# Аркадий Клабуков—Багай

## Ленин янына бару

БАЛЛАДА

Башта бүрек, өстә иске чикмән.
Чамасыз күп әйтер сүзләре.
Ә узарга Ленин бусагасын
Тартынганнар ләкин үзләре.

Ишек ачып каршы ала Ильич:
— Рәхим итеп, әйдә, керегез.
Сез халыктан нинди йомыш белән?
Хәлләр ничек? Сөйләп бирегез!

...Сакаллысы алдан кергән иде,
Башта Ильич аңа кул сузды.
— Исәнмесез! Исемегез ничек?
— Лавыр диләр... Илле ел узды...

— Ә атагыз исеме белән әйтсәк?
— Андый хөрмәт безгә тимәде...
Бу гомердә миңа һичбер кем дә
Лавыр Иванович димәде.

— Анысы аның элек шулай булган,
Ә хәзер бит власть үзгәрде.
Яңартыла иске тормыш хәзер,
Яңартабыз иске сүзләрне.

Сез Лаврентий Иванович, димәк... —
Кунакларны йомшак урынга
Утырта да Ленин сорый башлый
Авылдагы хәлләр турында.

— Яңа власть ничек ныгый? Ничек
Эшкә аша яңа законнар?
Йөрәкләргә алар нәрсә әйтә,
Күңелләргә ничек якыннар?

Крестьяннар ничек яши хәзер?
Ничек үтә авыл көннәре?..—
Кунакларның йөрәкләре эри,
Кунакларның ачыла телләре.

Үз белгәнен берсе башлап китә,
Берсе өзер эләп алмага.
— Әйтик,— диләр,— бездә шундыйлар
бар:
Ышанмаска куша аллага...

Кинәт Лавыр тамак кырып куйды
Һәм башлады нидер ымлап ул:
— Иптәш Ленин, власть безнеке дә,
Ләкин власть безне тыңламый.

— Ничек алай?
— Менә без күмәкләп
Кирпеч суккан идек авылда.
— Әйе, кирпеч.
— Шуңа күп көч куйдык,
Барчабызга төште авырга.

Иске иде агач чиркәвебез,
Кирәк дидек таштан салырга.
Власть белән комбед шул кирпечне
Карар кылды тартып алырга.

— Чиркәүгә дип, димәк, тырышкансыз...
Ә авылда мәктәп бармы соң?
Булса нинди: зурмы, яңамы ул?
Кем кайгырта аның кайгысын?

— Мәктәбебез, дөрес, яңа түгел,
Кыйшайган да инде бер очы...
Иптәш Ленин, бездә анысына да
Күп түгел бит әле йөрүче.

— Ә мәктәпсез, иптәшкәем, ничек
Үстерерсез совет илен сез?
Яңа тормыш төзүчеләр бит без,
Төзеп булмый аны белемсез.

Уйлыйк әле: сезнең ул кирпечтән
Буладыр ич мәктәп салып та?!
Килешсәгез, хәзер әмер бирәм
Кайтарырга аны халыкка.

Юк, китмәде Лавыр, һич китмәде
Сүзне Ильич шулай борасын.
Һәм уйлады тагы: «Каршы төшсәң,
Кайткач, ничек җавап бирәсең?..»

Карый Лавыр ике иптәшенә
Һәм Ленинга карый: — «Я, нишлик?»
— Дөрес әйтә,— диде иптәшләре,—
Ильич белән, әйдә, килешик.

Кичергәне Лавыр күңеленең
Бәреп чыкты хәтта йөзгә дә:
— Мин аңладым, иптәш Ленин, тормыш
Асты-өскә килеп үзгәрә.

Өсти тагын Лавыр кулын селкеп:
— Зур акылны синнән алабыз.
Без кайткач ук халык кирпеченнән
Зур иттереп мәктәп салабыз!

...Кремльдән чыкты крестьяннар
Таныш баскыч, таныш юл белән.
Дөрес якка борды алар уен
Ильич шулай тугры кул белән.

## Михаил Петров

*1905—1955*

### Ышанам

Ап-ак тузан, вак-вак тузан итеп
Дулкыннарны сибә давыл ярга.
Агачларны бер-бер артлы йолкый,—
Төбе-тамыры белән ава бар да.

Йөрәк әйтә серен сиңа, давыл,
Торган саен каты-көчлерәк:
Дошман килде безне юк итәргә...
Без синнән дә хәзер үчлерәк.

Синең ярсу кирәк безгә, давыл,
Бөек яуда мәйдан тотар өчен.
Синең гайрәт кирәк безгә, давыл,
Фашистларны изәр-сытар өчен —
Бөтенесен кырып салыр өчен,
Йөрәкләрен йолкып алыр өчен!

Мин ышанам: синдәй хәтәр булып,
Дошман күген каплар безнең болыт.
Алар керер бездә гүрләренә,
Без узарбыз Берлин түрләренә!

## Андрей Бутолин

### Ленин сүзе

*ӨЗЕК*

...Безнең илдән, безнең Кремльдән
Коммунизм юлы башлана.

Һәр кеше хәр минем илемдә,
Иркен сулый безнең башкала.

Ныграк итә йөрәк тибешен,
Ленин сүзе — җиңү җыры ул,
Тизрәк итә канның йөрешен,
Ленин сүзе — бәхет нуры ул.

Ленин сүзе — юллар сыза ул,
Байрак булып балкый кулларда.
Муллык булып түргә уза ул,
Тизлек булып гүли юлларда.

## Афанасий Лужанин

*1912—1966*

### Туган ил

Кочар идем сине, әнкәм итеп, илем,
Киңлекләрең кочагыма сыймас минем.

Кәрәштә дә һәм эштә дә җиңү өчен
Көч күп синдә — тиңсез көч ул синең көчең!

Син кушканда бердәм сафта атладык без,
Сине уттан һәм бәладән саkладык без.

Елгаларың көйләп дулкын каксын, дидек,
Йөрәкләрдән таныш моңнар аксын, дидек.

Донецта да һәм Валдә да юкәләрең
Чәчәк атсын, дидек, нурда иркәләнеп.

Чәчәкле дә һәм гөлле дә бул син, дидек,
Кеше бәхете синдә чиксез булсын, дидек.

Әнкәсе син җирдә азат халыкларның,
Синең юллар һаман алга алып барыр.

Безнең бурыч — җиңеп яуда, сөеп эшне,
Үстерергә синең данны, синең көчне!

## Филипп Кедров

*1912—1944*

### Фронттан сәлам

Удмуртиям! Бу сәламне юллыйм
Ерактагы айлы кичәләрдән.
Йөрәгемнең ярсу тибешен ул
Ишеттерсен ялкын эчennән.

Туган ягым, чиксез сагындырдың...
Винтовкамны кысып кулыма,

Салкын окобымда күрәм синең
Мин тагын бер яңа елыңа...

И туган ил — безнең үлемсез җыр,
Көнделеге аяз иртәбез:
Синең монда һәрбер карышыңны
Дошманга без кабер итәбез.

## Степан Широбоков

### Кайда очрашырбыз икән?

Шәфәкъ сүнде дә ай калыкты,
Шаулы бакча тынып калды.
Тик бер генә каен шунда
Безнең гәпкә колак салды.

Талгын җил дә әкрен генә,
Әйтерсең нидер сөйләде.
Юк, сөйләмәде, ул безнең
Хушлашу җырын көйләде.

ВУЗга китәм. Биек күктә
Очарга өйрәнү серен
Өйрәнергә! Иркәм кала —
Нечкә билле бердәнберем.

Өч яз килеп, өч яз китәр,
Каен өч кат яфрак кояр.
Сагыну сагышлары, белмим,
Күңелләргә ничек сыяр?!.

Кайткач, түбәм күкә тиеп,
Кайда очрашырбыз икән —
Болындамы, бакчадамы —
Кайда кочар мине иркәм?!.

Колагыма тиде ирене...
Әйттеме әллә шул хакта?
Сорамыйм... эш күбрәк калсын
Көн дә көтеп алыр хатка!

## Николай Байтирәков

### Поезд китә

Поезд китә. Тагын сәфәр кетә.
Шулай куша солдат йөрәге,
Уйлаган да, белгән дә юк инде,
Араларның бар дип ерагы.

Тагын китәм фронт узган якка
Яшьтәш дустым каберен эзләргә.
Җирдә хәзер ике пар аяктан
Кала кебек минем эзләр дә.

Шатлыгым да һәм кайгым да минем
Икеләтә зур бит — яшермим:
Хәтәр яуда чөнки исән калдым,
Ике кеше өчен яшим мин.

...Калкулыкка ике чәчәк куям.
Әкрен генә әйтәм иелеп:
Син үлмәдең! Бу тар гүргә дә бит
Без үлемне күмдек иң элек.

Авылыңда бакчаң шау чәчәктә,
Басу-кырлар бар да чәчелгән.
Кара кайгының синең яши бары
Әнкәеңнен ап-ак чәчендә.

Ә без исән! Яшьлек — һаман сафта.
Кулларыбыз эштән бушамый.
Юк! Авылда синең «үлеп калды»
Хәбәреңә һичкем ышанмый.

## Гай Сабитов

### Кояш чыга да бата

СОНЕТ

Гомерең синең янар чәчәк булып
Тамырларын җәйсен тирәнгә.
Күкләрдә оч, җирдә кыю атла
Дус-ишләрең белән тирәндә.

Чишмә төсле ташып тулган җырың
Челтерәп һәм шаулап туймасын,—
Яшь йөрәкләр аңа иярсеннәр,
Өлкәннәрне ул мул сыйласын.

Тик онытма безның кайнар була,
Ә уттан боз туа алмавын.
Дусны дус ит, ә дошманны — дошман,
Хисенең кирәк чынын аңлавың.

Яхшы белән яман яраша
Алмый һич тә — булмый янәшә.

## Данил Яшин

### Мәңге калыр

Тора биек гранит өстендә ул
Үлемсезлек булып үз халкына.
Баш иябез тирән хөрмәт белән,
Аңа йөрәк, аңа хис тартыла.

Еллар узар. Дөнья үзгәрер дә
Җир йөзенә яңа ямьнәр салыр.
Ләкин Ленин бүген ничек булса,
Йөрәкләрдә шулай мәңге калыр.

## Михаил Покчи-Петров

*1930—1959*

### Ватан

Малай чакта тирә-күрше
Авылларда күп йөрдем мин.
«Син кайдан?» дигән һәркемгә
Бер генә җавап бирдем мин:

Үз авылымның исемен әйттем!
Чөнки туган йортым-җирем,
Туган әнкәм шунда минем,
Шунда тамган тәүге тирем.

Унсигез яшем тулганда
Мин калада идем инде.
«Кайдан килдең?» диючегә
«Мин Можгадан!» дидем инде.

Чөнки минем туган авыл,
Дус-ишләрем, туганнарым —
Бар да шунда, һәм юк минем
Шуннан үзгә туган ягым.

Еллар узды. Үсә бардым.
Төрле яклар суын эчтем.
Инде бөтен удмурт җирен
Туган як диюгә күчтем.

Мәскәүдә бик күп дусларга
Күңелем белән үзем дәштем:
Иж буйларында үстем мин,
Шунда калды минем яшьлек.

Шунда туды мәхәббәтем —
Йөрәкнең кайнар җырлары,
Җитен чәчәгеннән зәңгәр
Минем туган як кырлары.

Туры килеп, чит илләрдә
Йөрсәм дә шунда кайтырмын,—
Шушы як, шушы җирләрне
Туган ил диеп әйтермен.

Ерак-ераклардан күрәм
Кайда булсам да аны мин.
Исеме аның Русь, Россия,
Шул Ватанның гражданы мин.

## Анатолий Уваров

# ӨЧ НОКТАЛЫ ДҮРТ ШИГЫРЬ

### Кузьма бүләге

Сыеры әле сатып алынмаган,
Бүләк итә шуның бозавын ул.—
Авылыбызда безнең бер Кузьма бар,
Хәтта шулай җайлый... үз җаен ул.

### Мыштым затлар

Төлке түгел — эзен себереп атлый,
Коры чыга судан — каз түгел.
Ә бит дуслар, безнең арада да
Шундый затлар... әле аз түгел.

### Хуҗасы һәм эте

Усал эттән сакланырга кирәк,
Хуҗасыннан аның — бигрәк тә.
Усал эте күзгә карап өрер,
Сүзсез тешләр хуҗа... кирәксә.

### Шартын китерә

«Җилгә каршы төкермәгез! — ди ул,—
Пычранасың чөнки төкереп».
Үзе исә һаман төкерә сиңа
Киресенчә... шартын китереп.

## Флор Васильев
*1934—1978*

### Бүләккә шатлык

Яңа көн туу — яңа бәхет ул.
Һәр яңа иртә — гүя балачак:
Яңа җырлары, хисләре белән,
Эшләре белән истә калачак.

Бөтен авылның күз явын алып
Таң җиле кырда дулкын уйната:
«Күр, нинди муллык өлгерә!» диеп
Күпме йөрәктә зур дәрт уята!

«Бәхетле булыйм!» дип ялгыз кеше,
Юк, эшли алмый җирдә бер нәрсә,
Җырдан яктырган күңел күзләре
Очкында әгәр учак күрмәсә.

Һәркемгә кирәк уртак бәхет.
Кайгы-сагышлар калмасын — бетсен.
Балкулы шатлык букеты итеп
Кеше Кешегә нур бүләк итсен!

## Василий Ванюшев

### Нарат

Нарат үсте Вала ярында
Вак дулкыннар белән кавышып.
Бер җил-давыл кинәт килде дә
Сынды нарат — тынды тавышы.

Калын кәүсә. Куе ботаклар...—
Кемнең генә кызмас күзләре!
Кискәләргә килде өч-дүрт ир.
Пычкылары сынды, түзмәде.

Ах-ух итте алар аптырап:
«Бу корычтыр, ахры, чукынчык?!»

Әйе, чынлап, нарат эчендә
Булган икән корыч кыйпылчык.

Туплар аны кемгә төбәгән?
Кемне, кайчан, ничек бу агач
Ышыклаган?.. Инде кем әйтсен
Нарат инде исән булмагач...

«Моннан — дисәм,— дустым, яу узган!»
Бәлки бергә тынычланырбыз
...Тагын яуса өскә ядрәләр,
Без дә шулай корычланырбыз

## Владимир Романов

### Солдат язы

Күкрәк тутырып яз һавасын сулыйм.
Лагеребыз безнең урманда —
Тар юлларын таптп, сукмакларын...
Ят та ауна яшел урганда.

Рәхмәт фәнгә: солдатны да хәзер
Нәкъ галимчә итеп уйлата
Рәхмәт язга: иртә таңда сине
Сандугачлар сайрап уята

Урман япь-яшь. Ә күк йөзе көзге —
Гыйшкың эзен гүя күрәсең:
Шул юлдан бит кичә миңа килде
Сөйгән ярым салган бер рәсем!

Кичер, син, яз, автоматлар тыр-тыр
Килгән өчен тып-тын якларда:
Без, солдатлар, шулай өйрәнәбез
Тын урманнар ямен сакларга.

**ЗӘКИ НУРИ** тәрҗемәләре

# Петр Поздеев

## Удмурт иле

Вакыт җиткәч, чит илләргә
Чыгарга да әзер мин.
Тик анда туган ягымны
Белүчеләр әздер дим...

Сорарлар анда: удмурт кем?
Удмурт иле нинди ул?
Удмурт иленә кем хуҗа?
Илтә аңа нинди юл?

Удмурт иле — яфрак кына
Мәһабәт бер имәндә.
Күз алдына Бәхет килә
Удмурт иле дигәндә.

Удмурт иленең хуҗасын
Ерактан була танып:
Ул — бәхетле, нурлы булыр,
Исеме аның — Халык!

Килсәгез, табын түрендә
Дәртле җырлар җырланыр,
Һәр авылда, һәр шәһәрдә
Сезгә бәхет юлланыр!

Әгәр дә телисез икән
Дуслык тәмен татырга,
Кагылырбыз без марига,
Башкортка һәм татарга...

Удмурт иле менә шушы!
Килеп күрә аласыз:
Рәхим итегез — һәр өйгә
Килеп керә аласыз!

Удмурт иле — бәхет иле!
Бәхет өчен туган ул!
Чөнки халкым Илемдәге
Бар халыкка туган ул!

# Вениамин Ившин

## Онытмыйк

Утырттык алма агачы —
Ул яшь әле, әр-яңа...
Әмма үткен балталар да
Бар шул әле дөньяда.

Карлыгачлар уйный күктә —
Югарыда, биектә...
Әмма шунда ук әйләнә
Козгын дигән киек тә.

Без бу җиргә барыбыз да
Яхшылыктан яралдык...
Әмма безне әле һаман
Саклап тора ямьлык.

Без — бәхетле! Бүген әле
Ямьлыклар янамый...
Әмма алма бакчасын да
Онытырга ярамый!

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәләре

## Татьяна Чернова

### Күптән таныш кебек...

Синең туган якларыңда
Булганым юк әле.
Авылың урамнары буйлап
Узганым юк әле.

Юк әле чишмәгез суын
Татып караганым.
Күргәнем юк сихри күлен,
Моңсу аланнарын.

Тик син туып-үскән җирләр
Миңа шундый якын:
Әллә кайчан таныш кебек
Киң күңелле халкың.

Таныш гүя бөтенесе
Балачактан бирле.
Күзләреңдә язмышымны
Күреп сөям сине.

## Галина Романова

### Тояклар тими җиргә дә

Ыргый аргамак,
Оча аргамак!
Тояклар гүя
Тими җиргә дә.
Үлән сәрлегә,
Сыгыла агачлар,
Ул шулай ярсып
Чабып килгәндә.

Аны тыярга,
Куып җитәргә,
Юк, беркемнең дә
Килмәс кулыннан.

Дагаларыннан
Очкыннар чәчри,
Әй, бер як читкә
Тайпыл юлыңнан!

Чү, нигә кинәт
Шып туктады ул?
Куркуга төшеп,
Кайгыга баттым.
...Каршына чыккан
Тәвәккәл егет
Ялларын сыйпый
Яшь аргамакның.

**РӘШИТ ГӘРӘЙ** тәрҗемәләре

# СОҢГЫ «ТАЯНЫЧ»

Сугыштан соңгы елларда империалистик илләрнең «советолог»лары Бөек Ватан сугышы тарихын, шул җөмләдән төрле милләт халыкларының бу сугыштагы ролен тырышып-тырмашып бозып күрсәтергә маташалар, һәркайсыбыз өчен изгедән дә изге нәрсәгә — совет халыкларының дуслыгына кизәнәләр. Бу эштә алар яманаты чыккан милләтчеләргә таяналар.

Германия Федератив Республикасының Мюнхен шәһәрендә чыга торган журналларның берсендә Музабай Б. дигән берәү: «Гитлер гаскәрләре Россия җиренә кетмәгәндә басып кергәннән соң, Кызыл Армиянең күп милләтле отрядлары этнографик компонентларга таркалуга юл тотты,— дип яза.— Фронтлардан Совет Армиясенең аерым берләшмәләре тулысы белән юкка чыга башлады. Рус булмаган милләтләрдән армиягә алынган резервчыларның күбесе үзләренең партия билетларын «югалттылар», фронтка килгән партияле күп кенә татарлар «партиясезләр»гә әйләнделәр».

Биредә тарихны зур әһәмияткә ия булган өч мәсьәләдә фальсификацияләргә маташу күзгә бәрелә:

Аяусыз каты сугышларда Кызыл Армия үзен ничек күрсәтте? Советлар Союзындагы азчылык милләтләрнең, шул исәптән татар халкының Бөек Ватан сугышына мөнәсәбәте нинди иде? Авыр сугыш шартларында татар халкы Коммунистлар партиясенә карата нинди карашта булды?

Бу сорауларның һәркайсына аерым-аерым тукталып узыйк.

Советлар Союзына һөҗүм иткәндә Гитлер, чыннан да, беренче көчле ударлардан соң ук Кызыл Армиянең таркалуына, этник компонентларга бүлгәләнүенә, аларның үзара талаша башлауларына исәп тотты. Ләкин аның бу уйлары челпәрәмә килде. Сугышның башында әйтеп бетергесез авырлыкларга дучар булуына да карамастан, Совет Армиясе Ватаныбызның һәр карыш җирен саклап калу өчен героик көрәш алып барды, күп санлы сугышларда дошманны җиңеп чыкты һәм, ахыр чиктә, аны берсүзсез капитуляция ясарга мәҗбүр итте. Бу фактлар кире каккысыз. Музабайның Кызыл Армиянең «этник компонентларга таркалуын» исбатларга маташуы тарихи фактлар яктылыгында аны кояш яктысын күрә алмаган сукыр тычкан хәлендә калдыра.

Татар халкының сугышка карата мөнәсәбәтен караганда да фактлар Музабайга каршы. Социализм төзүче тугандаш халыкларның бердәм, тату гаиләсендәге татар халкы үзен баркайчан да Музабайларның хыялый идеяләренә дәлил булу хәлендә калдырганы юк. Азия халыкларына, шул нәүбәттән татар халкына карата булган мөнәсәбәтен ачыктан-ачык белдереп, Гитлер болай диде: «Норд расасының бөтен дөньяга хуҗа булырга хокукы бар һәм бу хокук безнең тышкы политикабызда юл күрсәтүче йолдыз булып торырга тиеш. Шуңа күрә дә славян-татар гәүдәсендә еврей башы утырган Россия белән нинди дә булса бәйләныш турында сүз дә булуы мөмкин түгел»[1]. Фюрерның бу һәм башка сүзләре, фашизм җиңгән очракта, «түбән раса»дан булган башка халыклар шикелле үк, татар халкына да җирдән себереп түгелү кебек ачы язмыш хәзерләнгән булуы һичбер нинди шик калдырмый. Совет халкы, бер кешедәй булып, гитлеризмның нәк шундый вәхши планнарына каршы көрәшкә күтәрелде.

[1] История СССР, 1966, т. 2, 163 б.

Татар халкының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыгын 200 дән артык якташыбызга Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелүе, 175 мең кешенең сугышчан орденнар һәм медальләр белән бүләкләнүе үзе үк бик ачык раслый. Совет Армиясенең күп кенә полководецлары һәм хәрби начальниклары тарафыннан әйтелгән сүзләр татар халкы уллары һәм кызларына зур ихтирам белән сугарылган. Сугышта татар халкы Ватанны ярату һәм каһарманлык үрнәге күрсәтте.

Музабайның куркаклык, кайберәүләрнең «партия билетларын югалтулары» хакындагы ишарәсенә каршы болай дип җавап бирергә теләр идек: гаилә гарипсез булмый, ди халык. Меңнәрчә фидакарь көрәшчеләр арасында хыянәт юлына баскан йомшак характерлы аерым бер кешеләр дә булгандыр, бәлки. Югыйсә, Музабайлар, Дәүләтшиннар, Нигъмәтуллиннар, Гариф Солтаннар каян килеп чыгар иде? Ләкин биредә бит сүз татар халкының Коммунистлар партиясенә карата булган мөнәсәбәтенә оятсызларча яла ягу, пычрак ату турында бара. Төрле уйдырмаларга корылган мондый гайбәтләрнең һичбер нинди нигезе юк. Совет тарихчыларының фәнни хезмәтләре, архивларда сакланган һәм матбугатта басылып чыккан күп санлы материаллар чынбарлыкны бөтен тулылыгы белән ачык чагылдыралар.

Бөек Ватан сугышы елларында «коммунист» сүзе чыдамлык һәм каһарманлык дигән сүзләр белән аерылгысыз рәвештә бергә кушылды, халыкның партия сафларына тартылуы моңарчы һич кайчан күрелмәгәнчә көчәйде. Сугыш алдыннан Татарстанда партиягә ай саен 140-150 кеше кабул ителгән булса, 1942 елның соңгы айларында — Сталинград янында иң куркыныч һәм хәлиткеч бәрелешләр барганда партия сафларына керүчеләрнең саны өч-дүрт тапкырга артты. Эш нормасын ике йөз процентка үтәп килгән Казан эшчесе Хәйруллин үзен Коммунистлар партиясенә алуларын сорап язган гаризасын менә мондый сүзләр белән тәмамлый: «Сөекле Ватанымны саклаучылар сафына коммунист булып басарга һәм, тормышымны кызганмыйча, котырынган илбасарга — герман фашизмына каршы соңгы тамчы каныма кадәр көрәшергә телим». Мондый гаризаларны күпләп санарга мөмкин, фронтта да шундый ук хәл күзәтелә. «Сталинград өчен сугышка коммунист булып керергә телим»,— дип яза Сталинград оборонасының иң авыр көннәрендә Вазыйх Фатыйхов. Сугышта ул үзен чын коммунист итеп таныта һәм «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Дошман менә-менә шәһәрне ала дип җан тетрәп торган шул ук 1942 елның хәвефле ноябрь көннәрендә Сталинград фронты частьларында гына да рус булмаган милләтләрдән 551 кеше, шул исәптән 120 татар, 95 казакъ, 57 үзбәк, 57 әрмән, 39 грузин, 23 азәрбайҗан, 17 башкорт, 14 таҗик сугышчысы партиягә кабул ителә. Шулай итеп, Ватанга куркыныч янаган, аның язмышы хәл ителгән иң авыр сәгатьтә татар халкының сынал-ган уллары фронтта да, тылда да партия сафларына киләләр, ил өстенә төшкән бөтен авырлыкны, шатлык һәм кайгыларны аның белән бүлешергә телиләр. Сугыш елларында бер Татарстанда гына да партиягә татар халкының 15 мең улы һәм кызы алына. Дәһшәтле сугыш шартларында татар халкының Коммунистлар партиясенә карашы шушы саннарда да бик ачык чагыла. Бу авыр елларда халык үзенең партиясенә, ә партия исә халыкка тагын да ныграк якыная.

«Һәр совет дивизиясендә күчмә газета редакцияләре һәм типографияләре бар иде,— дип дәвам итә Музабай.— Фронтовик татар язучылары бу газеталар өчен мәкаләләр, поэмалар, шигырьләр яздылар. Ләкин аларның әсәрләренең стиле социалистик реализм алдына куелган официаль таләпләргә, ай-һай, туры килә алдымы икән? Ул әсәрләрнең күбесе, гомумән көрәшеп торырга кирәкме дигән пессимистик идеялар һәм шик-шөбһәләр белән сугарылган иде».

Монда инде татар совет язучыларының социалистик Ватанга, Бөек Ватан сугышына карата мөнәсәбәте тупас рәвештә бозып күрсәтелә.

Сугышның беренче көннәрендә үк бертавыштан кабул ителгән карарларында Татарстан язучылары болай дип белдерделәр: «Без, Совет Татарстаны язучылары, кулыбызга мылтык һәм каләм тотып, данлы Кызыл Армиябез сафларына басачакбыз һәм үзебезнең бөтен талантыбызны һәм белемебезне, бөтен көчебезне биреп, гомеребезне дә кызганмыйча, сөекле Ватаныбызны яклап сугышачакбыз»[1]. Алар үзләре-

[1] «Кызыл Татарстан» газетасы, 1941, 25 июнь.

нең сүзләренә тугрылыклы булып калдылар. Бик күбесе үз теләкләре белән Кызыл Армия сафларына чакыруны сорап хәрби комиссариатларга гариза язды.

Күренекле татар язучыларыннан К. Нәҗми, Ш. Маннур, М. Җәлил һәм башкалар фашизмга каршы аяусыз көрәшкә күтәрелергә өндәп, һәр сүзе тирән дулкынландыргын патриотик чакыру белән матбугат аша халыкка мөрәҗәгать иттеләр һәм безнең җиңәчәгебезгә ныклы ышаныч белдерделәр. Өлкән язучыларыбыздан Шәриф Камал ул көннәрдә болай дип язды: «...Бөек социалистик илебезнең бөтен күмәк көче, иң явыз дошманга ачу уты белән ялкынланган хәлдә, хәзерге көндә, бары бер генә максатны күздә тота, аның бөтен игътибары, бөтен омтылышы бер генә максатка төбәлгән: дошманны тар-мар китерү, җир йөзеннән аны юк итү.

...Без үзебезнең эшебез хак икәнлеккә нык ышанабыз. Бездә гаделлек, бездә хаклык... Әлбәттә, без җиңәчәкбез!» [1]

Татарстан Язучылар союзында член булып исәпләнгән 53 язучының 25-е сугышның беренче елында ук фронтка китте. Ә 1943 елда 64 язучының 36-сы фронтта булып, алар арасында М. Җәлил, Ш. Маннур, Ф. Кәрим, Н. Баян, Ә. Ерикәй, С. Хәким, Ә. Исхак, Г. Кутуй һ. б.лар бар иде. 1942—1943 елларда татар язучыларының зур төркеме (Г. Кутуй, А. Шамов, М. Максуд, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, Г. Әпсәләмов, И. Гази, А. Әхмәт, Г. Галиев, Ә. Исхак, Ш. Маннур, Г. Насрый, Ә. Фәйзи, Ш. Мөдәррис һ. б.лар) татар телендә чыга торган фронт газеталары редакцияләрендә эшләде.

Фронт матбугатында басылган күп санлы очеркларын, хикәяләрен, корреспонденцияләрен, шигырьләрен язучылар Ватанны саклау темасын яктыртуга багышладылар, сугышчыларны совет патриотизмы, илгә, партиягә бирелгәнлек, тугрылык рухында тәрбияләделәр, аларда дошманга каршы көчле нәфрәт тойгысы уяттылар. «Тирән пессимизм һәм шик-шөбһәләр белән сугарылган» әсәрләрне Музабай каян ала соң? Сугыш елларында уналты фронтта чыккан һәм Ленин китапханәсендә, шулай ук башка махсус урыннарда зур саклык белән сакланган газеталарның тупланмаларында татар язучыларының сугыш елларына кагылышлы иҗат мирасы бай чагыла. Ләкин «Музабай да, кем дә булса башка берәү дә татар язучыларының иҗатында «тирән пессимистик әсәрләр»не таба алмас, бу нәрсә аларның табигатендә юк.

Сугыш елларында Татарстан язучылары киң колачлы әдәбият тудырдылар. Ул елларда Татарстан китап нәшрияты гомуми тиражы бер миллион ярым данәгә җиткән 220 исемдәге китап бастырып чыгарды. Музабай социалистик реализм принципларыннан читкә тайпылуны каян тапкан? Әмма бер нәрсә ап-ачык: боларның барысы да фальсификаторның чираттагы уйдырмасы.

Коммунистлар партиясе политикасына яла ягу максатыннан чыгып, Музабай менә нәрсәләр яза: «Сталинградтан соң партия лидерлары татар язучыларыннан немецларга карата нәфрәт тойгысы дөрләтүдә катнашмауларын таләп иттеләр».

Коммунистлар партиясе сугышның иң-иң кырыс көннәрендә дә ике нәрсәне — немец халкын һәм немец фашистларын, немец фашист баскыннарын бутауга юл куймады. «Кайчакта чит ил матбугатында, совет кешеләре немецларны немец булган өчен дошман күрәләр. Кызыл Армия немец солдатларын немец булганнары өчен, немецларга хас булган бөтен нәрсәгә дошманлык белән караганлыктан юк итә, шуңа күрә Кызыл Армия немец солдатларын пленга алмый, дип лыгырдыйлар,— диелгән иде Оборона Халык Комиссарының 55 номерлы 1942 ел, 23 февраль приказында.— Әлбәттә, шундый ук тупас ялган һәм Кызыл Армиягә карата ахмакларча яла ягу. Кызыл Армия раса дошманлыгы хисеннән азат. Ул мондый хурлыклы хистән азат, чөнки ул расаларның тигез хокуклылыгы һәм башка халыкларның хокукларын ихтирам итү рухында тәрбияләнгән. Шуның белән бергә, безнең илдә раса дошманлыгы өчен закон буенча җәза бирелүне дә онытмаска кирәк» [2].

1944 елның 6 ноябрендә ясаган чыгышында бу мәсьәләгә И. В. Сталин яңадан борылып кайтып тукталды: «Совет кешеләре,— диде ул,— немец илбасарларны чит милләт кешеләре булган өчен түгел, бәлки безнең халкыбызга һәм барлык азатлык сөюче халыкларга санап бетергесез бәла-казалар китергән өчен дошман күрәләр. Безнең

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 1941, № 7, 10 бит.
[2] И. Сталин. Советлар Союзының Бөек Ватан сугышы турында. Казан, 1946, 42 бит.

халкыбыз борынгыдан ук әйтеп килә:— Бүрене соры булганы өчен түгел, сарык ашаганы өчен кыйныйлар,— ди».

Югарыда тукталып узылган мәсьәләләрдә фашистлар агрессиясе шартларында татар халкының позициясен бозып күрсәтсә, алга таба Музабай Б. совет халыкларының, аерым алганда татар һәм рус халыкларының дуслыгына селтәнә. Кайбер вакыйгаларның шаһиты булган немец язучысы Теодор Пливирга таянып, ул 1941 елның көзендә Мәскәүдән эвакуацияләнеп, Казанга килгән рус язучыларын салкын кабул иттеләр, дип расларга азаплана. 1974 елда Лондонда басылып чыккан «Совет Татарстаны — ленинчыл милли политика теориясе һәм практика» дигән соңгы китапчыгында да Музабай — Дәүләтшин шуны ук кабатлый.

Дошман илебезнең башкаласы Мәскәү янына ук килеп җиткән 1941 елның авыр көзендә, билгеле, мул табыннар хәзерләп, тантаналы итеп каршылаулар оештырырга мөмкинчелек булмый. Һәм Казанга килгән мәскәүлеләр моны бик яхшы аңлыйлар. «...мәрхәмәтсез сугыш чорында миңа һәм каләмдәш дусларыма сыенып урын биргән өчен Татарстанга мин чын күңелемнән рәхмәт әйтәм,— дип язды 1966 елда Михаил Исаковский, ул вакытларны искә алып.— Дөрес, аңа урын ул кадәр «аһ» итәрлек түгел иде, ләкин мин яхшы аңлыйм: чоры читтән тыш авыр, катлаулы чор иде һәм моның шулай икәнлеген һич тә истән чыгарырга ярамый»[1]. Шагыйрь Лев Иванович Ошанинның шул ук елларны искә төшерү уңаеннан әйткән менә мондый сүзләре бар: «Татар халкы белән безне дуслык җепләре генә түгел, туганлык җепләре дә аерылмаслык итеп бәйли».

Мәскәү язучылары белән бергә Казанга килгән Италия язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Джованни Джермонетто 1958 елда: «Матбугат йортында Казан язучылары һәм журналистлары белән очрашуыбызны беркайчан да онытмам,— дип язды.— Без рус, немец, француз телләрендә сөйләшсәк тә, бер-беребезне яхшы аңлый идек. Безне туганнарча җылы каршыладылар һәм без татар дусларыбыз арасында үзебезне туган йортыбыздагыдай хис иттек»[2].

Шулай итеп, Музабайның Татарстанда Мәскәү язучыларына карата булган ниндидер дошманлык хисләре турындагы усал кинаясе чынбарлыктагы фактларга якын килү белән шартлаучы сабын куыгы булып кала.

Татар халкының Бөек Ватан сугышында ни дәрәҗәдә катнашуын ачык раслаучы фактларны фальсификацияләүче Советка каршы бәндәләр хорында чыкылдап торган милләтче Гаяз Исхакыйның иярчене Гали Акыш тавышы да ишетелә. 1963 елда Анкарада басылып чыккан «Идел — Урал дәгъвасы вә совет империализмы» дигән китабында ул менә нәрсә яза: «1941 елда, Сталин җитәкчелеге чәчәк аткан чорда, рус-герман сугышы башланып китте. Бөтен азат дөнья буенча сибелгән Идел — Урал төрекләре Европада булсын, Ерак Көнчыгышта булсын, Шәфи Алмас җитәкчелегендә төзелгән һәм немецларга хезмәт иткән Идел — Урал легионына берләштеләр һәм аны алкышлап каршыладылар. Бу легион русларга каршы батырларча көрәште, югалтуларга дучар булды, милли бәйсезлек хәрәкәте идеяләренә тугрылыклыгын күрсәтте».

Мәскәү янында җиңелеп, Россияне «яшен тизлеге белән юк итү» планы җимерелгәннән соң, гитлерчылар үзләренең политикаларын вакытлыча үзгәртергә мәҗбүр булдылар. Элек алар «азиатлар»ны, «тулы кыйммәткә ия булмаган» халыклар буларак, җирдән себереп түгү программасын алга сөрсәләр, хәзер инде шул халыклар арасыннан үзләренә «туп итә» эзли башлыйлар. Фашистларның шундый курска күчүләре уңае белән Әхмәт Тимер, Шәфи Алмас, Искәндәр Яушев, Галимҗан һәм Шәмсия Идриси, Гариф Солтанов, Шиһап Нигъмәти кебек милләтче татар эмигрантлары һәм сатлык җаннар, Берлинда бергә җыелып, «Идел — Урал» дигән татар-башкорт дәүләте төзү турында карар кабул иттеләр. Аларның чыңга ашмас хыялларында гына төзелгән бу дәүләтнең «президенты» итеп элеккеге Казан сәүдәгәре, эмигрант Шәфи Алмас билгеләнә. Армиясез нинди дәүләт булсын ди? 1942 елның августында фюрер «Идел — Урал» легионы оештыру турындагы приказга кул куя. Гитлерчылар командалыгында төзелә башлаган легионга лагерьларда һәм төрмәләрдә йончудан, ачлыктан үлем хәленә килеп җиткән татар, башкорт, чуваш, мари хәрби әсирләре көчләп

---

[1] Климентовский В. А. Русские писатели в Татарии. Третье издание. Казань, 1974, с. 146.
[2] «Совет әдәбияты» журналы, 1958, № 8, 86 бит.

куып китерелә. Шуның белән беррәттән, легионга күзгә бәрелеп торган сатлык җаннар һәм череп таркалган, кешелек сыйфатларын югалткан җинаятьчеләр дә эләгә.

«Идел—Урал» легионы составында гитлерчылар дүрт батальон төзиләр. Батальоннарда Муса Җәлил һәм ул оештырган каршылык күрсәтү группасы зур патриотик эш алып бара. Легионның барлык подразделениеләрендә восстание штаблары вазифасын үтәячәк антифашистик яшерен оешманың күп тармаклы челтәре булдырыла. Легаль чыга торган газета аша листовкалар тарату, музыка капелласының эшен бер үк максатка юнәлтү һәм башка юллар белән җәлилчеләр легионда зур эш башлап җибәрәләр.

Нәтиҗәдә, легионның беренче, икенче, өченче һәм дүртенче батальоны һәммәсе үз кораллары белән партизаннар ягына күчеп бетә һәм аларның сафында көрәшә.

Сугышта фашистик Германиянең һәм империалистик Япониянең җиңелүенә көенеп, Акыш: «...бәйсезлеккә булган өмет кояшы батты»,— дип нәтиҗә ясый. Үз халкын гитлерчылар яки япон самурайлары кулына бирергә теләгән һәм алардан ниндидер «бәйсезлек» көткән кешенең әхлакый йөзе шулай ачыла. Татар халкы турында бертуктаусыз лыгырдаучы, чынлыкта исә кем күбрәк түләсә, шуңа хезмәт итүче, берниндн кавемсез һәм нәсел-нәсәпсез гадәти сатлык җан — шул гына. 1959 елда Америка Кушма Штатларында изелгән, җәберләнгән милләтләр атналыгы турында закон кабул ителүе һәм шундый 22 ил рәтенә «Идел — Урал»ның да кертелүе уңае белән Акышның шатланып бетә алмавы моның шулай икәнлеген бик ачык раслый. Ә нишләп шатланмасын ди ул? Бу бит аның байлыклары ташып торган яңа хуҗаларга килеп юлыгуы дигән сүз!

Татар халкы тарихын күралмаган фальсификаторлар, барлык сатлык җаннар һәм хыянәтчеләр, империалистлар сузган калҗа хакына көн-төн «эшләп» тир түгәләр. Бу — аларның соңгы таянычы.

**ҖӘМИЛ ГЫЙЛЬМАНОВ,**
тарих фәннәре кандидаты, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалындагы Галимҗан Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты өлкән гыйльми хезмәткәре.

Салих Баттал

# ШИГЪРИ МӨРӘҖӘГАТЬ

I

Мөрәҗәгать язам, Батый, сиңа,
гәрчә үлгән инде күптән син,
әмма кайбер шовинистлар өере
күңелендә әле исән син.

Варислыкның шундый төрләре бар —
тәхетне син алдың бабаңнан.
Безнең чорга күчә идеяләр
Нух туфаны күмгән заманнан.

Кенчыгышның бөек бер илендә
хәзер алды яңа этәреш
курылтайлар мәҗлесендүк инде
билгеләнгән синең юнәлеш...

Татар-монгол ханы! Мин дә татар,
тик моңарга күңелем зурланмый
һәм «төп бабаң — маймыл» дигәнгә дә
кеше хәзер һич тә хурланмый.

Егерменче гасыр диләр моны.
Шуңар, булыр өчен җитәкче,
революция дигән сүзне хәтта
син үзеңә маска итмәкче.

Культура дип исем алды анда
Пушкин әсәрләрен яккан ут,
ерак түгел, әнә факел тоткан
баскакларың тора чатта ук.

Әле күршеләреңә теш кайрыйсың.
Тик ниятең киткән еракка:
күңелең белән син тезгәнсең инде
күп илләрне шул ук чиратка.

Юнәлеше кая, лагерьгамы? —
Анысын әйтмисең син әлегә.
Ниятлисең ләкин бар җир шарын
китерергә лагерь хәленә.

II

Элек заман син маскасыз идең.
Чыңгыз ханның кара байрагын
кадар өчен Идел буйларында
һич тартынмый урын сайладың.

Суга батмый, утка янмый килдең,
ләкин баттың башка агымга —
коерык төбеңәчә эреп беттең
цивилизация канында[1].

Шәркый Европада иң беренче
корыч эретүче болгарлар
һәм башкалар миче әле дә кызу —
синдәйләрне эретә торганнар.

Шуннан бирле күпләр эретелеп,
яңа калыпларга салынды,

гадел хезмәт белән тамгаланган
яңа атомнарда табылды.

Шуннан бирле күпме агрессорлар
татыдылар безнең йоланы, —
уратылып тар-мар ителделәр
тетрәп, тыңлап безнең «Ура!»ны.

Россиягә сугышып килүчеләр
эчтән каушый икән шуңар бит, —
руска һөҗүм итсәң, коралланган
татар аннан бәреп чыгар, — дип.

Руслар белән бер үпкәгә сулап,
бер үк йөрәк куган канны да
Автономия булып җитешкәнбез
без Россия-ана карнында.

III

Ә соңыннан кайнап һәм чыныгып
Бөек Октябрьның утыннан,
илебезнең ирек байрагында
йөз милләтнең каны кушылган.

Индустрия, колхоз фронтында
шушы байрак белән җиңде ил:
хәтта уп чак туган улларыма
«Урал», «Металл» исемен бирдем мин.

---

[1] Варвар-илбасарлар үзләре басып алган цивилизацияле халыклар эчендә үзләре үк эреп бетә дигән хакыйкать күздә тотыла.

Шушы кызыл байрак асларында
интернационал рухлы эз салып,
һөҗүмгә тарган бер халыкны яклап
бәреп чыга бездә йөз халык!

Шул байрак астында төгәлләдек
кан дошманың Пушкин эшләрен,—
томнарына һәм дәфтәрләренә
без өстәдек «Моабит дәфтәрен».

IV

Шул ук байрак иде алдыбызда
Көнчыгышка таба походта
мең тугыз йөз кырык бишенче ел
Ирек алып барган вакытта.

Шушы кызыл байрак асларында
безнең белән барды бит алар —
Квантун армиясен тар-мар иткән
безнең Урал, безнең Металлар!

Бу кулларым штурвалда иде,—
мин дә шунда идем ул елны —
коллык алып килгән сарыларның
ирек сөйгән ак бер оныгы.

Шуның өчен мәллә, Батый, хәзер
миңа каршы тәртә борасың?

Күрәм, кемне шатландырасың син:
НАТОларның алтын урдасын!..

«Җен алмаштырган» ди бездә халык
тиле-миле бала турында.
Әйтче, Батый, кем җибәрде сине
зуп-зур Маоны алмаштырырга?!

Бетсен гегемонизм камуфляжы —
сарылыгы аның, аклыгы...
Бер үк былчыракка илтә торган
арий янсә батый «сафлыгы».
Хөрлек, Тигезлекне байрак итеп,
совет халыклары юл алдык
бетерергә сугыш куркынычын:
— Яшәсен, дип, Дуслык, Туганлык!

# ГЫЙЛӘҖ КАЗАНСКИЙНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Гыйләҗ Казанский үзе турында: «Мин 1891 елны, Казан губернасы һәм өязе, Яңа Кишет волосте, Өчиле авылында туганмын. Атам үз көче белән көн күрүче бер крестьян. 12 яшемә кадәр татар мәдрәсәсендә укып, шуннан соң байда хезмәт итә башладым. 1908—1909 елларны Казанда һәм Уфада сәхнә һәвәскәре булып уйнап килдем»,— дип яза.



Г. Казанский Уфага килгән елларны, шәһәр кечкенә булса да, халык тормышына ямь бирә торган төрле кызыклы вакыйгалар булып тора. Көймәдә пикникка чыгулар, Уфа әйләнәсен пароход белән сәяхәт кылу, чәчкә бәйрәме, төрле күргәзмәләр кешеләрне үзенә җәлеп итә.

Прогрессив татар яшьләре театр өлкәсендә дә зур активлык күрсәтәләр.

Нәҗип Әбдрәшитов үзенең бер истәлегендә ул еллар турында яза: «Һәвәскәрләр алдында торган иң зур мәсьәләләрнең берсе — яхшы уйнаучылар табып түгәрәкне ныгыту иде... Казарменный урамнан узарга туры килгәндә, кечкенә генә кибеттә ит белән сату итүче чибәр яшь егетне күрә идем. Бер көнне эштән бушагач һәвәскәрләр янына килүен үтендем. Ул исә: «Минем зур эшем юк, бер иптәшем гармун белән скрипкада уйный, ә мин җырлыйм. Шулай итеп вакытны үткәрәбез»,— диде. Икенче көнне Гыйләҗ Ибраһимов безнең түгәрәккә килеп, һәвәскәрләр уенында катнашырга теләвен белдерде. Без аңа «Беренче театр» комедиясендә асрау Бибн ролен бирдек. Әлбәттә, хатын-кыз җитмәү сәбәпле. Ул исә бу рольне бик матур гына итеп башкарып чыкты. Гыйләҗ, Казан ягыннан килүенә басым ясап, без чыгара торган афишаларда үзенең фамилиясен Казанскийга алыштырды».

Театр эшенә бөтен күңеле белән бирелгән Гыйләҗ үзенә тапшырылган рольләрне уңышлы башкара. Ә 1912 елда «Нур» труппасында эшли башлагач, аның таланты тагын да ачыла төшә. Башта аңа мәхәббәт каһарманнарының күңел дөньясын ачу уңышлырак бирелә. Заһид (М. Фәйзи. «Кызганыч»), Фәхретдин (Н. Вәзиров. «Мөсиббәте Фәхретдин»), Фердинанд (Ф. Шиллер. «Мәкер һәм мәхәббәт»), Борис (А. Н. Островский. «Гроза») образларында бу аеруча ачык күренә.

М. Фәйзинең «Кызганыч»ында Заһид (Г. Казанский) белән Гәүһәр (С. Гыйззәтуллина-Волжская) арасындагы мәхәббәт драмасы тамашачыда көчле тәэсир калдыра.

«Алар чыннан да яшьләрнең шундый вакытта рухи хәлләрен, мәхәббәтнең бер куәтекаһирә (җиңүче көч — Х. Г.) икәнлеген ачык күрсәтә алдылар»,— дип яза шул хакта «Тормыш» газетасы рецензенты Самат Шәрәфетдинов (1916 ел, 29 сентябрь).

«Нур» труппасы Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт» трагедиясен 1917 елның 24 февралендә һәм 12 декабрендә тамашага куя. Беренче кат спектакльне рус труппасы артисты Винарский, ә икенчесен Г. Казанский сәхнәгә куя. «Мәкер һәм мәхәббәт» кебек классик әсәрне уйнау артистларның профессиональ осталыкларын үстерүдә зур ярдәм итә. Моңа кадәр социаль-көнкүреш темасына язылган пьесаларда уйнап килгән артистларга күтәренке романтик рухлы трагедиядә уйнарга туры килә.

«Уйнаучыларның һәрберсе нык хәзерләнеп кергәннәр вә роль дә мөмкин кадәрле уенчыларның сәләхиятенә карап бүленгән»,— дип яза рецензент. («Тормыш» газетасы, 1917, 19 февраль). Фердинанд ролен Казанский, Луиза ролен С. Гыйззәтуллина-Волжская башкара. Алар шулкадәр ышандырырлык итеп уйныйлар ки, хәтта тамашачыларны үзләре тойган тойгылар белән чынлап та ялкынландыра алалар». Әсәрнең социаль эчтәлеген ачу дәрәҗәсе артык югары булмаса да, ике гашыйкның бәхетенә социаль аермалыклар киртә булуы спектакльдә ачык чагыла.

1918 елның язында Г. Казанский А. Н. Островскийның «Гроза» драмасында Борис ролен зур уңыш белән башкара. «Тормыш» газетасы бу спектакльгә уңай бәя биреп: «Тоткынлыкта изелүче вә шул сәбәпле дөнья белән исәнләшергә мәҗбүр булучы мәзлүмә яшь килен Катя ролен — Волжская, берәүне чынлап сөюдән башка гөнаһсы булмаган вә шул ук горефтән азап күрүче гашыйк Борис ролен Казанский чыннан да үз рольләренең рухына кереп уйнадылар»,— дип яза (1918 ел, 16 февраль).

Күргәнебезчә, Г. Казанский атаклы Сәхипҗамал Волжскаяның талантлы сәхнә партнеры буларак бергә уйнаган спектакльләренең төзек ансамбль хасил итүенә ирешә. Алар уены исә үз нәүбәтендә башка артистларның сәхнә осталыгына да уңай тәэсир ясый.

Гражданнар сугышы чорында Г. Казанский Кызыл Армия труппаларында эшли. Мәсәлән, 5 нче Армия политбүлеге карамагындагы труппа спектакленең бер программасында шундый сүзләрне укыйбыз. «Народный дом, 1919 ел. Дүшәмбе көн, алтынчы октябрьда 5 нче Армия хозурындагы мөселман секциясенең татар драма артистлары тарафыннан Петроград һәм Мәскәүдәге ач иптәшләребез файдасына куелачак спектакль: «Кызыл һәм кара». («Ике фикер»). 3 пәрдәдә, Г. Коләхметев әсәре»,— дип язылган. Кызыл — яңа фикер ролен бу спектакльдә Казанский башкара.

Гыйләҗ абыйның уенын мин беренче мәртәбә 1920 елның көзендә Уфа сәхнәсендә күрдем. «Галиябану» драмасында Хәлил ролен башкарды. Бу спектакль «Эш һәм сәнгать сараенда» (хәзер башкорт дәүләт опера театры бинасында) куелган иде. «Галиябану»ны караганнан соң без, яшьләрдә, театрга мәхәббәт уянды, театр безнең өчен җан азыгына, тәрбия мәктәбенә әверелде.

1921 елның август аенда шул ук «Эш һәм сәнгать сарае»нда Казанский Ф. Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә» драмасын куйды. Таһир ролен Г. Казанский үзе башкарды. Театр халык белән тулган. Каты ачлык өй бусагасына килгән чак булса да, артистлар халыкның күңелен күтәрергә тырышканнар күрәсең, спектакль зур һәм шаулы итеп куелды.

Башкортстанның атказанган артисткасы Гамбәрә Мансурова «Сәнгатькә багышланган гомер» исемле мәкаләсендә Казанскийның Уфада эшләү вакытында башкорт артистларына күрсәткән ярдәме турында зур хөрмәт белән искә ала. «Гыйләҗ Казанский кебек зур тәҗрибәле артистлар янында мин бөтенләй югалып калдым,— дип яза ул.— Бу хәлдән мине Әмин Зәбиров белән Гыйләҗ Казанский коткарды. Бик зур такт белән һәм түземлелек белән алар миңа образның эчтәлеген, һәр репликаның, һәр мизансценаның мәгънәсен аңлата башладылар». («Агыйдел» журналы. 1968 ел, № 6, 114—118 битләр.)

1928 елны Башкортстан дәүләт труппасы «татар сәхнәсендә хезмәт итә башлавына 15 ел тулып, сәхнәдә эшли башлаганнан алып фәкать театр эшендә генә булуын һәм революция көннәрендә кызыл фронтта артист һәм режиссер булып зур хезмәтләр күрсәткәнен игътибарга алып», Казанскийның сәхнә бәйрәмен (иҗат юбилеен) уздыру турында карар кабул итә. һәм бу юбилей чыннан да бик тантаналы үтә.

Аннары артист Урал шәһәрләрендә (Троицк, Свердловск) эшли, 1931 елны Казанга

күчеп килгәннән соң, ТДАТ артисты, соңрак Чистай театрында иҗерәнкә иҗат эшчәнлеген дәвам иттерә.

Чистай театры Минзәләгә күчерелгәч, Г. Казанский да гомеренең соңгы көннәренә кадәр (1938 ел, июль) Минзәлә театрында эшли.

Минзәлә театрына ул «Нур» труппасының үзенә генә хас бер уен стилен алып килә. Биредәге артистларга төрлечә ярдәм күрсәтә, актер уены, режиссерлык эше һ. б. өлкәләрдә үзенең бай тәҗрибәсе белән уртаклаша.

Татар сәхнәсе тарихында матур эз калдырган сәнгать остасы иҗат дөньясына аяк баскан талантлы яшьләрнең беренче ярдәмчесе һәм остазы була.

ХӘСӘН ГОБӘЙДУЛЛИН.

# АСИЯ ХӘЙРУЛЛИНАГА 60 ЯШЬ

Казан театр училищесында менә 20 елга якын инде сәхнә теле дәресләрен Татарстанның атказанган артисткасы, Тукай премиясе лауреаты Асия Хәсәновна Хәйруллина алып бара. Сәхнәләребездә дистәләрчә онытылмаслык якты образлар тудырган Асия Хәйруллина... Татар әдәби телен, сүзләрнең дөрес әйтелешен, яңгырашын, логик мәгънәсен шул кадәр тирән аңлау, тою һәм үз туган теленә шул кадәр зур мәхәббәт — кайдан килгән болар бу күренекле артисткага? Бәлки, Идел буенда үткән яланаяклы балачак елларыннандыр. Әнисенең җырлап көлтә бәйләүләре, авыл халкының эчкерсез гади сөйләме күңеленә сеңеп калгандыр. Моң булып, туган тел булып...



1921 нче ачлык елда дөньяга килгән бу кыз балага ил белән бергә аякка басарга, авырлыкларны күтәрергә, олы юлга чыгарга туры килә. Тугыз яшеннән әтисез кала ул, әнисе җиде баласы белән колхозга керә. Совет власте атасыз балаларны ачлыктан, хәерчелектән генә коткарып калмый, аларга ныклы белем дә бирә. Асия сугышка кадәр үк Куйбышев районының Спасс педагогия училищесын тәмамлый. Гаҗәеп зиһенле һәм тырыш кызны училищеның үзендә үк укытырга алып калалар. Инде институт, югары белем алу турында хыялланып яшәгәндә, Бөек Ватан сугышы башлана. Асия эшкә үзенең туган якларына — Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылына кайта. Аңа сугыш елларының бөтен авырлыгын тылдагыларның барчасы белән тигез күтәрергә туры килә. Нык ихтыяр көче, тормышка, кешеләргә, киләчәкнең матурлыгына ышаныч аңа һәрвакыт юлдаш була. Бәлки шул авыр елларда көндез мәктәптә балалар укыту, кичләрен мандолина уйнап, ялкынлы шигырьләр сөйләп, халыкны җыңгүгә рухландырып авылдан-авылга йөрүләре яшь кызда туган теленә шундый зур мәхәббәт хисе уяткандыр...

Инде сугыш тәмамланып килгәндә Асия Хәйруллина А. В. Луначарский исемендәге Мәскәү театр сәнгате институтына укырга керә. Шуннан соң ул сәхнәдә халыкның үз иткән, яраткан артистларының берсе булды. Бөтен дөньясын онытып, бирелеп уйный, сүзнең мәгънәсен, тәмен, ләззәтен белеп сөйли — аның уйнавын карау үзе бер бәйрәм тесен ала. Нигәдер, уйнаган геройлары да күп вакыт шат күңелле, энергияле, яхшы кешеләр була иде. Күпме якты образлар иҗат итте артистка ул елларда! Ул малайларны да, яшүсмер кызларны да, олы яшьтәге карчыкларны да уйный. Мәсәлән, Н. Исәнбәтнең «Зифа» комедиясе буенча куелган спектакльдә Идел, М. Фәйзинең «Галиябану»ында Галиябануның шаян энесе, Х. Вахитның «Рәхим итегез!» һәм «Беренче мәхәббәт» спектакльләрендә Гүзәл һәм Нурсәнә образларын да артистка

бик уңышлы иҗат итә. Ә менә республикабызның Тукай премиясенә К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» спектакльленнән Рокыя образын иҗат итүе өчен бирелә. (1958 ел).

«Театральная жизнь» журналы менә ни дип язды аның хакында: «Рокыя-Хәйруллина залга килеп керә дә сеңелесе Дилбәрнең көяз егет белән ләчтит сатып, төчеләнеп утыруын күрә. Ул сүзгә катнаша, мәсхәрәле көлеп, сеңелесен залдан елап чыгып китәргә мәҗбүр итә. Аннары, Батырхан белән икәүдән-икәү генә калгач, егетнең ниятен белергә тырышып, сораштыра башлый. Ә инде өйләнергә нияте барлыгын ишеткәч, утырган җиреннән сикереп тора да, зәһәрле көлеп:

— Миңа өйләнмисеңме? Минем байлыгым Дилбәрнекеннән бер дә ким түгел бит,— дип бәйләнә.

Рокыяның үтәдән-үтә күрүе Батырханны чигенергә мәҗбүр итә. Шушы кечкенә генә күренешне артистка Асия Хәйруллина дәртләнеп-ялкынланып башкара. Көяз егетнең әйтергә сүзе калмагач, йоны коелган күркәгә әйләнгәч, бөкре кыз ачыргаланып көләргә тотына. Ул атасы Нуретдиннән дә, яратмаган башка кешеләрдән дә әнә шулай рәхимсез рәвештә көлә белә».

Асия Хәйруллина Татар Дәүләт академия театрында эшләү дәверендә үк Казан театр училищесында сәхнә теленнән дәресләр бирә башлый. Туган телебезне, аның үткәнен яхшы белү, бөтен нечкәлекләрен тою аңа бу эшендә зур ярдәм итә. Чынлыкта бит татар телендә сәхнә теле дәресләрен уздыру өчен эшкәртелгән программа да, дәреслекләр дә булмый әле. Асия Хәсәновнага материалны тормыш үзе бирә, укучыларның сөйләм телендәге кимчелекләрен актерлык тәҗрибәсе белән тоеп ала һәм, индивидуаль дәресләр билгеләп, еллар буе һәр укучы белән аерым шөгыльләнә.

— Сәхнә теле укытучысы артист та, музыкант та, педагог та, филолог та булырга тиеш,— ди Асия Хәсәновна.— Бигрәк тә педагогика сәләте актерлык сәләте белән кушылырга тиеш. Һәм бу эшкә фанатикларча гашыйк булу... Шул чагында гына укучыларны кызыксындыра, үзеңә ияртә аласың. Үзең дә һәр дәрес, һәр көн, һәр чыгарылыш саен янасың, аларга да сәнгать дөньясында якты йолдыз булып кабынырга ярдәм итәсең. Туган телгә мәхәббәт, хөрмәт хисе уятасың.

...Хезмәтеңнең нәтиҗәсен күрү куанычлы. Бүген педагог Асия Хәйруллина шәкертләре Татарстанның барлык театрларында эшлиләр. Аларның инде дәрәҗәле исемнәре, сәхнәдә һәм тормышта тоткан урыннары бар. Педагог-наставник буларак та ул үзе белән кулга-кул тотынып эшләрлек кадрлар, сәхнә теле укытучылары әзерләде. Культура институтының сәхнә теле укытучылары Наил Сафиуллин, Фирдания Садриева, Казан телевидениесе дикторы, театр училищесының сәхнә теле укытучысы Эльмира Хамматова — аның мәктәбен узган белгечләр.

Асия Хәйруллина үзенең 60 еллык юбилеен шаулап торган сәнгать дөньясында, яраткан укучылары арасында, якын һәм кадерле кешеләре белән бергә каршылый. Нинди зур, нинди бай һәм нинди кызыклы тормыш юлы узылган! Ә иртәгесе көн ишеген инде яңа проблемалар, яңа мәсьәләләр шакый. Асия Хәсәновна соңгы вакытта «Текст өстендә эшләү» дигән китап яза. Ул 1978 елда чыккан «Тел күрке — сүз» китабының дәвамы булырга тиеш. Бу китабы белән дә Асия Хәсәновна укучыларын сөендерер дип уйлыйбыз.

**ФӘУЗИЯ БӘЙРӘМОВА.**

## ГАФУР КОЛӘХМЕТОВ ЮБИЛЕЕ

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Казан җәмәгатьчелеге вәкилләренең татар пролетар әдәбиятына нигез салучы революционер Гафур Коләхметовның тууына 100 ел тулуга багышланган тантаналы җыелышы булды. Җыелышны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Г. А. Ахунов ачты. Г. Коләхметовның революцион-иҗтимагый эшчәнлеге һәм иҗаты турында доклад белән КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыкты.

Җыелышта Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре В. С. Дергунов, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова, партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмалары, иҗат союзлары һәм производство коллективлары катнашты.

Соңыннан Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары Г. Коләхметовның «Ике фикер» пьесасы буенча куелган спектакль күрсәттеләр.

* * *

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы конференц-залында Г. Коләхметовның тууына 100 ел тулуга багышланган фәнни конференция уздырылды. Аны кереш сүз белән Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры урынбасары, философия фәннәре докторы Я. Абдуллин ачты. Конференциядә Г. Коләхметов иҗатының социаль-философик нигезләре, аның татар пролетар әдәбиятына нигез салучы буларак, пролетар интернационализм позицияләрендә язучылык һәм революцион эш алып баруы, әдипнең драматургиясе, марксистик-ленинчыл экономик идеяләрне пропагандалавы, революцион студентлар белән бәйләнеше һәм күпкырлы эшчәнлегенең башка тармаклары турында докладлар белән философия фәннәре докторы К. Фасеев, тарих фәннәре докторы Р. Нәфигов, педагогия фәннәре докторы Я. Ханбиков, филология фәннәре кандидатлары Б. Гыйззәт, А. Әхмәдуллин, Р. Нуруллина, И. Бәширова, экономика фәннәре кандидаты Ф. Газизуллин, күче фәнни хезмәткәр Р. Әмирханов, драматург Д. Вәлиев һ. б. иптәшләр чыгыш ясады.

Фәнни конференция эшендә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, ТАССР культура министры И. Н. Алеев катнашты.

* * *

Казан шәһәрендәге Тукай урамының 108 нче йортында 1914—1917 елларда күренекле татар язучысы, революционер Гафур Коләхметов яшәгән. Шушы тарихи бинага мемориаль такта куелды. Скульптор Н. Гаделов тарафыннан эшләнгән мемориаль тактаны куюга багышланган митингта философия фәннәре докторы Я. Абдуллин, филология фәннәре кандидаты Б. Гыйззәт, драматург Д. Вәлиев һ. б. иптәшләр чыгыш ясады.

Тантанада КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

* * *

«Искусство» нәшриятының Ленинград бүлегендә «Театр календаре — 1981» дип аталган басма дөнья күрде. Әлеге календарь бөтендөнья драма һәм балет театрлары, шулай ук цирк һәм эстрада тарихында булган әһәмиятле вакыйгаларны чагылдыра. Календарь битләрендә, нигездә, төрле юбилейлар билгеләп үтелә. Шулар арасында күренекле татар драматургы, революционер Гафур Коләхметовның тууына 100 ел тулу уңаеннан да мәкалә урнаштырылган. Бу язмада юбилярның «Ике фикер», «Яшь гомер» пьесаларына югары бәя бирелә.

## КПССның XXVI СЪЕЗДЫ МАТЕРИАЛЛАРЫ

Татарстан китап нәшрияты массовый тираж белән «КПССның XXVI съезды материаллары»н татар телендә бастырып чыгарды. Анда «Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең XXVI съездына КПСС Үзәк Комитетының отчеты һәм партиянең эчке һәм тышкы политика өлкәсендәге чираттагы бурычлары» турында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре иптәш Л. И. Брежнев доклады, аның съездны япкандагы речь, СССР Министрлар Советы Председателе иптәш Н. А. Тихоновның «1981—1985 елларга һәм 1990 елга кадәрге чорга СССРның экономик һәм социаль үсешенең төп юнәлешләре» турындагы доклады, «1981—1985 елларга һәм

1990 елга кадәрге чорга СССРның экономик һәм социаль үсешенең төп юнәлешләре» һәм съезд кабул иткән башка документлар тупланган.

## КИНЕМАТОГРАФИСТЛАР СЪЕЗДЫ

СССР Кинематографистлар союзы секретариаты Татарстан Кинематографистлар союзын оештыру турында карар кабул итте. Әлеге карар нигезендә, Казан кинохроника студиясендә республика кинематографистларының беренче съезды уздырылды. Съезд эшендә СССР Кинематографистлар союзы идарәсенең оештыру буенча секретаре, Грузия ССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Г. Б. Марьямов, СССР Кинематографистлар союзының документаль һәм телевидение фильмнары буенча комиссия бюросы члены, Ленин һәм Дәүләт премияләре лауреаты кинорежиссер Д. С. Фирсова, СССР Кинематографистлар союзының Идел буе бүлеге беренче секретаре В. А. Каштелян, Чувашстан, Мари, Мордва автономияле республикаларыннан, Куйбышев шәһәреннән килгән кунаклар, Татарстан кино һәм телевидение работниклары катнашты.

КПССның Татарстан өлкә комитеты Татарстан АССР Кинематографистлар союзының беренче съездына котлау хаты җибәрде. Анда мондый сүзләр бар: «КПСС өлкә комитеты, республика кинематографистлар оешмасы, язучылар, художниклар, архитекторлар, журналистлар союзлары, театр работниклары җәмгыяте белән тыгыз хезмәттәшлектә режиссерларның, операторларның, сценаристларның һәм тәрҗемәчеләрнең, кино белгечләренең — бу массовый төр сәнгатьнең иҗат процессында һәм аны пропагандалауда катнашучы барлык кешеләрнең тырышлыгын КПССның XXVI съездының тарихи карарларын, унберенче бишьеллыкның гаять зур планнарын тормышка ашыруда өлкә партия оешмасына һәрьяклап ярдәм күрсәтүгә, социалистик яшәү рәвешен камилләштерүгә, коммунизмның гуманлы идеалларын исбатлауга юнәлдерер, дигән ышаныч белдерә».

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Бөек татар шагыйре Габдулла Тукай туган көн уңае белән уздырыла торган шигырь бәйрәме быел да, узган еллардагы кебек үк, олы бәйрәм төсен алды. 27 апрель көнне әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре В. И. Ленин һәйкәленә, шулай ук Г. Тукай, А. Пушкин, М. Горький һәм М. Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар. Аннары М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы Г. Тукай һәйкәле алдында шигъри митинг уздырылды. Аны кереш сүз белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты шагыйрь Илдар Юзеев ачты.

1981 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреатлары язучы Атилла Расих, РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты Евгений Кузин һәм инженер-төзүче И. Паромонов иптәшләрнең чыгышларын да тамашачылар яратып тыңлады. Алар, барлык лауреатлар исеменнән, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре турында зур кайгыртучанлык күрсәтүләре өчен партиябезгә һәм хөкүмәтебезгә тирән рәхмәт хисләрен белдерделәр.

Аннары шагыйрьләр Сибгат Хәким, Мөхәммәт Садри, Михаил Скороходов, Мәхмүт Хөсәен, Рөстәм Кутуй, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Зөлфәт, Фәннур Сафин, Шамил Маннапов, Флера Гыйззәтуллина, Роза Хәлиуллина, Лена Шакирҗанова, Рашат Низамиев чыгыш ясады.

* * *

Тукайга багышланган шигырь бәйрәме Чаллы якларын да читләтеп узмады. Шигырь бәйрәмен уздырырга бирегә Казаннан бер төркем шагыйрьләр — РСФСРның Горький исемендәге, ТАССРның Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәким, Рөстәм Мингалимов, Роберт Миңнуллин, Марсель Галиев килде. Алар Чаллыдагы Муса Җәлил исемендәге Үзәк китапханәдә, Двигательләр заводында укучылар белән очраштылар, шигърият турында сөйләштеләр. Иң зур тантана «Энергетиклар» Культура сараенда үткәрелде. «Тукайга — чәчәкләр» дип аталган әдәбимузыкаль кичәдә РСФСРның атказанган укытучысы Г. Шамматова Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты турында сөйләде. Аннары залда шигырьләр, җырлар яңгырады. Тукай районында менә берничә ел инде иң югары күрсәткечләргә ирешкән хуҗалыклар Габдулла Тукай исемендәге приз белән бүләкләнә. Бу бүләкне икенче ел рәттән «Гигант» совхозы яулап алды. Әлеге кичәдә совхоз директоры, Социалистик Хезмәт Герое Н. Зыятдинов хуҗалык ирешкән уңышлар турында сөйләде. Кичәдә шулай ук Чаллы Язучылар оешмасының җаваплы секретаре, шагыйрь һәм прозаик Разил Вәлиев, «Ләйсән» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Газиз Кашапов, шагыйрьләр Нәҗип Мадьяров, Мәхмүт Газизов та чыгыш ясады.

Сибгат Хәким, Рөстәм Мингалимов, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин һәм Марсель Галиев Түбән Кама шәһәрендә уздырылган шигырь бәйрәмендә дә катнаштылар. Иң элек шәһәрнең Тукай һәйкәле каршында тантаналы шигъри митинг булды. Анда шагыйрьләр, район мәктәпләреннән килгән укучы балалар үзләре иҗат иткән шигырьләрен укыдылар. Аннары 5 нче татар урта мәктәбендә, 44 нче профессиональ-техник училищеда укучылар белән очрашулар уздырылды. Кич белән шәһәр хезмәтчәннәре Техника йортына әдәби-музыкаль кичәгә җыелды. Кичәдә язучы Рахмай Хисмәтуллин, яшь шагыйрьләр Мөхәммәт Шәйхи, Михаил Федосенко, Лев Воздвиженский, «Кама таңнары», «Данко» әдәби берләшмәләренең члennары, үзешчән

сәнгатьтә катнашучылар да чыгыш ясады.

Шагыйрь С. Хәким «КамАЗ төзелеше ударнигы» значогы һәм партиянең Түбән Кама шәһәр комитеты һәм башкарма комитетының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

## БӨТЕНСОЮЗ ИҖАТ КОНКУРСЫНДА ҖИҢҮЧЕ

СССР Журналистлар союзы идарәсе секретариаты 1980 елда журналистларның иң яхшы эшләре өчен СССР Журналистлар союзы премияләрен бирде.

Бүләкләнүчеләр арасында «Советская Татария» газетасы фотокорреспонденты **Ә. Ш. Шакиржанов** та бар. Ул бу бүләккә КПССның XXVI съездына әзерлектә республика хезмәт иярләренең уңышларын чагылдырган фоторепортажлары өчен лаек булды.

## ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ РЕСПУБЛИКА ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

Татарстан Журналистлар союзы идарәсе, журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, 1981 елгы премияләрне түбәндәге иптәшләргә бирергә карар чыгарды:

**Низамов** Илдар Маликовичка — Татарстан китап нәшриятының политик һәм тарихи әдәбият редакциясе мөдире. 1980 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Ул кабызган маяклар» дигән китабы һәм журналистика өлкәсендә нәтиҗәле эшләве өчен.

**Шакиржанов** Әсрар Шакиржановичка — «Советская Татария» газетасы фотокорреспонденты. В. И. Ленинның туууына 110 ел тулуга һәм КамАЗның икенче чиратын эшләтә башлауга багышлап, 1980 елда республика матбугатында һәм үзәк матбугатта басылган фоторепортажлары өчен.

## ҮЗӘК НӘШРИЯТТА

Мәскәүнең «Художественная литература» нәшриятында «В. И. Ленин СССР халыклары поэзиясендә» дигән җыентык басылып чыкты. Анда рус һәм СССРда яшәүче башка халыклар шагыйрьләренең даһи юлбашчы турындагы шигъри әсәрләре тупланган.

Китапта шулай ук Муса Җәлилнең «Ленинчылар», Һади Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасыннан өзек, Сибгат Хәкимнең «Кокушкино авылы крестьяннарының Ленинга хаты» да бар. Аларны рус шагыйрьләре В. Торопыгин, Л. Мартынов һәм Я. Смеляков тәрҗемә иткән.

## ТЕАТР ЭШЛЕКЛЕЛӘРЕ КИҢӘШӘ

Казанның Актерлар йортында Идел буе режиссерлары берләшмәсенең конференциясе булды. Ул партиянең XXVI съездына багышлап, куелган спектакльләр турында фикер алышуга багышланды.

Анда Мәскәүдән, Горький, Иваново, Чабаксар, Владимир, Кинешма, Йошкар-Ола һ. б. шәһәрләрдән режиссерлар, күренекле артистлар, театр белгечләре килгән иде.

Конференцияне Идел буе режиссерлары берләшмәсенең җитәкчесе, РСФСРның халык артисты М. Х. Сәлимҗанов ачты.

ТАССР культура министры И. Н. Алеевның кереш сүзеннән соң, сәнгать фәннәре кандидатлары Е. Я. Дубнова (Мәскәү), И. И. Илялова (Казан), театр белгечләре П. Б. Богданова, И. А. Лосева (Мәскәү), Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, Бөгелмә драма театрының баш режиссеры А. В. Сидорин иптәшләр чыгыш ясады.

Конференциядә КПССның Татарстан өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ЯШЬ ТАЛАНТЛАРГА ИГЪТИБАР

Татарстан Язучылар союзының яшь авторлар белән эшләү бүлегендә һәрвакыт иҗади сөйләшүләр булып тора. Бүлекнең яшьләр белән эшләү комиссиясе белән берлектә уздырылган чираттагы утырышы яшь шагыйрьләр Ркаил Зәйдуллин һәм Ләис Зөлкарнәев иҗатларына багышланды.

Р. Зәйдуллин иҗаты турында шагыйрь Роберт Миңнуллин, Л. Зөлкарнәев шигырьләре турында тәнкыйтьче Мансур Вәлиев сөйләде. Фикер алышуларда язучы Гариф Ахунов, тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев, шагыйрьләр Илдар Юзеев, Радиф Гатауллин, М. Әгъләмов, Разил Вәлиев, Әхмәт Рәшитов, Рашат Низамиев иптәшләр катнашты.

## ОЧРАШУЛАР

Казан шәһәренең 34 нче мәктәбендә В. И. Ленин туган көнгә багышланган әдәби кичә уздырылды. Анда шагыйрьләр Сибгат Хәким, Роберт Миңнуллин, тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев катнашты. Алар әдәбият турында сөйләделәр, шигырьләр укыдылар.

* * *

Шагыйрь Роберт Миңнуллин Буа район хуҗалыкларында әдәби концертлар белән чыгыш ясады. «Без — ленинчылар» дип аталган публицистик һәм лирик шигырьләр кичәсе районның Янтуган, Вольностан, Исәк, Түбән Наратбаш, Кул Черкен, Черки Килдураз, Адав-Толымбай һәм Иске Тиңчәле авылларында, Буа шәһәренең «Райсельхозтехника» берләшмәсендә, медицина училищесында, ветеринария техникумында, шикәр заводында булды. Шагыйрь үзәк китапханәдә район китапханә мөдирләренең район семинарында да катнашты. Ул китапханәчеләрне әдәбиятыбызның бүгенге торышы белән таныштырды, «Казан утлары» журналы турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде.

## СПЕКТАКЛЬНЕҢ ОЛЫ УҢЫШЫ

Драматург Туфан Миңнуллинның «Моңлы бер җыр» спектакле Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында зур

уңыш белән бара. Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган бу спектакль партиябезнең XXVI съездына багышланган спектакльләрнең Бөтенсоюз смотрында җиңеп чыкты. Татар дәүләт академия театры шушы спектакль белән, ССР Союзының Кече театры, Вахтангов исемендәге, Маяковский исемендәге академия театрлары, Ленинградтан, Ярославльдән, союздаш республикалардан килгән театрлар белән беррәттән, Бөтенсоюз смотрының йомгаклау өлешендә катнашты. 1200 дән артык тамашачыны сыйдырган Моссовет исемендәге театрда уйналган спектакльне Мәскәү тамашачылары өч көн рәттән яратып карады.

## ӘЛМӘТ ТЕАТРЫНЫҢ ИҖАТ КИЧӘСЕ

Бөтенроссия театр җәмгыятенең Үзәк актерлар йортында Әлмәт Татар дәүләт драма театрының КПССның XXVI съездына багышланган иҗат кичәсе булды. Сәнгать фәннәре кандидаты И. Илялова тамашачыларны театрның тарихы, коллективның иҗат юнәлеше белән таныштырды. Иҗат кичәсендә унга якын спектакльдән өзекләр күрсәтелде. Соңыннан театр коллективын Мәскәү артистлары котлады.

## УҢЫШ БЕЛӘН УЗДЫ

Татар дәүләт драма һәм комедия театры Ленинград шәһәрендә гастрольдә булып кайтты. Театр коллективы анда өч спектакль — Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ын, Илдар Юзеевның «Кыр казлары артыннан» әсәрен һәм М. Гафури әсәре буенча эшләнгән «Кара йөзләр»не күрсәтте. Гастрольләр уңыш белән узды.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен язучы, Татарстан китап нәшрияты редакторы Адлер Камил улы **Тимергалинга,** язучы Василий Николаевич **Юдинга** «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.


*
* *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен композитор Исмай Гайнетдин улы **Шәмсетдиновка** «Татарстан АССРның халык артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

## ХЕЗМӘТЕН ХӨРМӘТЛӘП

Татар совет әдәбияты өлкәсендә нәтиҗәле эшләве өчен һәм 80 яше тулу уңаеннан язучы Афзал Шиһабетдин улы **Шамов** КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

# Хәсән Туфан



Шушы елның 10 июнендә татар совет поэзиясенә нигез салучыларның берсе, бөтен иҗатын һәм илһам көчен илгә багышлаган шагыйрь Хәсән Туфан дөньядан китте. Совет әдәбияты өчен зур югалту бу.

Хәсән Туфан 1900 елның 9 декабрендә Татарстанның Аксубай районы Иске Кармәт авылында крестьян семьясында туган. Яшүсмерлек чорына аяк басу белән үк, ул Урал якларына чыгып китә — заводларда, шахталарда эшли.

1924 елда беренче әсәрләре матбугатта күренә башлый. Ул «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Соңгы сарай янында» кебек беренче лирик-эпик поэмаларында ук илдә барган эпохаль үзгәрешләргә, зур корылышларга һәм шул вакыйгалар эчендә кайнып-кайнып яңалыкка юл ноткан замандашларына мөрәҗәгать итә.

Шагыйрь безнең поэзиядә социалистик реализм принципларын хуплаучы, аларны өзлексез яклаучы һәм шуларга таянып иҗат итүче буларак та кадерле. Бу юлда ул Һ. Такташ, М. Җәлил, Г. Кутуй, Ф. Кәрим кебек әдипләребез белән рәттән тора. Социалистик реализмга тугрылык Х. Туфан тудырган образларның тормышчанлыгына, халыкчанлыгына, партиялелегенә китерә дә инде.

Утызынчы елларда Хәсән Туфан радио хәбәрчесе, «Совет әдәбияты» журналының җаваплы секретаре булып эшли. Бу чорда язылган лирик шигырьләре, җырлары — шагыйрьнең кеше күңелен нечкә тоя белүенә, чордашларына гаҗәеп бер шәфкать һәм ихлас белән каравына, илгә чиксез бирелгәнлегенә дәлил.

Шагыйрь соңгы чордагы иҗатын фәлсәфи яктан тирән, патриотик яңгырашлы әсәрләргә баета барды. Аның бу елларда язылган шигырьләре хаклы рәвештә күп милләтле совет поэзиясенең күркәм сәхифәләрен тәшкил итә. 1964 елда Хәсән Туфан Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булды.

Әдипнең тормышын аның хезмәт сөюе, җәмәгать эшләрендә кайнап яшәве бизи. Ул озак еллар буе Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены булып торды, «Казан утлары» журналының төпле киңәшчесе, авторларының остазы иде.

Аның шигырьләре генә түгел, тормыш тәҗрибәсе дә, яшәү принциплары да, кешеләргә гадел мөнәсәбәте дә — безгә якты үрнәк.

Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләте, шагыйрь Хәсән Туфанның хезмәтләренә зур бәя биреп, аны ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр белән бүләкләде.

Әле 1964 елда ук шагыйрь:

**...Син дә бит бер туктарсыңдыр, йөрәк,**
**Ә шулай да нигә син тынгыч!..**
**Миңа шундый — яшәп туялмаслык**
**Гаҗәп нәрсә шул син, и Тормыш!**

— дип язган иде. Әмма Хәсән Туфан бервакытта да салкын үлемнән куркып яшәмәде. Аның:

**...Үлгәнен дә белми кала кеше,**
**Яши бирә калган эшендә,**
**Яши бирә!**

— дигән юллары нәкъ менә шагыйрьнең үз гомеренә, үз мәңгелегенә багышлана сыман.

Әйе, Хәсән Туфан яши бирә! Аның якты образы, йөзләрчә шигырьләре, җырлары, үзәк өзгеч моңы — безнең күңелләрдә яши.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Озак та үтмәс, сезнең кулга журналның 8 нче саны да килеп керер. Алдан ук әйтеп куярга мөмкин — анда укучыны кызыксындырырлык язмалар шактый мул бирелгән.

Беренче битләрдән Ә. Маликовның «Күтәрелеп буразнадан» исемле шигырен укырга була. Әсәр илгә ике миллиард тонна кара алтын бирүче нефтьчеләребезгә багышлана.

Проза әсәрләреннән А. Гыйләҗевнең «Әтәч менгән читәнгә...» исемле яңа повесте игътибарга лаек. Повесть сатирик планда җор тел белән язылган. Автор көнкүрешебездә, үзара мөгамәләләрдә әле һаман сакланып торучы ямьсез күренешләрдән көлә, бу җитешсезлекләрнең кешегомерен кыскартуын, тормыш ямен җибәрүен ачып бирә.

Ф. Яруллин, Р. Фәйзуллин шигырьләрен дә, Р. Кутуйның «Сөенче» исемле хикәясен дә укучы яратып укыр дип ышанабыз.

«КПССның XXVI съезды карарларын — тормышка!» рубрикасы журналда даими бирелеп килә. Бу санда укучы съезд карарларын тормышка ашыруда Татарстан галимнәренең, аерым алганда, Казан дәүләт университеты хезмәткәрләренең өлеше белән танышачак. Мәкаләне Ш. Хәбибуллин һәм Ф. Әгъзәмов язган.

Әдәби тәнкыйть бүлегендә Р. Мөхәммәдиевнең «Шигъри хәрәкәт һәм аның кайбер тенденцияләре» исемле, Г. Хантимерованың «Төсләр балкышы» дигән мәкаләләре урнаштырылган.

«Китап күзәтү», «Культурабыз тарихына материаллар», «Төрлесеннән», «Безнең календарь», «Елмаеп та, көлеп тә...» шикелле даими рубрикаларга укучыларның мәгълүматын баетырдай тирән эчтәлекле күп язмалар тупланган.

Журналның соңгы битләрендә, гадәттәгечә, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары язылачак.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210